# Казан утлары

8

АВГУСТ-1976

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

8

АВГУСТ
1976

## БУ САНДА

М. ЗАРИПОВ. Үзеңнеке — үзәктә... Повесть . . . 3
З. НУРИ. Яңа җыр алып кил... Шигырьләр . . . 77
Р. ТӨХФӘТУЛЛИН. Кар күзе. Хикәя . . . . . . 84
З. МАНСУРОВ. Иделгә хат. Шигырьләр . . . 91
Ү. САТТАРОВ. Кызым хикәяләре . . . . . . 94

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Таулы Алтай поэзиясе битләреннән . . . . . 100

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 106
Д. ГАРИФУЛЛИН. Игенче улы . . . . . . . 109
С. ЗАКИРОВ. Туган яктан көч алып . . . . . 115

СӘНГАТЬ

Т. ӘЙДИ. Игезәк Абдуллиннар . . . . . . . 122

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Театрыбызның беренче тәнкыйтьчесе . . . . . . . . . . . . . . 129

КАЗАННЫҢ 800 ЕЛЛЫГЫНА

В. ИВАНОВ. Гасырлар аша карап . . . . . . 134
А. ХАЛИКОВ. Казан кайчан һәм кайдан башланып киткән . . . . . . . . . . . . . . 137

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Р. НӘФИКОВ. Фатих Әмирхан — публицист һәм җәмәгать эшлеклесе . . . . . . . . . . 144

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Ф. ХАТИПОВ. Эшче рухы . . . . . . . . . 154

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. ГАНИЕВА. Тирәннән алып . . . . . . . . . 163
Ф. САФИУЛЛИНА. Фатих Әмирхан прозасы рус телендә . . . . . . . . . . . . . . . . . 169

ТӨРЛЕСЕННӘН

Кариле нугайларының фольклор үрнәкләре . . 175
Г. РӘХИМ. Теләкнамәләр . . . . . . . . . . 178

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Ш. ГАЛИЕВ. Хәлим, Сәлим, Мәсәлим. Шигырьләр 181
Җ. ДӘРЗАМАНОВ. Тылсымлы чүкеч. Шигырьләр 184

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Мәсәлчеләр мәҗлесе . . . . . . . . . . . . 185
А. ВЕРГАЗОВ. Син дә рәис, мин дә рәис. Хикәя 188

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 29/IV-1976 ел. Басарга кул куелды 7/VII-1976 ел. ПФ 07109. Кәгазь форматы 70×108$^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 90744 экз. Заказ К-178. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

## Марсель Зарипов

# ҮЗЕҢНЕКЕ— ҮЗӘКТӘ...

ПОВЕСТЬ

### 1



Чит илгә китәр алдыннан профессор Курмашевны гыйльми бүлеккә чакырып, бер диссертациягә карата фикер әйтүен, яклаганда оппонент булуын үтенделәр.

Билгеле инде, андый чакта эшләп бетерәсе ашыгыч эшләр килеп чыга, вакыт дигәнең бик тыгыз була. Бу яңа эш, чүп өстенә чүмәлә сыман, Курмашевка зур мәшәкать булып тоелды, хәтта ачуы да килде. Алдан ук сөйләшеп-киңәшеп эшләсәләр бер хәл иде. Курмашевның ризалыгын да сорап тормаганнар — гыйльми бүлектә оппонент итеп раслап та куйганнар. Диссертант үзенең фәнни хезмәтенә җитәкче була алырдай, яклаган чакта төпле фикер әйтердәй кешеләрне гадәттә үзе таба торган иде. Курмашевның исә бу диссертантны әле күргәне дә, белгәне дә юк. Син менә шуңа оппонент бул, имеш!.. Ничек була инде бу? Аның бәлки моннан башка да мәшәкате җитәрлектер?! Бәлки ул андый эшкә алынырга теләмидер?!

Курмашев, эшем күп дип, баш тартмакчы булды. Китәр вакытым җитеп килә, болай да бик мәшәкатьле чагым, кеше эшен карау түгел, үземнекенә дә җитешә алмыйм, дип әйтеп карады.

Институтның гыйльми секретаре Нурми Гарифович Гаязов, чал профессорлар белән дә каты сөйләшә торган җитди бер кеше, Курмашевның дәлилләрен ишетергә дә теләмәде. «Эшлисе килмәгәнгә генә алдашып маташмыймы бу?»— дигәндәй, үткен карашлы кырыс күзләрен кыса төшеп, Курмашевтан:

— Сезнең инде төенчегегез дә төйнәп куелганмыни? Иртәгә юлга чыгасызмы?— дип сорады.

— Алай ук түгел түгелен дә... Бер-ике айдан... Сүзлекләр белән утырам, чит тел өйрәнәм,— диде Курмашев.

— Студент чагыгызны оныттыгызмыни? Бер төн эчендә япон теленнән имтиханга хәзерләнеп өлгерми идегезмени?

— Анысына өлгерә идек. Ләкин монысы бит имтихан өчен түгел, эш өчен.

— Барыбер. Бу вакыт эчендә өр-яңадан рентген нурларын ачарга, Ньютон законнарын уйлап чыгарырга була. Ә сез кеше эшләгән эшне карап чыгарга да теләмисез. Килешеп бетәрме соң болай?

— Безнең профильнеке түгел бит ул,— диде Курмашев, һаман да баш тартырга исәпләп.— Диссертацияне табигатьне саклаучылар хәзерләгән. Теге кемнәр... биологлар...

— Биологлар булса соң?!— диде гыйльми секретарь, җилкәсен сикертеп, кулларын җәеп җибәрде.— Сез, Госман Закирович, гафу итегез, безнең институтның тормышын, эшен күз алдыгызга бигүк дөрес китереп бетермисез.

— Шомартмагыз инде, артта калгансыз дип әйтегез!— диде Курмашев һәм шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ярый, шулай да булсын, тик көлмәгез. Табигатьне саклау институты урман, һава, суларны саклау эше белән генә шөгыльләнә дип уйлыйсызмы әллә? Мәсьәләнең икенче ягы да: табигать хәзинәсеннән — җирнең өстендәгесеннән генә түгел, эчендәгесеннән дә — чама белеп файдалану да шулай ук бик мөһим. Мәсәлән, урман караучылар миллион агач үстерә, ә бездә шуның тик яртысы гына эшкә тотылып, яртысы чүпкә китә. Шул акыллы, файдалы эшме?

— Мин бит урман мәсьәләсе белән шөгыльләнмим,— диде Курмашев, гыйльми секретарьның үзсүзлелегенә ачуы килә башлап.

— Анысының әллә ни әһәмияте юк, — диде Гаязов. Сөйләшенгәнкилешенгән кебек итеп, Курмашевка диссертацияне сузды. — Хәзерге көндә фәннәр үзара шул хәтле керешкәннәр — кемнең физик, кемнең химик икәнен дә аеруы кыен. Диссертацияне биологлар хәзерләсә дә, ул бит нефть байлыгыннан файдалану мәсьәләләренә багышланган. Бездә, җир асты гидравликасы белгече буларак, су белән нефтьнең тирәндә үзара ничек керешү, ничек сыешуларын иң яхшы белүче галим сез түгелмени?!. Бу диссертацияне бик кызыклы, перспективалы, безнең өчен бик кирәкле хезмәт диләр. Алыгыз. Күләме дә әллә ни зур түгел— нибары йөз бит чамасы! Үзегез беләсез: хәзер диссертацияне болай юка язмыйлар, килограммлап үлчәрлек итеп калынрак язарга тырышалар. Үзегезгә дә бераз файдасы тияр. Яңачарак хезмәт укып башны сафландырып алу зарар итмәс. Хәер, диссертант биолог та, нефтьче дә түгел, ә... кем дип уйлыйсыз?

— Кем соң?

— Химик.

Шуннан соң инде Курмашев ни дисен? Ул пошынып авыр сулап куйды, уйланган итенде, аннары, әйдә инде, миннән булсын яхшылык, дигән бер төс белән:

— Ярый, алайса, карап чыгыйм,— дип, папканы алды.

Папкадагы кәгазьләрне укырга керешкәч, Курмашев үзе дә сизмәстән кызыксынып, хәтта мавыгып китте. Диссертант төпле итеп фикер йөртә белә, олы агайларның дәрәҗәләренә исе китеп тормаган — аларның да ялгышларын тапкан, заманында профессор Курмашев тәкъдим иткән һәм хәзер дә кулланыла торган нефть ятмаларын эксплуатацияләү принцибының, яхшы яклары белән бергә, җитди кимчелекләре дә барлыгын бик дәлилләп исбат иткән иде.

Хәер, Курмашев өчен бу яңалык түгел, ул үз системасының җитешле һәм җитешсез якларын башкаларга караганда яхшырак белә иде. Соңгы елларда кайбер мәсьәләләр турында ул байтак баш ватты: әйтик, бер урында алмаз борау җирне тишү белән үк аннан нефть фонтан булып, шундый каты бәреп чыга — корыч торбаларны вата, ташкын булып җир өстенә җәелә. Ә икенче урында насос белән суыртып та бер тамчы нефть алып булмый.

Ул бик күп тапкыр промыселларга барды, шунда эшләүчеләрне күреп сөйләште, башында кайбер кызыклы гына фикерләр туды, тик, кызганычка каршы, аларны билгеле бер системага салырга вакыт таба алмады.

Хәер, вакыт җитмәгәннән генә микән? Тәвәккәллек, тырышлык җитмәүдән дә түгел микән?! Уйлаган эшен ни сәбәптән гамәлгә ашырып җиткерә алмавын әйтүе дә кыен!

Курмашевка укып фикер әйтергә дип бирелгән бу диссертация аның нефть ятмаларын эксплуатацияләү принципларына каршы килми иде. Дөресрәге, диссертант аның принципларын тагы да тулыландыра, үстерә төшкән иде. Курмашев хезмәтне укыган чакта алдагы биттә нәрсә буласын сизеп, диссертантның төпле, дәлилле фикерләренә ияреп кенә барды. Чыннан да, автор җир астында була торган, моңарчы әле беркем нинди математик, химик һәм физик формулалар да аңлатып бирә алмаган хәлләрне ачып салган иде. Ә менә Курмашев үзе, күпме тырышса да, шуларның серенә төшенә алмады, төрлечә фараз кылып караса да, бердәнбер чынын ача торган тылсымлы ачкычны таба алмады. Аның акылы төшенеп җитә алмаган шул катлаулы мәсьәләне икенче берәү, менә, тоткан да чишкән.

Инде байтак еллар узса да, Курмашев студент чагында фәннең өр-яңа өлкәсе — җир асты гидравликасы белән ничек мавыгып китүен әле һаман да онытмый.

Институтны тәмамлагач, ул биш ел бер группада укыган, бер бүлмәдә яшәгән дусты Яхин белән аспирантурага керде. Яхин автоматика өлкәсен сайлады, Курмашевны җир астындагы су һәм нефть халәте мәсьәләләре кызыксындырды. Күп эшләде ул, көчен кызганмады, моннан миллион еллар элек табигатьтә булган хәлләрне аңларга, әллә кайда тирәндә, җир астынданиләр барлыгын, анда капма-каршы ике нәрсә — су һәм нефтьнең нинди хәлдә булуларын, ни эшләүләрен күңел күзе белән күрергә тырышты. Су гидростанция турбиналарын әйләндерә, саллар агыза, кораблар йөртә, шәһәр-авылларга тереклек биреп тора, басу-кырларны сугара. Судан тагын бер эш эшләтеп — нефтьне дә җир астыннан чыгартып булмый микән?

Курмашев әнә шулай киң колач белән фикер йөртә, күңеле белән тар институт лабораториясен генә түгел, бәлки җир асты дөньяларын да күрә, үзен шунда кодрәтле һәм бик белдекле бер хуҗа итеп сизә иде. Аның эше бик акрын бара иде. Кайвакыт һич көтелмәгән бер нәтиҗә килеп чыга да, аңарчы эшләнгән бөтен эшен сызып ташлый иде. Андый чакларда ул, бу гидравлика дигәннән бөтенләй ваз кичеп, җиңелрәк эшкә алынырдай була, тик шулай да, кечкенә генә бер уңышка ирешкәч, тагын өмете уяна һәм яңадан эшкә керешә иде.

Тәҗрибә өстенә тәҗрибә өстәлә торгач, Курмашев шундый фикергә килде: бер караганда һич төшенеп булмастай кебек тоелган җир асты хәлләрен төгәл фәнни теория белән аңлатырга, төрле билгеләр, формулалар белән әйтеп бирергә мөмкин икән. Димәк, теоретик законнардан практик файда да китереп чыгарырга була. Иң беренче эш шул: җир астына зур басым белән су җибәреп, аннан нефтьне кудырып чыгарырга кирәк. Хәзергә — нефть. Аннары күмер, алтыннарга чират җитәр.

Курмашев шушы хыялы белән канатланганнан-канатлана барды, артык илһамланып киткән чакларында ул үзенә-үзе ниндидер бер кодрәтле тылсым иясе булып, теләгәненә ансат кына ирешә алыр кебек тоела иде. Моңарчы бер кемгә дә билгеле булмаган бер аспирант — Курмашев — әкияттәге тылсымлы лампа шикелле бер нәрсәне табып, аны кешеләр кулына тоттырыр да тегеләр үзләренә кирәк кадәр хәзинәне җир астыннан чыгара башларлар сыман иде.

Ә менә хәзер ул атаклы, зур кеше булгач, җир асты гидравликасының нигезен салучы мәшһүр бер галим булып танылып җиткәч, көннәрдән бер көнне бер акыллы баш килеп чыга да, аңарчы башкалар эшләгән эш начар, бернигә ярамый, төзәтергә-дөресләргә кирәк дип, үзенекен исбатларга маташа.

Курмашев инде күп еллар буена институтта үз фикерен беренче урынга куюларына гадәтләнеп беткән иде. Мәскәүдә дә, Бакуда да аның фикере белән исәпләшәләр, промыселларда бер генә яңалык та аның ризалыгыннан башка хәл ителми, ул кечкенә генә шиген әйтсә дә, хәтта икеләнгән сыман җилкәсен генә җыерса да, башкалар шундук аның белән килешәләр иде. Ә менә хәзер берәү килеп чыккан бит! Ничәмә-ничә еллар буена күпме хезмәт, тырышлык куеп тапкан идеясен ул үзе күмәргә, икенче берәүнең аны узып китүенә риза булырга тиешме? Мондый хәлләрнең элек-элек тә булганлыгын, хәзер дә булып торуын һәм киләчәктә дә булачагын ул белә. Әмма турыдан-туры үзенә кагылмаган хәлләрне белү бер нәрсә, үзеңә кагыла торганы исә бөтенләй икенче нәрсә икән. Нигә әле андый хәл ул исән чакта, аның күз алдында булырга тиеш? Нигә ул үзенә-үзе хөкем карары чыгарып, аны җиренә җиткерергә тиеш? Кеше көлкесе, ахмаклык кына булыр ул!

Курмашев диссертацияне укыган саен үртәлә, ачуы кабара барды. Оппонент итеп аны көчләп дигәндәй билгеләделәр, гыйльми дәрәҗә алырга теләүче кешенең аңа әле бөтенләй күренгәне юк. Я әдәп-инсаф белми торган бер томана, я бик әрсез бер бәндәдер. Курмашев менә шул кеше өчен мәшәкатьләнергә, вакыт әрәм итәргә тиеш. Намус, галимлек этикасы, һич югы, гади бер әдәплелек күрсәтү дигән нәрсә бу хезмәтнең уңай якларын да танырга куша. Курмашев исә эчендә кузгалган ниндидер бер ризасызлыкны җиңә алмый, акылы кушмаса да, диссертациянең кимчелекләрен, җитешмәгән якларын эзли. Менә аның кереш өлеше шактый йомшак язылган. Мәсьәләнең тарихы бәян ителмәгән. Тәҗрибәләр җитәрлек ясалмаган. Диссертациянең эчтәлеге диссертантның төп фикерләрен раслап бетерми, автор ашыга, әйтергә теләгәнен дәлилләп җиткерми, булачак нәрсәләрне инде булган шикелле итеп китереп куя. Барыннан да бигрәк — практикларның, бу ачышны практик эштә куллана башларга ярый, дигән ризалыклары юк. Монысы диссертантның эш тәртибен белеп бетермәвеме, әллә нефтьчеләрнең, бу хезмәттән файда алырларына ышанмыйча, үзләренчә саклык күрсәтүләреме?

Курмашев диссертациядә бирелгән катлаулы формулаларны укыган чакта авторның нинди кеше булуын күз алдына китерергә тырышты: чыннан да, бу гади әдәп кагыйдәләре белән исәпләшә белми торган сәләтле бер яшь галимме, әллә күз алдында ярылып яткан кимчелекләрен дә күрә белми торган әрсез томанамы? Әгәр Курмашев аның авторын берәр тапкыр күреп сөйләшкән булса, нинди кеше белән эш итүен, үзен ничек тотарга тиешлеген белер иде. Ләкин диссертант килеп аны күрергә теләми иде, ә Курмашев аны үзе эзләп йөрмәс бит инде!

Курмашев диссертантның өлешчә хаклы булып та, төп мәсьәләдә ялгышуын уйлап, аны күреп сөйләшергә, ярдәм итәргә, киңәшләрен әйтергә карар кылды. Тормышта бер утыруда ук бөтен ягы да килгән камил эшне башкарып булмый бит ул. Диссертант ашыга, ялгыша. Хаталарны төзәтсәң, хезмәт бөтенләй яхшырып китәр. Кешегә ярдәм итү, яхшылык итү — тормышта гадәти хәл.

Шулай уйлап, Курмашев бөтенләй тынычланды, диссертациянең соңгы битен япты да тышына күз салды. Карале, игътибар итеп җиткермәгән: бу хезмәтнең авторы... хатын-кыз икән ләбаса. Дания Дәүләтшина диелгән... Болай булгач, бөтенләй чамадан арта бит бу! Курмашевның хаталарын ниндидер бер хатын-кыз төзәтсен, имеш. Кара син аны! Җир астында, тирәндә, нинди нәрсәләр булуын, ни сәбәптән

скважиналар тынып калуын, промысел хәтле промыселларның эштән туктавын, шулар тирәсендә үсеп чыккан шәһәр, авылларда тормыш сүрелүен гомер буе нефтьтә эшләгән чал чәчле геологлар да әйтеп бирә алмый. Ә бу хатын бераз уйланган да сәбәпләрен ачып та салган, янәсе. Каян килгән бу акыллы баш?!.

2

— Шул гына җитмәгән иде!— диде Курмашев, яңадан ачуы кузгала башлап.— Хатын-кыз әнә торт пешерсен, хушбуйлар ясасын, анда да галимнәр кирәк, ә бу — җир асты гидравликасына кереп киткән бит. И алла, фән дигәнеңә кемнәр генә тыкшынмый! Теләсә кайсы, берни белән исәпләшмичә, башкаларны этә-төртә, урын алырга тырыша. Әле кичә генә студент булып, лекцияләргә йөгереп йөргәннәр, семинарларда рәтләп җавап та бирә алмаганнардыр. Әнә шулай көч-хәл белән укып бетереп, каяндыр бер фикер эләктереп алалар да, берәүнең авторитетына таянып, шул фикерне «бик акыллы» формулаларга салалар һәм диссертация оештыралар. Син шуны укып чыгарга, киңәшләр әйтергә һәм аны фәнгә җитәкләп кертергә тиешсең! Фән белән шөгыльләнүчеләр күбәйгәннән-күбәя бара, тик нигәдер алар арасында Эйнштейннар да, Курчатовлар да, Ландаулар да күренми.

Дәүләтшинаның диссертациясен укыган чакта Курмашевның күңелендә әнә шундый уйлар кайнады. Ул үзен фәннең сакчысы итеп, фәнгә җитешле, яхшы яшәү чыганагы итеп караучылардан саклаучы дип хис итте. Диссертация турында фикерен язганда да шушы уй аңа төп этәргеч булды.

Дөрес анысы, болай эшләү бик үк егетлек түгел инде. Иң элек Дәүләтшинаны күреп сөйләшергә, үзенең аның фикерләренә каршы икәнлеген яки оппонентлыктан баш тартачагын әйтергә, диссертацияне якламый торырга киңәш итәргә кирәк иде. Эшен эшләп бетерсен, шикле урыннарын ачыкласын, Курмашевның киңәшләрен тыңларгамы, юкмы — анысын үзе хәл итсен. Ә кагыйдәне беренче булып кем бозды соң? Курмашевтан: «Оппонент булырга телисеңме, юкмы?»— дип сорадыларм соң?

Дания Дәүләтшина яшь кенә аспирант икән әле, яше егерме бишләрдән ким булмаса да, чырае белән яшь кызлар төсле иде. Әмма диссертация яклаганда ул үзен олы кешеләрчә бик җитди, сабыр тотты, бер дә дулкынланмады-каушамады. Әйтерсең ул диссертация якламый, бәлки гади бер студентлар түгәрәгендә доклад сөйли иде. Курмашев аның кыюсызлыгын сизәргә никадәр тырышса да, сизә алмады. Тик Дәүләтшина үзе сөйләргә керешер алдыннан стендка диаграмма, схемалар элгәндә генә Курмашев аның колак яфраклары кызарган булуына игътибар итте. Пешкән мүк җиләге төсенә кергән иде кызның колак яфраклары. Курмашев башта: «Шундый колак алкасыдыр бу, ап-ак йөзенә бик килешеп тора. Кара син аны, нинди мут!» — дип уйлаган иде, текәлебрәк карагач, үзенең ялгышын белде дә ачуы тагы да кабара төште.

Диссертация яклау нәкъ башка вакытлардагыча ук алып барыла: минутына чаклы дигәндәй төгәл исәпләп куелган, мең тапкыр уйналган бер үк спектакльдәге шикелле, тик рольләрне башкаручылар гына үзгә... Ваза белән чәчәкләр, графин белән су куелган өстәл артына директор, гыйльми секретарь, гыйльми советның башка әгъзалары утырышкан. Залда — аспирантлар, өлкән һәм кече фәнни хезмәткәрләр. Болар — киләчәктә булачак кандидат һәм докторлар; һәр диссертация яклау алар өчен файдалы, кызыклы бер репетиция генә. Арада диссертантның туганнары белән танышлары да бар булса кирәк.

Яхин ишек янынарак утырган: берәр эш белән чакыра-нитә калсалар, чыгып китәргә якынрак булсын, дигәндер. Әкәмәт бер кеше инде! Үзенең әле диссертация яклап караганы юк, профсоюз мәшәкатьләреннән башы чыкмый, гадәттә, ул диссертация яклау утырышларына йөрми иде, бүген сабакташы, дусты Курмашев чыгыш ясыйсы булгач, түзмәгән, эшләрен ташлап килеп утырган.

Курмашев диссертант сөйләгәннәрне тыңламады диярлек. Нигә тыңласын? Диссертацияне инде ул укыды, һәр формуласын, һәр өтерен дигәндәй хәтерли. Дәүләтшинаның нәрсә сөйләячәген алдан ук белеп тора: моңарчы нефть ятмаларын эшкәртүдә яңалык булып, фәннең соңгы сүзе булып саналган Курмашев вариантының кимчелекләре бар, җир астында су гел безгә кирәкле юнәлештә генә йөрми, бәлки каршылык азрак булган юлларны эзли, диячәк. Гади бер физика законы бу! Шул сәбәпле яхшы катламда булган нефть тизрәк бетә, каты токымлы урыннарда «җир маен» алып булмый. Ә менә алай эшләргә кирәкми, диячәк. Суны тоттың да җир астына кудың түгел, бәлки алдан ук аның кая китәсен белеп эш итәргә кирәк. Кирәкле җиргә китсен ул. Бөтен хикмәт шунда!— диячәк.

Дәүләтшина да мәсьәләне нәкъ Курмашевтагыча куя, тик ул эшнең тәртибен үзгәртергә кирәк дип саный. Курмашев тәкъдиме буенча зур бер мәйдан тирәли уннарча, йөзләрчә ярдәмче скважиналар тишәләр дә шулардан җибәрелгән су, тыгыз бөҗра сыман, нефть ятмасын кысып ала. Әллә ничә чакрым озынлыгында су торбалары сузалар, насос станцияләре корып, куәтле моторлар куялар, ә су җибәрергә дип бораулаган әлеге скважиналарның берничәсе каты катламнарга туры килгән булып чыга, су җир астына китми. Шулай итеп, күпме эш бушка эшләнә, күпме торба, механизм, вакыт әрәм була.

Курмашев, әлбәттә, тынычланып калмады. Яхшы белгеч булып танылып җиткәч тә, кимчелекләрен бетерү турында күп уйланды, күп эзләнде, ләкин рәтле-юньле әмәл таба алмады. Ничек табасың? Җир астынданиләр барлыгын күреп булмый бит! Андагы хәлләрне тик чама белән генә күз алдына китерәсең.

Ә менә, бактың исә, шул ук эшне башкача да эшләргә мөмкин икән. Скважиналар саны да шул ук, акча, торба, моторлар да шул. Тик Дәүләтшина ашыкмаска, кай төштән нефть чыгарырга, кай төшкә су җибәрергә кирәклеген алдан ук билгеләп куймаска куша, башта скважиналар бераз эшләп карасын, кайсының яхшы урынга, кайсының начар төшкә туры килгәнлеген күрик, ди... Нәтиҗәдә бораулаган скважиналарның барысы да эшли башлаячак һәм нефтьне дә күбрәк чыгарып булачак. Мәсьәлә ап-ачык!

«Шаккатырлык нәрсәсе бар соң моның! — дип, Курмашев үз-үзен тынычландырырга тырышып карады.— Тарихта күпме шундый очраклар булган — бөек галимнәр юк кына бер нәрсәне күреп җиткермәгәннәр, моны әле беркемгә танылмаган башка кешеләр күргәннәр дә яңа ачыш ясаучы булып киткәннәр». Ләкин алай дип кенә юанып булмый иде. Ул күпме тырышты, күпме баш ватты, янды-көйде, ләкин таба алмады, ә менә Дәүләтшина мәсьәләгә яңачарак карап, күреп алган да әйтеп тә биргән. Ни дип тә булмый шул!

Дания Дәүләтшина нәкъ Курмашев уйлаганча сөйләде. Сүзем кемнәргә ошамас, кемнәрнедер рәнҗетермен дип тормады, диссертациясен язган чакта уйлаган фикерләрен әйтеп бирде. Диссертация яклаганда шулай сөйләргә кирәк дип белде, күрәсең. Кулына кәгазьләр тоткан иде ул, ләкин аларны бик тиз онытты, үз эше турында, үзен борчыган уйлары турында тотлыкмыйча, кәгазьгә карамыйча гына сөйләргә керешәте, тормышының һәм эшенең төп асылын тәшкил иткән зур, мөһим нәрсәләрне залдагылар белән уртаклашты.

— Беләсезме, без бер көн узса ярый дип киләчәк турында уйламаучы кешеләр шикелле,— дип сөйләп китте ул, алдында утыручыларга мөрәҗәгать итеп, әйтерсең кешеләрнең киләчәк турында уйламауларына залдагылар гаепле иде.— Озакламый Көнбатыш Европага гына да ел саен миллиард ярым тонна нефть кирәк булачак. Бу рәвешчә файдаланганда нефть запасы нибары кырык елга гына җитәчәк. Ләкин шул хәлдә дә без эзләп тапкан байлыкның яртысын гына алабыз, калганын бөтенләйгә җир астында калдырабыз. Варварлык бит бу! Үзегез уйлап карагыз: әгәр без агачны кисеп яртысын урманда калдырсак, ничек булыр иде икән?!

Дәүләтшина, гомумән, диссертациясенең генә түгел, Курмашев хезмәтләренең дә бик кирәкле икәнлегенә басым ясап сөйли, чөнки Курмашев та ахыр чиктә шул мәсьәлә турында — ничек итеп нефтьне күбрәк чыгару турында баш ваткан. Курмашевның исә хәзер, диссертациягә карата тискәре бәя әзерләп куйган хәлендә, диссертантка: «Бик шәп! Молодец!»— дип кычкырасы килде, ләкин сүз аның нефть чыгару алымнарын камилләштерү турында бара иде. Әгәр кешеләр җир астындагы бөтен байлыкны чыгара алмыйлар икән, димәк, монда иң элек ул, Курмашев, гаепле, чөнки нефть ятмаларын эшкәртү мәсьәләләре белән күп еллар буена ул шөгыльләнеп килә бит. Сүз шул хакта барганда ничек итеп инде кул чабасың, «хуп, хуп!» дип кычкырасың?!

«Менә бит нинди кеше син! Шул хәтле көнче булма, кеше уңышына да шатлана бел,— дип, үз-үзен тиргәде Курмашев. — Камиллекнең чиге бармыни? Табигать бит үзен бертуктаусыз төзәтеп, яхшыртып торганга үзенең гармониясен саклаган, арттыра төшкән. Нигә кешеләр дә шулай эшләмиләр? Тициан, Микеланджело, Рубенс, Левитан һәм Репиннар хәзер үз әсәрләренә күз салсалар, мөгаен, алар да тагы да яхшырак итеп эшләргә мөмкин дип табарлар иде».

Чын хакыйкать булып башына шундый уй килүенә Курмашев сөенеп куйды, үз каршында дәрәҗәсе тагы да үсеп киткән кебек тойды, ләкин шул ук вакытта ниндидер чит бер тавыш пышылдап кына әйтте: «Әлбәттә, үз-үзләрен төзәтерләр, анысы искитәрлек нәрсә түгел. Менә син Рафаэльга әйтеп кара: «Сикстини мадоннасы»н синең өчен үзем язйым әле, син карап тор» дисәң, хәтере калмас идемени?!» диде.

Бигрәк тә Дәүләтшинаның бөтенләй кәгазьгә карамыйча сөйләве ачуын китерде Курмашевның. Гыйльми совет утырышына байтак халык җыелган, буш урын калмаган диярлек, әмма зал шул хәтле тыныч, һәр пышылдаган тавыш та ишетелеп тора иде.

Курмашев залдагыларның Дәүләтшинаны бирелеп тыңлауларына карап утырганда ни сәбәптәндер Ленинградта Петр Беренче музеендагы бер указ исенә төште. Шул указында Петр патша, ачуы килеп булса кирәк, сенат әһелләренә әйткән: «Речьне кәгазьдән укып сөйләмәскә, бәлки һәркемнең ахмаклыгы бөтен кешегә күренеп торсын өчен, үз сүзләрең белән сөйләргә»,— дигән.

«Кәгазьгә карамыйча гына сөйли, акылы белән мактанмакчы була»,— дип уйлап куйды Курмашев, югыйсә, моның өчен башка берәүне, киресенчә, мактаган да булыр иде. Үзе ул кешеләр алдында чыгып сөйләгәндә каушабрак кала, буталып, ялгыш сүз әйтүдән курка, шуңа күрә җитди чыгыш ясарга хәзерләнгәндә әһәмиятлерәк фикерләрен кәгазьгә теркәп куя иде.

Трибунага чыгып кәгазьгә карамыйча сөйли белүчеләргә ул һәр вакыт соклана, алардан көнләшә дә иде. Гадәттә теләсә нинди аудитория каршына чыгып речь сөйләргә остарган җитди, мөхтәрәм кешеләр шундый була, ә бирердә пешеп җитмәгән бер аспирант кыз шундый булып кылана. Диссертация якламый, нотык сөйли бу!

— Гафу итегез,— дип, Курмашев утырган җиреннән генә диссертантка сүз кушты.— Сез технология буенча катламнардан илле генә

түгел, алтмыш процент нефть алып була дисезме? Сезнең тәкъдимегезнең өстенлеге шундамы?

— Әйе, шунда.

Дәүләтшина шундук бернинди тоткарлыксыз җавап бирде, андый сорау булырын белеп торган, күрәсең.

— Сез инде бала-чага түгел, фикер йөртә белә торган кеше. Әйтү генә җитми, аны исбатларга да кирәк бит. Әйтик, бер урынны сайлап алырга да аннан бөтен нефтьне чыгарып бетерергә. Шуннан соң алдан уйланган запасның ничә процентын тәшкил итүен исәпләп чыгарырга кирәк. Сез шулай эшләдегезме? Андый мисалыгыз бармы?

— Юк...

— Менә бит,— диде Курмашев. Бу фикеренең башкаларга ничек тәэсир итүен чамаларга тырышкандай, залдагыларга, өстәл артында утырган гыйльми совет әгъзаларына күз йөртеп алды, үзалдына гына сөйләнгән сыман, ләкин башкаларга да ишетелерлек итеп: — Мисалыгыз юк, ә нәтиҗәне чыгарып та куйгансыз. Бик тиз!— диде.

Дания Дәүләтшина оппонентының бу «усал» репликасыннан каушап калмады, мондый сорауның да буласын белеп торган кебек, бик тиз җавап кайтарды:

— Без ул экспериментны хәзер эшлибез. Алтын күл промыселенда махсус тәҗрибә үткәрәбез. Гадәттә бер мәйданны эшкәртү егерме-утыз ел дәвам итә, кайвакыт скважиналар ярты гасыр буена һәм аннан озаграк та нефть бирә. Шулай булгач, без скважинадан нефть чыгып беткәнне көтеп торырга, шуннан соң гына теоретик исәпләрне практик фактлар белән исбат итәргә тиеш булабызмыни?

— Ә сез ничек уйлыйсыз соң?

— Мин башкачарак уйлыйм. Фактлар җыелганны көтеп яту дөрес түгел ул. Ул чагында андый зур эшкә бер кеше гомере дә җитмәс иде. Галимнәрнең бурычы — бөтен мәгълүматларны җыеп бетергәч түгел, бәлки булган кадәресенә таянып, алдан фикер әйтү. Дөньяда ачылып җитмәгән серләр, гипотезалар шул хәтле күп — аларның һәркайсын практикада тикшереп бетереп буламыни? Циолковский Гагаринның галәмгә очачагын ярты гасыр алдан әйтмәгәнмени? Менделеев таблицасындагы буш урыннарны ул үзе үлгәннән соң да әле һаман тутыра киләләр...

— Тарихта андый мисаллар шул хәтле күп — бер үк вакытта теге яки бу фикерне раслый да, инкарь итә торганнарын да табып була. Шулаймы?

— Шулай. Мин башка өлкәләрдән мисаллар китереп тормыйм — нефтьчеләр тормышыннан гына алып карыйк. Академик Губкин Идел буенда һәм Себердә нефть фонтаннары ата башлаячагын бик күп элек алдан әйткән. Бу җирләрдә хәзер илдә иң бай нефть промыселлары эшли.

Шулай итеп, чын бәхәс кузгалып китте, залда бик сирәк була торган хәл — диссертациянең якланмаячагын белгертә торган киеренке тынлык урнашты.

Утырышны алып барган гайльми секретарь, кулын күтәреп, Дәүләтшинаны сүзеннән туктатты да ачулы бер төс белән Курмашевка карап алды.

— Сезнең моңа хәтле бәхәсләшергә вакытыгыз булмадымыни? Әллә халык алдында чәкәләшергә уйладыгызмы? Юкка алай итәсез. Безне кинога да, телевидениега дә төшермиләр,— диде ул.

— Вакыт булмаган, күрәсең,— дип мыгырданды Курмашев, кашларын җыерып.— Диссертация яклау ул — бәхәсле урыннарны бөтен кеше алдында ачыклау өчен бит инде...

Курмашев, чыннан да, диссертацияне яклаганчы күрешеп сөйләшергә вакыт булмады, без менә хәзер монда гына очраша алдык, димәкче

иде дә тыелып калды. Хикмәт диссертантның оппоненты белән алдан күрешеп сөйләшеп куюындамыни? Мәсьәләнең асылы нинди фикерне алга сөрүендә, нәрсәне яклавында бит.

Диссертантның гыйльми җитәкчесе сөйләгәннән соң ук Курмашевка сүз бирделәр. Ул сүзен уйлап, ашыкмыйча, сабыр гына сөйләде, гыйльми оппонентларча объектив, гадел булырга тырышты, шул ук вакытта үзе ихлас күңелдән түгел, бәлки мин-минлек, ачу коткысына ияреп сөйләвен дә сизде.

Өстәл читендәге тәбәнәгрәк кафедра артына чыгып басу белән үк ул:

— Минем берничә җитди сүзем бар,— диде. — Хөрмәтле диссертантта караш киңлеге, эрудиция һәм кыю принципиальлек тә юк түгел. Боларын инкарь итеп булмый. Тик шулай да, «ошый-ошамый» дигән кебек тойгыларны читкә куеп торып, объектив һәм... таләпчәнрәк булыйк. Беренчедән, кешеләрне юкка куркыту нигә кирәк? Әлбәттә, дөньядагы нефть запасы без теләгәнчә күп түгел. Кырык ел ул — бер кеше гомеренең яртысы гына. Ләкин бу бит бөтен мөмкинлекләр бетте, «нефть бүтән юк» дип эзләнүдән туктаган очракта гына шулай булачак. Ә нефть эзләү әле һаман дәвам итә. Менә күптән түгел генә Көнбатыш Себердә зур ятмалар ачылды, запаста җир шарының океаннары бар, безнең әле ул океаннар төбенә төшеп тә караганыбыз юк. Беләсезме, киләчәктә кешеләрнең нефтьне атмосферадан, ягъни үзебез сулый торган гади һавадан ала башлаулары да ихтимал. Әйе, әйе, андый фикерләр бар, тик расланып җитмәгән әле. Аннары шунсын да онытмаска кирәк: киләчәк заманның энергиясе — атом, плазма, кояш җылысы.

Бу уңайдан атаклы белгечләрнең авторитетына таянып берничә мисал китереп китәсем килә. Совет физигы академик Иоффе шундый саннар китерә: безнең планетага бер тәүлек эчендә килгән кояш җылысы җирнең үзе барлыкка килгән заманнан бирле туплаган энергия запасына бәрабәр икән. Шуннан файдалана белсәң, күмер дә, нефть тә, газ да кирәк булмаячак. Макс Борн әйтә: водород төше процессы белән идарә итәр заман ерак түгел инде, ди. Ул чагында кешелек дөньясы гомумән энергия чыганаклары турында кайгыртудан берничә елга гына түгел, хәтта берничә гасырга гына да түгел, бәлки геологик чорлар дәвамына котылып торачак, ди. Водород төше ягулыгы — гади су ич ул, ә җир йөзендәге су — диңгез, океаннар тулы!..

Хәзер инде Курмашев, залдагылар белән фикер уртаклашкандай, гади итеп, иркенләп сөйли иде, аларның бирелеп тыңлауларын күргәч, ул үзенең сөйләгәне Дәүләтшинаныкыннан ышандыргыч икәнен сизде. Аңа бирешмәскә тырышып, Курмашев та кәгазьгә карамыйча гына сөйләде. Нигә кирәк кәгазьгә карау? Хәтердән генә сөйли алмыйммыни ул?!

Яхин аңа гаҗәпсенеп күзен төбәде, алгарак күчеп утырды һәм: «Әйдә, капла әле шуның авызын!» дигән шикелле, күз кысты. Гыйльми секретарь шалтыратмаска тырышып кына графиннан стаканга су агызды да кафедра кырыена куйды. Сенсация яратучылар, бер-бер хәл була хәзер, диссертацияне туздырып ташлый бу дип, тыннарын кысып көтеп утыра башладылар.

— Иң мөһиме, бу очракта хикмәт анда да түгел... — Шулай дигәч, Курмашев бераз су йотты, баш кагып кына гыйльми секретарьга рәхмәт белдерде, кискен күчеш булмасын дип, фикерен икенче төрлерәк итеп әйткәндә тыңлап утыручылар аның уй сөрешен онытмасыннар дип, беркадәр пауза ясап алды. — Уйлап караганыгыз бар микән: нигә без Айга, Марска күчеп тора башламыйбыз, шул хакта фантастик романнар гына язабыз? Теләмибезмени? Эш теләктә генә түгел шул — хәзергә ул эш безнең көчебездән килми. Мин булган кимчелекләремне үзем дә беләм. Нишләргә соң? Әйдәгез, тәкъдимнәрегезне әйтегез, бергәләп уйлашыйк. Хәзерге көндә практикага шуннан да яхшы нәрсә тәкъдим

итә алабыз? Минем уемча, без бирегә Курмашевның кимчелекләрен тикшерергә җыелмадык, бәлки хөрмәтле диссертантның хезмәтендәге уңай якларны күрергә дип килдек. Беләсезме, мин мактау сүзләреннән тыелып торырга тиеш булам. Гөман кылу ул фактларны алмаштыра алмый, фараз итүләр дә объектив дөреслек булып җитә алмый. Резерфорд атом үзәгенә үзенең интуициясе, физик-галим сиземе белән үтеп кергән, дип әйтүләре ихтимал. Ләкин бу — бөтенләй башка хәл. Анда сүз теоретик ачыш турында бара. Көндәлек практика бездән коры теләккә генә корылган шикле гипотезалар түгел, бәлки эштә таяныч булырлык, ялгышсыз, төгәл теория көтә...

Курмашев, зал уртасына карап, анда утыручыларга мөрәҗәгать итеп сөйли, шул ук вакытта күз кырыен гына алда беренче рәттә утырган Дания Дәүләтшинага да төшереп алгалый. Ул аңа ниндидер үчлекле бер хис белән карый, Дәүләтшинаның аптырашта калуын, күзләре белән ялварып, үзен якламаган тәкъдирдә дә, һич югы, мәрхәмәтлерәк булганны соравын тели. Әмма Дәүләтшина үзен ачу китергеч дәрәҗәдә тыныч тота. Бераз сөрмә тарткан кара керфекле күзләрен тутырып ачкан да кафедрадагы Курмашевка төбәлгән, аның карашыннан үтенеч түгел, бәлки балаларча бер кызыксыну, гаҗәпсенү сизелеп тора, әйтерсең ул ниндидер бик кирәкле бер соравына дөрес җавап таба алмыйча утыра. Аның бу кыяфәте Курмашевның ачуын гына китерә төште. Ул, диссертантка җиңелрәк булсын дип, әйткән сүзләренең мәгънәсен йомшартырга тырышмады, киресенчә, үзенең дәрәҗәсен-чамасын белсен әле дигәндәй, катырак итеп әйтергә тырышты.

— Мин мондый хезмәтнең кимчелекләре булмаска тиеш димим, җитешсезлекләрнең булуы бик табигый. Ләкин ялгышлыкларның чиге дә булырга тиештер бит? — дип, Курмашев, залда утыручыларга карап, кычкырып сорау куйды. Шуннан соң бераз тын алып торды да җиңүче кыяфәте белән туп-туры Дәүләтшинаның күзенә карады. Чак кына күтеп торгач, тавышын үзгәртмичә, сүзен болай дип тәмамлады: — Әйдәгез, бер генә минутка мондый бер хәлне күз алдына китерик. Без — дәрәҗәле, зур кешеләр, бу хезмәтне яклап тавыш бирдек ди, промыселларда безнең фикергә хөрмәт белән карап, диссертант тәкъдим иткәнчә эшкә керешәчәкләр. Һәм шундый хәл килеп чыга: практика аның фикерләрен расламый. Мин монда сүзнең миллионнар турында, миллионнарча тонна нефть, бу эшкә тотылган миллионнарча сум акча турында барганлыгын әйтеп тормыйм. Әйтергә теләгәнем шул: фәннең абруе турында уйларга кирәк. Бүген без ашык-пошык кына уйлап тапкан идеяне тәкъдим итәрбез, аңа юл ачарбыз, ә иртәгә безнең үзебезгә ничек карарлар? Бик уйланырлык нәрсә бу!

Курмашев кадәр Курмашев мондый фикер әйткәч, нәтиҗә билгеле инде: диссертациянең язмышы хәл ителде. Икенче оппонент — яшь булса да инде башы пеләшләнгән фән кандидаты — бу теманың бүген дә, киләчәктә дә бик кирәк икәнлеген, перспективалы булуын исбат итәргә тырышты, әмма диссертацияне барыбер кире кактылар.

Тавыш бирү нәтиҗәсен игълан иткәннән соң, Курмашев өске катка, үз кабинетына менде. Нигәдер аның кәефе әйбәт түгел иде. Тиктомалдан кешенең хезмәтен юкка чыгарды бит. Алай итәргә кирәк түгел иде, билгеле. Юкка алай эшләде! Әйтерсең аңа гына нидер җитми. Гыйльми житәкче тема өчен оппоненттан азрак җаваплымыни? Ул бит яклап сөйләде!.. Хәзер менә алар ресторанда утырырлар иде, тагын бер кандидатны «юарлар», матур-матур сүзләр әйтерләр иде, бөтенесенең дә күңеле хуш булыр иде.

Бирегә менә хәзер Дания Дәүләтшина килеп керер. Килеп керер дә хатын-кызларча үкереп елый башлар, сез мәрхәмәтсез, вак җанлы, көнче кеше икәнсез, дияр. Институтта кырын күз белән карарлар — директор да, гыйльми секретарь да, башкалар да Курмашевка үчләшерләр.

Мөгаен, диссертацияне эш планына кертканнәрдер, ни генә булмасын — аны төгәлләргә кирәктер, югыйсә, фәнни-тикшеренү программасы һәм гыйльми кадрлар хәзерләү планы үтәлмәгән булып саналачак. Ярый ла, программадан тыш, «өстәмә» рәвешендә тагын бер диссертация яклау булса! Югыйсә, директорга да, гыйльми секретарьга да шелтә эләгер, башкаларга да бик үк күңелле булмас. Болар барысы да аның аркасында, Курмашев аркасында бит...

Кабинетка Яхин килеп керде. Ул ашыгып кына Курмашевның беләген кысып: «Шәп!» — диде дә чыгып та китте. Мактавы булдымы, шелтә белдерүеме — аңламассың.



### 3

Көндезге ыгы-зыгыдан, шау-шулардан арыган шәһәр инде ял итсен дигән кебек, тиз арада шәфәкъ алсулыгы сүрелеп, кичке караңгы да төште. Өйгә кайтырга вакыт җиткән иде.

Курмашевның өе ерак түгел, ашыкмый гына атлаганда да нибарысы егерме минутлык юл. Ул мех эчле жылы плащын, эшләпәсен киеп, муенына шарфын буды да кайтырга кузгалды. Урамга чыккач, биш-алты адым да атлап өлгермәде — артта шапылдап ишек ябылганы ишетелде. Курмашев әйләнеп карады һәм тагын Дания Дәүләтшинаны күрде. Ул да институттан чыгып килә иде. Кирәк бит! Курмашевның кайтырга чыгуын юри көтеп торган диярсең!

Дәүләтшинаның кайту юлы кире якта иде, ахры. Башта аның асфальтка шык-шык басып атлавы якын гына иде, аннары ерагая-ерагая әкренрәк ишетелә башлады. Курмашев аңа әйләнеп карады — Дәүләтшинаның өстендә көлсу төстәге пальто, башында махер җебеннән бәйләгән алсу-кызыл йон башлык, аягында молния каптырмалы, озын балтырлы нәфис итек. Шушы кыяфәтендә ул әле генә Курмашевка каршы чыккан үзсүзле диссертантка бер дә охшамаган иде.

Курмашев, нигә икәнен үзе дә аңлап җиткермәстән:

— Дәүләтшина! — дип эндәште. Аннары аңа исеме һәм әтисенең исеме белән дә эндәшмәкче иде дә хәтеренә китерә алмады. Дәүләтшина тавышка әйләнеп карады, Курмашевны күргәч туктады.

Курмашев, үз-үзенә беркадәр ачуы килеп: «Нигә кирәк булды инде? Үзем кешенең диссертациясен «батырдым», үзем, берни булмаган кебек, аңа сүз кушам», дип кенә уйланды да гадәтенчә сабыр-салмак атлап Дәүләтшинага таба китте.

Әмма шулай да бик уңайсыз бит, шайтан алгыры! Шундый хәл килеп чыккан икән инде, аларга киләчәктә дә очрашмас өчен үз юллары белән китеп кенә барырга иде. Дәүләтшина акыллы, мөстәкыйль фикерле хатын булырга охшый, — монда якламаса, икенче җиргә барып яклар, Курмашевның дон-кихотлыгыннан көлеп, берәр төрле котлау открыткасы да җибәрер әле — янәсе, менә күрегез: барыбер кандидат булдым. Бер дә искитәрлек түгел — күпме кеше әнә шулай кандидат була!

Курмашев үзен әдәпле, инсафлы кеше дип саный иде. Берәр кешегә мәкерсез начарлык эшләсә, уңайсызлана, намусы борчыла иде. Хәзер ул соңга калып булса да Дәүләтшинаны, күңелегезне төшермәгез, дип юатырга җыенды: янәсе, тормышны гел зур уңышлар белән генә башламыйлар, баштарак уңышсызлыкка очрасаң — яхшырак та. Алда әле байтак вакыт бар. Инде эшләгән эшең соңрак чәлпәрәмә килеп җимерелсә, ул чагында инде хәл начарга китә, ачынырга-сыкранырга, ут йотарга гына кала. Яңадан керешергә көч тә, теләк тә булмый.

Дәүләтшина аның ни әйтергә теләгәнен сизенде, ахры, кисәткән шикелле, кулын күтәреп:

— Кирәкми, — диде. — Сез бит минем диссертациямнең кимчелекләренниндидер әшәке ният белән ачмадыгыз, болай файдалырак булыр дип ышанганга шулай эшләдегез. Дөресме?..

— Сез дә минем хезмәткә шул максаттан чыгып карагансыздыр бит? — дип сорады Курмашев.

— Әлбәттә. Минем хезмәтемнән сез тапкан җитешсезлекләрне башкалар да күрмәс идемени? Әгәр диссертациямне ВАКтан кире борып кайтарсалар нишләр идем?!.

— Башта бер-ике ел анда чират көттереп яткырырлар иде әле. Күпме вакыт әрәм булыр иде!

— Әйе шул! — диде Дәүләтшина, әңгәмәдәше аның уйларын алдан ук аңлап торганга сөенгән кебек.— Ни буласын белмичә, еллар буе көтеп ятудан да начар эш юк инде. Яшерен-батырын түгел анысы — һәркемнең дә тизрәк кандидат буласы килә. Олыгаеп беткәч, галим булуның ни мәгънәсе бар? Шул бер исеме генә бар, аннары пенсиягә чыгарга да вакыт җитә. Эшең терәлеп калса, бик күңелле хәл түгел шул. Гомумән, дәрәҗәле кешеләр якламаганда практиклар һәртөрле яңа тәкъдимнәргә шикләнеп карыйлар, ә галимнәр практиклар ни әйтер бит дип көтәләр. Сихерле бөҗра кебек. Барып төртелерлек почмак табып булмый...

— Талымсыз, әрсез, үзсүзле булырга кирәк.

— Һай, һәркем дә шундый була алса икән!..

Дәүләтшина, күңелле әңгәмә вакытында тапкыр сүз әйткәндәге кебек, кинәнеп. көлеп куйды. Курмашев, бу минем ни әйтәсемне чамалап ярашырга гына тырышмыймы? — дип шикләнә дә башлады. Диссертацияләре уңышсызлыкка очраган кешеләрне ни дип юатуларын кем белми? Ярый әле, вакытында һәм тиешле урынында шулай булып калды, диләр. Эшеңне ВАКтан борып кайтарсалар, аннары бетте диген — якын да барып карама! ЧП! Карап та тормыйлар, шундук кире кайтаралар, янәсе. Ә монда артыгын алып ташларга, аңлашылмаган җирләрен ачыкларга, җитмәгәнне өстәргә дә диссертацияне яңадан якларга мөмкин, янәсе!..

Шулай да Дәүләтшина ихлас күңелдән рәхәтләнеп көлә кебек иде. Курмашев үзенең шулай шикләнүеннән, аның һәр сүзеннән астыртын мәгънә аңларга тырышуыннан уңайсызланып куйды.

Дәүләтшина аңа шат чырай белән күтәрелеп карады да:

— Ларсенның Фишерга оттырганнан соң ни дип әйткәнен беләсезме? — дип сорады.

Курмашев, сүзнең шундук икенчегә алмашуына беркадәр гаҗәпләнеп:

— Юк, — диде. — Монда Фишер белән Ларсенның ни катнашы бар соң әле? — дип сорады.

— Ларсен бит нуль дә алты исәбе белән оттырган. Ә үзе, Фишерны отып, чемпион булам, дип мактанган булган. Дуслары Ларсенны, кунакка чакырып, юатмакчы булганнар. Беләсезме, килеп кереп сәлам бирмәс борын ук, нәрсә диган ул?

— Шахмат — кызыксынган нәрсәм түгел. Мин — преферанс остасы. Домино, дураклы уйный алам, ә менә «шах» һәм «мат» дип әйтә белмим. Хәер, Фишер белән берише гроссмейстерлардан бер дә ким уйнамас идем: ноль очко алыр идем... Гафу итегез, Ларсен Фишерга оттырганнан соң дусларына нәрсәләр әйткән соң?

— Шахмат турында бер сүз дә булмасын, диган...

Курмашев, сүзне кыен темадан читкә алып китkәне өчен күңеленнән Дәүләтшинага рәхмәт әйтеп:

— Аңлашыла,— дип куйды.

Алар, шулай сөйләшә-сөйләшә, янәшә атлап киттеләр. Шахматтан коккейга күчтеләр, аннары жырчылардан кайсы артистның — Азат Аббасовныңмы, Мөслим Магомаевныңмы яки Эдита Пьеханыңмы жырлавы тамашачыларга күбрәк ошавы турында сүз кузгалды, кайбер китаплар һәм кинофильмнар турында да фикер алыштылар. Курмашев, бер нәрсәне төшенеп, көнләшеп куйды: бу Дәүләтшина бик күп нәрсә белән кызыксына, бик күп нәрсә белә булса кирәк, өстәвенә, шактый тирәнтен белә икән. Курмашевка, «әйе, әйе» дип баш кагып, аның сүзләрен жөплләп барырга гына туры килә иде.

Дәүләтшина балаларча ихласланып, кечелекле, йомшак, ягымлы бер тавыш белән сөйли иде, шуңа күрә мондый сөйләшү Курмашевны үртәлдерми, ачуын китерми иде бугай. Әңгәмәдәшенең сүзен әнә шулай жөпләп барганда ул, китаплар укырга, театрга йөри башларга, былтыргы сезонда беренче группадан икенчегә төшкән футбол командасы өчен «авырый» башларга кирәк, дип үз-үзенә сүз бирде. Югыйсә, ул болай тормыштан артта бара икән ич, әдәбият, сәнгатьне дә белми, бары тик үз эше белән генә кызыксынып яши!

Кала урамнарына яз якынлашуын сиздереп торган жылымса, рәхәт бер кич кергән. Шәһәргә хас бензин, корым-сөрем исләрен аралап, юка, тополь исләре, дымлы жир исе аңкый башлаган иде.

Кызык кына килеп чыга икән кешеләр арасындагы мөнәсәбәт дигәнең! Менә Курмашев бүген шушы Дәүләтшинаның диссертациясен «батырды», ә хәзер, шул күңелсез хәл бөтенләй булмаган да кебек, һич уңайсызланмыйча, рәхәтләнеп аның белән сөйләшеп бара. Өстәвенә әле, бөтенләй өеннән кире якка, юлдашына кирәк якка таба китеп бара түгелме? Туктап, «хушыгыз» дип, кире китәргә көче житми, дөресрәге, аерылып китәсе килми иде.

Гадәттә ул хатын-кызлар белән ни сәбәптәндер жиңел генә танышып китә алмый иде. Алар янында гади була белми, беренче танышуда ук телефон, адреслар сорашу, ресторанга, пляжга яисә кунакка чакыруны күз алдына да китерә алмый иде. Санаторийга баргач та чит-ят кешеләр арасында кызыксыз бер адәм булып күренүдән курка, ялгызлыктан эче поша, башкалар шикелле гади генә, жиңел генә яши белмәвенә ачуы килә иде.

Ә бүген бөтенләй киресенчә килеп чыкты. Дәүләтшина белән ул иркенләп сөйләшә, аның фикерләрен рәхәтләнеп тыңлый, бәхәсләшә. Вакыт-вакыт Курмашевка хәтта алар бер-берсен бик күптән беләләр кебек тоелып китә иде.

Ниһаять, ул сүзне үзе күбрәк белгән нәрсәләр тирәсенә күчерде — нефть чыгару турында сөйли башлады. Мәктәп баласы кебек авыз ачып тыңлап бару гына уңайсыз бит! Ни дисәң дә, нефть фәнендә зур дәрәжә казанган кеше ул, аның һәр фикеренә колак салалар, чөнки ул әйткән сүз — бик күп еллар эшләп зур тәжрибә туплаган атаклы белгеч сүзе. Менә хәзер инде Дәүләтшина аны тыңлап, «әйе, әйе» дип баш кагып барсын.

Чыннан да, баштарак Курмашев кына сөйләде. Ул яңа теорияләрне телгә алды, тәмуг уты кебек эссе Маңгышлак ярыматавында, сазлыклы, салкын Ханты-Манси тайгасында нефть чыгару эшен ничек оештырырга кирәклеген сөйләп китте, сүз арасында гына ычкындыргандай, мактанып та алды: аны Якын Көнчыгышка китәсе совет белгечләренең башлыгы итеп чакырганнар икән, тик ул бераз шүрләбрәк тә тора икән. Булдыра алмасаң, ояты нинди бит, янәсе!

Курмашевның борчылган сыман итеп әйткән бу сүзләрен Дәүләтшина хатын-кызларча йөрәгенә якын алып:

— Курыкмагыз сез, үз-үзегезгә ышансагыз — булдыра алырсыз. Менә күрерсез! — диде.

Сүз тагын гомумирәк темаларга күчте. Курмашев янә: «Әйе шул», «Чыннан да», «Шулаймы?» дип, аңгәмәдәшенең сүзләрен җөпләп баруын гына абайлады. Дәүләтшина, яннарыннан узып киткән кешеләрдән бер дә уңайсызланмыйча, кычкырып-кычкырып һаман үзенекен сөйли: әллә кайдагы җир астыннан нефть суыручы насослар һәм нефтьне өскә этеп чыгаручы су — хәзер инде бик иске нәрсәләр, ракета двигателе заманындагы пропеллерлы самолетлар шикелле алар, ди.

— Ә сез нәрсә телисез соң? — дип сорады Курмашев, үзенең малай хәлендә калуына ачуы килеп.

— Ничек нәрсә телим? — диде Дәүләтшина сорауга каршы сорау белән.— Нефтьне башка юллар белән дә чыгарып була ич!.. Җир астына, су урынына, төрле реагентлар җибәреп, анда мең градус кызулыктагы химик реактор хасил итәргә мөмкин. Ә атом шартлатсаң? Аны анда да шартлатып була бит,— дип, Дәүләтшина аяк астындагы асфальтка ишарәләде.— Ул чагында инде кешегә буйсынмаган катламнар калмаячак, бөтенләй өметсез дип саналган урыннардан да, кайнап торган вулкан авызыннан магма ташыган кебек, нефть ургылып чыгачак.

— Бала-чага хыялы! Андромеда томанлыгы! — дип, Курмашев көлеп кулын селтәде.— Уйлап карагыз: атом шартлатып нефть чыгару кайчан булачак әле ул? Егерме беренче гасырдамы?!

— Анысы инде үзебездән тора. Хәтерегездәме: радиоактивлыкны кайчан ачканнар?

— Үткән йөзнең азагында. Елын хәтерләмим.

— 1896 елда. Ә радиоактив элементларны ясап булуын кайчан белгәннәр?

— Утыз дүртенче елда. Анысын төгәл хәтерлим. Шул елны, мин беренче курста укыган чакта, Пьер Кюри Мәскәүгә килеп китте. Шул вакытта ук Нобель премиясе лауреаты иде инде ул.

— Менә бит. Шуннан соң унбер ел узгач та американнар Хиросимага атом бомбасы ташлыйлар.

— Чагыштырдыгыз! Атом бомбасын ясарга бөтен дөнья галимнәре керешә, бернинди байлыкны кызганмыйлар. Немецлар, американнар һәм французлар бер-берсен узарга тырышалар. Анда — атом бомбасы, ә монда — нефть...

— Анысы шулай: анда — үлем, монда — тереклек, яшәү. Дөньяда хәзер нефтьтән дә кирәгрәк нәрсә юк. Газеталардан укып барасыздыр: бензинны талон белән генә бирәләр, яңадан велосипедка утырып йөри башлаганнар. Заводлар эштән туктый, кораблар юлга чыкмый. Кешеләрнең водород төше реакциясе белән идарә итәчәкләренә, океан көчен электр энергиясенә әйләндерәчәкләренә һәм кояшның җиргә килә торган нурларын бер генә бөртеген дә бушка әрәм итмәячәкләренә сез мин ышанмый дип уйлыйсызмы? Капитан Немо үзенең «Наутилус»ы, аның экипажы өчен кирәкле бөтен нәрсәне: корабны йөртерлек энергияне дә, командага кирәкле азык-төлек, кием-салымны да океаннан алган бит...

— Иһи-һи, сез фантастиканы бик яхшы беләсез икән! Андый дип үк уйламаган идем...

— Монда фантастиканың катнашы юк. Киләчәктә ни буласын көтеп ятып кына булмый. Киләчәк өчен һәркем хәл кадәренчә бүген үк нәрсәдер эшләргә тиеш. Күз алдыгызга китерә аласызмы: әгәр дөньяда бүген үк нефть бетсә, тормыш нишләр икән? Бер мотор да эшләмәс, шәһәр-калалар дөм-караңгыга чумар. Ниһаять, нефть бит ул азыкка ярарлык аксым дигән сүз, җир йөзендә ачлык бетәчәк дигән сүз.

— Фәнни коммунизм буенча сез нинди билгегә укыдыгыз? Өчлегәме? — диде Курмашев елмаеп.

— Нигә өчле булсын — бишле!

— Җир йөзендә ачлыкның нидән булганлыгын беләсезме? Басукырлар начар уңдырганга, кешеләр нефтьтән азык ясый белмәгәнгә, дисезме? Алай түгел шул. Хикмәт сезнең ул нефтьтән ясаган таблеткаларыгызның кемнәр кулына эләгүендә, аларны кемнәр ясавында: җәмгыять үзе җитештерәме аны, әллә аерым эшкуарлар: Морган, Рокфеллер, Дюпоннармы...

Курмашев Дәүләтшина белән әнә шулай дип бәхәсләшкән, аның фикере белән килешмәгән булды, ә эченнән юлдашының хаклы булуын тойды. Гомере буена нефть мәсьәләләре белән шөгыльләнеп килгән белгеч буларак, ул җир астына ясалачак химик реакторлар, атом шартлатуларның бары тик фараз итү, гипотеза гына икәнен, бу эшләрнең әле бүген-иртәгә түгел, бәлки киләчәктә генә чынга ашачагын аңлый, шулай да Дәүләтшинага: «Тормышка ашмас хыяллар белән яшисез икән», дип әйтергә теле бармый иде.

Гәптәшенең балаларча рухланып-канатланып, киләчәк заманнарны көтмичә дә теләгәненне тизрәк тормышка ашырырга мөмкин дип ышануына эченнән генә сокланган-көнләшкән хәлдә, ул: «Бу хәтле фикер каян килә моның башына? Нигә мин дә шулай хыялланмыйм? Теләкомтылышларым сүнеп-бетеп бара микәнни?» — дип уйланды. Үзенең көндәлек эшләр белән генә яшәвенә беркадәр пошынып куйды. Дәүләтшина шикелле хыяллана алмавын белсә дә, аның һәр сүзе белән килешергә әзер иде ул. Нигә килешмәскә?! Дәүләтшина хыялланган нәрсәләр алай бик үк чынга ашмаслык фантазиямени? Әнә бит галәмгә очтылар, Айга барып кайттылар. Элегрәк хыялга да килмәслек нәрсә иде бит алар!

Берәр кеше синең борчуларыңны уртаклашса, күңелеңдә шул кешегә карата рәхмәт хисе уяна. Дәүләтшина аның чит илгә китүгә бәйләнешле мәшәкать-борчуларын үзенеке шикелле итеп, йөрәгенә якын алып, кайбер киңәшләр дә әйткәч, Курмашевның үз хәл-әхвәлләре турында чишелебрәк сөйлисе, зарланасы килеп китте. Чыннан да, менә ул хәзер өенә, хатыны янына кайтачак. Хатын ул гомерлеккә яраткан бер кешең, әмма аның янына кайтуның бер шатлыгы да юк, күңел бер дә ашкынып тормый.

Юлдашы белән янәшә атлап барганда Курмашев аның белән саубуллашканнан соң өенә кайтып китәсен, күңелсез, шыксыз бетон баскычтан өченче катка менәсен, кара дермантин белән тышланган ике йозаклы ишекне ачкыч белән ача башлавын күз алдына китерде. Хатыны шунда каршы чыгып, аны эчкә кертеп җибәрәчәк тә ишекне ныгытып ябып куячак. Һәм Курмашев шунда үз гаиләң иминлегенә генә кагылышлы вак-төяк кайгы-мәшәкатьләр белән тулган, эшеңдәге тормышыңа бөтенләй ошамаган икенче бер дөнья эчендә торып калачак. Бүген ул, диссертация яклау буласын уйлап борчылган хәлдә, эшкә китеп барганда юк сәбәптән генә тагын хатыны белән ачуланышты. Хатыны: «Эштән соң малай белән килен янына барып кайт әле, яңа фатирга ничек урнаштылар икән? Бераз җиһазлашырга булышыр идең», дигәч, Курмашев шундук кабынып китеп:

— Әйе, шулай гына итәсе калган! Аннан башка кайгым беткән! — дип кырт кисте.

Хатын да җавапсыз калмады:

— Улың белән килен өчен кайгырырга тиеш түгелмени син? Бер җирең дә кителмәс — барып кайтырсың! — диде ул, ачу белән үртәлеп.

Менә хәзер Курмашев аның сүзләрен генә түгел, шул сүзләрне әйткәндәге торыш-кыяфәтен дә, ачулы тавышын да хәтерләде. Янында янәшә генә атлап барган Дания Дәүләтшинага, минем гомерем буена кайгы-борчуларымны уртаклашучы якын кешем булмады, эшемдәге уңышларым һәм дәрәҗәм белән ганләмә матди файда китерү җәһәтен-

нән генә кызыксыналар иде. Мин ялгызлыкта яшим: кайгы-хәсрәтемне дә, сөенечемне дә бүлешер кешем юк, дип, зарын сөйләмәкче булган иде дә тыелып калды — рәтләп танышып та җитмәгән бер аспирант хатын-кыз алдында болай эчендәгене чыгарып селкүне яхшысынмады.

«Беләсе иде: ничә яшь икән моңа? Егерме бишме? Утызмы? — дип уйланды Курмашев. — Әле юньләп тормыш та күрмәгән бу ябь-яшь хатында каян килгән мондый ирләр акылы?» Ә Курмашевка илле яшь бит инде. Аның гомере узып бара микән инде? Бернинди уй-фикер омтылышы да калмаганмы? «Көн узса — ярый» дип кенә яшәү була бит бу!

Алар шактый озак сөйләшеп бардылар. Яннарыннан кешеләр, машиналар үтеп торды. Узып китүчеләр шактый олы күренгән бу мәһабәт иргә, аның кечкенә буйлы, яшь кенә юлдашына игътибар иттеләр, үтеп киткәч, борылып-борылып карадылар. Курмашев озын, төз буйлы булса да, хәрәкәте салмакланган инде, ә Дәүләтшина буйга аның җилкәсеннән генә булса да, шундый җиңел гәүдәле. Әнә шул гәүдә аерымлыгы аларның яшь аермаларын да бик нык сиздереп тора иде.

«Бик сөйкемле үзе! — дип, юлдашы турында уйланды Курмашев. — Характер-холкы да әйбәт булырга кирәк... Вакыт дигәнне кирегә әйләндереп, яңадан кайтарып булсын икән!..»

## 4

Курмашев кай төштән баруларын, ни сөйләшүләрен яхшылап абайламый, күңеле белән ул ниндидер икенче бер рәхәт дөньяга килеп кергән сыман иде. Шәһәр урамына ошамаган, авылдагы шикелле таза бура йортлар тезелеп киткән тыныч, аулак бер урамга җиткәч кенә әлеге тойгыларыннан айнып китте. Дания Дәүләтшинаның бистәдә яшәгәнлеген аңлап алды, уңайсыз бер хәлдә калуларын уйлап куйды. Малайларча урам уртасында саубуллашып китеп бару уңайсыз, Дәүләтшинага Курмашевны өенә чакыру — килешмәс. Юньле хатын-кыз төн уртасында дигәндәй өенә чит ир ияртеп кайтмас!

«Килеп эләккәнмен! — дип, үз-үзенә ачуы килеп уйланды Курмашев.— Нигә аңа эндәшергә, нигә ияреп китәргә кирәк иде инде? Өендә кемнәре бар икән? Ире, ага-энесе, әти-әнисеме яки карчык әбисе белән карт бабасымы?»

Курмашевны уңайсыз хәлдә калдырган нәрсәләр Дәүләтшинаның уена да кермәде, ахры. Капка төбенә килеп җиткәч, ул чак кына туктালып торган кебек булды да шуннан соң, һичбер икеләнүсез, келәне күтәреп, капканы ачып җибәрде.

— Менә шушында инде минем куыш. Рәхим итегез, кунак булырсыз. Чәй эчеп, җылынып алырбыз,— дип, Курмашевны өйгә чакырды.

Башка вакыт булса, Курмашев берәр сәбәп табып баш тарткан да булыр иде, тик бүген ул нигәдер үз-үзен аңларлык хәлдә түгел иде. Башта ул юлдашының ничек сөйләшүе, бәхәсләшүе, хыялларын сөйләнүләре белән мавыгып барды, ә хәзер аның ничек яшәвен күреп беләсе килде. Күңелендәге икеләнүләренә кул селтәде дә беренче булып капкадан эчкә атлады.

«Куыш» дигәне чыннан да алты почмаклы йортның җылытылган чоланындагы, ак пәрдә корылган кечкенә генә тәрәзәле, җыйнак кына, бәләкәй бер бүлмә икән. Бер як стена буена диван урнаштырылган, диван башы белән фанер бүлем арасына яшел киндерле раскладушка җыеп куелган, икенче стенага бизәкле чаршау корылган — анысы кием шкафы сыман бер нәрсә иде, күрәсең.

Бүлмәнең хуҗасы ут кабызуга, алар янына шактый олы яшьләрдәге, дәү гәүдәле таза-симез бер апа килеп чыкты.

Өйгә чит кеше килеп керүенә ул бер дә уңайсызланмады — итләч, симез кулы белән урындык өстен сыпыргалап алды да Курмашевка: «Утырыгыз»,— дип урын тәкъдим итте һәм Дәүләтшина белән сөйләшергә кереште:

— Эшең уздымы? Куанычлары белән булсын инде!

— Узмады шул, Хәдичә апа, кичектерделәр. Мәскәүдән профессор килмәде,— диде Дания Дәүләтшина һәм, ялганымны тоттырмагыз инде, дигән сыман Курмашевка күз кысты. — Грипптан авырып киткән.

Хәдичә апа дигәне, бот чабып:

— Ай аллам, менә күрәсең булса!— диде. — Мәскәүдә гел шулай инде. Яз-көз җиттеме — грипп тарала. Врачлар азмы соң анда, әллә халкы шундый саклана белми торганмы?.. Гөбәдия пешергән идем: шатлыктан бер бәйрәм итеп алыйк әле, мин әйтәм. Гүзәл-балам гөбәдияне бик мактады инде, йокларга яткач әйтә: «Дәү апа, тагын шундый бәлеш пешерерсең, яме?» ди. Сатар өчен түгел лә ул, ашагыз!

Сөйләгән чакта Хәдичә апаның юан беләкләре бер дә тик тормый — ул гел кулын селкеп сөйли, иңнәренә салган мамык шәле дә дәү түше белән бергә тирбәлеп-тирбәлеп ала иде.

Шуннан соң ул тиз генә чыгып әйләнеп тә керде. Кулына зур калай поднос белән гөбәдия күтәргән иде. Өсте кызарып пешкән йөземле гөбәдияне өстәл өстенә китереп куйды, шундый сый китерә белүенә үзе дә сөенгәндәй елмаеп, тегеләрнең икесенә дә, рәхим итегез дип, баш какты да чыгып китте.

Хуҗа ханым өстеннән пальтосын салып, ишек янында стенадагы элгечкә элеп куйды. Курмашевка да өстен чишенергә кирәклеген искәртеп, башы белән элгечкә таба ымлады да керогаз кабызырга кереште.

Курмашев плащын һәм бүреген салып элгечкә элгән чакта, кызыксынуын сиздермәскә тырышып кына, бүлмәгә күз йөртеп чыкты. Артык күзгә ташланырлык бернәрсә дә юк, һәммә нәрсә үз урынында, кирәксез бер әйбер дә күренми иде. Хәер, мондый квартирда нинди артык нәрсә булсын! Буйга өч, аркылыга ике адымлы кечкенә генә бер бүлмә. Бер өстәле бар, өстәл турысында өстәрәк — китап киштәсе, шуңа берничә китап һәм журналлар куелган. Киштәнең яңак ягында арзанлы гына транзистор эленеп тора. Диван сыман нәрсәдә, чәчәкле юрган ябынып, дүрт-биш яшьлек кыз бала йоклап ята иде.

«Иреннән аерылган нәрсәкәй, ахры. Бәлки бөтенләй ирсездер. Хәзерге хатын-кызлар арасында төрлесе бар бит»,— дип уйланды Курмашев.

Ул Дәүләтшинаның керогаз кабызып, төбе корымланып беткән ак алюмин чәйнекне кайнатырга куйганын көтеп торды да:

— Күптән яшисезме инде сез монда?— дип сорады.

— Өч ел инде, диссертациямне яза башлаганнан бирле. Хуҗа апамнан бик уңдым. Үзем эштә чакта кызымны да карый, командировкага китсәм дә аңа калдырам, кич кайтуыма аш пешереп куя. Бу бала белән үзем генә берни дә эшли алмас идем. Командировкага шактый озакка — атна-ун көнгә китәргә туры килә. Нишләр идем? Кызымның үсеп җиткәнен, кул-аягым бушаганын көтәргә туры килер иде.

— Кул-аяк барыбер бушамый,— дип, көрсенеп әйтеп куйды Курмашев. — Бала кечкенә чакта мәшәкате дә кечкенә, үсә төшкәч, мәшәкате дә зурая. Ярар, берәр ничек җайланыр әле. Балконы кояш ягына караган, газлы-сулы квартир алырсыз да бик әйбәт яши башларсыз. Без әле сезнең яңа квартирыгызны котларга килербез, берәр шампански шартлатырбыз. Күпме көтәсе калды соң әле? Озакмы?

— Озак шул әле. Чиратка да басмаганмын.

— Ə моңарчы нәрсә карадыгыз?— диде Курмашев, гаҗәпләнүдән кулларын җәеп.— Минә хәзер исемлектә беренче кеше булып торыр идегез инде, һич югы, беренче ун кеше арасында булыр идегез.

Дәүләтшина, бик кызыклы, шаян сүз ишетеп күңеле булгандай, рәхәтләнеп көлеп җибәрде, аннары нидер хәтерләп, уңайсызланыбрак китте, авызын кулы белән каплый төшеп, җитдиләнебрәк калды.

— Бик мәшәкатьле эш шул. Гаризасын язарга, райисполкомнан, профкомнан комиссия китертергә кирәк: нинди шартларда яшисең, кемнәрең, күпме туган-тумачаң бар, үз йортың юкмы, тегесе-бусы... Я, диссертацияңне ташлап, квартир артыннан йөрисең, я, квартир турында онытып, эшеңне эшлисең. Ярар, берәр ничек җайланыр әле,— диде ул, Курмашев сүзен кабатлап.— Әйдәгез, чәй эчеп алыйк.

— О-о, сез барысына да бик тиз ирешмәкче икәнсез!— диде Курмашев, сүзне дәвам иттереп. — Кандидатлыкны гадәттә илле тирәсендә генә яклыйлар, ә докторлыкны — пенсиягә чыкканда. Кайвакыт докторлыкка да, пенсиягә дә кәгазьләрне берьюлы тутыралар.

— Шуны сез яхшы хәл дип уйлыйсызмы? Тормышта моның киресе юкмы? Совет галимнәреннән беренче булып Нобель премиясен Ленинград химигы Семенов алган. Кырык яше дә тулмаганда ул академик булган. Ампер унөч яшьлек малай чагында ук инде Архимед, Ньютоннар күпме баш ваткан түгәрәк квадратурасы мәсьәләсен чишкән. Ә Христиан Эрстед, Пьер Кюри, безнең Камай?..

— Алары аның — меңгә бер.

— Ə нигә, мин меңнән бер була алмыйммыни? — дип, Дәүләтшина елмаеп куйды, сораулы бер төс белән гәптәшенә карады. Нишләргә: шаяртып кына әйттем, дияргәме, әллә чыннан да үзем турында шулай зур уйлаганлыгымны расларгамы дип икеләнеп калды, ахры. Һәрхәлдә, ул берни дә әйтмәде — рәхәтләнеп көлде генә.

Курмашев нигәдер уңайсызлана калды. Дәүләтшинаның болай көлүе артык гамьсезлек, җиңел акыллылык кебек тоелды. Әле моннан өч сәгатьләп элек кенә диссертациясен яклый алмады, ә хәзер үзен бөек кешеләр янына янәшә куеп сөйләшә. Бик чая кылана!

— Сезгә ничә яшь хәзер?..— дип сорады Курмашев һәм, урынсыз сорау ычкындырганлыгын шундук аңлап алып, гафу үтенергә керешге: — Кичерегез, онытып җибәргәнмен. Хатын-кыздан кайчан туганлыгын белүгә караганда ир кешедән кайчан үләчәген сорау ансатрак, диләр бит.

— Барыбер түгелмени?— диде Дәүләтшина, берни булмаган кебек.— Узган атнада егерме сигезне тутырдым. Илле тулганны көтсәм, тагын егерме ике ел гомерне әрәм итәргә кирәк. Алай көтәргә вакытым юк.

— Вакытыгыз юктыр да, ашыгып ни мәгънә бар соң?

— Болай да ничә елым әрәм булды инде! Сигезенче класстан соң туп-туры промыселга киттем, өч ел оператор булып эшләдем...

Курмашев үзенә, ягъни галим профессорга, каршы чыгарга кыюлыгы җиткән бу аспирант ханым башта күренгәнчә үк бик гади, беркатлы түгел икән дип уйлады да:

— Тормыш тәҗрибәгез ярыйсы икән, пролетарларча, — дип, саклanып кына сүз кыстырды.

— Унынчы класс имтиханнарын экстерн тапшырдым да университетка кердем, шуннан соң яңадан промыселга кайттым, аннары инде аспирантурага кердем,— дип Дәүләтшина, Курмашевның әлеге сүзенә әһәмият итмичә, сөйләп китте.— Күпме көтәргә мөмкин инде? Мин шулай дип уйлыйм. Минемчә, бөтен кеше дә үз җае белән җиткәнне көтеп ятмаска, ашыгырга, тырышырга тиеш. Шулай булмаганда гомер узып китәчәк, син берни дә эшли алмый калачаксың.

Өй эче жылына төште шикелле. Хужа ханым чаршау артына кереп китте. Аннан кире чыкканда инде ул кофтасын салган, кыска итәкле модный кара юбка, ап-ак челтәр блузка кигән, челтәрле блузка аша лифчигенең алсу тасмалары, эчке күлмәге беленеп тора, аякларына гади оек, тәбәнәк үкчәле туфли кигән иде.

Курмашев аның зифа буй-сынына күз салып: «Кара, нинди чибәрләнгән! Киенә белә, күрәсең, киенә белеп киенә торган. Бөтенесе дә таман гына, бер артык нәрсәсе юк...» — дип уйлап куйды. Өстәлгә якынрак килеп, ишеккә ян беләнрәк урнашты. Икесе дә сүзсез калдылар. Хәер, нәрсә сөйләшсеннәр икән? Яз җитүе турындамы? Озаклამый Иделдә боз да кузгалыр дипме?

Бәлки Курмашевка үзенең дә тиз генә профессор булмавын сөйләп, Дәүләтшинаны бераз юатырга кирәктер? Бик күп еллар тир түгеп кенә шушы дәрәҗәмә ирештем. Фатир мәсьәләсендә дә нәкъ сезнеке шикелле чор кичердем. Башта «почмак» алып тордым, аннары үземә бер бүлмә бирделәр, шуннан соң «яхшырту» өчен чират тордым — ике бүлмәле аерым квартирга тиендем. Ә хәзерге дүрт бүлмәлегә олыгаеп, атаклы белгеч, лауреат булгач кына тиендем дияргәме?.. «Монда синең катнашың булдымыни?— диде ул аннары үз-үзенә. — Барысын да хатын эшләде бит. Хатын оста инде андый эшкә, нинди йомыш белән кемгә барырга кирәклеген ул яхшы белә, аннары Яхин да ярдәм итте, иң четерекле, иң катлаулы эшләрне ул үз өстенә алды. Зур хыяллары белән шашып яшәгән гади бер аспирант хатын өчен кем квартир юллап йөрсен? Бүген диссертация яклый алмады, иртәгә моңарчы эшләгән эшеннән баш тартыр, акылына килеп, үз-үзен тиргәргә, үкенергә керешер. Алсу томан эчендә яши әле, менә томан таралыр да тирә-юне ялангач калыр».

Курмашевның Дәүләтшинага шулай дип әйтәсе, аны хаталардан саклап каласы, җитдирәк булырга кирәк дип, акыл-киңәш бирәсе килде, ләкин аның турында уйлаган саен аспирант хатынның тормыштагы беркатлы тәҗрибәсезлеге, үз-үзенә һәм үзенең эшенә шул кадәр ышанган булуы үзенә ошый икәнлеген күбрәк аңлый барды. Курмашев элек үзе дә шундый кеше түгел идеме соң? Тормышчан акыл кушканнарга каршы килеп эшләми идеме, күңелендә туган беренче теләккә юл куймый идеме? Сугыш вакытында ул аспирантурасын ташламадымыни, үзенә тиешле броньнан, галимлек карьерасыннан баш тартып, үзе теләп фронтка китмәдеме, Яхиннан үзен аның белән бер батальонга, бер ротага урнаштыруын үтенмәдеме?!

*
* *

Дөрес анысы, Курмашевка күп сугышырга туры килмәде. Беренче тапкыр немецлардан утыз-кырык йортлы кечкенә бер авылны сугышып алгач та аны батальон командиры янына чакырдылар. Комбат мунча алачыгында, бил каешын чишеп ташлаган килеш, корымланып-ысланып беткән такта сәкедә йөнтәс аякларын кайнар сулы ләгәндә парлап-пешеклэп утыра, үзе тез өстенә нингдидер кәгазьләр салган, шуларны актара иде. Ләгәндәге су кайнаррак иде булса кирәк: комбат ах-ух итә, аякларын ләгәннән чыгарып-чыгарып тора иде.

Курмашев аның янына кереп, үзенең килгәнлеген әйткәч, комбат беренче сүзе итеп:

— Синең ничек соң?— дип сорады.

— Нәрсә ничек?— диде Курмашев төшенмичә.

— Борының дим. Үкчәңнән бик югарымы?

— Гадәттәгечә.

— Ә минеке үкчәгә тоташкан кебек! Аптыраган инде. Аяк аз гына чыландымы — борын шул минутта ук лышкылдый башлый!— Шулай дигәч, комбат борынын тарткалап, бармагы белән тотып кыскалады да мактанган төсле сөйләнергә кереште:— Һич кенә дә алдап булмый мәлгуньне — хәзер сизеп ала юешне! Аякларны бераз парлап алырга кирәк, югыйсә, Берлинга хәтле барып җитеп булмас. Анда чаклы шактый ерак шул әле!.. Ә минем Берлинга бик барасым килә, ничек диләр әле... теге ниләре... Унтер-ден-Линденнәре буйлап бер узасы иде. Фашистларның үз өйләрендә ничек яшәүләрен күрәсе килә...

Ниһаять, комбат Курмашевны ни өчен чакырганлыгын исенә төшерде. Ләгәнне аяклары белән эләктереп бер читкәрәк күчерде дә:

— Утыр, аяк өсли сөйләшкән сүздә дөреслек юк,— дип, Курмашевка үзе яныннан урын бирде, шуннан соң тез өстендәге кәгазьгә шапылдатып бер сукты да әйтте:— Бүген бик батыр сугыштың син, молодец! Менә наградной листлар тутырып утырам. Әйт, сиңа нинди медаль бирик? «Батырлык өчен» дигәннеме, әллә «Сугыштагы казанышлары өчен»ме?

Курмашев һаман басып торган килеш:

— Белмим. Мин бит медаль өчен сугышмадым,— дигән булды.

— Чудак! Әллә син мине орден өчен сугышып йөри дип беләсеңме? Монда олимпиада түгел — чын сугыш, агай-эне. Я син батыр каласың, я башыңны саласың. Белдеңме? Мин үзем, мәсәлән, сиңа «Батырлык» өчен» дигәнен тәкъдим итәм. Ә казанышларың булыр әле.

— Ярый, алайса, «Батырлык өчен» дигәнен языгыз. Казанышларны икенче тапкыр билгеләрбез,— диде Курмашев.

Башта ул, «Сиңа нинди медаль бирик?»— дип үзеннән сорауларына сәерсенебрәк калса да, аннары, ярый, шулай тиештер, дип беркадәр тынычланды. Инде китәргә дип рөхсәт сорарга җыенгач кына, комбат аны ни өчен чакырганлыгын әйтте — аны тылга, яңадан нефть институтына кайтарып җибәрәселәре икән.

— Әллә син бик зур белгечме?— дип сорады комбат, ах-ух итеп аякларын ышкый-ышкый. Кызыксынып Курмашевка карады.

— Юк, аспирант хәзергә...

— Кара син! Бик зур галим дип торам мин сине! Чакыралар икән, димәк, синнән башка эш бармый анда. Ярый инде, алайса, күрәсең, бергә Берлинга барып җитәргә язмагандыр безгә. Әйберләреңне җый да — сау бул!

Комбат, бер кәгазьне тез өстенә куеп, кәкре-бөкре имзасын салды да:

— Әйберләрең бармы соң? — дип сорады.

— Солдатның нинди әйбере булсын?! Сакал сабынлый торган пумала да пәке...

— Анысы да байлык. Сугышта анысы да ярый, калганын тылга кайткач табарсың.

— Ә мин тылга кайтмыйм.

— Ничек инде ул — кайтмыйсың?

— Кайтмыйм, шул.

Сугыштан чыккан кызулыгы белән Курмашев тылга кайтып китүдән баш тартырга маташкач, батальон командиры аны мунча алачыгында «смирно!»га бастырды да акылга утыртты:

— Беләсезме, рядовой Курмашев, сез үз карашларыгызны фәнни симпозиумнарда әйтерсез. Анда гына күпме телисең — шул кадәр сөйләргә була. Ә монда — команда. Әйтелдеме — үтәргә тиешсең! Кемгә нәрсә эшләргә кирәклеген: алгы сызыкта торып фашистларга атаргамы, я булмаса тылдагы бер институтта формула чыгарып утырыргамы — анысын начальство яхшырак белә. Атакага барудан баш тартучыларны да, кирәксезгә атакага ыргылучыларны да бер үк

штрафной батальонга җибәрәләр. Синең аркада штрафнойга китәргә теләмим мин. Минем дә хатыным, балаларым бар!.. Сиңа ике сәгать вакыт бирәм, әзер булмыйсың икән — хәрби кыр судына озатам үзеңне. Аңлашылдымы?

Курмашев алгы сызыктан китте китүен, ләкин институтта да калмады. Монда алты-җиде ел элек студентлар семинарында укыган беренче докладындагы сызымарын, исәп-хисапларын алды да, озакламый якларга тиешле диссертациясенә дә кул селтәп, геолог-разведчиклар янына китте. Алар белән бергәләп ул буровойларда йөрде, шыксыз, салкын вагоннарда йоклады, үз фикерләре өчен көрәшеп, аны тормышка ашырырга тырышты һәм, ниһаять, үзенең теләгенә иреште: сугыш вакытында ачылган Алтын күл промыслен эксплуатацияләү схемасын ул чагында әле галим дәрәҗәсенә дә ирешеп җитмәгән Курмашев төзеде. Ярый әле, тырышлыгы эшкә-гамәлгә ашты, югыйсә, бушка күпме көч түгеп йөрүе дә ихтимал иде!

*
* *

Курмашев хуҗа ханымның ничек табын әзерләп йөргәнен күз чите белән генә дигәндәй күзәткәләп торды: менә Дәүләтшина ашыкмый гына чәй пешерде, өстәлгә савыт белән шикәр, стаканнар китерде — бер стакан авыр көмеш аслык белән — анысы берәрсенең бүләге булса кирәк, икенчесе гади ашханәләрдә була торган гадәттәге кырлы стакан иде. Курмашев яшьрәк чагында үзенең дә менә шулай Дәүләтшина шикелле йорт җыя белми, акыл-исәп белән яшәми торган хәйләсез бер кеше булганлыгын, ләкин шулай да төп максатына ирешкәнлеген уйлап, балаларча сөенеп утырды.

Табын әзерләнеп бетте. Дания ханым өстәлдәге савытларга күз йөртеп чыкты, бер-ике генә мизгел уңайсызланыбрак торган кебек булды, аннары җәһәт кенә өстәл асты капкачын ачты да аннан бер шешә коньяк, бер шешә «коры» шәраб, зур гына лимон һәм ике гади рюмка чыгарды.

— Менә алган идем әле... бәйрәм итмәбезме дип...— дигән булды Дәүләтшина, үсмер кызлар төсле кызарынып.

— О-о! — дип, Курмашев хуҗа ханымның бу сүзен хуплап каршы алды.— Дөрес итәсез, югыйсә, грипп эләктерүебез бар. Мәскәү кешеләре кебек!

Дәүләтшина сөенеп елмаеп куйды да кунагына пычак бирде. Курмашев үзенә нинди эш кушылганлыгын шундук төшенде, пычак очы белән калай бөкеләрне ачты, шулай да рюмкаларга коньяк кына саласы итте. Башта бераз үзенә агызды, аннары икенчесенә рюмканы яртысыннан арттырып салды да яңадан үзенекенә бераз өстәде.

— Ә сезнең банкет ничек соң? — дип сорады ул, хуҗа ханымга рюмка сузып.— Гадәттә андый нәрсәнең кайсы ресторанда булачагы, нинди закуска, нинди эчемлекләр куелачагы бер атна алдан билгеле була бит. Беләсезме, диссертация яклау да шактый күңелле, җиңел уза...— Курмашев: «...Сезнеке шикелле булмый»,— дип әйтеп җибәрә язды.

— Анысына башым җитмәгән шул.

— Әйтүче дә булмадымы?

— Булды. Барыбыз берьюлы берәр ресторанга барырбыз да утырырбыз дип уйлаган идек. Булып чыкмады шул. Мин яклау бетү белән тиз генә төшеп киттем дә завхоз бүлмәсенә кереп качтым. «Син бер дә борчылма, хафаланма, теге дә бу» дип, мине юаткан, илтифат күрсәткән булырлар иде, ялгыз калдырмаска тырышырлар иде.

— Андый чакта бездә илтифат күрсәтә беләләр инде.

— Таралышканнарын күтеп ике сәгать утырганмындыр. Бүгенге кичне ялгызым гына үткәрермен дип уйлаган идем — менә сез килеп чыктыгыз. «Мең дә бер кичә» әкиятендәге кебек! Әйдәгез, эчәбезме?

— Әйдәгез.

Курмашев тост сымак берәр сүз әйтергә җыенган иде дә хуҗа ханым аны көтеп тормады, кыланчыкланмыйча гына рюмкасыннан коньякны эчеп тә җибәрде.

Моңарчы Курмашев белгән хатын-кызлар аракы эчкәч тә ах-ух киләләр, авызларын ачып, кулларына өргәлиләр, аякларын тыпырдаталар, күзләрен йомып, тизрәк су сорый торганнар иде. Шул минутта Курмашев, хуҗа хатын менә хәзер берәр хикмәт күрсәтер: «Әх!» дип авызын сөрткәли башлар, дип уйлады. Ләкин Дәүләтшина, рюмканы куйгач, ике бармагы белән генә эләктереп бер телем лимон кисәге алды да, ашыкмыйча гына ике ягына да шикәр комы сибеп, лимонны кабып җибәрде.

Аннан күрә Курмашев та шулай эшләде: рюмканы эчеп куйгач, лимонга үрелде.

Шуннан соң чәй эчәргә керештеләр. Курмашев нәзберекләнеп кенә бәлеш чемченә-чемченә чәй эчте. Бүгенге шушы кичәгә, шушы бүлмәгә бәйләнеше булмаган бөтенләй башка нәрсә турында уйлады ул. Янып беткән учак көлендәге утлы күмергә коры-сары өстәгәндәге кебек, аның күңелендә инде сүрелә башлап та, әле бөтенләй сүнеп җитмәгән күптәнге хатирәләре яңарды.

## 5

Алтын күл дигәннәре әллә ни зур күл түгел, аркылысы — биш чакрым чамасы, буе — шуннан бераз гына артыграк булыр. Тиз арада зуррак мәйданны тикшерү өчен күл тирәсенә, бер-берсеннән шактый еракта, берьюлы сигез скважина бораулый башладылар. Мастерской, склад, алачыкларны һәм котельный белән конторларны күл буена, кечерәк бер поселок читенә корып куйдылар. Ремонтчылар, геологлар, инженерлар шушы поселокка, бригадалар, буровойларга якынрак булу өчен, тирә-як авылларга урнаштылар.

Бригадалар төрле халыктан җыелган иде: болар фронтта сугышырга яраксыз, ләкин госпитальдән чыккач хезмәт армиясенә җибәрелгән кешеләр иде. Буровойда эш авыр булса да, карточкага алты йөз грамм икмәк, маргарин бирәләр. Бораулаучылар, үзара сүз беркеткән кебек, Курмашевның «Кернны әйбәтләбрәк алыгыз, җир астыннан чыгарылган пробаларны тизрәк анализга җибәрегез»,— дип боеруына да, игътибар итмиләр, эшләрен ансат кына бетерергә тырышалар. Бораулап та, керн алынмагач, ул скважина нигә кирәк? Эшне төгәлләсәң дә, проба, анализ булмагач, барыбер берни белә алмыйсың!

Әгәр Курмашев фронттан гарипләнеп кайткан авыру кеше, зур белгеч яки бик карт бер бабай булса, бораулаучыларны тыңлатуы җиңелрәк тә булыр иде бәлки. Авыр эш эшләп, шуның өстенә туктаусыз күченеп йөреп тәмам йончыган, хәлдән тайган нефтьчеләр япь-яшь, тап-таза бер егетнең акыл-киңәшен тыңлыйлармыни?! Алар аңа, бу егет балчык пробалары белән маташканчы, тимер торбалар күтәрешсен иде, дип карыйлар!

Бервакыт буровойдан-буровойга күчеп йөрү башланды. Беренчесе — базадан ун чакрым чамасында, Алтын күл буенда ук иде, икенчесе — Кама аръягында, бөек рәссам Шишкин сурәтләгән нарат урманында, өченчесе — Шушма аръягындагы ялан кырда... Базадан бер тарафка йөз чакрым, икенче тарафка тагын йөз чакрым барасың, ә ул елларда такыр шоссе түгел, юньле ат юлы да юк иде! Бу скважиналар Курма-

шевка әллә кай еракта, аулак бер төбәктә югалып яткан бик кечкенә бер нокта булып кына тоела, шуңа ул, мин монда салам кибәне эченә төшкән энә кебек югалырмын, максатыма ирешә алмам, дип шикләнә иде.

Бервакыт Курмашев бөтен вахтаны яңадан эшләтеп керн алырга кушкач, Зиннәт Шәрифуллин дигән усал телле бер бораулаучы әйтте аңа:

— Бик күп беләсең, бик елгыр да икәнсең, туган. Болай булгач, бик ерак китәрсең син!— диде.

Шәрифуллин гастрит авыруы белән җәфалана, бу буровойларда ел буе адәм рәтле доктор күрмисең, болай булгач, барып чыгам инде мин, дип һаман саен зарлана-тиргәнә торган иде. Ул сугыш алдыннан, дәваланырга дип, Кисловодск санаториясенә барган булган, разведкага туптуры әнә шуннан килеп эләккән иде. Сугыш башлангач, санаторийны госпиталь иткәннәр, Шәрифуллинны, корал тотарга ярамыйсың дип, хезмәт армиясенә җибәргәннәр, гастритыңны сугыш беткәч дәвалarбыз, дигәннәр. Сугыш бетәргә исә бик ерак иде әле. Немецлар Ленинградны камап алганнар, Сталинградка якынлашып киләләр, кешеләргә бары бер генә өмет калган — дошманны җиңеп чыгачагыбызга ышану, шул көнне якынайту өчен көчеңнән килгәнчә тырышып эшләү иде.

— Бер дә елгыр түгел. Нәрсә эшләргә тиешле — шуны эшләгез. Сугыш вакыты хәзер,— дип, кырыс кына җавап кайтарды Курмашев.

— Әйе шул, сугыш вакыты!— диде Шәрифуллин. Аның авызын алай гына каплый алмассың! Шәрифуллин кычкырынырга ук кереште:— Син үзеңнең хокукыңны күрсәткәнче, кулыңа әнә лом ал, көрәк ал, торба күтәреш, измә изеш. Беләбез без синең ишеләрне!..— дип тезеп китте.

— Булдыра алмас дисеңмени?

— Булдыра алсаң — рәхим ит, эшләп күрсәт!..

Курмашев, ачу белән, кулына көрәк тотты, носилка белән балчык ташышты, измә изде, лом белән торбаларга күчерде. Торбаны такта басма өстенә китереп салгач, аңа элмәкле тросны кигезде дә, башка бораулаучылар шикелле, әче тавыш белән: «Вира-а-а!» дип кычкырып җибәрде.

Көз җитте, яңгырлар ява башлады. Аяк асты былчыранып, балчык измәсенә әйләнде. Курмашев бораулаучылардан берәр кеше белән носилкалап юеш авыр балчык ташыганда аяклары тубыктан былчыракка бата, яка эченә яңгыр суы ага, һәм шул чакта бу эшләрнең барысын ташлап, әллә кая китеп барасы килә иде. Нигә кирәк аңа бу эш, моның өчен ул чиләнергә тиешмени? Курмашев, абына-чайкала, носилка күтәреп бара, шушы авыр, газаплы эш ритмына күнегергә, җайлашырга тырыша. Шәрифуллин әнә чирле була торып та түзә, ә ул сәламәт, таза булып та — эшли алмыймыни?!

Вахта беткәндә инде Курмашев тәмам хәлдән тая, шундук урынга авып, баш калкытмыйча йоклыйсы килә. Тик шунысы гаҗәп: мондый минутларда ул әллә нинди кыенлыкларга да карамастан үз эшләрен башкаручы кешеләрнең сүгенү-тиргәнүләренә рәнҗемәвен тоя. Һәр кешене, һәр бригаданы ул аерым-аерым карамый, ә бәлки дошманны җиңәргә дип кузгалган халыкның олы бер рухи батырлыгын күрә сыман иде. Бу хәл аның үзенең дә рухын үстерә, көчен, түземлеген арттыра иде.

Курмашев беркатлы үсмер малай кебек, тырышлыгымны аз сүзле, кырыс йөзле бораулаучылар күрсеннәр иде, мактасыннар иде дип тели, ләкин тегеләре әйтерсең берни абайламыйлар, һаман эш белән мәшгульләр. Әгәр Курмашев берәр ничек тоткарланып, трос элмәген эләктереп өлгермәсә һәм шул сәбәпле лебедканы туктатырга туры килсә, Шәрифуллин усалланып кычкырырга тотына: «Нәрсә йоклап торасың, фәлән-фәсмәтән!»— дип, аның тетмәсен тетә иде.

Курмашев та үз дигәненнән чикмәде. Скважиналарны үзе кирәк тапканча гына бораулатты, кешеләр белән каты итеп сөйләшергә өйрәнде, ә Шәрифуллин түземлерәк була башлады, аны тетеп сукмәде, кычкырынса да, ачу белән түгел, бәлки яратыбрак, үз итебрәк кычкыра торган булды. Курмашев икенче урынга, Алабуга янына китәргә җыенып, кернны алу белән үк лаборанткаларга җибәрегез, дигәч, Шәрифуллин бөтенләй йомшарып китте. Чөйдә эленеп торган катыклы чиләкне алды да (вахтага чиләк белән катык алып килә иде ул) катыкны, бер кружка тутырып, Курмашевка сузды.

— Мә, эч. Бик шәп нәрсә. Аракы эчкәндә бик файдалы. Мин инде авыру кеше, аракы эчә алмыйм, ә син яшь, таза әле, менә сынап карарсың,— диде.

— Ярый, сынап карармын,— диде Курмашев, буш кружканы кире кайтарып.— Тик сез кернны гына онытмагыз, юкса, бөтен эш бушка тегермән әйләндерү генә булып калыр. Бу скважина янына икенчесен бораууларга туры килер.

— Онытмабыз. Нигә ике эш эшләргә? Без сине теш арасына кысып карадык инде. Әйбәт егет икәнсең! — диде Шәрифуллин.

Әлбәттә, ул чактагылар хәзер әллә ничек малайлык булып кына тоела. Ил өчен иң авыр, иң куркыныч вакытта Курмашевны фронттан кайтартканнар икән, димәк, аның тикшеренү-эзләнүләрен кирәк дип санаганнар. Ә берәү дә аны астан этеп менгезмәде, өстән тартып алмады, барысына да үз көче белән ирешге — моның белән ул һәр вакыт горурлана иде.

*

* *

Хуҗа ханым Курмашевның каршысында гына чәй эчеп утыра, вакыт-вакыт чәче төсле үк коңгырт-сары озын керфекләрен күтәреп кунагына карый, нидер әйтмәкче, ахры, тик карашын яңадан аска төшерә. Әллә хатын-кызга хас оялчанлыгы белән, әллә сүз сөйләп кунакны ялыктырмыйлар дип, ул беренче булып Курмашев сүз башлаганны көтә иде.

Дәүләтшина тыныч карашлы, зур күзле икән — күзләре эченнән җылы бер йомшак нур сирпелеп торган кебек. Әгәр әлеге диссертация вакыйгасы булмаса, шул хәл Курмашевның күңеленә шик-шөбһә салып борчып тормаса, кечкенә генә шушы бүлмәдә утырып кич уздыруы искиткеч рәхәт булыр иде.

Ни сәбәптәндер ул Дәүләтшинаның диссертация хезмәтен укыгач та күңелендә туган беренче тойгыга күбрәк ышана иде — ул аңа җитәрҗитмәс белемле бер аспирант итеп кенә карый, шуның өчен ул аның диссертациясен «батырды», ә менә хәзер шул аспирант хатын үз өендә Курмашевны кунак итеп утыра, бу ханым кай ягы беләндер галим профессорлардан өстен дә, тик кай ягы белән, күпмегә өстен — Курмашев монысын тәгаен күз алдына китерә алмый иде.

Әлбәттә, аның өстенлеге, иң элек, көндәлек тормыш ваклыкларына кереп батмыйча, үз-үзен аямастан, җитди, зур бер эшкә бирелгән булуында. Тагын бер өстенлеге шул — Дәүләтшиналар буыны тормышны өлкәннәрнең тәҗрибәсенә, акылына таянып башлый, аларның әле алда яшисе гомерләре бар. Яшьләрнең уңышсызлыгы — әле эшнең башы гына, картларның һәр уңышы исә: урын, дәрәҗә, чит илгә чакырылу һәм башкалар — гомернең азагына илтә. Шуннан соң инде яхшысы да, яманы да булмас, фәкать үтеп киткән гомернең сагынычлы хатирәләре генә калыр.

Мондый уйлар Курмашевның күңелен күтәрмәде генә түгел, киресенчә, катлаулы авыр сораулары арта гына төште. Ул аларга җавап

бирергә теләсә дә, җавап таба алмый. Бәлки, таба алса, җавап бирергә теләмәс? Чөнки ул җаваплар кирәгеннән артык аяусыз булыр кебек иде.

Курмашев үзенең инде күптән күңелен ашкындырган хыяллар белән генә яшәүче яшь аспирант түгеллеген белмимени?! Дөрес ансы: ул дәрәҗәле галим, танылган белгеч, ә менә аның көннәре, айлары, еллары телгә алырга да оялырлык вак-төяк ыгы-зыгы белән, семья низаглары, квартир гайбәтләре белән, кичә яраксызга чыгарылганны бүген яхшы итеп күрсәтергә тырышкан буш бәхәсләр белән уза. Килешми, оят, хурлык!

Шуларны башка берәр кеше әйтсә, Курмашевның хәтере калыр, бәхәсләшә башлар иде, ә үзе турында ул яхшысын да, яманын да уйлый ала иде. Хәзер әнә шундый уйлар ихтыярына бирелеп киткәч, ул вак-төяк мәшәкатьләрне сылтау итүе өчен үзен-үзе тиргәп утырды, ник дисәң, андый мәшәкатьләр аның төп эшенә комачаулый, эшләгән эшенең азлыгын, ирешергә теләгәне белән ирешкәне арасындагы зур аерманы күрергә мөмкинлек бирмиләр иде.

Хуҗа ханымның диванда яткан кечкенә кызы йокы аралаш шыркылдап көлеп куйды, юрган өстенә салган нәни кулларын селеккәләп алды да тиз-тиз генә нәрсәдер әйтте. Берәр төрле матур төш күреп ята, ахры.

Дания, урыныннан торып, кызының юрганын рәтләде, аннары урындык өстенә газета җәйде дә, туфлиләрен салып, урындыкка оекчан гына менеп басты һәм лампочка өстендәге кәгазь абажурны кызының күзенә якты төшмәслек итеп җайлап куйды.

«Каян килгән аңа бу кыз? Ирдә булып кайткан, күрәсең».

Курмашев Дәүләтшинаның, аяк очларына гына басып, абажурны җайлавын карап торды, үзе теләмәсә дә, хуҗа ханымны — ак челтәр блузкасы аша карасуланып беленеп торган култык астыннан башлап, аяк очларына басып үрелгәч күренеп киткән сыек алсу төстәге юка эчке күлмәк итәгенә, капрон оегын тарттырып куйган каптырмаларына хәтле — күздән кичерергә мәҗбүр булды.

Коньяк пары аның башына китте, ахры, Курмашевның чигәләре кызыша башлады. Хуҗа ханымның таза яшь тәне исе аңа таныш кебек тоелды, шушы минутта, ни хикмәттер, бу хатынны сөясе, иркәлисе килде.

Дания иплән кенә урындыктан сикереп төште дә тиз генә юбка итәкләрен төзәткәләде, Курмашевның күз карашыннан аның үзенә карап торганын сизенде булса кирәк — хатын кызарынып китте.

— Кызым турында сорамакчы буласызмы?— диде ул җәһәт кенә.

— Әйе... Юк, юк.— Курмашев уңайсызланып китте, үзенең дә кызара башлаганын тойды.— Бик сөйкемле кыз. Каян алдыгыз, дигәндәй, э-э-э... әгәр уңайсыз димәсәгез?

Курмашев дулкынланып хуҗа ханымның җавабын көтте. Дәүләтшина гади генә итеп җавап бирде:

— Уңайсыз түгел. Әллә мин иремә яраша алмадым, әллә ул артык үзсүзле булды — килешеп яши алмадык. Ир белән тормыш итү алай ансат эш түгел икән, иң элек, үзеңнән бигрәк, аның турында уйларга кирәк. Без хатын-кыз үзебез турында күбрәк уйлауларын, ирек куюларын, бәйсез булуны телибез бит. Бер-беребезнең тормышын бозып, ел ярым җәфаландык та аерылыштык. Хәзер ул икенчегә өйләнде инде. Минем менә кызым бар. Ярый, боларны куеп торыйк...— диде Дәүләтшина кырысрак бер тавыш белән.— Кешенең үзе алдында аның турында сөйләшмиләр, үзе югында сөйләү — гайбәт була, шулаймы?

— Әйе, шулай, — дип, тиз генә килеште Курмашев, Дәүләтшинаның нык, түземле характерлы булуына исе китте, — әйе, кирәкми шул, — дип куйды. Вакыт шактый соң инде, сөйләшәсе сүз сөйләшенде, кузгалырга

да вакыт, дип уйланды. Әлеге юан апа тыштан караганда гына болай ачык чырайлы булып күренәдер, — түзмәс, иртәгә үк күршеләренә сөйләр: «Минем өйдәшем бер ир ияртеп кайткан иде», — дияр. Шуннан гайбәт таралыр, ә Дәүләтшинаның тормыш итәсе, кызын үстерәсе бар әле. Бәлки иргә дә чыгып куяр. Мондый хатын, теләсә, чыкмый калмас.

Курмашев стаканындагы чәен дә эчеп бетермәде, тиз генә торып, китәргә җыена башлады. Хуҗа ханым кунагының болай капыл кузгалуына гаҗәпләнә калды шикелле, шулай да сүз әйтмәде, аңа бүреген, плащын алып бирде, чоланга, аннары ишегалдына озата чыкканда да бер сүз әйтмәде.

Ай инде күктәге иң биек ноктасына менеп җиткән, кызу-кызу агылган болытлар, җир өстенә караңгылык пәрдәсе бөркеп, айны каплап алгалыйлар, ә ай ачыклыкка килеп чыкканда тирә-юнь яктырып китә, аяк астына җәйгән ташларга хәтле ялтырап күренә.

Дәүләтшина ян капканы үзе ачты, бер мәлгә генә туктады да саубуллашып: «Хушыгыз!» — диде. Курмашев аңа таба борылды һәм шул минутта аның бу яшь ханымны кочып аласы, чәчләреннән сыйпыйсы килде.

— Сез инде минем турыда, ир кеше була торып, кичнең кич буе хатын-кыз турында, мәхәббәт турында бер сүз сөйләшмәде дип уйлыйсыздыр, — диде Курмашев, капка төбендә туктап. Кайтып китәргә туры килүен уйлап кызганып куйды.

— Нигә? Алай дип уйламыйм.

— Әллә мин ул хакта сөйләшә дә алмыйммы?

— Юк. Әгәр сез мәхәббәтегезне белдерә башласагыз — чын түгеллеге шундук сизелер иде, ә бернинди хиссез үзеңне хатын-кызга тәкъдим итү — ул иң элек үзеңне, аннары шул хатын-кызны хөрмәт итмәү булыр иде. Шулай түгелме?

Курмашев аның бу соравына җавап кайтармады, йөрәгендә кинәт туган әлеге дәртне тыярга, бу уңайсыз хәлдән котылырга тырышты. «Акылыңнан яздыңмы әллә, шайтан коткысына бирелдеңме? Нигә кирәк ул?» — дип, эченнән үз-үзен тиргәде. Тыелып кала алмам, коточкыч ахмаклык эшләрмен дип курыкты. Рәсми, коры бер тавыш белән: «Хушыгыз», — дип саубуллашты да капкадан тиз генә чыгып китте.

## 6

Өенә ул соң гына кайтып керде. Хатыны Маһирә ханым, ире ишек ачканны ишеткәч, кухняга чыгып, аш әзерләргә керешә. Суыткычтан бер шешә кефир алды, кишер котлетлары җылытты, өстәлгә каймак куйды, аннары чәй пешерде дә иренең каршысына килеп утырды.

Ашап утырган иренә карап, хатын өй яңалыкларын сөйләргә тотынды.

— Үзебезнекеләргә барып кайттым, — диде Маһирә ханым, тәлинкәгә котлетлар өстәп. — Аша, аша, кишерне яңа гына уган идем, витаминлы. Башта троллейбус белән бардым, аннары — трамвай белән, бер сәгатьтә барып җиттем. Күрәсең, анда да барып кайттым, базарга да кереп чыктым, сине ашатырга да өлгердем!..

Моннан ике ай элек аларның уллары белән киленнәре, өч яшьлек малайларын алып, аерым квартирга күчеп киттеләр. Гомере буе гаилә мәшәкате белән мәш килеп яшәгән Маһирә ханым өйдә ялгыз калуына һич ияләнеп җитә алмый иде әле. Көн буе ялгызлыктан аның эче поша, кич җиткәч исә иренә аш хәзерләргә керешә, аннары аның каршысына килеп утыра да берәр яңалык сөйли башлый.

— Бик уңган хатын син! — дип, Курмашев аны мактаган булды.

Хатын ишетмәгәнгә салышты, үпкәләгән сыман авыр сулады да:

— Ә син килмәдең? — дип куйды.
— Я, шуннан ни булган? Сәгать алтыда эшемне ташлап шәһәрнең бер башыннан икенче башына сөекле балаларым янына ашыгыймммыни? Ничек яшәгәннәрен карармын, берәр ярдәм кирәкмиме дип сорармын. Җибеткә чыгып кефир алып керермен, буш шешәләрен тапшырырмын, идәннәрен юып чыгарырмын...
— Нигә алай дисең?! Кирәк булса тапшырырсың да. Бөтенләй чит кешеләргә дә ярдәм итәләр әле.
Курмашев, хатынының бу сүзенә бер дә исе китмәгән кебек, чәнечке белән котлетын кадап алып:
— Бәлки икәүләп Маркизларын һавага чыгарып та йөртербез? — диде.
— Йөртербез шул. Табылсын гына иде, бичара...
Маркиз дигәннәре гади бер эт иде. Сумала төсле чем-кара йонлы, бик матур ак тәпиле, биеклеккә зур дог чаклы бар, әшәке гадәтләре белән исә гади урам этенә охшаган иде. Ул этне малайлары, бер айлык эш хакы чамасы акча биреп, кулдан сатып алган иде. Маркиз — бик акыллы эт ул, күз карашыннан ук бөтенесен аңлап-сизеп тора, дип мактый иде.
Чыннан да Маркиз гаҗәп сизгер бер эт иде, үзе өчен түләгән акча бәһасенә торырлык иде. Эт үзенең хуҗасы кем икәнен монда килгәч үк сизеп алды, өйдә Аликны гына тыңлый иде, — Алик аны ауга алып чыга, дачага алып бара, — Курмашевка исә Маркиз, аны санламаган шикелле, илтифат та итми, аның каравы, Маһирә ханымны, мыскыллаган кебек, аптыратып бетерә иде.
Төш җитәрәк Маһирә ханым аш пешерергә керештеме, эт, шуны гына көтеп торган кебек, коридор идәненә шып-шып басып кухняга килеп җитә дә бер күзе белән, керфеген дә какмыйча, хуҗа хатынга карый, икенчесе белән «әйдә, киттек!» дигән шикелле ишеккә ымлый.
— Ай, аллам!.. — дип, Маһирә ханым алъяпкычын салып, сызганган җиңнәрен кире төшерә дә тиз-тиз генә этнең муенына каешын тага.
Бичара Маһирә ханым! Гомере буе квартирында хайван асрамаган, хәтта мәчедән дә җирәнгән бер кеше — әнә нишләргә тиеш бит! Ул өйдәге бетмәс-төкәнмәс эшләрне эшли-эшли тупасланып, яргаланып беткән кулларын тиз-тиз генә сөртә дә Маркизны тышка алып чыгып китә. Курмашев, хатынының әнә шул әрсез эт белән җәфалануын күреп, аны кызгана, йөрәге әрни иде.
Маһирә ханым әнә шулай Маркизны тышта йөртә: эт туктап йомышын башкара торган һәр куак төбен белә, «Маркиз, әйдә монда. Хәзер монда. Яхшы, молодец», дип, үзе аны кирәк җиргә әйди. Курмашев, күләргә дә, еларга да белмичә, аларны тәрәзәдән карап тора.
Курмашев хатыныннан, уллары янына барып, Маркизны һавада йөртмәбезме? — дип сорагач, Маһирә ханым иренең үзеннән көлүен аңлады, кашларын җыерды.
— Нигә йөртмәскә?! Чит кеше эте түгел ич — үзебезнеке... — диде.
— Мин йөртмәячәкмен.
— Йөртерсең...
— Юк...
— Йөртерсең...
Курмашев үзе әнә шулай хатыны белән тиргәшеп, малае турында, эт турында сөйләнеп утыра, ә үзенең күңеле, уйлары һаман да шәһәр читендәге теге кечкенә бүлмәле фатир эчендә иде. Кызык инде бу дөнья, нинди генә кешеләре юк аның! Берәүләр яхшы мебель, автомобиль дип хыялланып яши, көне вак-төяк тормыш ыгы-зыгысы белән үтә, икенче берәүләр бирегә башкалар аңламый торган бүтән дөньядан килгән шикелле, аларның тормышы да бөтенләй башка, хыялдагы дөнья шикелле.

Иренең үзсүзлеге Маһирә ханымның ачуын китерде, күрәсең. Аның аш өчен рәхмәт әйткәнен көтеп тормады, савыт-сабаны шалтыр-шолтыр китереп раковинага ташлады да, аларны юмыйча, өсләренә газета тына каплап, йокларга китте.

«Концерт ясадык. Бер-беребезнең нервыларын кайрадык!..» — дип куйды күңеленнән Курмашев, бүгенге кичнең азагы күңелсез бетүен уйлап кухняда шактый озак утырды. — Болай кирәк түгел иде лә! — дип, һаман үз-үзен битәрләде. — Ә ничек кирәк иде соң? Үз сүзеңне бирмәсәң — хатынны җәберләү була, ул теләгәнчә эшләсәң — үзеңә начар».

Ул ничек итәргә тиешлеген ачыклап өлгергәнче, хатыны йокы бүлмәсеннән мендәр, юрган һәм җәймәләр күтәреп чыгып, иренең кабинетына кереп китте. «Болай булгач, бүген аның яныннан ераграк булу яхшырак — зарын-үпкәсен олавы белән чыгарып аударачак».

Маһирә ханым, чәчләрен бигуди белән бөтергән, импортный нәфис эчке күлмәк кигән килеш, арлы-бирле йөргәләде дә, яхшы бикләнгәнме дип, тышкы ишекне тартып карады, аннары кухняга килеп керде. Курмашевны юри үртәгән шикелле, газ краннарын бер ачып, бер ябып маташты.

«Минем ачуны китерергә тырыша, — дип уйлады Курмашев, хатынын күз чите белән генә күзәткәләп.—Кара син аны: пляжда йөримени!»

Хатынының буй-сыны чыннан да әле шактый зифа, тәненең тазалыгы, аклыгы импорт гарнитур аша да сизелеп-беленеп тора. Әгәр аның чәчләре коелып, сирәкләнеп калмаган булса, Маһирә ханымны илле тирәсендәге хатын дип һич әйтә алмассың. Курмашев беренче тапкыр аның аякларына игътибар итте: хатынының аяклары кыска, юан; тубык турысыннан ук башлап озын, сирәк кара төк үскән; таза, йомры кулбашларына коңгырт сипкел бөртекләре чыккан. Боларны моңарчы бер дә искәрмәде микәнни Курмашев?!.

Маһирә ханымның әллә нинди кремнәр сөртеп тә яшәрми торган сулган йөзе, бигудигә бөтереп тә матурланмый торган йолкыш чәчләре, симез кулбашлары, яратышканда да, ачуланышканда да акыл уяулыгын җуймый торган бер кыяфәте Курмашевка никадәр күңел кайтаргыч булып тоелганын хатыны сизсә-белсә икән! Курмашев, бу уйларымны хатын үзе сизмәгәе, дип, эчтән сискәнеп куйды да башын читкә борды.

— Чишенгәч, бөтенләй чишенәсең калган! — дип чәнчеп әйтеп куйды ул.—Миннән уңайсызланмаска да мөмкинме? Мин ир заты түгелме?

Бу сүзләрдән соң Маһирә ханымның чыраена зәһәр ачу чыкты, елап җибәрергә җыенгандай, иреннәре тартыша башлады.

— Ир заты булсаң — карама, артың белән борылып утыр! Мине күргәнең юкмы әллә?!

«И алла, шушы хатынны мин кайчандыр үлеп яраттым микәнни, роза чәчкәсе шикелле итеп телеп апельсиннар ашаттым микәнни, дөньяда миннән дә бәхетле кеше юк, дип уйлап йөрдем микәнни?» — дип пошынып уйланды Курмашев. Аны бик тиз генә яратып китеп, өйләнүен, гомер итә башлауларын бүгенгедәй күз алдына китерде.

## 7

Алтын кул промыселендагы беренче скважиналарда эшләүче бораулаучылар Курмашевны интектергән кебек, Курмашев үзе дә анализ ясаучы лаборант кызларны аптыратып бетерә иде. Тузып, ямьшәеп беткән күн итеген киеп, өсте-башы тәмам таушалган бер кыяфәттә, ул ай азагында базага кайтып төшә дә тәүлекләр буе чыкмыйча лабо-

раторияда ята. Моңарчы әле нефтьле урынга туры килә алмадылар, ике скважина коры булып чыкты; күпме тырышлык, вакыт әрәм булды, ләкин башка урыннардан алган анализлар өметле, күңелне сөендерерлек иде. Озакламый нефть булачак. Тырышлык янына бераз бәхет дигән нәрсә дә өстәлсә — җир астыннан фонтан атачак!

Атар микән соң? Курмашев көн-төн приборлар белән мәш килә, лаборант кызлардан тәүлегенә уникешәр сәгать керн анализлата. Кызлар аның нәрсә таләп иткәнен аңламыйлар, Курмашев исә аларны булдыксызлар дип тирги.

Лаборантлар күп түгел — якын-тирә авыллардан җыйналган яшь кенә биш-алты кыз. Курмашев аларны көч-хәл белән дигәндәй иң гади химик һәм физик анализ хикмәтләренә өйрәтте. Ул аларның берсенә дә арадан аерып артык мөнәсәбәт күрсәтми, берәрсе белән якыннанрак танышу теләге бөтенләй юк, мондый чакта эшкә кагылышы булмаган нәрсә белән мавыгу кирәксез, чит бер шөгыль булып тоела иде.

Билгеле инде, лаборант кызлар да аның мөнәсәбәтенә күрә үзләренчә мөнәсәбәт күрсәтәләр: ул барында артык сөйләшмиләр, эш белән шөгыльләнгән булып кыланалар, Курмашевка яулык астыннан куркып кына күз салалар. Шуңа күрә бу кызлар Курмашевка барысы да бертөсле — вакытыннан иртә картая, сула башлаган кызыксыз кыяфәтле сыман күренәләр иде.

Бервакыт ул лабораториядә кызларның җырлаганын ишетте. Ул көнне Курмашевның ерактагы буровойдан кайтып килеше иде, озын барак коридоры буйлап конторга житкәч, лаборатория ишеген ачыйм дигәндә генә җырлаган тавыш ишетте...

Курмашев матур җырлаучыларны ярата, җыр хисенә бирелмичә, кыланчыкланып кына җырлаучы түгел, бәлки ихлас күңелдән җырлыйсы килеп җырлаучыларны ярата иде. Ул, токага кулын куйгач, ишекне ачыйм дигәндә генә абайлап алды: әгәр хәзер ул бүлмәгә килеп керсә, кызлар, галим начальникларыннан уңайсызланып, җырлаудан туктаячаклар. Аның алдында җырлыймы соң инде алар!

Курмашев, җырга сокланып, кулын ишек токасыннан алды да тыңлап тора башлады, җыр моңына бирелеп, гади кеше тавышының сафлыгына, тылсымлы көченә исе китеп, ишек төбендә шактый озак басып торды. Ә лабораториядә җыр кызганнан-кыза бара иде: моңлы җырны җиңел, шаян җыр алмаштырды, аннары янадан моңлы, озын көй сузып, кызның сөйгән егетен сугышка озатуы, аның исән-сау әйләнеп кайтуын көтүе турында җырларга керештеләр.

Моннан соң инде Курмашев лабораториягә тиктомалдан йомышсыз кереп йөрүдән тыелды, ишек төбендә туктап кына кызларның сагышлы җырын тыңлый торган булды. Мондый минутларда аның ничектер күңеле йомшарып китә, үз-үзенә ышанычы арта, үзенә йөкләнгән эшне башкарып чыгасына шикләнми, тик мәлҗерәп төшмәскә, эшләргә дә эшләргә кирәк, монда, тылда да, атыш-үтереш булмаса да, шул ук сугыш, шул ук алгы сызык, дип уйлый.

Тик көннәрдән бер көнне әлеге җыр юкка чыкты. Дөресен әйткәндә, бөтенләй үк юкка чыкмады, лабораториядә кызлар һаман җырлыйлар, тик аларның җыры ничектер күңел кылларын чиртми, моң үсеп көчәеп җитмәстән сүнеп-сүрелеп кала иде.

— Ник җырламыйсыз? Әллә күңелсезме? — дип сорады Курмашев кызлардан.

— Булдырып булмый. Иң баш җырчыбыз юк, — дип җавап бирде өлкән лаборантка.

— Эштән киттеме әллә?

— Авырып китте. Үпкәсенә салкын тидергән, йөткерә башлады.

— Бүлмәгездә җил уйныймы әллә? Алай дисәң, тәрәзәләрегез ябыштырылган ич.

— Монда түгел, җәяүләп керн алырга барган иде, буранга эләгеп, бик каты туңган. Больниска салдылар. Хәле әйбәтләнә инде, озаклап тазарып чыгачак.

— Нигә буранда йөрергә инде? Нигә хаҗәт ул кадәр? — диде Курмашев, җилкәсен сикертеп.

Ул әлеге авырып киткән кызны күз алдына китерергә тырышты, тик аның нечкә, саф, көчле тавышын гына хәтерләде. Атна буе нишләргә белмичә борчылып йөрде дә якшәмбе көнне иртүк базарга китте, өч кисәк шикәр, бер бөтен такта чәй сатып алды. Аннары, һич уйламаган җирдән, күзенә кызгылт-сары зур гына апельсин чалынды — бер атналык икмәк карточкасына алмаштырып шул апельсинны да алды...

Больница бер катлы агач йортка урнашкан, эчтән такта белән урталай бүлеп, бер ягын ирләрнеке, икенче ягын хатын-кызларныкы иткәннәр. Курмашев, рөхсәт сорап, хатын-кызлар ягына килеп кергәч тәрәзә кырыеннан башлап тиз-тиз генә койкаларга күз йөртеп чыкты. Палата эче тып-тын: авырулар барысы да гаҗәпләнеп аңа төбәлгәннәр, каян килгән бу кадәр яшь, чибәр, таза егет? — дип уйладылар булса кирәк.

Авырулар арасыннан үзенә кирәк кызны таба алмыйча чыгарга җыенганда гына Курмашев арадан берәүнең үзенә текәлеп караганын тойды. Әйләнеп караса, ишек янындагы иң кырый койкада үзенең лаборант кызын күрде.

Кыз Курмашевны болай бөтенләй көтмәгәндә больницага килеп керер дип уйламаган иде, ахры — битләре кызарып китте, күзен кыса төште, керфекләре тетрәнеп куйды.

Палатада буш урындыклар юк икән, шуңа күрә Курмашев, каты, авыр матрасның кырыен күтәрә төшеп, койка читенә утырды. Лаборант кыз одеялын тиз генә иягенә хәтле тартып куйды. Әйтерсең Курмашев аның одеялын алып китәргә җыена!

Курмашев ни сорашырга, сүзне нидән башларга белмичә бераз каушабрак калды, шулай да үзен бик тиз кулга алды, шикәр белән чәйне тумбочкага куйды да апельсинны кызга сузды.

— Мә, тот, сиңа бу! Моны ашасаң — бернинди сырхавың калмас, — диде.

Билгеле инде, бөтен палатаның күзе аларда иде. Кыз моңарчы бер тапкыр да рәтләп сөйләшкәне булмаган ир кешедән мондый илтифат көтмәгән иде, күрәсең — бик уңайсызланды, битләренә сизелерсизелмәс алсу таплар йөгерде. Курмашев аңа апельсин сузган, кыз: «Юк, юк, кирәкми», дип башын селкә, курыккан шикелле, койка читенәрәк шуыша, башкаларның карап торуыннан уңайсызланып, оялып, һаман кызара бара иде.

— Мә инде, тот, тот. Бәлки мине синең яныңа профсоюз җибәргәндер? Син бит эштә авырып киткәнсең! Җәмәгатьчелек сиңа илтифат күрсәтергә тиеш.

Лаборант кыз койкасының икенче кырыена ук шуышты, әмма одеалы кыскарак булып чыкты — иягенә хәтле тартса, аяклары ачыла иде. Курмашев күзенә кыз өстендәге больница күлмәгенең якасы, төймә урынына бәйләп куя торган тасмалары чалынды. Шунда кызның күзенә карап, аның гомерендә әле бер тапкыр да апельсин күрмәгәнлеген, аны ничек ашарга икәнлеген белмәвен, шуңа уңайсызлануын аңлап алды. Менә сиңа хикмәт түгел диген!

Ә палатаның күзе һаман боларда, нәрсә булыр икән дип күзәтеп торалар.

— Менә кара — нинди нәрсә ясыйбыз хәзер без әфлисуннан. Роза ясыйммы? — диде Курмашев шаян, көр тавыш белән.

Кыз, апельсинын кесәсенә кире салып куяр да мине бу уңайсызлыктан коткарыр дип уйлады булса кирәк, ризалык белгертеп баш какты.

Курмашев кесәсеннән пәке чыгарды да апельсинның кабыгын тиз-тиз кисеп, таҗ яфрагы шикелле сигез кисәккә аерды — кабык эченнән аксыл-сары элпәле җимеше килеп чыкты. Ниндидер җәйге кояшлы көннәрдә була торган татлы, нәфис бер ис таралды, палата эче җылынып, рәхәтрәк булып киткән кебек тоелды. Курмашев апельсинны өлешләргә аергалады да бер кисәген үзе капты, икенчесен кызга бирде, калганнарын палатадагы башка авыруларга өләште.

— Нишләп авырып киттең әле син? — дип шелтәләгән булды ул кызны. — Авырырга ярамый, эшләргә кирәк. Нигә кернны шулай күтәреп кайттың. Бураннан соң да өлгергән булыр иден әле.

— Соңгарырга ярамый, диделәр. Балчыгы бозыла да проба яраксызга әйләнә... — Кыз шулай диде дә беравык тынып торды, шуннан соң пышылдап диярлек әйтеп куйды: — Аннары сез ачуланырсыз дип курыктым...

Курмашевка әле генә шундый гозер-шелтә белән юаш кына караган күк күзләр хәзер инде, рәхмәт белдереп, ягымлы нур сирпеп торалар иде.

— Кем әйтте аны, юләр?

— Буровойда шулай диделәр.

— Шәрифуллинмы?

— Әйе.

— Ә син шуңа ышандыңмы?

Әлбәттә, бораулаучылар кызны шаяртканнар, вакытында кайтып житмәсәң, пробалар бозылачак, әрәм булачак, аннары усал начальник Курмашев үзеңнең тетмәңне тетәчәк, дигәннәр. Ә бу, беркатлы, алар сүзенә ышанган да, керн салган тартманы җилкәсенә күтәреп, юлга чыккан.

Курмашев өстенә сырма, аягына иске киез итек кигән, башына шәл ураган бу кызның кар ера-ера, егыла-тора базага кайтуын күз алдына китерде. Курмашев аркасында шулай җәфа чиккән бит ул! Шуны уйлагач, аның ничектер йөрәге эреп, рәхәтләнеп киткән кебек булды, аны-моны уйлап тормастан, шушы кызга өйләнәсе килде. Ә нигә өйләнмәскә? Аңа хәзер егерме сигез яшь бит инде, язылышырлар да бергә тормыш итә башларлар. Сугыш беткәч, хатыны укырга китәр, институтка, я булмаса консерваториягә керер — әнә нинди матур җырлый бит ул, андый тавыш артисткаларда да юк! Алар бер-берсен бик яратып, гомер буе бәхетле яшәрләр...

*

* *

Дөнья дигәнең шул хәтле дә тиз үзгәрә икән! Ул вакытта, Курмашев хакына карга-көрткә бата-чума, буранда керн күтәреп кайткан, больница койкасында апельсинны ничек ашарга икәнен белмичә аптырап-уңайсызланып яткан оялчан, юаш кыз шушы Мәһирә ханым булдымы икән соң?!

Курмашевның танышлары, хезмәттәшләре аңа, хатыннан бик уңгансың, диләр. Ул алар фикеренә кушыла. Әйе, Мәһирә ханым булмаса, Курмашев тормышта ирешкәннәрнең уннан берен дә эшли алмаган булыр иде.

Чыннан да, аңа дан-дәрәҗә китергән хезмәтендә эшләргә комачауларлык нинди тормыш мәшәкатьләре булды соң? Ул бер кап тозның ничә тиен торганын, квартир хакын кая барып түләргә кирәклеген белмәде, гомерендә бер тапкыр чалбар үтүкләгәне булмады.

Хатыны йорт идарәсенә барып андагы хуҗалар белән эш йөртә, җәй көне үк слесарьлар китертеп, җылыткыч батареяларны тикшертә, иренең кулъязмаларын машинисткаларга бастырырга илтә, хаталы итеп бассалар, бите-бите, бүлеге-бүлеге белән яңадан эшләтә һәм аның өчен бер тиен дә акча түләми. Әгәр Курмашевның берәр җиргә китәсе булса, поездга яки самолетка билетны Маһирә ханым үзе юнәтә иде...

Уллары өйләнеп, йортка килен төшергәч (киленнәре тормыш итәргә өйрәнмәгән бер аспирант кыз иде), Маһирә ханым дача йортларына мансард кору теләге белән янып яши башлады. Курмашевның коты очты! Бар икән кураселәрем, бик кирәк мәшәкать иде! — дип хафага калды.

Ләкин хатыны бу юлы да аны борчымады. Кибетләргә чаба-чаба кадак, пыяла, буяу юнәтте, ниндидер фабрикага барып — каян башы җиткән диген! — арзан гына хакка зур-зур ящиклар китертте, шул ящиклардан әйбәт кенә такталар чыкты.

Сәләтеннән килсә, балта, ышкы эшләренә дә Маһирә ханым үзе керешкән булыр иде дә, нишлисең бит, хатын-кызга ходай андый сәләт биреп җиткермәгән. Хатыны бу мәсьәләдә дә аптырап калмады: каяндыр балта осталары — кайчан карама, салмыш баштан йөри торган шабашникларны тапты. Тегеләр иртүк бер яртылык акча сорый башласалар, Маһирә ханым аларны тетеп тирги иде. Алай да җиңә алмагач, ул әлеге осталарны исәп-хисап ясаганда яртыга дип алган акчаларны тотып калачакмын дип кисәтеп куйды. Шуннан соң инде тегеләр дә аңа ялынмас булдылар, эчүне бөтенләй ташлаганнардырмыюкмы — анысын шайтан белсен. Ләкин шуннан ары яртылык акча сорап интектермәделәр.

Әнә шундый эшләрнең рәтен-юлын белә торган Маһирә ханым көннәрдән бер көнне ниндидер бер буфетчы хатын белән танышып кайткан. Шуннан соң инде өйдә табынга гел бәйрәм ашлары гына куела башлады. Бер көнне иртән Маһирә ханым өстәлгә кара икра белән май, күмәч куйса, икенче көнне иртән тозлаган сөләйман балыгы, осетр сырты китерә, төшкә лангет, анар соусы белән бастырма, яки парда гына пешереп йомшак бозау ите хәзерли, кичкә савытта томалап кына боҗыр яисә куян ите пешерә иде. Бер тапкыр ул өйдәгеләрне омар дигән әкәмәт белән дә шаккатырды. Кичке аш алдыннан ул иренә бер фужер «Гурҗани» яки «Цинандали» дигән затлы шәраб эчертә, малаена исә бер рюмка «Столичный» салып бирә.

Ул вакытта әле алар уллары белән бергә яшиләр иде. Шунда уллары Алик түзмәде — әйтеп куйды:

— О-о, бездә хәзер көн саен бәйрәм! — диде.

Маһирә ханым, бу мактаудан бик канәгать булып, хәтта беразкызарып китте, ләкин тыштан сиздермәде, киресенчә әле, мактаучыны шелтәләгән булды:

— Бәйрәм итеп утырма син, ашавыңны бел. Юкса, кыяфәтең шүрәленеке кебек! — диде. Үзе исә өй эчендә атна буе кала алган батыр кебек йөрде.

Бервакыт Маһирә ханым бер атналап больницада ятты — аның баш өянәге кузгалган иде. Шунда инде Курмашев өйләрендәге бәйрәмнең каян килгәнлеген белде.

Эштән соң аларга Курмашевлар институты күршесендәге ашханәдә эшләүче буфетчы хатын керде. Ул үз өенә кайткан кебек килеп керде дә, кухняга үтеп, зур гына сумка куеп чыкты.

— Рәхим итеп алыгыз. Алтмыш ике сум да егерме дүрт тиенлек. Аннары... мәшәкате өчен дә азрак өстәрсез... — диде.

— Нәрсә ул? Нинди мәшәкать? — дип сорады Курмашев, берни төшенмичә.

— Ике банка кызыл икра, бер кило белуга, бүген генә суйган сыер

ите, кофе, бер шешә вино. Маһирә ханымга әйтерсез: вобла юк, китермәделәр. Ачуланмасын инде. Сумканы кайтарырга онытмассыз.

— Мин төшке аш вакытында буфетка кергән идем, анда бер дә мондый нәрсәләр күренмәгән иде бит, — диде Курмашев, өйләрендәге бәйрәмнең каян килгәнен төшенә башлап. — Дуңгыз сарделькасы белән кәбестә винегретыннан башка нәрсә юк иде...

— Сезгә чит ил туристларын ашата торган буфетка керергә иде.

— Мин бит чит ил туристы түгел!

Курмашев, буфетчы хатынга рәхмәт әйтеп, китергән мәшәкате өчен ун сум акча чыгарып бирде, аннары, сумкагызны алып китегез, моннан ары мондый нәрсәләр китереп йөрмәгез, диде. Шуның белән өйдә бәйрәм дә бетте.

Элегрәк, Маһирә ханым ире турында гына кайгырткан чакта, Курмашевка бик рәхәт иде. Хатыны нәрсә генә эшләсә дә, Курмашевка ошый, Маһирәсе гел сөйкемле, әйбәт булып күренә. Күңеленнән хатынына рәхмәт укып: «Чын йорт хуҗасы!» — дип уйлап куя, шундый булдыклы тормыш иптәше туры килүенә сөенеп бетә алмый иде. Маһирә ханым бары тик ире тормышы белән генә яши, башканы бар дип тә белми иде.

Ләкин еллар үтү белән Маһирә ханым үзгәрде, безнең гомер узды инде дип карый торган булды, элек нинди зур тырышлык белән иренең күңелен күргән, теләген үтәгән булса, хәзер әллә нинди юк сәбәпләр табып аны борчый, мәшәкатьли башлады: әле кибеткә барып кайтырга куша, әле танышларына кунакка алып китә, базарга ияртеп бара. Шулай итеп, Курмашевның көннәре, айлары бөтен гомерен багышлаган эшенә бернинди бәйләнеше булмаган вак-төяк тормыш мәшәкатьләре белән тула.

Ул хатынының әнә шундый бәйләнүләреннән, кешеләр алдында тату, әйбәт яшәгән булып күренергә тырышуларыннан тәмам туйса да, берни хәл кыла алмый, ихтыярыннан тыш, тормыш агымы аны үзе белән ияртеп агызып бара, бер урында туктап торырга ирек бирми иде.

Ул элеккечә күп эшли, хәтта бәйрәм, ял көннәрен дә шуңа багышлый, күбесенчә кич утырып эшли, тик шулай да элекке кебек ашкынып, дәртләнеп, бирелеп эшләү юк шул инде.

... Ә менә бүген хәл башкача булды, үзе дә көтмәгәндә, аңарда ниндидер бер каршылык көче туды, әллә ни зур нәрсәгә ирешмәсә дә, хатынына баш бирмәвенә, үз сүзендә торуына горурланды. Маһирә ханым юылмаган савыт-сабаны ачу белән раковинага катырак ташлагаен саен, Курмашевның да, хатыны әйткәнчә түгел, бәлки үз күңеле кушканча эшләргә теләве көчәя генә барды.

Менә хикмәт: күңел дигәнең бик аздан да үсеп китә икән! Кечкенә генә, юк кына бер эштән дә үзен биек тау түбәсенә менгән кебек хис итте.

Ачуы кузгалган Маһирә ханым, эчке күлмәктән генә килеш, кабинетка мендәр, юрган, җәймәләр кертеп ташлагач, Курмашев бүген хатынының ачуы кайтмаячагын, ялгызы гына иске каты диванда йокларга туры киләчәген төшенде. Хатыны үпкәләсә үпкәләр! Бу хәлгә Курмашевның җаны борчылмый, киресенчә, тынычлана гына бара иде.

## 8

Курмашев гадәттә тиз генә йоклап китә алмый иде. Башка көннәрне ул, йокыга киткәнче, ашыкмыйча гына берәр нәрсә турында уйланып ята, бүген исә уйларының бер дә рәте-чираты булмады, күңеленә әле бер уй, әле икенче, әле өченчесе килеп керде. Бүген ул уйламаганда-көтмәгәндә күңелендә туган яңа кичерешләрен аныкларга

тырышты, гадәттәге җан тынычлыгы югалуына пошынып ятты, үзен көчләп булса да, Дәүләтшина белән булган хәлне онытырга тырышты.

Әлеге диссертациягә хәтле аның тормышында аңлашылмаслык, четерекле бер нәрсә дә юк иде. Кыенлыклар элек тә булгаламады түгел — ансыз тормыш буламыни?! — ләкин иң мөһиме шул: төп мәсьәләдә ул үзен хаклы дип саный иде. Әлбәттә, егерме ел буена инде аның ачышына күнегеп, гадәтләнеп беттеләр, ләкин, бүгенге «кара алтын» шәһәрләре Курмашев катнашыннан башка гына барлыкка килде, дип әйтергә кемнең намусы җитәр? Киләчәктә, яңа техник шартлар тугач, ул тапкан ысулны төзәтәчәкләрен, хәтта бөтенләй юкка чыгарулары ихтималын да белә, әмма бу кадәр үк тиз булыр дип уйламый иде.

Шәһәр манарасындагы сәгать шаң-шоң итеп сугарга кереште. Сәгать суккан саен манара ташлары алланып янып китә һәм бүлмә эченә дә алсу шәүләләр төшә. Курмашев шул манара утының алсу шәүләсе нинди мизгелдә бүлмә эченә төшүен чамаларга тырышып ятты, һәм чамасы гел соңгарак калды. Шуңа аның ачуы килде, һаман тынычлана алмады. Ахыр чиктә, сабыры бетеп, урыныннан торды да тәрәзә каршына килде, манарадагы сәгатькә карап, ташларның яңадан яктыруын көтә башлады. Ләкин сәгать инде сугудан туктаган иде, күрәсең — манарадагы алсу утлар кабынмады.

Курмашев, ачуы килеп, авыз эченнән генә тиргәнеп куйды һәм шунда үзенең Дания Дәүләтшинаны уйлаганлыгын искәрде. Хәзер инде ул Дәүләтшина турында кичен урамнан бергә барганда, аның бүлмәсендә икәү чәй эчеп утырганда һәм капка төбенә озата чыккан чактагыча уйламый, бәлки саф акыл белән аңа соклана, аны гел яхшы итеп кенә күрә иде.

Курмашев бу уйларын икърар итәргә теләми, әмма Дәүләтшинадан көнләшкәнлеген, бүген диссертациясен яклый алмаган яшь аспирант хатын урынында улым Алик булса иде, дип теләгәнен сизә. Юк, ул улының кемнәрнеңдер ярдәме белән этә-төртә дигәндәй диссертация яклавын теләми, ул да Дәүләтшина шикелле яклый алмасын, беренче булып әтисе каршы чыксын. Барыннан да бигрәге — аның улында да Дания Дәүләтшина характеры булсын иде, ни өчен, нинди максат хакына яшәгәнен белсен иде. Уйланырлык та шул: икесе дә бер яшьтә, сугыштан соң туып үскәннәр, бер үк вакытта укыганнар, ә бер-берсенә тамчы да охшамаганнар. Күк белән җир аермасы кебек!

Курмашевның улы турында гел яхшыны гына уйлыйсы килә, ә хәтер дигәнең, үч иткән кебек, гел начарны гына искә төшерә иде.

*

* *

Уллары Алик өйгә Маркизны алып кайткач, зур гына тавыш булып алды. Алар арасында вак-төяк ачуланышу элек тә булгалый торган иде, ләкин бу юлы сүз шактый зурдан купты.

— Беләсеңме, әти, мин үзем кешеләрне өч төргә бүләм, — диде Алик.

— Кызык. Я, нинди өч төр ул?

— Беренчеләре — иң күп эшләүчеләр һәм, гаҗәпкә каршы, иң бәхетсез кешеләр. Алар бервакытта да канәгать-риза түгелләр, үз-үзләрен азаплыйлар, интектерәләр, күпме эшләсәләр дә, һаман аз, һаман аз, диләр. Шулаймы?

— Я, шулай булсын. Тагын?

— Икенчеләре гомум мохит эчендә аерылып тормыйлар, алар — масса, алар — титаннарны җилкәләре белән күтәреп торучы таш кантары. Болары иң гади, иң аз нәрсәдән дә бәхет таба беләләр.

— Өченче төре кемнәр инде? — дип сорады Курмашев, улының үзен кайсы төргә кертүен белергә тырышып.

— Өченчеләре — эчкече, алдакчы кешеләр, зур караклар, карьеристлар, тагы әллә кемнәр!..

— Үзең кайсы төргә керәсең инде син?

— Минме?.. Икенче төргә керәм бугай. Мин беренчеләр дәрәҗәсенә күтәрелә алмыйм, анда омтылмыйм да, сәләтем дә җитәрлек түгел, ә гомум масса арасына сыям. Иң кирәге — башкалардан аерылып торырга тырышмау: бик алга да чыкма, артка да калма. Этсәләр-төртсәләр — егылабыз, торгызсалар — атлап китәбез!

— Син үзеңне икенче төрдән өченчегә якынрак дип уйламыйсыңмы?

— Юк, уйламыйм...

Курмашев бу сүзгә улының ачуы килер дә бүтән сөйләшмәс дип уйлаган иде, ләкин Алик, берни булмаган кебек, сүзен дәвам итте:

— Мин бит, эти, синең нәрсәгә азапланганыңны күреп торам. Мин күктәге йолдызга үрелмим, башкалардан алгарак атылып чыгарга омтылмыйм. Нигә кирәк? Мин эшемә соңга калмыйм, исерекләр айныткычына да эләкмим. Минем тормыш графигым шул: эшләгәннән соң — әйбәтләп ял итү, ял иткәннән соң — кирәк кадәренчә эшләү.

— Эшләүгә караганда яхшырак ял итәсең син.

— Мине эгоист димәкче буласыңмы?

— Әйе.

— Бәлки шулайдыр. Әни белән сез икегез эгоистлар түгелмени? Институт бетергәннән соң нигә мине Норильскига җибәрмәдегез? Миңа яхшылык теләгәнгәме? Үзегез өчен ул! Кадерле балакаебыз салкын төньякта ни хәлдә яши икән, туңмый микән, җиләк-җимеш ашый микән? — дип борчылып торган булыр идегез. Мине эшкә билгеләгән вакытта начальство тирәсендә ничек йөргәнеңне хәтерлисенме? Институт завхозыннан башлап, ректорга кадәр барып җиттең. Төньякта мин бәлки бернигә торгысыз начар белгеч тә, чыдамсыз кеше дә булырмын, ләкин ул профессор Курмашев малаена биргән бәя түгел, үземә биргән бәя булыр иде. Мин өйләнгәч, нигә сез безгә частный квартирга чыгарга рөхсәт итмәдегез? «Юк, юк, безнең белән торыгыз, безнең күп яшисе калмаган инде!» — дидегез.

Алик әтисен үртәргә тырышып сөйләнә иде. Курмашев аның тавышыннан шул кадәр усал, мыскыллы көлү сизеп, коты очты. Шушындый усаллыкның тамчысы гына булса да аңа алардан — әти-әнисеннән күчте микән соң?

Курмашев аңа: «Җитте, тукта!» — дип кычкырырга теләде, шулай да тыелып калды, чөнки малаеның ниндилеген күреп торуы аңа бик кызык иде: Курмашев бит аны дөньяга тудырып кына калмаган, кеше итүгә дә катнашкан.

Ул малаеның сүзләрен тыңлап торганда гадәтенчә һәр җөмләсен мәгънәсе буенча киштәләргә сала барды: фактларын бер якка, фикерләрен икенче якка аерды. Улының сүзләрендә дөреслек барын сизсә дә, аны икърар итәргә дә, кире кагарга да теләмәде.

Шул вакыт бүлмәгә нечкә буйлы, юка гына гәүдәле киленнәре килеп керде. Ул алдан да, арттан да бер җыерчыксыз булып тартылып торган чалбар кигән иде. Килен аларның сөйләшкәнен ишек артында тыңлап торган, күрәсең, моның өчен бер дә уңайсызланмыйча, гафу да үтенмичә, ирен якларга тотынды:

— Әлбәттә, без монда квартирант хәлендә яшибез! Теге вакытта частныйга чыккан булсак, хәзер үзебезгә квартир биргән булырлар иде.

Курмашев:

— Ник китмәдегез соң, эти-әни квартирына ышанып калдыгызмы? — дип башлаган иде дә, кулын гына селекте. — Яхшы, квартирны бүлербез. Безгә ике бүлмә, сезгә — ике, юк, сезгә өч бүлмә бирербез, үзегез теләгәнчә яшәрсез, эти-әнидән башка гына!

— Менә син тагын үзеңчә «яхшырак булсын» дип тырышасың инде. Башкаларның андый «яхшылыкка» ирешергә хәленнән килмимени?

Малаеның бик нык ачуы килгән, сырт йоннары кабарган иде — менә хәзер усал сүзләр әйтеп чәнчә-чага башлар дип торганда, ул кинәт үзгәреп куйды — җилкәләрен салындырды да, исе китмәгәндәй кул селтәп:

— Әй, теләсәгез ничек итегез! Безгә барыбер... — диде.

...Курмашев хәзер, ата кеше буларак, улы турында уңай яктан гына уйларга тырышты. Улы Аликта яхшы сыйфатлар бар иде бит, тик хәтергә генә килми, шайтан алгыры. Ә хәзер, аның ихтыярыннан тыш, малаеның телгә алып сөйләү түгел, хәтердә сакларга да оят булган начар яклары гына искә төшә иде.

Теге сәгатьнең инде яңадан сукканы ишетелмәде, әле вакыты җитми иде, күрәсең, манарада кызыл ут та кабынмый иде. Курмашев, сәгатьнең механизмына бер-бер хәл булгандыр: я туктагандыр, я башка берәр сәбәптер, дип уйлады. Үз фаразына үзе ышанып, сабый бала кебек, тынычлана калды, үзе өчен хәзер һәр мизгел — бер сәгать, һәр сәгать — бер көн булып тоелганлыгын уена китермәде.

Йокысызлыктан тәмам алҗыгач, ул йокы бүлмәсенә кереп, андагы трельяж тартмасыннан элениум таблеткасы алып йотарга уйлады. Әмма ул бүлмәгә керергә күңеле тартмады. Хатынының йокламаганлыгын, аңа ачу саклап ятканын ул тәгаен белә иде, шуңа күрә, кухнядагы аптека тартмасында әрем суы барлыгы исенә төшкәч, шуның белән генә канәгатьләнергә булды. Ярамаганмыни? Башка дарулар шикелле, бу да әче бер нәрсә бит!

Маһирә ханым иң яхшы даруларны аптека белгечләре түгел, ә табигать үзе ясый дип ышана, тик төрле тамыр, яфракларны иренмичә вакытында җыярга гына кирәк, аннары кешеләргә поликлиникаларның, докторларның кирәге дә калмый. Врачлар авыруларга аптекада үлән яфракларыннан, үлән тамырларыннан ясалган шул ук даруларны язып бирәләр ләбаса, дип уйлый ул.

Беренче язгы җылы көннәр җитү белән Маһирә ханым урманнарга бара башлый, Зөя, Мишә, Идел буендагы болыннарга хәтле барып чыга. Көз җиткәнче әнә шулай өй белән ике арада мәш килә. Кар төшү белән нарат җиләге яфраклары җыя, ә август кергәч, шуның җимешләрен җыеп кайта, кычыткан, яшь юкә бөреләре хәзерләп куя, әллә ничә төрле әрем һәм әрекмән киптерә...

Өйдәгеләрнең берәрсе төчкерә, аппетитым юк, башым авырта, дип зарлана башладымы — Маһирә ханым шундук даруын күтәреп килеп тә җитә. Аппетитың булмаса, алой суы бирә, йокысызлыктан интексәң, әрем суы эчертә, баш пеләшләнгәннән әрекмән тәкъдим итә... Гомумән, йөзләгән дәва белә ул.

Маһирә ханымның табиплык сәләтен шәһәрдә байтак кеше белә иде, күрәсең, аның төрле авыру, дарулар турында туктаусыз сөйләшә торган танышлары бик күп иде. Курмашев өйдәге кабинетында эшләп утырганда кайвакыт аларның кешедәге төрле авыру-чир турында сөйләшүләрен ишетә дә, минем хатын бу кешеләр өчен бик зур авторитет булса кирәк, дип уйлап куя. Өйдә әледән-әле телефон шалтырап, сары мәтрүшкәне ничек кайнатырга, йоклар алдыннан кайнар сөт белән балны күпме эчәргә, буйга узмас өчен горчичникны кай төшкә куяргга? дип сорыйлар.

Беркөнне Курмашев кухняда хатыннарның сөйләшүләренә колак салды: алар ирләрнең рәте китүе мәсьәләсен тикшерәләр, олыгаю ягын гына түгел, ирләр белән хатыннар арасындагы характер, психика үзгәлеген дә шактый нечкәләп сөйләшәләр иде. Төскә-биткә әле ярыйсы гына яшь чырайлы бер хатын Маһирә ханымга, ирем белән торуыбыз-

ның рәте китте әле, дип зарланып утыра иде. Ире диванда аерым йокларга гадәтләнеп бара икән.

— Син аңа суган күбрәк ашат, суган!. Менә күрерсең — диванын бик тиз онытыр!

— Онытмас! Мин аны диванында юри йоклатып саргайтам әле!

Аларның сөйләшүен тыңлап торганда Курмашевның эче катып көләсе килде, шулай да тыелды, үзен сиздермәде. Кунак хатын киткәннән соң инде, ул үз хатынына шелтә белән әйтә куйды:

— Карале, нигә син кешеләрне ялгыш эшкә үгетлисең? Бәлки врачка, белгечкә күренергә кирәктер аларга...

Мәһирә ханымның бу сүзгә хәтере калды, битләре тимгелләнеп кызарып китте. Ул, ачу белән иреннәрен кысып, үлән дарулары саклана торган шкафын ачты да аннан калын гына китап алып:

— Син генә белдекле инде, синең генә башың акыллы! Беләсеңме җир йөзендә ничә төрле үлән бар? — дип сорады.

— Мин бит ботаник түгел. Бик күптер.

— Нервы тынычландыра торганы — йөз дә биш, авыртуны баса торганы — ике йөз дә унсигез, эчне йомшарта торганы йөз дә кырык алты, бәвел куа торганы — ике йөз дә кырык ике, баш авырткаңнан — алтмыш өч... Санап бетерә торган түгел!..

Мәһирә ханым, китабына карамыйча гына, кирәкле битне ачты да:

— Менә, мә, укы! Тиктомалга гына язмаганнардыр моны, — дип, китапны иренә сузды.

Курмашев китапны кулына алып, тиражын, кайда басылганлыгын, бәясен карады, китапның Мәскәүдә чыкканлыгына игътибар итте, авторы — гыйльми дәрәҗәле кеше икән, рәсемнәр, төрле таблицалар белән, бик әйбәт итеп җитмеш мең данә чыгарганнар. Бәясе дә ярыйсы — өч сум. Хатынының күңелен күрер өчен, ул иҗекләп диярлек: «Яшел суган зәңгелә авыруыннан һәм импотенциядән файдалы» дигән сүзләрне кычкырып укыды да:

— Җиңелдем, җиңелдем, син — молодец! — диде.

— Молодец, имеш! — дигән булды Мәһирә ханым һәм, җай чыккаңнан файдаланып, иренә суктырып әйтте: — Суган ашау сиңа да зарар итмәс иде!..

Курмашев, кухняга чыгып, әче әрем суын бер тапкыр эчте, аннары тагын бер эчте, өченче тапкыр салмакчы иде дә, ике дозаның файдасы тимәсә, өченчесеннән файда булмас дип, артыгын эчмәскә уйлады.

Дөрес чамалаган икән шул! Әрем суы эчкәнгә карап, күзгә йокы төшмәде. Курмашев, каты диванда әле бер ягына, әле икенче ягына әйләнгәләп, ничәнче тапкыр инде эшендәге көйсезлекләр, бүгенге теге ни... теге... кем әле... Дания Дәүләтшинаның диссертациясе үтмәве турында уйланды...

Кызык: шушы минутта ни уйлый икән ул хатын? Йоклыймы, диссертациясен яклый алмавы өчен борчылып-ут йотып ятамы, әллә Курмашев белән икәү урам буйлап атлауларын, чәй, коньяк эчүләрен күз алдына китереп уйланып ятамы?..

Табигать дигәннәре кешеләрне ике төргә бүлеп дөрес эшли микән? Берәүләр вак-төяк дөнья мәшәкатьләрен яратмыйлар, матди як белән һич яраша алмый торган югары хыяллар белән яшиләр. Дөньяны үз җилкәләрендә күтәреп торучы титаннар түгел, бәлки вак пигмейләр яшәү рәхәтен күбрәк татый. Алар башка кешеләр өчен үзләреннән берни дә бирмиләр, киресенчә, үзләренә күбрәк алырга тырышалар. Моцартны ярлылар зиратына җирләгәннәр. Мусоргскийны, гади бер деньщик дип, солдат больницасында дәвалаганнар. Тукай сасы бер кунакханәдә чахоткадан авырып үлгән... Левитан, Крамской, Рембрандтлар тормышларында нинди рәхәт күргәннәр? Алар искиткеч сәнгать җәүһәрләре иҗат итеп калдырган, кешеләр ул җәүһәрләрнең бәһасен бер-

кайчан да кайтарып бетерә алмаячаклар, ә алар фәкыйрьлектә үлгәннәр, торыр йортлары, ашар ризыклары булмаган. Оят-хурлык бит!

Курмашев мондый мисалларны тагы да китерә алган булыр иде дә, уйлары артык читкә китүен абайлап: «Кая барып чыктың әле? Бөек кешеләр белән нинди уртаклыгың бар синең? Гадилек, тыйнаклыкка омтылуыңмы, башкалар хакына үз-үзеңне корбан итәргә тырышуыңмы? Хыял-теләкләр генә бит бу. Аларны эшең белән расларга кирәк!» — дип, үз-үзен шелтәләп алды.

Шунда аның күңеленә гаҗәп кызык, сәер бер уй килде. Хәзер менә торып урамга чыгарга да, берәр йөк машинасын тотып, кичен үзе кунакта утырып кайткан теге бистәгә китәргә, Дания Дәүләтшинаны бөтен әйберсе, кызы белән машинага төяп, үзләренә алып кайтырга да уллары яшәгән бүлмәгә урнаштырырга. Ул бүлмә барыбер буш тора бит. Дәүләтшина менә шушында алар белән бергә яшәсен, диссертациясен эшләп җиткерсен, кирәк икән — Курмашевны төзәтсен, кирәк икән — юкка чыгарсын. Маһирә ханымга да сөйләшергә, ләчтит сатарга кеше булыр. Оныклары Айдарны да үзләренә китертергә мөмкин, теге кызчык белән икәү уйнарлар. Карале, шул баланың исемен сорамаган бит. Нинди сөйкемле кызчык бит!

Курмашев шуннан соң ниләр булырын күз алдына китереп карады. Әлбәттә, Маһирә ханым аның ихлас күңелен аңламаячак, бу хәлгә үзенчә, хатын-кыз күзе белән караячак, зур җәнҗал куптарачак... Шуннан ары инде аның уйлыйсы да килмәде. Юрганын башыннан ук бөркәнде дә чытырдатып күзләрен йомды.

Бүлмә эче тып-тын, тәрәзәдән саркып кергән сыек кына ай яктысында түшәм, стеналар агарып күренә. Курмашев, күзен йомган булса да, баш өстендәге зур түгәрәк люстраны күңеле белән күреп ятты. Түгәрәк калпак эчендәге лампочканың кылдай нечкә чыбыгы утлы күмер шикелле кызып кабынган да шуның җылысы йомшак, рәхәт булып күкрәгенә таралып бара сыман тоелды. Ул йөрәгендә нинди тойгылар уянганын аңлап-төшенеп җитмәде, тик бернәрсәне күңеленә беркетеп куйды: ул иртәгә дә, берсекөнгә дә, аннан ары да беркая чыгып йөрмәячәк, бер айдан соң инде чит илгә китәчәк. Ярый, булган — беткән, кирәкми, онытылсын...

## 9

Чит илгә киткәнче Курмашев тагын ике зур эш башкарды.

Теге кичне Дания Дәүләтшиналарда булганнан соң ул аның белән яңадан очрашмаса да, күрешергә теләмәсә дә, аны һаман күңеленнән чыгармады.

Юк, ул аны профессиональ яктан үзеннән өстен дип санарга җыенмый, эшендә һәм тормышында уңышсызлыкка очраган ялгыз бер хатынга, көчле ир кеше буларак, түбәнчелек белән генә карый иде.

Курмашев түзмәде, чит илгә китәр алдыннан профсоюз комитетына Яхин янына барды. Яхин бу вакытта кешеләр кабул итә, аның кабинетына бик күпләр туктаусыз кереп-чыгып тора иде. Курмашев дусты белән баш кагып кына исәнләште дә, ишек төбендәге урындыкка утырып, Яхинның эше беткәнен көтә башлады. Ул Яхинның кырыкмаса-кырык төрле эшне берьюлы эшли алуына шаккатып карап торды, балалар бакчасы өчен, ашханә өчен кашык-савыт юнәтергә дә, зур телевизорны турыдан-туры акча түләп кенә сатып алырга ярамый дип телефоннан талашырга да һәм башкаларына да түземе җитүенә исе китте...

Әнә шулай кырык төрле эшне кырык хәйлә белән җайлаган вакытта Яхин кешеләр кабул итәргә дә өлгерә иде. Кайберәүләренә ул киләчәктә өметләнмәслек итеп кырт кисеп әйтә, икенче берәүләргә бераз

сабыр итәргә куша, өченчеләренә юк нәрсә белән йөрмәгез ди, дүртенчеләрен берәр төрле файдалы эш эшләргә үгетли...

— Остарган, тәмам шомарган! — дип, дустына сокланып уйлап куйды Курмашев. — Бөтен юлын-әмәлен белә. Махсус академиясен бетергән диярсең! Ә менә диссертациясен язмады. Үз-үзен эшкә җигә алмады. Пошмас җан!..

Нефть ятмаларын эшкәртү буенча сугыштан соң махсус төзелгән фәнни-тикшерену институтына Яхин кырык алтынчы елны килде. Бу вакытта инде Курмашев шактый авторитетлы белгеч булып киткән, Идел буендагы скважиналарны аның сызмалары буенча гына бораулыйлар иде. Ул ким дигәндә кандидат дәрәҗәсе алырлык зур гына диссертация хезмәте тәмамлап килә, берничә вак-төяк формаль эше генә калган иде.

Ул вакытта әле Курмашевлар фронтта һәлак булган бер командир хатыны квартирында бүлмә алып торалар иде. Курмашев күрешкән көнне үк Яхинны үзләренә кунакка алып кайтты. Маһирә мичкәдән генә агызып сата торган бер шешә сасы аракы чыгарды, бәрәңге пешерде. Яхинның офицер паегына алган бер банка ит консервысы, шикәре, икмәге бар икән — бик әйбәтләп сыйланып утырдылар.

— Әйдә, синең өчен күтәрик! — диде Курмашев, рюмкасын тотып. — Молодец! Исән-сау кайткансыз, өстәвенә, орденнар да тагып. Тагы ни кирәк?!.

— Сез дә тик ятмаган бит, — диде Яхин, ун айлык Аликны кулында тирбәтә-тирбәтә. — Менә, күрәсезме, нинди таза малай булдыргансыз!

Маһирә, мәк чәчкәсе төсле кызарынып, тиз генә кухняга чыгып китте — анда таба чыжлый башлаган иде. Курмашевның мондый мактауга бераз күңеле үсеп китсә дә, тыштан бирешмәде.

— Анысы кыен эш түгел. Бала булдырыр өчен әллә ни акыл кирәкми.

— Белмим. Андый тормышны мин оныткан мын инде. Мин кеше үтердем, үзем дә үлемнән бер генә котылмадым, сугышның нәрсә икәнен үзең беләсең. Күңел җанга рәхәт нәрсә тели, балалар тирәсенә тарта. Хәзергә бераз сабыр итәм әле, баш-күз алыйм.

— Баш-күз алыйм дип сузасың юк,— диде Курмашев.— Беләсеңме — эшләр нинди гә китте? Хәзер иң кирәклесе идея түгел, аны тормышка ашыра белү. Буш хыяллар өеме-өеме белән архивта өелеп, чират көтеп ята. Теория уйлап чыгаручылар гына түгел, практик тәҗрибә ясаучылар, уйлаганын тормышка ашырырдай кешеләр кирәк. Синдә андый сәләт җитәрлек. Әйдә, эшкә кереш. Диссертацияне язып бетер.

Дөрес, Яхин диссертация эшенә бик дәртләнеп кереште. Курмашев хәтта аңардан көнләшеп тә йөрде, ләкин көнләшүен гамәленә чыгармады, кешеләр алдында дустын мактап сөйләде:

— Яхинда Эдисон, Резерфорд, Губкиннар тырышлыгы бар... Ул үзен күрсәтер әле! — диде.

Вакыт үтә торды, ә Яхин ул кадәр әллә ни күрсәтмәде. Гомумән, һич аңлап, төшенеп булмый иде аны. Ул әле партбюро секретаре булып сайлана, әле профсоюз комитетында эшли, башка җәмәгать эшләренә дә үзе теләп җигелә. Иң гаҗәбе шул: шул эштән тәм тапкан кебек, һәммәсенә бик риза булып алына иде.

...Еллар уза барды. Сугыш инде артта, еракта калды. Курмашев доктор, профессор, лауреат булды. Яхин исә кандидатлыкны да яклый алмады. Я эшләргә теләми, я үз-үзен мәҗбүр итә алмый. Өйләнеп, дүрт-биш бала үрчетте, шулай итеп, үзенең талантын әрәм итте. Нигә, ни хаҗәтемә кирәк аңа ул балалар бакчасы?

Кайвакыт Курмашевның күңеленә әллә нинди сәер уйлар да килгә-

ли. Анынча, тәкъдир, ходай һәркемгә бәхетне тумыштан тигез биргән, ә ул, Курмашев, әрсезләнә төшкән, дустыннан алгарак узып, гыйльми дәрәҗәгә, дан-шөһрәткә һәм башкаларына ирешкән, Яхинга берни калдырмаган. Шушы балаларча беркатлы, сәер уй Курмашевны гел борчый, газапка сала, Яхин исә, сукыр кеше кебек, берни күрми, берни эшләми.

Курмашев, әлбәттә, дусты өчен борчыла иде. Ул аны кызгана да, ялкау син, эшлексез дип тиргәп тә ташлый, ә Яхин моңа каршы маңгаен гына җыерып куя да, бер дә исе китмәгән шикелле, сирәгәя башлаган бөдрә чәчен тарарга керешә. Була бит шундый үзсүзле, тискәре кешеләр!..

— Туктале, тагын берсенең тетмәсен тетим әле! — дип, Яхин башын күтәрмичә генә Курмашевка күз төшереп ала да тагын телефоннан кычкырырга керешә: — Карале, чүлмәкләр белән нәрсә маташтырдыгыз сез анда? Мәсьәлә шул — кырык чүлмәк табарга кирәк! Нәрсә? Сметага кертергә кирәк? Кирәк анысы, кирәк!.. Смета төзүче түтәй үзен әнисе кайчандыр чүлмәккә утыртканлыгын оныткан булса, мин нишлим?! Әйе, әйе, ул хәзер зур үскән инде, туалетка йөри башлаган. Бик акыллы киңәш бирәсең! Нәрсә, шул чүлмәк аркасында яслене ябаргамыни? Тавыклар көләр аннары бездән... Менә анысы ярый. Юкса, бар белгәнең — смета да лимит, параграф! Ярый, хуш!..

Бетми торган эш юк икән ул. Ниһаять, Яхин телефонны шалт иттеретеп бер читкәрәк алып куйды, өстәл өстендәге кәгазьләрне аерып тормыйча, барысын бергә тартмага сыпырып төшерде дә киерелгәләп алды. Шуннан соң гына кием элгече янында тып-тын утырган Курмашевка күтәрелеп карады.

— Берәр борчуың бармы әллә? — дип сорады Яхин, аңа якынрак килергә ымлап.— Мондарак узып утыр. Профсоюзга күптән төшкәнең юк, гел минем үземә өскә менәргә туры килә иде.

Курмашев Яхинныкы төсле үк тавыш белән:

— Ярый, дөнья булгач төрлечә була, — дип җавап кайтарды, йомыш белән керүчеләр өчен дип куелган өстәл янына килеп утырды. — Башта берәү өскә менә, аннары икенчесе аның янына аска төшә. Саубуллашырга дип кердем.

— Дөрес иткәнсең! Югыйсә, вакыты килеп тәрәлгәч кенә ашыга башларсың да сәлам дә бирмичә китеп барырсың.

— Алай китеп бармам анысы. Саубулашканда берәр нәрсә оештырырбыз әле. Минем өчен дә бер кичәңне тамгалап куй.

— Оештыру — яхшы нәрсә анысы, — диде Яхин, календарена билгеләп куйды.— Ерып чыккысыз эш, мәшәкать. Эш-эш ди-ди, мәҗлесләрне дә онытып барабыз. Чит илгә чыгып, бер тапкыр да йөреп кайта алганым юк бит әле минем. Булмый. Бик барасым килә, үзебез сугышып йөргән, дусларны күмеп калдырган җирләрне күрәсем килә. Күпме кешебез корбан булды — исең-акылың китәрлек! Безнең комбатны хәтерлисеңме? Бик шәп егет иде бит, бик уенчак күңелле иде...

— Бранденбург капкасыннан узарга хыяллана идеме әле?

— Уза алмады шул, Берлинга кергәндә үлеп калды. Нинди шәп кешеләр һәлак булды. Аларның каберенә барып, зиярат итәргә иде. Шулар искә төшсә, күңел сафланып, пакьләнеп китә!.. Путевкалар да үз кулымда инде, рәхим итеп кит тә бар — юк шул, әле бер сәбәп, әле икенчесе, әле өченчесе чыга да тора. Чоңгылга эләккән йомычка шикелле, бер урында һаман әйләнәсең дә әйләнәсең!..

Яхинның тавышы ничектер калтыранып киткән кебек булды, йомшара төште. Күзләренә яшь тә чыккан сыман тоелды Курмашевка. Ләкин бу хәл озакка сузылмады, бер-ике минуттан инде Яхин гадәттәге корырак тавыш белән:

— Я, йомышыңны әйт! Ярдәм кирәкме? — диде.— Бераз бирә алам, беркадәр ресурс бар. Гариза яз, кул куярмын.

— Уңайсыз. Акчаны кая куярга урын юкмыни? Тишек-тошык җитәрлектер әле.

— Нәрсәсе «уңайсыз»? Бер син генә ярдәм сорыйсыңмы әллә? Берише кешеләр санаторийга, ял йортына бушлай бара, өстәвенә, юлга дип, дәваланырга дип тагын акча сорый. Узган атнада гына синең шикелле атказанган берәү кереп, сәгать буе минем алда үзенең хокукларын даулады — квартирындагы бәдрәфен ремонтларга акча сорады... Тишек-тошык дигәннән — бөтен тормыш гел ямау-ялгаудан гына тора бит ул.

— Бәдрәфләренә бирдеңме соң?

— Бирде-ем. Менә шундый хикмәтләр, дус. Ә син «уңайсыз» дисең! Син бит Кавказга курортка бармыйсың, чит илгә китәсең, безнең илнең вәкиле, безнең халыкның вәкиле булып. Кем әйтмешли, ходай үзе кушкан инде сиңа ярдәм итәргә!..

— Булганы да җитәр әле. Башкаларга ярдәм ит,— диде Курмашев һәм, сүзнең үзенә кирәкле якка борылуыннан файдаланып: — Кара әле, Дәүләтшинага квартир бирү мәсьәләсе ничек? Аспирантка ул, кандидатлык диссертациясе яклап караган иде. Хәтерлисеңме? — дип сорады.

— Яклап караганын хәтерлим. Син искиткеч чыгыш ясаган идең — таң калдырырлык итеп.

— Шулайдыр инде!..

— Чынлап, чынлап, — диде Яхин һәм уйга калды. — Ә квартир мәсьәләсен һич хәтерләмим, валлаһи! Йөзләгән кеше — аларны ничек хәтерләп бетерәсең. Тукта әле, кәгазьләргә күз салыйм.

Яхин өстәл тартмасын ачты да аннан кыстыргыч белән электереп куйган берничә бит кәгазь чыгарды, бармагын йөртеп, кирәкле фамилияне эзләргә кереште.

— Юк, исемлеккә теркәлмәгән. Квартир сорап килгәне юктыр.

— Син әйт инде: квартир сорап аптыратканы, теңкәгә тигәне юк, диген.

— Тукта, аның өчен нигә син борчыласың әле? — диде Яхин һәм хәйләкәр генә итеп күз кысты.— Минем белүемчә, аспирантлар мәсьәләсе белән гыйльми бүлек шөгыльләнә. Кара аны, аспирант кызлар белән кызыксынуыңны Маһирә ханымга ычкындырсам...

— Кая инде безгә аспирант кызлар. Чыннан да, квартир бик кирәк аңа. Фамилиясе синең исемлектә булмаса ни! Бездә исемлеккә кемнәр эләгә? Чыннан да, мохтаҗ кешеләр дисеңме? Беренче булып оят белми торган җыен әрсезләр керә, чөнки алар иң элек, эш турында уйлаудан бигрәк, үзләре турында борчылалар. Шулай түгелме?

Курмашев, чишелеп китеп, үзенең теләгеннән тыш үзен оппонент итүләре, диссертация яклаудан соң Дания Дәүләтшинаны өенә чаклы озата баруы, аңарда кунак булуы, чәй, коньяк эчүе турында сөйләде.

— Борчыламы бу, ә? — дип, Яхин кулы белән йөрәген күрсәтте. — Үкенәсеңме?

— Юк, үкенмим. Минем урында булсаң, син дә нәкъ шулай итәр идең.

— Күпмедер дәрәҗәдә син хаклысыңдыр да,— диде Яхин, аның сөйләгәннәрен сабыр гына тыңлап торганнан соң, — мине дә аңла син: кешегә тиктомалдан, тота-каба дигәндәй, квартир бирә алмыйм бит. Кеше үзе йөрми, сорамый — ә без аңа, менә рәхим ит, дип, кулына ордер тоттырыйкмы?! Гафу ит, алай булмый ул. Гариза бирүчеләр белән дә хәл бик кыен әле.

— Кешегә яхшылык эшләү өчен аңардан гариза яздыру кирәкмени? Шунсыз ярамыймы? — дип, Курмашев үз сүзен куәтләде.

— Ярамый шул менә. Алай булмый. Әйт әле: менә бу гариза язган кешеләрдән синең аспиранткаң кай ягы белән артык?

— Һич югы, әрсезләнеп, сорап-даулап йөрмәве белән. Беләм: синең дә хәлең җиңел түгел — теләсәң дә ансат кына эшләп булмый. Закон буенча эш ит син: комиссияләреңне эшкә куш, башка якларын карагыз. Менә, күрәсезме, кеше нинди шартларда яши, диегез. Шуннан соң, минемчә, Дәүләтшина синең исемлектә беренче булыр.

— Ярый, ышандырдың, — диде Яхин, ниһаять, ризалашып. — Хәлемнән килгәнчә тырышып карармын. Син үзең дә инициатива күрсәт. Җитәкчеләргә сүз салып кара, бераз фикер тудырырга тырыш, аннары минем өчен дә җиңелрәк булыр. Килештекме?

— Килештек. Тагын бер үтенечем шул — син минем исемне алай-болай кыстыра күрмә инде, яме?

Яхин, бу сүзгә кәефе килеп, чәнчеп әйтә куйды:

— Яхшылыкны кача-поса, оялып кына эшлибез, ә яманын кешегә күрсәтеп, бер дә уңайсызланмыйча, зур трибунадан торып эшләргә тырышабыз. Янәсе, күрегез: без менә болай да булдыра алабыз!

— Их, әйтер идем!.. Кешегә яхшылык эшлим дип, аңа гыйльми дәрәҗә бирергәмени, аны академик итәргәме?

— Ярый, ярый, берүк кыза күрмә. Мин бит гомумән шундый димим, булган фактны гына әйтәм.

— Авыз ерма син, башкалардан акыллырак булырга тырышма...

## 10

Чит илгә киткәнче Курмашев Алтын күл промыселына барып кайтты, кырыс чырайлы, кызу канлы бораулаучы Зиннәт Шәрифуллин белән тагы бер тапкыр очрашты.

Чит ил сәфәренә дүшәмбе көнне чыгып китәсе иде. Шимбә көнне исә Маһирә ханым олы бүлмәдә чемоданнарга юл кирәк-яраклары тутыра башлады.

— Кулъяулыкларыңны үтүкләдем. Сакал кыргычыңны куйдым, — диде ул, ире ишетсен өчен катырак кычкырып. — Җиң каптырмасы эчәү, галстукларың да шунда. Кырынганнан соң сөртенә торган кремны Мәскәүдә алырсың, анда үзәктә, Петровка тирәсендә яхшылары була... Ишетәсеңме? Петровка тирәсендә!

— Кайгыртуың өчен рәхмәт инде, — дип җавап кайтарды Курмашев кабинетыннан. Һәм шунда, күңеленнән, якшәмбе көнне бушка әрәм итмәскә кирәк, дигән карарга килде. Хатынына әйтер: институтта кайбер эшләремне төгәллисе бар, әллә ни зур эшләр булмаса да, бик кирәкле, кичектерергә ярамый, дияр. Алтын күлгә барып, Дәүләтшина идеясенең гамәлдә нинди икәнлеген карар. Самолет белән бер сәгатьтә барып җитәсең. Бәлки ул юкка гына борчыла торгандыр, әллә ни искитәрлек нәрсәсе дә юктыр? Янача маташтырырга тырышу гынадыр?!

Курмашев үз күңеленең дөрес сизенүен аңлый: диссертациядәге расчетларның (байтак ялгышлары булса да һәм Курмашев аларны ашыгыч эшләнгән дип кире кагарга киңәш итсә дә) күбесе дөрес, ялгышларны төзәтүе кыен түгел. Тик шулай да, шул ук күңелнең бер кырыенда, ни генә булмасын, барыбер мин хаклы, дигән мәкерле өмет чаткысы да яши иде. Аның гомерендә күпме зур планнар, иң югары инстанцияләр тарафыннан тормышка ашырырга рөхсәт ителгән күпме кыю тәкъдимнәр булды! Аларның да җентекләп исәпләнгән теоретик нигезләмәсе бар, аны яхшы белгечләр, зур җитәкчеләр яклый иде, әмма барыбер файда китерәсе урында зыянлы гына булдылар, тавыш-тын чыгармыйча тып-тыныч кына онытылып калдылар. Чыннан да, Дәүләтшина түгел, Курмашев хаклыдыр бәлки? Соңга калу начар булган кебек, ашыгу да зарарлы бит.

Алтын күл — Курмашевның беренче эшли башлаган җире, ул аның туган авылы Сарабиккол янында гына. Ул урыннарны Курмашев яхшы белә, барыр да карар — һәммәсен үз күзе белән күрер. Кем җиңгән, кем җиңелгәнен нигә алдан юрап, юкка борчылырга?! Барырга дигәч — барырга! Югыйсә, ул озакламый чит илгә китәчәк. «Ничек икән?» дип һаман борчылып йөргәнче, мәсьәләне хәзер үк ачыклап китәргә кирәк.

... Курмашев, килеп төшкәч тә, элек үзе йөргән урыннарны бик тиз таныды. Моннан егерме ел элек кебек, һаман шул ук куе кара урман, тик бу юлы Курмашев ул чактагы шикелле җәяү атламады, яхшы асфальт юлдан таксига утырып кына килде. Бу юлларны нефтьчеләр салган, юл буендагы челтәрле баганаларда ак фарфор чынаяклар асылынып тора, шулар буйлап авыр, юан электр чыбыклары сузылып киткән иде.

Әнә шунда ук таныш каен үсеп утыра. Ләкин бик нык үзгәргән, картайган инде. Кәүсәсе дә теге чактагы шикелле ап-ак түгел, ботаклары юанаеп, җәелә, кәкрәя төшкән, шулай да бирешми әле. Ботаклары кибеп, очы корый башласа, үзен кисеп ташлаячакларын белгән кебек, тырмашып булса да яши!

Монда йөк машиналары күп күренми — иркенрәк шосседан йөриләр, күрәсең. Нефтьчеләр вахта кешеләрен скважиналарга иртүк илтеп куйганнар, якшәмбе көнне башка йөк ташымыйлар, шуңа күрә урман эче аулак дип әйтерлек тын иде.

Курмашев таксистка каен турысына туктарга кушты да, үзе машинадан чыгып, агач янына килде. Агачка сөялеп, кытыршы салкын кайрыга колагын куйды һәм кайры астыннан каен суы күтәрелүен ишеткән кебек булды. Каен башына тукран килеп кунды. Каралы-кызыллы түшле чибәр кош, ботактан ботакка сикергәләп, башта өскә үрмәләде, аннары аскарак төште, шуннан тагын агач башына менеп китте. «Нишләргә икән?» дип уйланган сыман булып торды да тукылдатырга кереште. «Тук-тук» иткән авазы урман эченә тарала да кире кайтып яңгырый...

Дөньяда һәр кеше башта киләчәгенә омтылып яши, аннары хезмәт итү еллары җитә, узганнарга әйләнеп карарга, киләчәккә күз салырга һич вакыт артмый. Шуннан соң инде, ниһаять, истәлекләр белән яшәү чоры килә: ул истәлекләрнең күңеллесе, күңелсезе, җиңеле, авыры булса да — алар барысы бер дәрәҗәдә сагышлы, чөнки алар кире кайтмый торган гомернең күңелдәге шәүләләре генә шул.

Курмашев карт каен төбендә, әнә шулай уйланып, каралы-кызыллы камзул кигән тукранның томшыгы белән кизәнеп-кизәнеп агач тукылдатуын карап торды, Шәрифуллин белән икәү шушында урманга мотор алып килүләрен, өшәнгән атларны ял иттергәндә учак ягып җибәрүләрен хәтерләде.

## 11

Ул чагында инде мәсьәлә тәмам ачык билгеле булды. Нефть эзләүчеләрнең вышкалары Кама аръягына чыктылар. Алтын күл промыселында инде эксплуатацион бораулау эшләре җәелеп китте — дүрт йөз метрга алты йөз метр итеп сызылган схема буенча тирән скважиналар бораулыйлар. Шул мәйданның чите буйлап бер рәт булып Курмашев нокталары тезелеп бара, бу скважиналардан җир астына су кудыртачаклар, уртадагыларыннан фонтаннар бәреп чыгачак.

Узган гасырда Дрейк дигән бер авантюрист бәндә, нефть скважинасы тиштереп, нефтькә кызыгучы башка кешеләргә: «Монда мин хуҗа!» — дип, алтатары белән янаган заманнардан бирле һәр промысел өчен иң куркыныч нәрсә — су булган, ә менә Курмашев, киресенчә, акыл ышанмаслык хикмәт эшләмәкче — җир астына су кудыртмакчы.

Нефть катламында бушлык калмасын өчен бер тонна нефтькә дүрт тонна су кудыртырга кирәк!

Әйтәсе дә юк, бер уйлаганда мондый эш бик зур тәвәккәллек сорый. Ә шунсыз уңышка ирешеп булмый. Алтын күл төбәгендә миллиардларча тонна нефть бар. Ләкин насос белән суыртып кына бу запасның яртысын да чыгарып булмаячак, шуннан башкасы бөтенләйгә җир астында калып, әрәм булачак. Табигать үзенең шул хәтле байлыгын кешеләр әнә шулай бәрәкәтсез итеп тотсын өчен миллион еллар буена барлыкка китереп, саклап ятканмыни? Насоска су белән ярдәм итәргә кирәк, су нефтьне скважиналарга кысып-куып китерсен, шул чагында инде катламнарның нефть бирү чамасы илле процентка җитәчәк. Илле процент инде ул кырык кына түгел, бу очракта исә ул өстәмә рәвештә бик күп нефть дигән сүз.

Моны эшләсәң бары тик хәзер генә эшләп каласың! Шулай булмаганда ничә еллык тырышлыгың бушка китәчәк, өмет-ышанычың чынга ашмаячак. Моның өчен алгы сызыктан кайтып киткәнче, штрафной батальонга кит идең!

Станциядән Алтын күл промыселена кыш буе ат белән торба, насос, электр моторлары ташыганда Курмашев әнә шуны уйлап юанды. Авыр йөк ташырга атлы олауны колхозлардан алалар иде. Арык атлар йөкне көчкә-көчкә тартып бара, бер юл әйләнүгә генә дә өч-дүрт көн вакыт китә, юлда очраган авылларга туктап, куныл чыгарга туры килә иде.

Бервакыт алар Шәрифуллин белән шушы агач төбендә төн чыктылар. Менә хәзер, күпме гомердән соң, Курмашев әлеге карт каен төбендә басып тора, хәлсез атларга тау менеп, тау төшәргә ярдәм итүләрен һәм көч-хәл белән шушы төшкә килеп җитүләрен хәтерли. Бик ардылар алар, тәмам хәлдән тайдылар, ләкин Шәрифуллин, атына кычкыргалап, һаман алдан атлый бирде, арткарак калып икенче олауга да күз салгалады. Ә Курмашев аңардан калышмаска тырышып атлады...

Җир астына су кудырту өчен насослар, моторлар куясы төшкә барып җитәргә ике-өч кенә чакрым калган иде инде, менә шунда, әлеге каен янында, Шәрифуллинның җирән алашасы хәлдән таеп ауды. Атны селеккәләп-йолыккалап та, тәртәсеннән эткәләп, камытыннан күтәреп тә карадылар — файдасы булмады.

Җирән алаша, үзе алгы аякларына басып, бер талпынып караган иде дә торып басарга хәле җитмәде, яңадан ауды.

Курмашев, ачуы килеп:

— Ай, хайван! — дип, дилбегә очы белән атка китереп сукты. Атның тузанлы сыртында буй-буй эз калды, ләкин җирән алаша селкенмәде дә, миннән булмый инде, дигән шикелле, күзен йомып, башын сузды.

— Тимә, — диде Шәрифуллин. — Ат өйгә кайтканда арыса, чыбыркының файдасы юк. Бераз хәл алсын. Тик салкын тия күрмәсен, яшь ат әле ул, бик арыгайган, хәлдән тайган. Монда бераз утырырга туры килер.

Кич җитеп караңгы да төшә башлады. Кояшның эссесе беткән сыман, шәфәкъ яктысы сыек кына булып болыт астын алсуландырып торды да сүнеп тә калды. Алар икәү, юл буена коры-сары ташып, ут ягып җибәрделәр. Шәрифуллин тунын учак өстендә тотып җылытты да аты өстенә илтеп япты.

— Монда кышлап ятарга җыенмыйк без. Әнә тегендә, аста бер кеч-кенә авыл бар. Мин шунда барып килим. Бераз печән табып булмасмы, — диде ул Курмашевка.

— Сиңа анда хәзерләп куйганнардыр!

— Бушлай бирмәсләр, билгеле. Менә хәзер мотор салган ящикны сүтеп, кадакларын җыеп алабыз да шуна алмаштырабыз. Ящикны барыбер ватасы, ә кадаклары бик шәп, ике йөзле. Мин озак йөрмәм. Син атларны карый тор. Югыйсә, җавап бирәсе булыр, акча түләтерләр. Сугыш вакыты, бик нечкәреп тормаслар. Ут яккач, җәннәттәге кебек монда.

— Әйе шул. Тик янда анабыз һава гына юк, — диде Курмашев.

Шәрифуллин авылга китте. Курмашев ут кызуында әле шинелен, әле Шәрифуллин калдырган тунны җылытып, атлар өстенә япты, учакка коры-сары өсти торды һәм ахырда арыганлык үзенекен итте — ут җылысында аны йокы басты. Бик тынычсыз, ярым уяу йоклады ул, төшендә теге кырыс чырайлы комбатны күрде. Комбат, мунчага кергән шикелле, тыныч кына, сабыр гына бер кыяфәттә, учак янына килеп утырды да йөнтәс сыйракларын җылытырга тотынды, имеш; Курмашевка төрткәләп, коры-сары җыеп килергә куша, имеш.

Шул вакыт Курмашев уянып китте. Аны җилкәсеннән төрткәләп, янында Шәрифуллин басып тора иде.

— Акылың бармы синең? Катып үләсең бит! — диде ул, ачулы итеп.

Ут инде янып беткән, учак урынында көл генә өелеп калган, атлар кырт-кырт итеп печән ашап торалар иде.

Курмашев, Шәрифуллинның юлы уңганлыгын чамалап:

— Я, ни хәлләр бар? — дип сорады.

— Хәлләр ярый. Мин нефть эзләп йөргәндә анда берәүләрдә фатирда торган идем. Онытмаганнар икән әле. Чанага төяп печән биреп җибәрделәр, үземне дә бәрәңге белән сыйладылар, сиңа да өлеш чыгардылар. Мә, аша. Бик әйбәт кешеләр, ярдәм итәргә атлыгып торалар, — дип сөйләнде Шәрифуллин.

Яңадан учак ягып җибәрделәр. Учак уты, кешеләргә тагын хезмәт итүенә сөенгән кебек, күңелле, рәхәт булып дөрләп китте.

Курмашев җылы бәрәңге ашады, бер-икесен атка да каптырды. Ат, бәрәңгеләрне чәйнәп йоткач, иренен тагын сузып караган иде дә, бәрәңге юклыгын белгәч, каты итеп пошкырып кына куйды.

## 12

Хәзер урманга бара торган машина юлы юк, аны кыш башындамы, кыш уртасындаракмы бульдозер белән ачкан булганнар да, бураннан соң юлның ике кырыенда калку тасма сыман сузылып кар гына өелеп калган, уртадан бер кеше узарлык кына тар сукмак салынган. Сукмак әле нарат асларына кереп китә, әле әллә ничек бормаланып буталып бетә иде, шуңа күрә Курмашевка машинасын калдырган теге олы юл буена яңадан килеп чыккаларга туры килде. Станциягә таба атлаганда ул күңеле белән яңадан теге елларга әйләнеп кайтты. Бүгенгедәй бик яхшы хәтердә икән әле ул вакытлар. Кайда икән хәзер теге усал, чая Шәрифуллин? Эшли микән әле? Пенсиядә микән? Әллә теге ашказаны авыруы белән дөньядан ук китеп барганмы?

Язгы тын урман эченнән атлаганда Курмашев ул вакытларның кадерле минутларын яңадан кичергән кебек булды, шуңарчы бу як кешеләренең башына да килмәгән эшкә керешеп, бирегә җәфаланаҗәфалана җиһаз ташуларын хәтерләде. Уйлаган эшләрен барыбер җиренә җиткерделәр бит алар. Хәзер менә җәй җиткәнче шушында

торып каласы иде, каен җиләге пешкәнен, беренче гөмбәләр үсеп чыканын, ландышлар, кыңгырау чәчкәләр чәчәк атканын күрәсе иде, яшел имәннәр арасында йөрисе, киң, иркен зәңгәр күккә, шунда агылган ак болытларга карап, агач төбендә ятасы иде.

Ак таштан салынган бер катлы насос станциясе бинасына килеп керүгә, Курмашевның моторлар гөрелтәсеннән колагы тонып китте. Металл түгел, һава үзе гүләп тора сыман иде. Яктыдан берни шәйли алмый торды, күзләр ияләшә төшсен дип, ишек төбендәрәк туктап калды. Бина эче буш, кеше-кара күренми, бары тик мотор, насос, приборлар гына гөрелдәп-шаулап тора. Юк, кемдер берәү бар икән — башындагы түбәтәен төзәтебрәк кия-кия, бирегә таба килә.

Курмашев: «Әссәләмөгаләйкем! — дип кычкырып, картларча сәлам бирде.

— Вәгаләйкем әссәләм, — дип сәлам кайтарды түбәтәйле кеше, аңа якынлашып һәм: — Госман Закирович түгелме соң? —дип сорады.

Курмашев: «Миңа исемем белән эндәшүче кем булыр икән бу?» дип уйлап та өлгермәде — әлеге абзыйның кешегә текәлеп карый торган җете күзләрен күреп, Шәрифуллин икәнлеген танып алды. Өстенә пөхтә генә зәңгәр халат кигән, түш кесәсеннән ак башлы авторучкасы күренеп тора; кулына әле яңа гына прибордан алган зур түгәрәк картограмма тоткан иде. Түгәрәк тирәли кәкре-бөкре кара сызыклар сызылган — алары күпме су җибәрелгәнлекне күрсәтә. Чәчләре агаруын һәм авыз кырыйларына ике тирән җыерчык сызылуын исәпләмәгәндә, башка ягы тамчы да үзгәрмәгән, шул ук Шәрифуллин иде. Эшен дә ташламаган икән — шунда эшли. «Молодец!» дип уйлап куйды Курмашев.

Хәер, аның нәрсәсенә гаҗәпләнәсең! Курмашев үзе дә һаман шул ук эшендә эшли түгелме соң? Әмма кешене инде дөньяда юктыр дип санап та, көтмәгәндә-уйламаганда аның белән күзгә-күз очрашу — мондый хәл китапларда, киноларда гына була торгандыр.

— Син исәнмени? — дип гаҗәпләнүен яшермичә әйтеп ташлады Курмашев.

— Менә күрәсез: эшләп йөрим әле, — диде Шәрифуллин.

— Безнең күрешмәгәнгә ничә ел инде, күпме гомер? Сугыш заманыннан бирлеме?

— Алай ук түгел. Сигез-ун еллап.

— Ничек алай?

— Мин сезне бер тапкыр очраткан идем. Сез мине күрмәдегез. Хәтерегездәме — Алтын күлгә килгән идегез? Бер тапкыр шулай карыйм — промысел директоры белән сөйләшә-сөйләшә, сез киләсез. Сез лауреат булгач, промыселда бәйрәм ясаганнар иде бит.

— Шунда ник килеп эндәшмәдең соң? Миңа да күңелле булган булыр иде.

— Күңелле буласы булса — эзләп табарга иде. Мин сезгә кирәк кеше булмагач, әрсезләнеп йөрмим инде дидем...

Шәрифуллин Курмашевның мондый шелтә сүзләр ишетер өчен килмәгәнлеген абайлады, күрәсең, — тотлыгып калды да кызарынып китте, аннары сүзне икенчегә борды:

— Мин менә һаман эшлим әле. Пенсиягә чыкмакчы идем дә — җибәрмәделәр. Чыгып та кызык түгел: өйдә тик утырырмынмыни? Эчең пошып үләрсең.

— Тәвәккәлли алмыйсыңмы? Пенсиягә бер көн соң чыкканчы, бер ел алдан хәзерләнеп кую яхшырак, диләр бит.

— Аның ни аермасы бар?

— Бик зур аермасы бар. Көнендә китсәң — син әле кешеләрне туйдырып бетермәгәнсең, сиңа чын-ихлас күңелдән яхшы теләкләр телиләр, рәхмәт әйтәләр, бүләк бирәләр, соңгарып китсәң — сине кемнәр-

дер артыксына башлый, синнән котыласы килә. Ул чагында сине инде ялга озатмыйлар — чыгарып җибәрәләр.

— Анысы бәлки сез галимнәр арасында шулайдыр. Бездә бит гадирәк халык, дипломатиясез генә. Хәзер эшләве дә күңелле. Бөтен җирдә — автомат; станциягә, бер-бер хәл булмаса, атна буе килмәскә дә була. Мин инде алай итә алмыйм, менә бүген якшәмбе булса да килдем. Машиналарны үзләрен генә калдырып китеп булмый лабаса! Без бит машина янында кеше басып торырга тиеш дип күнеккәнбез.

Курмашев авыр сугыш елларында бергә эшләп йөргән таныш бораулаучыны бер тапкыр да исенә төшермәве өчен күңеленнән уңайсызланып куйды да:

— Эчең ничек соң? Бик борчымыймы? — дип сорады.

— Төзәлде инде, — диде Шәрифуллин, берни булмаган кебек кулын селкеп. — Сакландым, ярамаганны ашамадым-эчмәдем — шуннан соң төзәлде. Аракыны бөтенләй ташладым. Зур бәйрәмнәрдә генә берәр чәркә каплап куям да шуның белән вәссәлам!

— Өеңдә ничек? Җәмәгатең таза-саумы?

Һәркем белән очрашкандагы шикелле хәл сорашкан булып, гадәттәге бертөрле сораулар биреп торуына Курмашевның эче поша башлады: юк-бар сүз сөйләшеп вакыт әрәм була бит. Аның башка эше юкмыни? Бирегә ул Шәрифуллинның хәл-əхвәлен, хатыны, бала-чагасының сәламәтлеген сорашу өчен килмәде лә! Егерме ел буе аны дөньяда бар дип тә белмәде, ә хәзер бик үз иткән булып сөйләшеп тора. Кем ышансын инде моңа?!

Ләкин Шәрифуллин аны-моны сиздермәде, берни булмаган кебек, үзенең өендәге хәлләрен сөйләп китте:

— Өйдә дә әйбәт кенә. Карчык өйдә генә. Беләсеңме, бик уңган хатын бит ул, бөтен йорт эшен алып бара. Кыз да маладис, үзебезне әби-бабай итте дә куйды, ире белән бер промыселда эшлиләр. Кияүгә сүз әйтерлек түгел, бик әйбәт егет, ә менә малай андый түгел. Малай бездә мастер булып эшли. Һич өйләндерә алмыйбыз әле үзен. Сизеп торам: Дәүләтшинага күңеле төшеп йөри шикелле. Шул хатын монда килдеме — гел бергә йөриләр, үзара сөйләшеп аңлашмыйча, бер эшкә дә керешмиләр. Егетнең күзен-башын әйләндермәгәе дип куркам. Бик кодрәтле хатын!

— Куркасы юк. Әйбәт хатын ул, моның өчен ходайга рәхмәт укырга гына кирәк!

— Әйбәтен әйбәттер дә, баласы бар шул.

— Анысы инде иске заман карашы.

— Искесен искедер дә... Менә сез, хәтерегездәме, ниндигә өйләндегез? Пешеп җиткән алма кебек иде бит. Ә ул чагында яшь, чибәр солдаткалар аз идеме?.. Билгеле, мин каршы түгел түгелен... Дәүләтшина белән бергә эшләгәндә үз-үзенә ышанычың артып китә. Ул югында дөнья тып-тыныч кебек, ә менә ул килдеме — бөтен эш гөжли башлый. Берүзе өч-дүрт ир чаклы эшли. Хәтерегездәме: без ничек эшли торган идек? Бөкребезне чыгарып ташый идек. Ә ул баш белән алдыра.

— Хәзер заманы башка шул. Тик шунысы начар: кешеләр үзләре үзгәреп өлгерә алмыйлар! — диде Курмашев.

— Анысы хак. Бездә хәзер эшләрнең ничек икәнен күрдегезме? Элекке насослар бөтенләй юк инде, хәзерге бер агрегат кына да аларның уңысына тора. Суны кая кудырганны да хәзер җир астыннан күреп торабыз. Аста, җир астында, ниләр барлыгын стенадагы изотоплар бөтенесен әйтеп тора. Кинодагы кебек. Мин насослар янында шуларны карап кына йөрим.

— Ә мәгънәсе бармы соң?

— Ник булмасын? Без чыгарган нефтьнең инде исәбе-хисабы юк. Скважиналар тәмам беткән иде, тамчылап-тамчылап кына нефть би-

рәләр иде, ә хәзер өч тапкыр күбрәк чыгарабыз. Дәүләтшина әйтә, һәрбер промыселда бездәге шикелле булачак, ди.

Шәрифуллин, үзе турында, эше турында тагы да сөйлисе килсә дә, кунакның да хәл-әхвәлен сорашырга кирәклеген абайлады:

— Үзегезнең хәлләр ничек соң, Госман Закирович?

— Ярый, эшләп ятам. Бераз яшәрәсе иде дә — булмый. Чит илгә китәргә йөрим әле менә.

— Турист булыпмы? — дип сорады Шәрифуллин.

— Юк, эшкә чакыралар, договор буенча.

— Ничек ул чакыралар? Бездә әллә тәртип дигән нәрсә юкмы, теләсә кемне чакырып алырга буламы?

— Мине җибәрәләр анда, — диде Курмашев, «җибәрәләр» сүзенә басым ясап. Шунда аның үзенең дә гомере бушка узмаганлыгын, кирәкле кеше булуын сиздерәсе килде. Бу бораулаучы артык масаймасын әле. Әйтерсең бер ул гына бик кирәкле белгеч!

Шәрифуллин Курмашевның күңелендәге бу үзгәрешне сизмәде, ахры, аны үзләренә кунакка барырга кыстый башлады.

— Әнә теге каен янына хәзер вахта автобусы килеп җитә, станцияне бикләбез дә асфальтка чыгып, автобуска утырып китәбез. Безгә кайткач, мунча ягарбыз, мунчадан соң квас, сыра эчәрбез, — дип кызыктырган булды.

— Бик шәп булыр иде дә, вакытым юк шул! — диде Курмашев, башын чайкап. — Кайтып җитәргә кирәк. Мунчада да чабынырбыз, сырасын да эчәрбез әле, борчылма...

Алтын күлгә килү көткән нәтиҗәне бирмәсә дә, Курмашев бирегә килүеннән бик канәгать булды. Һич югы, күп нәрсә аңлашылды. Промыселга ул болай күрер өчен, кызыксынып кына килгән булып күренергә тырышты. Чынында исә Шәрифуллиннан күзен алмый, аның үз эшен бик пөхтә, тыйнак итеп башкаруына сокланып карап тора. Курмашевның үзенең дә, теге чакларда бораулаучылар: «Давай, давай!» дип кычкырып торгандагы кебек, басмалар буйлап йөгереп йөрисе, носилка белән балчык ташыйсы, торбалар тәгәрәтәсе, ул вакыттагы кызу эшнең утын-ялкынын яңадан тоясы килде. Ләкин хәзер мондагы станциядә бөтен эшне, кемнеңдер командасына, ихтыярына буйсынгандай, приборлар эшләп тора, көч куеп эшләүнең кирәге калмаган иде. Курмашев шунда үзенең эшенә, тормышына бәя биреп, бер нәрсәне төшенде: ул үзе дә бик күптән инде, берни уйлый белми торган конвейерга куелган автомат кебек, һаман бер үк эшне эшли икән — ул яңа туып килә торган промыселларның проектын штамплап сугып кына тора икән ләбаса, яңа сызымнарның элеккеләреннән үзгәлеге дә саннар аермасында гына: әйтик, монысында күбрәк скважина бораулана, җир астына күбрәк торба салына. Иң ахырда инде Курмашев проектка кул куеп, минем имзамнан башка моны эшкә ашыра алмыйлар дип юана. Чынында исә аның проектларына бер дә шаккатмыйлар икән, промыселларда аны эшкә яраштырып, үзләренчә үзгәртеп бетерәләр, галим кешенең белдекле тәкъдимнәреннән коры имзасы гына торып кала икән. Хәзергә әле Алтын күл промыселеның гына гомерен озайтканнар, моннан соң башкаларын да шулай эшләрләр һәм аннары инде промыселны корганда ук Курмашев кушканча түгел, бәлки Дәүләтшина тәкъдим иткәнчә эшли башларлар.

Курмашевны шофер асфальтта көтеп тора иде. Ул пассажирын көтә-көтә ялыгып беткән иде, ахры, Курмашевтан: «Туйганчы озон суладыгызмы?» — дип сорады. Пассажирының сөйләшерлек кәефе юклыгын күргәч, ишекне шартлатып япты да моторны кабызып, тиз генә кузгалып та китте.

Курмашев, үзенең бу дорфалыгын бераз йомшартырга теләп, үзенә кешечә яхшылык иткән — бирегә китергән, аны никадәр вакыт кө-

теп торган шофер белән сөйләшергә дә уйлап карады, ләкин сүз башлап китә алмады. Аның белән нәрсә сөйләшсен инде ул? Күрмәгән-белмәгән чит бер кешегә эчендәгене чыгарып селкәсенме, әрем кебек ачы хакыйкатьне сөйләп бирәсенме: мин менә гел зур, гүзәл омтылышлар белән яшәдем, кешеләргә этлек эшләмәдем, үз файдам өчен тырышмадым, ә шулай да, теләк-ихтыярымнан тыш, бөтенләй кире якка китеп бардым, диясенме? Курмашев моңа карышып карады, бирешмәскә тырышты, ә файдасы булдымы соң? Барыбер тормышы ур-талай аерылды: бер яртысы вак-төяк, юк-бар мәшәкатьләргә тотылып бетте, бармак арасыннан коелган ком шикелле, акты да китте, икенче яртысы, кош шикелле, аны читләтеп очып үтте.

Әле кайчан гына ул, ачлы-туклы хәлендә, усал телле бораулаучылар белән сүгешеп, туңган атларын җылытырга тырыша, шушы салкын урманда үзе дә туңа, әмма, шуңа да карамастан, күңеле аның якты, җаны тыныч; бөтен гомере буена җитәрлек бердәнбер хыялы гына бар: уйлаганын тормышка ашырып, аулак, тын бер төбәктә бай промыселлар, шунда эшләп, бәхетле яшәүче кешеләрне күрергә тели иде түгелме? Инде хәзер юллар да салынды, самолетлар да оча, шәһәрләр калкып чыкты, кешеләр дә бөтенләй башка: әнә Шәрифуллинны гына күр, гыйльми хезмәткәрмени: өстенә зәңгәр халат киеп алган, изотоплар белән генә эш итә, башы тулы хыял, ә Курмашевның күңелен үсендереп торган хыяллары сүнде инде, ул күз алдында күргәннәрдән башканы уйлый алмый, йөрәге беркая да ашкынмый. Югыйсә, аның илле яше тулмаган бит әле?

«Ярар, төшенкелеккә батма! — дип, Курмашев самолетка утыргач үз-үзен юатырга, тынычландырырга тырышты. — Егерме биш-утыз яшьләреңдә көчле-дәртле булыр өчен әллә ни күп акыл кирәкми, — менә илле яшеңдә бирешмә. Үз-үзеңне кулга ал! Узган гомерне кире кайтарып булмый инде, ләкин алдагысы, запастагысы да бар бит әле!»

Тик никадәр генә шулай юанса да, кәефе аның яхшырмады, күңеле каршылыклы, борчулы, ямансу тойгылардан арынмады. Ничек көч, теләк табып, кайдан, нәрсәдән башларга?

Самолет чайкалып куеп, кырыная башлады һәм аннары борылып җитте дә кайту юлына турылап очып китте. Курмашев, түгәрәк тәрәзәдәге ак пәрдәне ачып, аска күз салды. Ап-ак кырлар белән аралашып, артка таба ялангач, карасу урманнар агыла, кар астында, күзгә күренмичә, Алтын күлне суга туендыручы инешләр көч җыеп ята, күл буенда шәһәр калкып килә. Ул икегә аерылып тора: бер ягы — сугыш заманында разведчиклар салган иске бараклардан, икенчесе — соңгы елларда төзелгән зур-зур ак йортлардан гыйбарәт.

«Их, шәһәргә кереп чыгасы калган, бер унайдан туган авылым Сарабикколга да сугылган булыр идем. Җиде чакрым урап килү зур арамыни? Тагын кайчан киләм әле монда?!» — дип үкенеп куйды Курмашев.

## 13

Чит җирдәге промыселларда Курмашев өен, туган ягын сагынып яшәде, эшен тизрәк бетереп кайтып китәсе килә иде. Шулай да ул ашыкмыйча, эшен җиренә җиткереп эшләде, шушы чаклы ерак җиргә китергән зур, җаваплы бурыч аның күңелендә дәрт, илһам уятты, тырышлык һәм түземлек бирде. Ул, контрактны тагын уникe айга озайтырга риза булып, чит илдә ялсыз-нисез ике ел эшләде.

Курмашев чит җирдә, бөтенләй чит-ят кешеләр арасында яшәсә дә, Дәүләтшина белән үзе арасындагы бәхәсне дәвам иттергәнен ан-

лап яшәде. Диссертация яклаган вакыттагы кебек, күңеленнән ул аның фикерләре белән килешми, үзенең хаклы икәнен дәлилләү өчен аргументлар эзли, тик шунысы гаҗәп — эссе ком чүлендә төзелә торган промыселның проектын эшләгәндә, җир астыннан нефтьне чыгарганда шундый-шундый чаралар кулланырга дип тәкъдим иткән вакытта, ул үзе кире каккан диссертациядәге расчетларны хәтерләп, шулардан файдалана иде. Ул үзенең нәрсәгә ирешергә теләгәнен генә түгел, аны ничек гамәлгә ашырырга кирәклеген дә белә. Һәм үз дигәненә ирешкәч сөенеп бетә алмый, аның рухы күтәрелә, җаны тынычлана бара иде.

Күңеленнән ул, теге вакыттагы шикелле, урамнан Дания Дәүләтшина белән янәшә атлап бара, аның тавышын ишетә сыман: Дәүләтшина нәрсәнедер кайтарып сорый, Курмашев җавап бирә, аннары үзе сорый һәм, шулай сөйләшеп бара торгач, кызып бәхәсләшеп китәләр. Билгеле, Курмашевның аргументлары нигезлерәк, төплерәк, Дәүләтшинаның килешми хәле юк. Ул ике кулын күтәрә дә: «Биреләм, биреләм. Каршы тора алмыйм!» — ди.

Ул, инде күп яшәп тормыш акылы җыйган олы кеше буларак, Дәүләтшинага түбәнчелек белән генә карый да: «Яшь шул әле, сыеграк! — дип куя. — Фән өлкәсендә иң мөһиме — артык мавыгып, ялгыш юлга кереп китмәү, ялгышмыйча, җиренә җиткереп зур, җитди эш башкару», — ди.

Курмашев аңа кыска гына бер хат язып салырга да уйлаган иде. Хатында, мин күзәтүләремне дәвам иттерәм, язып барам, бик бай материал җыеп кайтам, мин аны сезгә бирә алам — диссертациягездә файдаланырсыз, димәкче иде. Тагын бер уйлаганнан соң, бу ниятеннән кире чикте. Юк, алай ашыгырга кирәкмәс! Менә өйгә кайткач, институтка барыр... Бәлки, нәкъ диссертация яклаган чагына туры килер. Шунда чыгып сөйләр. Менә бу — сюрприз булыр, ичмасам!

Курмашев боларның буш бер хыял, җәй азагында таң алдыннан җир өстенә төшә торган алсу томан гына икәнен белә, тик мондый хыяллардан арына алмый, аның күңелендә, ихтыярыннан тыш, соңгарган теләк-омтылышлар, тормышка ашмый калган өмет чаткылары баш калкыта иде.

«Ярар, ашмаса ашмас, — диде ул, хисләнә белүне яхшы күреп. — Өмет, теләк, омтылышлар белән яшәү начар нәрсәмени? Күңелендә теләк булса, яшәү дәвам итә дигән сүз. Чынга ашмас хыял — кабул булган теләктән матуррак. Алар менә икәү бергә эшләсеннәр иде, Курмашев икәү тиң дәрәҗәле булып, хәтта аның кул астында эшләргә дә риза, тик күңел теләгән, күңел сораган бәхетле минутлар озаграк кына дәвам итсен иде.

Бервакыт ул үзенең хатыны, гаиләсе турында бик аз уйлавын искәрде. Бер-ике тапкыр гына күреп калган чит бер Дания Дәүләтшина турында уйлаганга караганда, үзенекеләрне шактый сирәк искә төшерә икән ул.

Курмашев моңа хәтта уңайсызланмады да, шундук акланырлык нигез дә эзли башлады. Моның нәрсәсе гаеп? Хатыны белән алар ничек яшәделәр соң? Хатыны йорт эшләре, көндәлек тормыш мәшәкатьләре белән үзалдына, Курмашев үзенең фән дөньясында үзалдына яшәде, кешеләр алдында да, үз-үзләре алдында да әйбәт, тату яшәгән булып күренергә тырыштылар...

Курмашев Алтын күл якларының нинди булуын күз алдына китерергә тырышты — үзе корган нефть вышкаларын күрде, шул вышкалар арасында, ямь-яшел кырда, ике як иң өстенә кечкенә-кечкенә канатлар тегелгән яшел брезент курткадан, башына зәп-зәңгәр яулык бәйләгән Дания Дәүләтшина хуҗа булып атлап йөри, имеш. Менә ул ашыга-ашыга урман эченнән, вышкалар арасыннан бара, аның артыннан, калышмаска тырышкан кебек, кояш күтәрелеп килә. Кояш

эллә кайда, җир читендәге бишегендә ял итеп, уянып торган да чалт иткән нурлы йөзе белән дөньяны яктыртырга ашыга сыман...

Курмашевның чит илдә техник эксперт вазифаларын башкаргандагы тырышлыгы, мәсьәләне киңрәк колач белән тиешенчә исәпләп хәл итә белүе андагы хуҗаларның күзенә чалынмый калмаган, күрәсең. Яңа нефть ятмаларын эшкәртү өчен төзелгән милли концернның президенты инженер Әхмәт Габбас бер көнне аңа болай дип сөйләде:

— Беләсезме, безнең промыселларда моңарчы бик күп төрле халык — американнар да, голландиялеләр дә, инглизләр дә, французлар да эшләде. Аларның максаты ап-ачык — капитал, табыш. Менә сез русларны, — президент Курмашевның кай җирдән килгәнлеген, аның милләтен белә иде, шуңа күрә сүзен төзәтебрәк әйтте: — совет кешеләрен аңлавы кыенрак. Сез эшкә бик бирелеп, нык эшлисез, әмма абруйдан башка үзегез өчен файда күрмисез.

— Аз нәрсәмени ул? Абруй дигәнегез бик зур капитал ул, аны бернинди акчага да сатып алып булмый. Американнар, инглизләр, французлар һәм немецларның безнең белән эш итәргә тырышулары очраклы түгел...

Бу әңгәмә зур гына бер портлы шәһәрдә, проектларны эшләп бетереп килгән вакытта булган иде. Шушы шәһәргә промыселлардан торбалар уздырасы, ягулык саклагыч резервуарлар корасы, океан танкерлары килеп туктарлык причаллар саласы бар иде. Инде эш сәгате беткән, чит илдән килгән экспертлар, бергәләп проектларны эшләшкән җирле белгечләр кичерәк кенә арзанлы бер ресторанда, эш хакындагы әңгәмәләрен дәвам иттереп, ашап утыралар иде.

Ресторан бик матур урынга — биек, иркен бер террасага урнашкан. Аста гына, нигез буенда, диңгез чайкала, бухтада бертуктаусыз буксирлар гүли, җиңел, җитез катерлар әрле-бирле йөреп тора, мазутка буялып каралып беткән ерак причалга озын бер танкер килеп туктаган, шуның койрык ягында япон флагы җилферди. Мачтасында да тагын бер флаг — өч почмаклы җете-кызыл әләм бар — анысы танкерның янып китү куркынычы булган йөк төявен искәртеп тора. Икенче яктан — ком чүле ягыннан — шәһәрнең бер катлы тәбәнәк йортларына түгәрәк металл резервуарлар килеп тезелгән.

Диңгез суы бирегә ерак океанның рәхәт сулышын алып килә кебек, шәһәр урамнарын ут кебек кыздырган чүл эссесе монда бөтенләй сизелми диярлек. Бөркү шәһәргә кайтасы килми иде.

— Бераз кофе эчеп утырабызмы? — диде милли концернның президенты Әхмәт Габбас.

Әхмәт Габбас әле шактый яшь күренә, яше кырыклар тирәсендә булыр, кайчандыр француз колледжы тәмамлаган, үзен Европа кешеләренчә нәзакәтле тота, шәрыкчә илтифат күрсәтә белә иде.

Өстәл янына, башын әдәпле генә иеп, кара чалбар, ак ефәк куртка, башына чуклы яшел түбәтәй кигән озын гына буйлы официант килеп баскач, президент Курмашевтан:

— Коньяк белән китертикме? — дип сорады.

— Ярый. Мөмкин булса, коньякны — аерым! — дип үтенгән сыман итеп әйтте Курмашев.

— Ул чагында ике өлеш итегез, — диде Әхмәт Габбас, официантка карамыйча гына.

— Коньякны боз белән китеримме? — дип сорады официант.

— Тешкә салкын тидермәбезме соң?

— Карап карарбыз. Китерсеннәр, — диде Әхмәт Габбас, официантка баш изәп. — Коньякка бер кисәк боз салырсыз, ярыймы?

Кофены кечкенә-кечкенә кара чынаякларга салып китерделәр. Эчемлек суынмасын, тәмле исе очып бетмәсен өчен аларның кечкенә генә капкачлары да бар иде. Коньякны озын таш графин белән китер-

деләр, рюмкалары да шундый таштан ясалган иде. Эре-эре боз кисәкләре салынган зур гына савытны түгәрәк аслык өстенә куйдылар.

Бик илтифатлы, игътибарлы официант зал белән кухня арасында тавыш-тынсыз, тып-тын гына йөреп, тегесен-монысын китереп тора. Стена эченә кертеп ярым түгәрәк рәвешендә эшләнгән кечерәк эстрадага өч музыкант, бер җырчы ханым чыкты.

Әхмәт Габбас, бер дә тартынып тормыйча, тегесен-монысын сораша, Көнбатыш Себердә, Идел буенда нефть табу эшенең ничек куелышы белән вак-төягенә хәтле кызыксына, бирегә чакырылган белгечләргә техник экспертлар итеп кенә түгел, бәлки безгә булышучы дус дәүләтләрнең вәкилләре итеп карыйбыз, ди. Курмашев үзенең асылда консультант, киңәшче итеп кенә чакырылган булуын, аның бурычы — расчетлар ясау, конкрет эш буенча теге яки бу киңәш бирү генә икәнен онытып җибәрде, эшкә тизрәк, кыюрак керешергә дип, кызып-үгетләп сөйли башлады, «без»гә күчеп, «эшләрбез, башкарып чыгарбыз, тиешбез»... дип тезеп китте.

— Сез русларның эше җиңел, — диде Әхмәт Габбас, әз-әзләп коньяк белән кофе йота-йота. — Сез бөтенесен дә үзегез эшли аласыз: разведка да ясыйсыз, машиналар, приборлар да. Нефтен дә эшкәртеп бетерәсез.

— Сез дә шулай итегез.

— О-о! Моның өчен күпме капитал кирәк!

— Булса соң.

— Без бит саткан нефть акчасына гына яшибез.

— Чимал белән генә сату итәргә ашыкмагыз сез. Хәзер бит егерменче гасыр, төп капитал — хезмәт. Американнар, инглизләр, французлар сезнең нефтьтән ясаган нәрсәләрне үзегезгә өч бәясе белән кайтарып саталар, сез аларны үзегез ясый аласыз ич.

— Алай бик ансат эш түгел шул ул. Уйлап карагыз: безнең банкларга нефть саткан акча бер генә көн кермәсә дә, казна бушап калачак. Шуннан соң импорт өчен каян акча алып түлибез, эшсезләргә, ятимнәргә, фәкыйрьләргә ни белән ярдәм итәбез, балаларны ничек укытабыз, студентларны ничек хәзерлибез? Безнең казна алай бик бай түгел шул, чит илләрдән килә торган акчадан башка яши алмый.

— Без дә шулай, юктан башладык. Әлбәттә, техника кирәк, яхшы белгечләр, материаль ресурслар кирәк, бу эшкә кайчан да булса керешергә кирәк. Иң мөһиме — эшне башлап җибәрү. Әнә, карагыз!..

Курмашев, сүзен әйтеп бетермичә, торып, парапет буена килде дә шәһәр аръягында ерактагы рәшәле офыкка таба тезелеп киткән ак металл резервуарларны күрсәтте.

— Сулдагылары инглизләрнеке, алар янында голландиялеләрнеке, ерактагы иң зурлары американнарныкы, — диде Әхмәт Габбас, Курмашев белән янәшә басып.

— Барыбер шәп түгел инде! — диде Курмашев, кызып китеп. — Уйлап табарга кирәк бит! Металл «сулый» бит ул, резервуарлардан җиңел фракцияләр — нефтьнең каймагы очып бетә. Аңардан бөтен әйберне ясарга мөмкин: мех, аяк киеме, бактерияләр, уенчык, синтетик тукымалар. Металл резервуарларда нефтьнең биш проценты югала. Миллион тонна нефть чыгарсаң — шуның илле мең тоннасы һавага очып бетә.

— Нефтьне кайдадыр сакларга да кирәк бит.

— Без нефть саклагыч резервуарларны җир астына төшерәбез, тимерле бетоннан эшләп, бер граммын да әрәм итмәячәкбез. Нефтьне сатканчы, аның әнә шул каймагын аерып алыгыз, нефтьне танкерга төяп, тиешле урынына илтеп җиткергәнче каймагы барыбер очып бетәчәк. Аннары аны теләсә ни эшләтә аласыз. Үзегез эшкәртегез дә чи

нефтькә караганда биш-ун мәртәбә кыйбатрак сатыгыз. Ярлылык ул — җитмәгәннән түгел, исәпләп эш итә белмәүдән дә килә...

Курмашевның сүзләрен бик кызыксынып, игътибар биреп тыңладылар, хәтта ресторан музыкантлары да коралларын бер читкә куеп тордылар. Үзенә бик зур белгеч, тирән белемле кеше итеп шундый хөрмәт күрсәтүләре Курмашевка бик ошый иде. Зур дәрәҗәле галим булуына ул яңадан ышана башлады, күңеле хозурлык кичергән шушы минутта аңа Дания Дәүләтшина белән ике арада килеп чыккан конфликт үзеннән-үзе хәл ителгән, очраклы бер аңлашылмаучылык булып кына тоелды.

## 14

Курмашев чит илдән үз машинасы белән кайтты. Дөрес, аның машинага әллә ни мохтаҗлыгы юк, башка профессорлар шикелле үк, ул да кирәк вакытта институт машинасын чакырта ала, ләкин хәзер шундый гадәт кергән инде: чит илдә эшләп кайтучылар үзләренең машиналары белән мактанырга яраталар. Ә ул башкалардан киммени?

Чит илдә чакта Курмашев машина йөртергә өйрәнде, Мәскәүгә кайткач, правасын яңадан яздырып алды, туган шәһәренә кайтканда инде ул машина йөртә белүенә тәмам күнегеп-гадәтләнеп беткән иде. Рульдә ул үзен бик иркен тота. Кешеләр яныннан узганда, миңа машина йөртү берни түгел дигәндәй, рәхәтләнеп як-ягына карангалап бара.

Вакыт бик тиз үтә шул, өенә кайтып баш-күз алганчы бер атналап вакыты узып та китте. Беренче көннәрдә Курмашев кайту белән үк эшләргә ниятләгән эшләренең берсен дә эшләмәде. Ул чит илдә чакта күңелен дәртләндергән изге ниятләре тормышка ашмый торган коры теләк кенә булганлыгын аңлады. Башта уйлаганда бик гади, бик ачык булып тоелган иде — менә ул кайту белән институтка барып, гыйльми секретарь янына керер дә, моннан ике ел элек мин хаклы булмаганмын, менә хәзер ул диссертациягә җитешмәгән аргументларны алып кайттым, аны яңадан яклатырга кирәк, дип әйтер кебек иде. Ләкин шул бик гади, табигый күренгән эшне эшләргә Курмашев үзүзен мәҗбүр итә алмады. Ничек була инде ул: күпме еллар буена эшләп, зур дәрәҗәгә ирешү, атаклы кеше бул да аннары көннәрдән бер көнне үзең үк әйт: минем ул казанышларым искергән, артта калган, дисеңме? Ул үз теләгеннән үзе курыкты, ихтыярыннан тыш, күңелендә икенче бер өмет уянды: бәлки әле Дәүләтшина иргә дә чыгып куйгандыр, гыйльми эшләрен ташлап, семья мәшәкатьләренә кереп баткандыр?

Курмашев шулай булуын, үз хәле элеккечә, искечә калуын тели иде. Яңадан аның үз-үзенә, үз тормышына ышанычы артты. Тик чит илдә чакта хыялы тудырган теләкләре генә кызганыч. Алдагы айлары, еллары бернинди хыялсыз-омтылышсыз, күңелсез узачагы гына аның җанын борчып тора иде.

«Бәлки, бу борчуларның барысын ташлап, гади генә, тыныч кына яшәрлек берәр җиргә китәргәдер?» — дип уйланды Курмашев.

Башта ул дачасына китәргә уйлады — аларның дачалары Идел буенда, нарат урманы эчендә иде — тик анда улы белән килене яшәгәнлеген, ул тирәдә кармак белән суалчаннан башканы белмәүче балыкчылар тулып ятканлыгын хәтерләгәч, анда бармаска, өендә калырга булды.

«Әллә Сарабикколга китеп барыргамы? Анда Алтын күл дә якын», — дип, туган ягын исенә төшерде... Курмашевның туган авылына сугыш вакытыннан бирле кайтканы юк иде бугай инде.

Начар булмас иде бит бу! Ял сорап алырга да җәй буена авылга, авылдашлары янына кайтып китәргә?! Авылдашлары атаклы галим,

профессор Госман Курмашевның шул авылдан чыккан кеше икәнлеген онытып та бетергәннәрдер инде. Искә дә алмыйлардыр. Анда аны кем юксынсын, кем сагынсын? Курмашев әтисе белән әнисен шәһәргә күчеп килергә күпме чакырса да, алар туган якны ташлап китәргә теләмәделәр, менә хәзер инде алар ак каенлы тыныч зиратта яталар. Абыйсы сугышта үлеп калды — Одерга җиткәч, йөрәгенә мина кыйпылчыгы тигән. Сеңелесе, Госман абыйсы шикелле, читкә китеп урнашты, күптән тормышта инде — үзе дә килми, абыйсын да чакырмый.

Чыннан да, туган җиргә кайтып, рәхәтләнеп бер ял итәргә, андагы халыкның ничек яшәгәнен күреп кайтыргадыр? Ул инде күптән шәһәр кешесе булып бетсә дә, зур җирнең кечкенә бер кисәге булган авыл аңа кадерле, якын, газиз түгелмени?

Авылның хәзер бик күңелле, ямьле чагыдыр! Иртәләрен авыл өстенә томан төшә торгандыр: томан башта җиргә, читән буйларына сыланып, чокырларга җәелә, аннары, кояш чыгу белән, авыл өстенә күтәрелеп юкка чыга. Елгада каңгылдашып-шаулашып казлар коена, бакча башларында, салынып төшкән кызыл кикрикләрен селкеткәләп, кәпәренеп кенә күркәләр йөри. Хәтта яңа фермалар да, манарасы сүтелгән иске мәчет өстендәге антенналар челтәре дә, трактор, мотор тавышлары да крестьян тормышының борын-борыннан килгән асылын үзгәртә алмаганнар: дөнья яралганнан бирле кешеләр иген игә, терлек асрыйлар, тырыш хезмәтләре белән бөтен илне туендырып торалар.

Кеше кем генә булмасын, никадәр генә югары үрләмәсен — ул барыбер үзен тудырган, ашатып-эчертеп үстергән шушы җирнең бер бөртеге генә.

Бу вакытта инде, билгеле, сандугачлар сайрамыйдыр: аларның сайрар чаклары узган: бала чыгарганнардыр. Ә менә болынга төшеп, авыл агайлары белән ярыша-ярыша печән чапсаң икән! Ә кичләрен учак янына җыелып, авыл агайларының явым-төшем, игеннәр турында, тормыш әхвәлләре, дөнья хәлләре турында ашыкмый гына гәп сугуларын тыңлап утыру үзе бер бәхет булмас идемени?!.

Ә төне тагы нинди — шул хәтле тын, шул хәтле рәхәт! Әрәмәлектә ара-тирә генә берәр кош сызгыргалап куя: башта ул сайрарга керешмәкче сыман итә дә тынып кала, таң атканны, көн туа башлаганны көтә. Елгада, тирән чоңгылда, җәен шупырдаганы ишетелә, су буендагы тал куакларына дулкын килеп бәрелә дә ярдан чупылдап балчык кисәге убылып төшә. Менә шунда, торып, якынрак барсаң, чуртан балыгының камыш кыштырдатып вак балык сагалап йөргәнен дә ишетерсең кебек.

Хәер, авылда нинди печән чабу булсын инде хәзер? Печәнне машина белән бер атна эчендә чабып ташлыйлардыр, кешегә үзенең көчен, тырышлыгын күрсәтерлек тә эш калмагандыр?! Кем хәзер аңа чалгы бирсен? Ул чалгычылар арасына басып, авыл агайлары белән беррәттән чалгы белән үлән кыдырып, теземгә салып бара аламыни?! Андый эшне хәзер оныткан инде ул, дәрт-дәрман да элеккечә түгел, бер буй чыкканчы ук сулышы кабып, хәлдән таяр. Алдагылар сине әллә кайда калдырып китәр, арттагылар, үкчәңә җитеп: «Әй, профессор, кызурак селтән! Үкчәңә чалгы тия бит!» — дип кычкырырлар.

Курмашев, туган авылын әллә кайда еракта калган сыман итеп күз алдына китергәч, туган йорт, газиз бала чак хатирәләре елдан-ел онытыла, күңеленнән чыга баруын уйлады һәм шуңа йөрәге ямансулап, әчетеп куйды.

Кайтканнан бирле узган бер атналап вакыт эчендә ул ничә тапкыр инде үз-үзенә: вакытны әрәм итмим, дип, сүз бирде, кичтән әйберлә-

ремне жыеп, багажникка, арткы урындыкка салам да, күчтәнәчләр, юл азыгы алам да, Маһирә ханымны утыртып, Сарабикколга, Алтын күл буена китәбез, дип ниятләде.

Ләкин көн артыннан көн үтте, Курмашев һаман җыенып чыгып китә алмады. Ни сәбәптәндер аның шәһәрдән чыгып китәсе килми, тик үзен нинди сәбәп тоткарлаганын төшенеп җитә алмый иде.

Дөрес анысы, бер тапкыр ул хатынына: «Авылга кайтып, җәйне шунда торып килмикме? Авылны күрербез, кешеләрне», — дип әйтеп тә карады, тик Маһирә ханым шундук аның авызын каплады!

— Әйттең сүз! Авылның нәрсәсен күрмәгән без? Фермаларын, сыерларынмы? Анда кайтканчы, әнә санаторийга китәр идем әле. Башкалар путевка таба алмый, ә без ялкаулыгыбыз аркасында кузгалырга куркып ятабыз, — диде, сәерсенеп кашларын гына җыерды.

Шулай итеп, көн артыннан көн узды, Курмашев дачага да, Сарабикколга да бармады, чит илдән кайткан чакта күңелен җилкендереп торган шатлыгы сүрелеп баруын, ниндидер шом-борчу басуын тойды.

Күңеле теләп эшләгән бердәнбер эше — хатыны белән базарга барып кайту иде. Монда да ерак авыллардан килгән кешеләрнең ни-чек, нинди шөгыль белән яшәүләрен күрәсең. Курмашев иртән торгач, җиңелчә генә капкалап, кофе эчеп ала да Маһирә ханымны машинасына утыртып, колхоз базарына китә.

Бу дөньядан күпме хәлләр кичсә дә, базарлар бер дә үзгәрми икән, дөньяның шушы кечкенә генә бер почмагында вакыт-заман дигәнең, бер нәрсәгә тимичә-кагылмыйча, бөтенләй тукталып калган кебек. Нинди генә халык юк монда: мактый-мактый җимеш сатучы үзбәк, әзербәйҗан, грузиннар да, тирә-як авыллардан тозлы помидор, кыяр, гөмбә китергән рус түтәйләре, товарны артык биреп җибәрмәгәем дип курка-курка гына үлчәүче чуваш, мари, мордвалар да бар. Мең төрле тавыштан базар эче гөжләп-гүләп тора.

Курмашев Маһирә ханымга ит, җиләк-җимеш, яшелчә сайлап алыша, авылдан килгән татар апайларының кызык кына итеп русча сөйләшүләрен тыңлый-тыңлый, базарда йөри.

— Җәичке каму? Бири кислый малака! Мюд йис, мюд!.. — дип кычкыралар.

Алар белән бераз шаяртып аласы да килә. Ул пычак яки кашык очына гына эләктереп, бал кабып караган була, балың чын түгел, ширбәт кушылган, ди, я сөтеңнең өстен җыеп алгансың, ди. Сатучы хатыннарның моңа ачулары килә, аны прилавка яныннан куып:

— Ни хучеш — ни нады. Хади магазин, там бульны хураша! — диләр.

Базардан кайткач, Курмашевлар аш хәзерләргә керешәләр.

Хәер, ашны Маһирә ханым гына әзерли. Кухняда мәш килеп, тегесен-монысын пешерешә. Курмашев шунда аның аш-суга оста, җитез булуына сокланып карап утыра. Менә Маһирә ханым кай арада гына яшелчәсен турап, каймаклап салат та ясап өлгерде, өй эченә укроп, Маһирә ханым әйткәнчә, бер ашасаң да ун елга яшәртеп җибәрә торган яшел кычыткан ашы исе таралды, плитәдә өсте капланган табада сыер ите чыжылдап кыза башлады. Ни генә дисәң дә, үз өең — үз өең шул инде, үзең теләгәнчә эшлисең, җаныңа рәхәт: нинди шәп санаторийлар да, чит ил кунакханәләре дә алмаштыра алмый аны!

Курмашев яңадан үз өендә, якын кешеләре янында булуына сөенеп бетә алмый иде. Күңеле тәмам тынычланып, ул, моннан ары башкачарак яшәргә кирәк булыр, дип, үз-үзенә сүз бирде. Әмма ни рәвешле башкарачак яшәр — анысын күз алдына китереп бетерә алмый иде әле.

Ниһаять, ул институтка барып килергә кирәк дигән карарга килде: санаторийга путевкалар сораган иде, шуны белешергә кирәк, югыйсә, икенче бер кешегә биреп куюлары да бар. Юк, ул начальствоны борчып тормас, вахтер белән генә исәнләшеп, коридордан узар да Яхин янына керер. Моңарчы алар нигә күрешмәделәр соң әле? Үзләре сабакташлар, дуслар, сугышта да бергә йөрделәр бит!..

Курмашевның кайтканын Яхин ишетмәгәндер, күрәсең, югыйсә, әллә кайчан килеп җитәр иде! Күрешеп исәнләшкәч, бераз сөйләшеп утырырлар да Курмашев: «Хәлләр ничек соң монда? Мәш киләсезме һаман?» — дип сорар. Яхинның берәр житди эше булмаса, сыра яки башкасын алырлар да шәһәрдән чыгып, берәр күл буена яисә Иделгә үк китәрләр.

Дөрес, Курмашевка аракы эчәргә ярамый, врачлар бу хакта аңа кисәтеп әйттеләр. Хатыны да, син минем ачуымны китерер өчен кәеф чигеп йөрисең, дияр. Әйтсә әйтер инде! Тегеләй ярамый, болай ярамый, дип, күпме тыелып яшәргә мөмкин?!

Яхин үзгәрде микән, шул ук микән? Шул уктыр: тыз-быз килә, ашыга-кабалана торгандыр, гадәтенчә, төрле вак-төяк эш-мәшәкатькә чумгандыр. Башкалар җәйләрен бушка әрәм итмиләр, кайсы кая китеп беткәндер, ә ул һаман җигелеп эшли, көзен яки яңа ел җитәр алдыннан гына ял итәргә кирәклеге исенә төшә... Бераз картая төшкәндер, башындагы соңгы бөдрәләре дә коелып беткәндер. Егерме яшендә генә ул гомер узуның эзе сизелми, илледә гомернең һәр көне үз тамгасын калдырып китә: биткә җыерчыклар сыза, чәчкә чал өсти, яки тагы да яманрагы — берәр авыру китерә. Яшь чагында Яхинның бөдрәләре нинди матур иде бит! Бигуди белән борып ясаган шикелле, эре-эре бөдрә иде. Курмашев аның ул бөдрәләренә кызыга торган иде, чөнки үз чәчен күпме тараса да, тиешле җиренә үзенә ошаганча яткыра алмый иде.

Бәлки Яхин әле һаман да аңа карата ачу-үпкә саклыйдыр? Шуның өчен килмидер? Һи, юләр!..

*
* *

Чит илгә китәр алдыннан Курмашев, якын дус-ишләрен, шул исәптән Яхинны да чакырып, саубуллашу мәҗлесе сыман бер нәрсә үткәргән иде. Шунда ике араларында Яхинның һаман да кандидатлык диссертациясен якламавы турында сүз чыгып, бәхәсләшеп киттеләр һәм бер-берсенә шактый чәнечкеле сүзләр әйттеләр.

Ул вакытта алар аңлаша алмадылар. Курмашев үз фикерендә калды, Яхин аның фикере белән килешмәде. Кызык: әгәр Яхин хәзер бөтенләй үзгәргән булса, вак-төяк оештыру эшләрен ташлап, диссертациясенә керешкән булса, диссертациясен якларга Курмашевны зарыгып көтеп торса? Әкәмәт бер могҗиза булыр иде бит бу!..

Курмашев килеп кергәндә Яхин үз кабинетында иде. Гаҗәпкә каршы, бөтен эшен эшләп бетергән сыман, беркая да ашыкмый, кабаланмый иде ул. Кулына ипи тотып, ачык тәрәзәдән чыпчыкларга ипи ашатып тора иде. Әрсез чыпчыклар, очып килеп, ипигә ташланалар да күбрәк чукып алырга тырышалар, Яхин исә көлә-көлә аларны котырткан була: «Кап, кап, әләктер. Хәзер икенчегез. Тагын кап. Шулай, шулай, молодец! Чыпчык түгел — бөркет болар!» — ди, ә үзенең бөтен кыяфәтеннән бу минутта аның уенда чыпчыклар түгел, бәлки чит кеше күзенә күренми торган бөтенләй башка нәрсә иканлеге сизелә иде.

Курмашев җайсызрак вакытка туры килүен кызганып куйды. Кешегә комачауламаска иде бит! Ләкин ул, уңайсызлануын шундук җиңеп, түргә таба атлады. Хәзер ул менә арттан килер дә Яхинның күзләрен кысып алыр — кем кысканын белер микән?

Кабинетның хуҗасы, бүлмәгә кемдер кергәнне сизеп, ялт кына борылып карады, әмма Курмашевны күргәч аз гына да гаҗәпләнмәде, әйтерсең алар әле моннан бер-ике сәгать элек кенә аерылышканнар. Әкәмәт тә кеше инде!

Дөрес анысы, Яхинның күзләре чаткыланып-ялтырабрак китте, йөзенә шат-шаян бер төс чыкты һәм ул:

— О-о, нинди мут булып кайткан бу! Мыек үстереп җибәргән! Чын гарәп түрәсе булган! — дип күрешергә кулын сузды.

— Килешәме? — диде Курмашев, мыегын сыпыргалап.

— Бик шәп. Хатын-кызның күзе гел синең мыекта гынадыр инде?

Дусты мыегын мактавы Курмашевның күңеленә бик хуш килде, шулай да ул аның мактавына кушылып китмәде, кулын гына селкеп:

— Ярар, арттырма. Кая инде ул хәзер безгә хатын-кыз күзенә күренү! Борын астың буш булмаса — шул җиткән, — дигән булды.

Алар шактый озак сөйләшеп утырдылар. Яхин кемнәрнең докторлык диссертациясе тәмамлавын, кемнәрнең өметле күренүен, үсеп килүен тиз-тиз генә санап-әйтеп үтте. Курмашев башын гына чайкады, «Кара, нинди молодец! Шулай укмы? Кирәк бит!» дигәләде һәм ахырда институтка ни өчен килүен хәтерләп, кулы белән өстәлгә шапылдатып алды да:

— Кара әле, Зөфәр, акыллым, — диде. — Без юк-бар белән баш катырып, гомер черетеп ятабыз, әйтерсең яңарак бирәр нәрсә уйлап табарга безнең башыбыз җитми. Әйдә бер сәйран кылып кайтабыз! «Ягулыгын», тегесен-монысын алабыз да Идел буена куна китәбез, ә? Учак ягып җибәрербез, гәп сугарбыз, утка карап хыялланып ятарбыз. Теге җирләрдә учак та яга алмыйсың — анда эссе ком чүле генә. Машинам бар, теләгән җиреңә җилтерәтеп кенә алып барып җиткерермен...

Курмашев бу тәкъдимен бик урынлы әйткәнлеген абайлады, Яхинның да машинага утырып кына Идел буена китәсе, учак янында төн кунасы килә иде, әлбәттә.

— Гөнаһларым булмаса, оҗмахка гына керер идем, дип әйткән ди берәү, — диде Яхин. Эчтән яктырткан ниндидер нуры сүнгән сыман, аның чырае кинәт сүрелеп, караңгыланып калды. — Соңгы тапкыр Идел буенда кайчан булганымны да хәтерләмим инде. Бик барасы иде дә... Шулай да, әйдә, икенче бер вакытка калдырып торыйк бу нәрсәне. Сиңа кайчан эшкә чыгасы әле?

Курмашев уңайсызланып калды, ниятләгән эше болай булып чыгар дип һич уйламаган иде ул. Ярый, дус, сабакташ булуларын исәпкә алмыйк, ди! Профессор, фән докторы, бөтен илгә атаклы бер белгеч гади бер хезмәткәргә, фәндә иң кечкенә дәрәҗәле бер кешегә үзенең компаниясен тәкъдим итә, ә ул: «Әйдә, икенче бер вакытка калдырып торыйк», — ди. Сөйләшә белә кешеләр!

Курмашевның иртәннән башланган күңел күтәренкелеге әкренләп сүрелде, аның урынына ниндидер бер үртәлү тойгысы, ачу баш калкытты.

Ул Яхинга ни дип җавап бирергә дә белмәде, дәрәҗәсен җуярга теләмичә: «Кара аны, әйтүем хак булсын», — дип шаярта да алмады, саубуллашмый-нитми, үпкәләп чыгып китәргә дә яхшысынмады...

Шул вакытны, ишек ачылып китеп, кабинетка... Дания Дәүләтшина килеп керде.

## 16

Курмашев бу очрашуга күңеленнән әзер иде, аны, иртәме, соңмы дигәндәй, я бередә, я теге бистәгә барып күрәчәген белә иде, ләкин ул очрашуның соңрак, бүтән бер җирдә, чит кешеләрдән башка гына булуын тели иде. Ә монда, Яхин янында очрашу... Курмашев уңайсызланыбрак калды, йөзе кызара башлавын, чигәләре чәнчешүен тойды.

Дәүләтшина да Курмашевны, араларында булган хәлләрне онытмаган иде, күрәсең. Ул да беравыкка каушабрак калды, узаргамы, кире чыгып китәргәме дип, ишек төбендә икеләнеп торды.

Шулай да оялчанлыгын җиңде, өстәл янына кыю гына килеп: «Исәнмесез», — диде, урындыкка утырмады, дәрәҗәсен белеп, әдәп белән генә: «Гафу итегез, мин бер генә минутка», — диде дә йомышын әйтергә керешге.

— Зөфәр Садыйкович, — дип, Яхинга мөрәҗәгать итте, — балалар дачасына баргач, минем кыз белән дә кызыксыныгыз әле. Аның беркеме дә юк дип уйламасыннар. Кызганып карамасыннар. Аңа кызгану кирәкми, башкаларга караган шикелле үк карасыннар. Минем бераз тоткарлануым ихтимал, төрле хәл килеп чыгуы мөмкин бит. Сез аны, зинһар, икенче срокка да калдыртыгыз инде. Менә гариза яздым...

Ул шыртлатып сумкасын ачты да өстәлгә бер бит кәгазь чыгарып салды.

Яхин, кәгазьгә күз төшереп алгач, Дәүләтшинага күтәрелеп карады да:

— Сез әллә чит илгә турне ясарга җыенасызмы? — дип сорады.

— Нинди турне булсын?! Без анда концерт куеп йөрергә бармыйбыз, эшләргә барабыз. Шуннан туп-туры Самотлорга очам, аннары, Камада тагын бер нефть ятмасын эшкәртергә керешәләр, анда да барып чыгарга кирәк. Баланы үзем белән алып йөри алмыйм лабаса. Анда бала-чага түгел, олылар да муен сындырыр. Юлы да юк, торыр җире дә, эшне яңа башлыйлар гына әле!

— Ярар, бер дә борчылмагыз, Дания Салиховна! Барыгыз, барыгыз, конгресста уңыш телим үзегезгә. Борчылмагыз, монда без барысын да оештырырбыз, барысын да эшләрбез!

Хатын-кыз барында утырып торуны Курмашев яхшысынмады, урыныннан торды. Хәзер алар өстәл аша гына кара-каршы басып торалар иде. Дания Дәүләтшина карашын аңардан читкәрәк юнәлткән, туры карарга кыймый иде, күрәсең. Курмашев, киресенчә, юри аның йөзенә текәлгән, шушы ике ел эчендә аның никадәр үзгәргәнлеген чамалый сыман иде.

Хәер, үзгәреш күп юк иде. Өс-башы теге чактагы шикелле үк гади, бик ыспай. Гәүдәсенә сыланып, тыгыз күкрәкләрен белгертеп торган ачык якалы йон кофта, муенына нәфис алтын чылбырлы, патша хатыны Нефертити сурәте төшерелгән модный медальон таккан. Чәчләрен буятмаган, кистермәгән дә — толымлап үреп, баш артына төйнәп куйган. Зур соры күзләре шактый кырыс карый. Шул ук вакытта беркадәр хәйләкәрлек, шаянлык та сизелә сыман. Дөрес, кулбашлары итләчләнә төшкән, шулай да буй-сынында кызлар зифалыгы әле күзгә ташланып тора. Чырай-кыяфәтендә дә балаларча беркатлылык белән олы сымак җитдилек бар кебек иде.

Курмашевның аның квартир хәлләрен, ничек яшәвен беләсе килә, бәхетлеме сез? дип сорыйсы килә иде. Ләкин араларында алай сорашырлык якынлык булмагач, яхшысынмады: теге диссертация яклагандагы хәлдән соң аның иң яхшы ният белән сорашуы да әрсезлек, кешене рәнҗетү булып тоелыр сыман иде.

Курмашев ул хәл онытылыр, күктә атылып сүнгән йолдыз шикелле, хәтердән эзе җуелыр дип уйлаган иде. Шулай булуын бик теләгән иде, ләкин, бактың исә, онытылмаган, хәтердә һаман саклана икән әле...

Дәүләтшина теге вакытта да Курмашевка нык характерлы, ихлас күңелле булуы белән ошаган иде. Хәзер менә аның Яхин белән сөйләшкәнен, кызын балалар бакчасының җәйге дачасына урнаштыру хакында үтенүен тыңлап торганда Курмашев аның үз-үзен тотышына тагын таң калды. Ул аны нибары өченче тапкыр гына күрә, әмма күргән саен Дәүләтшина яңа бер кеше сыман тоела иде. Хатын үзен бик табигый, гади тота, шәрыкчәрәк йөзенә килештереп сөрмәләнгән күзләре игътибар белән җитди карый, шул ук вакытта мөлаемлыгы, хатын-кызга хас назлылыгы да сизелеп тора.

Курмашев шунда бер нәрсәне төшенде: ул чит илдә йөреп кайткан арада Дәүләтшинаның тормышында зур гына үзгәрешләр булган булырга тиеш, тик Курмашев нинди үзгәрешләр икәнен генә чамалый алмый иде.

«Билгеле инде, иргә чыккан, гаилә тормышы килешкән үзенә»,— дип уйланды Курмашев. Элегрәк ул аның тормышка чыгуын теләсә дә, бу юлы моны кызганыч бер хәл сыман итеп тойды. Кешеләр өйләнешәләр, гаилә коралар, әйбәт буламы, начармы — аларның тормышы алда әле, ә менә Курмашевныкы үтеп китте инде, андый чакка яңадан кайтып булмый шул инде. Кызык: диссертациясе ни хәлдә икән бу ханымның?

Дәүләтшина үзен гади генә тотса да, тартынуы сизелеп тора иде. Ул Курмашевның шулай әрсезләнеп, төбәлеп каравыннан уңайсызлана иде, күрәсең: нәфис колак яфраклары, диссертация яклаган вакыттагы кебек, мүк җиләге төсле кызарып чыккан иде. Курмашев бая, теге очрашуны Дәүләтшина да онытмагандыр, мин командировкада чакта ул да минем турыда уйлагандыр, дип фараз итүенең дөрес булуын төшенде. Шуннан соң кәефе яхшырып, күтәрелебрәк китте, Яхинга булган ачуы да сүрелде.

Ул Дәүләтшинадан диссертациясе хакында сорамакчы, төзәттегезме, яңадан якларга хәзерләнәсезме? димәкче иде дә шул вакыт — кирәк бит! — үзенең аны озата баруы, коньяк, чәй эчүләре, бәлеш ашаулары, яңа квартирын котларга бер шешә шампанский күтәреп килергә вәгъдә итүе исенә төште. Хәтеренең шулай яңаруына шатланырга да, пошынырга да белмәде. Башын чайкап куйды да ярым шаярткан бер төстә:

— Хәтерегездәме: сез, квартир алам, дигән идегез, мин бер шешә шампанский вәгъдә иткән идем? Ике вексельнең дә срогы чыкты. Әйбәт түгел бит! — дигән булды.

Дәүләтшина кызарып китте, Курмашевка әллә ничек кенә сәерсенебрәк карап алды, бер мизгелгә генә күзләрендә каушау галәмәтләре сизелде.

Курмашев, моның иргә чыгуы дөрес икән, шулай булгач, кинаялар ясап, сүз кушып торасы юк, дип уйлап, авыр сулап куйды.

Дәүләтшина, Курмашевның шелтәсен бөтенләй ишетмәгәнгә салышып, Яхинга таба борылды да:

— Алайса, мин киттем, ярыймы? Мин анда артык тоткарланып тормам: барам да кайтам, — диде.

— Алай бик ашыкмагыз, — диде Яхин. — Чит илгә баргач, андагы халыкның ничек яшәгәнен дә күреп кайтырга кирәк. Кызыклы да, файдалы-гыйбрәтле дә була ул.

— Эшем күп, җитешеп булмый. Шуннан туп-туры Себергә китәм. Сезгә рәхмәтемне алдан ук әйтеп куям!

— Нинди рәхмәт инде ул тагы?! — диде Яхин, башын чайкап. —

Кызыгызны урнаштырырбыз, бер дә борчылмагыз. Тыныч булыгыз. Чит илдән вак-төяк сувенир сыман нәрсәләр алып кайтыгыз.

— Значокмы? Чәйни торган резинамы?

— Шул гына җитмәгән иде! Киноактрисалар сурәте алып кайтыгыз. Хәзер андый нәрсәләр бик модный бит.

Яхин болай дип, әлбәттә, шаяртып кына сөйләшә иде, Дәүләтшина исә, беркатлы җан, аның һәр сүзен чынга алып, үтәргә риза булды.

— Алып кайтырмын, альбомыгызны әзерләп куегыз.

— Юк, юк! — диде Яхин, кулын селкеп. — Берүк карап алыгыз. Андагы халыкның әдәп дигән нәрсәгә бик исе китми — фотога теләсә ничек төшәләр. Сезнең ул артисткаларыгыз минем хатын кулына эләксә — алла сакласын!..

Дәүләтшина елмаеп кулын гына селекте дә:

— Аңлашылды. Ярар, борчылмагыз, берәр нәрсә табармын әле, һәрхәлдә, диңгез аръягыннан атом бомбасы алып кайтмам! — диде.

Ул тагын бер тапкыр Яхинга рәхмәт әйтте дә Курмашевка да сүзе бар шикелле күтәрелеп карады. Тик әйтәсе итмәде, ахры, баш кына какты да чыгып китте.

## 17

Коридорда аның аяк тавышы тынгач, Яхин:

— Бик булдыклы, акыллы хатын. Андыйлар аз хәзер, — дип куйды.

— Укымышлымы? — диде Курмашев. Ә үзе, ни сәбәптәндер, Дәүләтшинаның кире керүен тели иде.

— Хикмәт анда түгел, — диде Яхин. Пошынгалап башын чайкады. — Укымышлылар күп, акыллылары аз. Ә бу — бик башлы хатын, уран белән эш итәргә, атом төше физикасы белән шөгыльләнергә куш — анысын да булдырыр. Читтән караганда, бик тыйнак, оялчан гына бер хатын кебек, ә үзе эшен белә. Каян килә кешегә андый сәләт? Мин көнләшеп тә куям хәтта. Ничек ул үзенең әлеге идеясен бик вакытында уйлап табып, нәкъ кирәкле җиренә туры китергән диген?! Ни өчен мин диссертацияне ташладым? Дәртләнеп керешеп китәрмен, илһам табармын, мин әйтәм. Эшкә тотынгач, карыйм — юк, барып чыкмый, ерунда. Мин теләгән нәрсә түгел. Ни кыйрата алабыз без? Егерменче гасыр, җир тирәли спутниклар оча, лазер уйлап чыгардылар, рак авыруын гади трахома шикелле итеп кенә дәваларга җыеналар. Безнең кымшанудан гына әллә ни мәгънә чыкмый. Алга карамыйбыз — койрыкта сөйрәләбез без.

Курмашев башта, Яхинның Дәүләтшинага ачык йөз, йомшак мөгамәлә күрсәтүе аның профсоюзда шундый эштә утыруыннан һәм Дәүләтшинаның сөйкемле, чибәр хатын булуыннан, дип уйлаган иде. Ләкин соңга табарак Яхин тегеңә уңышлар тели, борчылмагыз, тегебу дип аны тынычландыра һәм саубуллашкан вакытта шаярта да башлагач, Яхинның башкача эшли алмавын аңлады. Дөрес! Һәркем үзе теләгәнне, үзенә ошаганны гына түгел, бәлки сәләтеннән килә, кешеләргә файда китерә торганны эшләргә тиеш!

— Карале, аның диссертациясенең хәле ничек? Хәтерендәдер: теге вакытны яклый алмаган иде. Яклады мы инде?

— Юк бугай. Фәнни эшләр миңа кагылмый бит. Ишетүемчә, Мәскәүдә аны хуплап күтәреп алганнар, шунда яклатырга җыеналар, ди. Хәзер Самотлорда, бөтен Себер промыселларын аның ысулы буенча коралар бит. Күрдеңме — халыкара конгресска бара, нефть ятмаларын эшкәртүдәге перспективалы методлар турында чыгыш ясаячак. Хәзер нефть — бик зур нәрсә бит!

— Мәскәүнең монда ни катнашы бар соң? — дип, кашларын җыерып сорады Курмашев. Бу эшкә Мәскәүнең катнашуына әйтерсең Яхин гаепле иде. — Бу эш бит бездә эшләнгән, мәскәүлеләр аны үз эшләре итеп күрсәтмәкчеме?!

Яхин җилкәсен сикертеп, телен генә шартлатты:

— Башкала шул, берни эшләп тә булмый...

— Фәндә нинди башкала ди ул? Ачышны кайда ясаганнар, кайда тапканнар — шунда аның башкаласы. Мәскәү — башкала, ә менә парамагнит резонансының туган җире — Казан! — диде Курмашев, үз сүзен куәтләп.

— Турысын гына әйт син — Дәүләтшинаның ачышын анда күргәннәр, таныганнар, диген. Беренче тапкыр пар машинасын рус механигы Ползунов ясаган, ә кешелек дөньясы инглиз Уайтны беренче дип таныган...

— Мисалларны мәктәп дәреслегеннән китерәсеңме? — диде Курмашев, бәхәскә керешеп.

— Алайса, яңарак факт та китерә алам. Нигә менә син Дания Дәүләтшинаның ачышын күрмәдең, Мәскәү галимнәренә калдырдың аны?

— Фәндә күрәзәчеләр юк.— Курмашев тыныш ясап алды да, катгый бер тавыш белән: — Һәм булмаячак та! — диде.

— Дөреслек — бер, ялгышлык — мең. Шулаймы?

— Нәкъ шулай. Колумб үзен Һиндстанга барып җиттем дип уйлаган булган да, караса — Американы ачкан икән. Эйнштейн әйткән: атом төшен беркайчан да таркатып булмаячак, дигән...

— Хәтта Наполеон да, — дип өстәде Яхин, ниндидер астыртын бер мәгънә белән.

— Әйе, Наполеон да, — диде Курмашев, аның сүзен бүлеп. — Ул үзен галимнәрне яклаучы бер кеше дип санаган, ниндидер максат белән фәннәр академиясенә дә баргалаган, ә менә аның янына Фултон килгәч, җилкәнле корабларга пар машинасы куйсак, Британия флотын тар-мар итәбез, дип, үзенең тәкъдимен әйткәч, Наполеон аны чудак; фанатик дип атаган. Тәхеттән төшерелгән императорны инде җилкәнле корабта изге Елена атавына озатканда, аларның корабын пароход узып китә. Шул чагында Бонопартның нәрсә уйлаганын чамалыйсыңмы?

— Син дә Бонопарт булам дисеңмени? — дип, чәнечкеле соравын төртте Яхин. — Кешеләр бер-берсенең әчке яхшы сыйфатларын үстерергә тырышсалар, кимчелекләрен гафу итсәләр, нинди яхшы булыр иде. Тормышта киресенчә шул: иң элек синең ялгышыңны күзенә бәреп әйтәләр. Бигүк күңелле булмаса да, тулаем дөрес. Иң беренче кеше булып диссертацияне син укыдың бит, яклаган вакытта аны яраксыз дип кире кактың, ә хәзер дәгъваңны белдерәсең!..

— Алай булмый, алай ярамый дисеңмени син?

— Гомумән алганда — мөмкин. Ә менә конкрет фактлар, таныш кешеләр турында сүз барганда алай ярамый! — диде Яхин. — Син ул хезмәтне аңламагансың, аның асылын, әһәмиятен күрмәгәнсең икән — ул чагында нинди галим инде син? Белә торып каккансың икән — анысы инде берниндн киртәгә дә сыймый. Гадәттәге мин-минлек чире! Янәсе, мин — дөньяның кендеге!.. Берише кешеләр башкаларның талантын күрергә сәләтле, икенчеләре үзеннән башка берәүне дә өскә чыгармаска тырыша. Үзе ул, әлбәттә, бик акыллы кеше, ә менә аның тирәсендә чуалучылар — вак-төякләр генә. Аларның бар кирәклеге — һәр нәрсәне хуплап тору, каршы сүз әйтмәү, ялагайлану. Нигә алай? Хикмәт шунда: бөекләр арасында алай ук калкып тора алмыйсың, ә бәләкәйләр арасында бөек булып йөрү — ансат.

— Димәк, мин — дөньяның кендеге, бәләкәй кешеләр арасында бөек булырга тырышам? — диде Курмашев, дустының күзенә туп-туры карап. Яхин да каушап төшмәде, шундук җавап кайтарды:

— Изге адәмгә салышма! Янәсе, менә мин нинди әйбәт кеше— үзем өчен күңелле булмаса да әйтәм, имеш. Шулаймы? Син үзеңне зур кеше дип санарга гадәтләнгәнсең, баскычның иң югары басмасын үзеңә алгансың да башкаларны түбәнрәк урнаштыргансың, көннәрдән бер көнне сәләтлерәк, талантлырак икенче берәү калкып чыга да аның синең белән тигезләшүе, аннары узып китүе дә ихтимал. Син инде менә шул кешенең башыннан басасың. Телең белән син — изге, ә табигатең белән — мәртәбә сөюче вак көнче.

Бу ике кешенең берсе фән докторы, профессор, зур белгеч, икенчесе исә кандидатлык диссертациясе дә язып яклый алмаган булса да, бәхәсләшкәндә алар үзара хәтер саклап тормыйлар, турысын әйтеп сөйләшәләр, чөнки бер-берсен кеше буларак тиң саныйлар иде. Ләкин Курмашев бу юлы инде дустының сөйләшүендә дусларча чеметкәләү генә түгел, усал итеп тешләү барлыгын да тойды. Шуңа хәтере калып: «Минем Дәүләтшина хезмәтенең яхшы ягын күрмәвемә сөенә!» — дип уйлап куйды. Чыннан да, аның Яхинга нинди начарлык эшләгәне бар соң? Үзенең диссертациясен яза алмаганга Курмашевтан үч аламы? Нигә килде соң әле ул шушы Яхин янына, җыен пычрак сүз ишетер өченме?

## 18

Яхин исә Курмашевның бу минутта ни кичерүенә игътибар да итми, аны нindидер үз уйлары борчый сыман иде. Шуңа ул, бөтенләй көтмәгәндә, тагы да катырак суктырып әйтте:

— Син үзең доктор булсаң да, бик акыллы димәс идем мин сине! Каян алдың әле син квартирга күчү дигән сүзне? Минем белүемчә, ә мин тәгаен беләм, синең аспиранткаң беркая да күчкәне юк, шул ук частный фатирында яши.

— Ничек күчкәне юк? — диде Курмашев, төзәтеп булмаслык коточкыч зур ялгыш эшләгәнен аңлап.

— Күчәр җире булмагач, кая күчсен?! Әллә айдан төштеңме син?

— Нигә күчәр җир булмасын?! Бөтенесе әзер иде бит инде, ордер гына яздырасы калган иде. Мөгаен, үзең вакытында тиешенчә эшләп җиткермәгәнсеңдер. Мероприятиеләреңә кереп баткансыңдыр!..

— Бик тиешенчә, бик вакытында эшләдем, — диде Яхин, сабыр гына. Тавышы тыныч булса да, сүзләреннән нindидер усаллык сизелеп тора иде. Курмашевка әллә нинди аңлаешсыз, куркыныч бер көч үзен караңгы упкын өстенә күтәрә сыман тоелды, аның шул упкынга карыйсы, төбендә ниләр барын күрәсе килә һәм шул ук вакытта үзе бу теләгеннән курка да кебек иде.

— Мероприятиегә кереп батканмынмы?! — диде Яхин, аны үчекләп һәм торды да тәрәзә каршына барып басты. — Монда кергән чагында күрдеңме: мин чыпчыклар ашатып тора идем? Чыпчык ул беркатлы, аңгыра кош, хәйлә-мазар белми, берәр нәрсә эләктерергә теләсә, туп-туры, яшеренми-нитми килә. Ә менә кешене алай тиз генә белеп булмый. Глобаль масштабта фикер йөртү ансат ул — уйлау белән үк бөтен кешелек дөньясы күз алдына килә. Бөтен дөнья революциясе белән чагыштырганда аерым шәхес — тузан бөртеге шикелле генә булса да, син аның каршында дәрәҗәңне төшермә. Беләсеңме, революцияләр нәрсә аркасында ясала?

— Нәрсә аркасында соң? — дип сорады Курмашев, Яхинның сүзенә ияреп.

— Әнә шуның аркасында, әнә шул кечкенә кеше аркасында, табигатебезнең тузан бөртеге аркасында... Фәлсәфә сата башладыммы?

Яхин тәмам кызып китте. Сүзен тыңлыйлармы, юкмы — аның өчен хәзер барыбер иканен Курмашев белә иде.

— Син мине бюрократ, чиновник дип атадың, ә үзеңне эксперт, судья итеп куйдың. Ә чынында кем судья икән соң әле? Дәүләтшина синең аркада квартирга күчми калды түгелме? Син бит болын чаклы квартирыңны горисполкомга тапшырып, ике аерым квартир алырга тиеш идең. Шулай түгелме?

— Шулай.

— Син үзеңнекеләрне аерым квартирга урнаштырдың, ә искесен, сөйләшенгән булса да, тапшырмадың.

— Тапшырырга өлгермәдем.

— Чит илгә киттең шул, әнә нинди мыек үстереп кайткансың. Без синең белән, вак алдакчылар шикелле, хәйләләргә, совет властен алдарга маташтык. Горисполкомда безнең хәйлә корганны сизделәр дә яңа йорттан бер квартирны каерып калдылар. Синең малаеңа биргәне урынына. Шуннан соң без нишлик инде? Сезнекеләрне кире кайтарыргамы? Үзләренең шуңа башлары җитмәде, инициатива күрсәтмәделәр, квартирны үзләренә тиешле нәрсә дип кабул иттеләр, ә минем инде судлашып йөрергә кыюлыгым җитмәде.

— Юкка судлашмагансың. Минемчә, синдә кыюлык аз түгел. Ул квартирны бушаттырырга иде.

— Куып чыгартыйммыни? Утыз ел буе дус булып яшибез, үлгәч, икебезне бер зиратка җирләячәкләр. Хикмәт минем кыюлыкта түгел.

— Нәрсәдә соң?

— Синдә. Малаеңны квартирдан чыгара гына башла — Маһирәң сөрән салачак. Профессор кешене, зур галимне мыскыл итәләр! — диячәк.

— Мәрхәмәтсез кеше икәнсең, Зөфәр! Миңа яманлык эшләр өчен ничә ел буе сагалап, җай көтеп торгансың.

— Ай-һай, кеше өстенә мичкә тәгәрәтергә оста да инде без! Алайболай берәр хәл булдымы — кемдер җай көтеп торган, имеш. Бәлки син үзеңә-үзең яманлык эшләгәнсеңдер? Хәзер түгел, кичә дә түгел, элегрәк, хәзер шуның очы гына килеп чыккан.

Яхинны үз урынына утырту өчен хәзер каты итеп, берәгәйле итеп аның авызын капларга кирәк иде, ләкин Курмашев андый усал сүз таба алмады, теленә килгәнне дә әйтә алыр хәлдә түгел иде ул.

Дөресен генә әйткәндә, Курмашев чит илгә Дәүләтшина квартиры белән бәйләнмичә дә китә ала иде. Аның документлары кулында иде, китәр алдыннан әлеге диссертация белән килеп чыккан хәлнең моңа катнашы юк, Курмашевның намусы чиста иде. Ул күңеленнән ни уйласа, шуны сөйләмәдемени, үз карашын якламадымыни?

Яхинга диссертация якламыйча гына докторлык дәрәҗәсе биргәннәр, ә Курмашевны профессорлыгыннан мәхрүм иткәннәр, дисәләр, хәзер ул шуңа да ышаныр иде. Күпме вакыт йөреп, күпме мәшәкатьләнеп, кеше үзенең квартир мәсьәләсен җайлаган, моның өчен аны, зур эш эшләгәнсең, дип мактыйсы урында, гаепле-гөнаһлы итәләр!

Курмашев шул минутта сәер бер тойгы кичерде: әйтерсең ул гомере буе, абына-сөртенә, аллы-гөлле салават күпере өстенә үрмәләгән. Егылып аска тәгәри язган чаклары да булгалады, ләкин, көчен җыеп, яңадан өскә үрмәләде. Инде менеп җитәргә күп тә калмады кебек, бөтен дөнья искиткеч матур булып, аллы-гөлле булып күренде, һәм көтмәгәндә шул салават күпере юкка чыкты, нур сүнде, Курмашев бозлы, салкын упкынга очкандай булды. Ул кычкырып, аваз салып та карады, тавышы упкын эченә китеп югалды, кире кайтып яңгырамады...

19

Улы белән киленен башка чыгару өчен квартир алмаштырганда Курмашевның үз гозере белән гомерендә беренче тапкыр йөрүе булгандыр.

Әлбәттә, бик кыен, бик уңайсыз булды. Шәһәр башкарма комитеты председателенең җилкәсендә бөтен шәһәр мәшәкате, бөтен шәһәр кайгысы, Курмашев ише кешеләр аның өчен йөз меңләгән; шуларның барысын ашатырга-эчертергә, киендерергә, торак белән тәэмин итәргә, өстәвенә, әле ял мәсьәләсен дә: театр, кино, пляжларын кайгыртырга, транспортны булдырырга кирәк. Ә менә Курмашев, оялмыйнитми дигәндәй, үз кайгысы белән йөри, имеш. Аңа квартир алмаштырырга, улы белән киленен урнаштырырга кирәк, янәсе. Газетага игълан биреп бастырырга да шул юл белән генә алмаштырырга иде!

Ләкин бер ияләшкән урыннан күчеп китәсе дә килми иде. Ун ел эчендә Курмашев үз квартирына инде тәмам ияләнеп беткән иде, соңгы вакытта алар монда Маһирә ханым белән өйләнешкәннән бирле яшиләр сыман тоела башлаган иде. Алар йорты — түшәме өч метр ярым биеклегендәге иркен-иркен бүлмәле, элеккерәк елларда салынган йорт, коридорында велосипедка атланып йөрерлек, кухнясына өстәл, сервант һәм суыткычлар иркенләп сыя. Балконыннан Идел өсте күренеп тора, җилсез тыныч көнне пароходлар гүләгәне дә ишетелә, кич җиткәч, шәһәр манарасындагы сәгать сукканда бүлмә эчләрендә алсу шәүләләр уйный. Хәзер менә шул квартирны тапшырып, үзләренә дә, улы белән килененә дә икешәр бүлмә сорарга туры килә. Ярый әле, юньлерәген бирсәләр! Бәлки бу мәшәкатьне ташларгадыр, искечә калдырыргадыр! Маһирә ханым белән аңа тагын күпме яшисе калган инде? Биш елмы, унмы!..

Тик шулай да Курмашев карарыннан кире чигенмәде: гаилә мәнфәгате корбан сорый шул, улы белән килене аерым яшәргә телиләр икән — яшәсеннәр, ул аларның теләгенә каршы килми. Шәһәр башкарма комитеты председателе янына барыр да хәлне сөйләп бирер, артыгын сорамас, беркадәр илтифат итүләрен генә үтенер — менә шул. Мондый зур шәһәрдә аерым яшәп, бергә кушылырга телəүче семьялар аздыр дисеңме!

Башкарма комитет председателе янына керү алай ансат эш түгел икән. Шәхси йомыш белән кабул итә торган көнне Курмашев биек колонналы иркен залга менде — элекке заманда берәр князь яисә купец йортының залы булгандыр — монда зур гына чират җыелган иде. Стена буендагы урындыкларга картлар, карчыклар, яшь-яшь ирләр, хатыннар тезелешеп утырган, арада бала күтәреп килүчеләр дә бар иде.

Курмашев ишек янында туктап:

— Соңгы кеше кем? — дип сорады.

Җавап бирүче булмады. Курмашев беренче урындык янына килде дә шунда утырган тәбәнәк кенә гәүдәле, түгәрәк сакаллы бабайдан кычкырып: «Председательгә керүчеләрдән соңгы кеше сезме?» — дип сорады.

Бабай сакалын күтәреп, күзләрен кыса төште, җавапны ничегрәк дип әйтергә икәнен чамалап торды, ахры, һәм — исең китәр! — телетелгә йокмый сөйләп тә китте:

— Монда беренче дә, соңгы да юк, — диде ул, башын тиз-тиз чайкап. — Син бит монда кинога билет алырга килмәгәнсең. Монда әммә кеше список буенча утыра, ә менә персидәтел янына элгү мәсьәләсен хәзер мин сиңа, иптәш, аңлатып бирәм, — диде бабай, һәр сүзен ачык итеп.— Персидәтел бит ул бөтен шәһәргә берәү генә. Әммә кеше дә йомышы белән шуңа керергә тырыша. Менә шуннан чират җыела. Без нинди халык? Йомшак җиргә чуан чыкса да, профессор

карасын дибез, югыйсә, аның бөтен дәвасы шул: әрекмән яфрагы яки суган пешекләп яптыңмы — икенче көнне ялап алгандай була. Бүгенге приюмга иртәнге сигездән яздылар, чиратка тагы да иртәрәк килергә кирәк. Соңрак килсәң, сине тыңламыйлар да, кеше нормасы тулды, диләр дә бетте-китте. Мин беренче тапкырында сигездә килгән идем — соңга калдым. Җидегә килдем — анда да житешмәдем. Алтыга килдем — анысында да кичектем. Дүртенче тапкырында гына эләгә алдым... Я, төшендереп бирә алдыммы?

Карт шулай сүзгә мавыгып сөйләнсә дә, үз эшен исеннән чыгармый иде. Ул күз чите белән генә чиратны күзәтә: чират кузгалуга, ялт кына сикереп тора да алдагы урындыкка күчеп утыра. Кыбырсынгалап ала да: «Күрдеңме? Мин алга таба үрмәлим, ә син утырмагансың да әле» дигән шикелле, Курмашевка ялт кына карап куя иде.

— Төшендердең, бабай, бик рәхмәт, — диде Курмашев. Үзе, мена бит кешегә мактаныр өчен әллә ни күп тә кирәкми, дип уйлап куйды.

— О-о, маладис, зиһенле егет икәнсең! Икенче тапкыр исемлеккә теге атнада язачаклар, йоклап калма, иртәрәк килергә тырыш. Моннан ерак торасыңмы?

— Юк, урам аша гына.

— Ул чагында өлгерерсең. Шулай да мин әйткәнне онытма син: әгәренки йомышың бик зурдан булмаса, персидәтелгә язылып азапланма, аның синнән башка да мәшәкате җитәрлек. Икенче бер кабинетка кереп кара. Чынлап!..

— Киңәшең өчен рәхмәт, бабай, — диде Курмашев, картны сүзеннән бүлеп. Башкарма комитетның кабинетлары буйлап йомышын йомышлап йөрүен күз алдына да китерә алмады: һәркайсына аңлатырга, һәркайсыннан үтенергә кирәк булачак!

Ләкин эш ул уйлаганнан ансатрак хәл ителде. Алдагы атнада Курмашевны махсус депутатлар группасына керттеләр — ул инде рәттән өченче тапкыр шәһәр советының депутаты булып сайланган иде — бу группага парикмахерскийларның эшен тикшерү бурычы йөкләделәр, өстәвенә, Курмашевны группаның башлыгы итеп билгеләделәр. Тикшерү эше атна буена сузылды, өч көн — белешмәләр язуга китте. Курмашев тикшерү нәтиҗәләре турында фикерләрен язып башкарма комитетка китергәч, кабул итү бүлмәсендәге техник секретарьга тапшырып торганда, кабинетыннан председатель үзе килеп чыкты.

Курмашевны таныды ул, кул биреп исәнләште һәм монда нишләп йөрүен сорады.

— Менә белешмә китергән идем,— диде Курмашев, кәгазьләрен күрсәтеп.— Парикмахерскийларны тикшердек. Фикерләремнең барысын да шушында әйттем. Кимчелекләр дә, тәкъдимнәр дә әйтелде.

— Яхшы, бик вакытлы эшләгәнсез, әйдәгез хәзер минем янга керегез. Нинди чаралар күрергә кирәк — уйлашыйк.

Курмашевның туры килүенә председатель бик сөенде шикелле. Ул, аны кабинетына алып кереп, белешмәгә сыймый калган кайбер нәрсәләрне сорашты, бу эшкә алынулары, әйбәт кенә башкарып чыгулары өчен рәхмәт әйтте.

Курмашев, мактаганга уңайсызланып, кызарынып китте, тырышлык күрсәтү, эшне җиренә җиткереп эшләү — ул безнең депутатлык бурычыбыз инде, диде. Аннары, тәвәккәлләп, үзенең квартир мәсьәләсен сөйләп бирергә булды.

— Беләсезме, Кашшаф Сөләйманович, мин инде күптән сезнең янга керергә җыенып йөри идем. Әле сезнең эшегез күп, әле минем вакыт юк...

— Ул вакыт белән аптыраган инде,— дип, председатель авыр сулап куйды.— Ашыгабыз, кабаланабыз, тәгәрмәч эчендәге тиен шикелле бөтереләбез...

— Минем квартир белән кыенлык килеп чыкты бит әле,— диде Курмашев, сүзсез торудан файдаланып.— Хәтерегездә микән: теге вакытны, миңа дүрт бүлмә биргән чакта, мине яңа квартир белән тәбрик иткән идегез? Хәзер икенче мәсьәлә... аны нитәргә, алмаштырырга иде.

Курмашев, уңайсызлана-уңайсызлана гына, өйдәге хәлен сөйләп бирде, миңа бер метр да артык кирәкми, тип-тигез булсын, без дә, сез дә берни югалтмыйбыз һәм берни отмыйбыз, диде.

Председатель бөтен хәлне аңлатып гариза язарга кушар, дип уйлаган иде ул, шуңа күрә кесәсендә әзер гаризасы да бар иде. Гаризага имза салгач, төрле инстанцияләр, ЖЭК комиссияләренең бусагасын таптарга туры киләчәк. Нишләргә соң? Кирәк булгач — эшләргә инде!

Ләкин председатель аны-моны төпченеп тормады, селектордагы төймәгә басты да, сулга борыла төшеп, ак төймәле зәңгәр ящикка кычкырды:

— Жилотделмы? Берәрегез менегез әле монда... Ярый, берәр әмәлен уйлашырбыз, — диде председатель. — Киресенчә эшләү җиңелрәк булыр иде дә — сездән ике квартир алып, шуларны бер итү. Күп халык хәзер аерылыша — әллә нинди чир кебек! Әле ир белән хатын тату яши алмый, әле күршеләр талаша, әле яшьләр картлардан риза түгел, ирек, мөстәкыйльлек кирәк.

— Нәкъ-нәкъ...

— Без инде шуларны хәл итәбез, булышырга тырышабыз. Без сезгә ярдәм итәрбез. Тик беләсезме нәрсә? Нигә сезне ике бүлмәгә кертеп кысанда яшәтергә? Җан башына тугызар метрдан сезгә, хатыныгыз белән икегезгә, унсигез квадрат метр тиешле, шуның өстенә сезнең, профессор буларак, закон буенча тагын егерме метр алырга хакыгыз бар — шулай булгач, хәзер үк өч бүлмәлегә күчегез. Кечкенә габаритлыга түгел, тулы метражлы йорттан алыгыз. Бераз артыграк булса да — әллә ни түгел. Югыйсә, бер-ике елдан тагын, квартирыгызны зурайтырга дип, чиратка басарсыз, безгә тагын мәшәкать булыр. Сез, әлбәттә, бернәрсәгә игътибар итмәгәнсездер — мин үзем кабул иткән кешеләр арасында икенче тапкыр килүчеләрне дә бик еш күрәм. Башта алар коммуналь квартирдан бер бүлмә сорадылар — анысын алдылар, хәзер инде аерым квартир кирәк, диләр. Башта ук квартир бирсәк, аларга да яхшы була, безгә дә мәшәкать калмый иде. Бер дә уңайсызланмагыз сез. Бездә лауреатлар күп түгел, хәзер гади семьялар да бик иркен яши. Әлбәттә, бу мәсьәләгә сезнең балаларыгызның катнашы юк, әтиләреннән башка гына квартир алсыннар, үзләре шуңа лаек булсыннар, ләкин андый хәл гомумән уйлаганда гына дөрес. Сезнең институт хуҗалары безнең исемгә гариза язып, профессор Курмашевның торак шартларын яхшыртуыбызны үтенсеннәр. Үзең сорау — бер нәрсә, ә коллектив, оешма соравы — икенче. Без ул кәгазьне тоткарламабыз.

Шул рәвешчә кешенең күңелен күрергә тырышу председательнең үзенә дә ошаса кирәк. Ул мондый эш вакытындагы рәсмилекне саклап, үзен шактый җитди тотса да, күзләре ягымлы, карашы нурланып-нурланып китә иде. Курмашев аның тавышыннан аз гына булса да ризасызлык чаткылары сизәргә тырышып карады, ләкин андый нәрсә сизелмәде. Ул аның әнә шундый була белүенә, кешенең ихтыяҗын, кайгысын аңлый белүенә сокланды. Андый кешеләр була шул! Бу квартир мәсьәләләрен ул төшләрендә дә күреп саташып бетә торгандыр инде, ә үзе бер дә гасабиланмый-үртәлми, киресенчә, шат шикелле әле. Председатель генә түгел, егет икән! Юкка гына ун ел эшләмидер! Мондый урынга теләсә кемне куймыйлар шул.

Кабинетка торак бүлеге мөдире — озын буйлы, таза тәнле бер ир кеше килеп керде. Галстугын да ул гәүдәсенә ярашлы итеп, түшенең йодрык чаклы итеп төйнәгән, култыгына «К докладу» дигән папка кыстыр-

ган иде — үзен дәрәҗәле генә тотып, ихтирамлы бер кыяфәттә өстәл каршына килеп басты.

Председатель, сине чакыруымның сәбәпчесе менә шушы кеше дигән сыман, башы белән генә Курмашевка таба ымлады, дүрт бүлмәле бер квартирны ике һәм өч бүлмәле ике квартирга алмаштыру турында кәгазьләр тутырып эшкә җибәрергә боерык бирде һәм, өч бүлмәлесе зур метражлы, биек түшәмле булырга тиеш, дип искәртеп куйды...

Әмма квартир алмаштыру рөхсәт алуга караганда шактый катлаулы эш булып чыкты.

Кәгазьләр белән эшне тиз җайладылар. Яхин институт исеменнән үтенеч язып, директордан, партком секретареннан кул куйдырды, үз имзасын да салды. Бер атнадан яңа йорт өлгертеп, шуңа кешеләр кертә башладылар. Курмашевның улы белән килене әнә шул йортка ике бүлмәле квартирга күчте. Квартирлары әйбәт кенә: өченче катта, балконы да бар, ваннасы белән туалеты аерым. Аз гынадан да канәгать булып яши белүче кешеләргә тагы ни кирәк?!

Ә Курмашев белән Маһирә ханым иске квартирларында торып калдылар. Маһирә ханымны яңа күршеләре хакында барып сорашырга шайтан котырткандыр, күрәсең. Алар күчәсе подъездда бер эчкече яши икән. Йортта һаман гауга, талаш, сугыш булып тора, ди. Әлеге исерек башны айныткычка алып китеп, унбиш тәүлеген утыртып кайтаралар да яңадан шул ук хәл башлана, ди.

— Акылыңнан яздыңмы әллә?! — дип тиргәнергә тотынды Маһирә ханым өйгә кайтып керү белән. — Ул адәм чын газап булачак безгә. Ничек яшәмәк кирәк анда?

— Газап булыр инде бик...

— Булмас менә. Көн саен эчеп кайтыр, ызгыш чыгарыр, баш төзәтергә дип бирәр сумлап акча сорый башлар. Андый халык бурычын кире кайтармый...

— Һаман-һаман эчмәс әле. Бавыры авырта башлар, бөерләре эштән чыгар. Врачлар дәвалар аны.

— Дәвалерлар!

— Дәваламасалар, читкә сөрерләр.

— Кая сөрерләр?

— Кайман атавына, берәр җиргә шунда.

— Кемгә кирәк ул исерек баш анда?

— Күршеләр булмаган йорт каян алыйм мин сиңа? Горисполкомга бүтән бармыйм, үзең бар әнә.

— Барам шул.

— Бар.

— Әллә бара белмәс дисеңме?

— Рәхим итеп бара күр.

Курмашев хатынын бу ниятеннән кайтыр дип уйлаган иде. Шәһәр башкарма комитетына барып, кабинеттан кабинетка йөрер дә, эш чыгара алмагач, гайрәте чигеп, кайтып китәр. Ярый әле, Курмашевны председатель белә. Өйдә генә утыра торган гади бер хатынны анда ничек кабул итәрләр бит!

Маһирә ханым эшне бер тотынуда ук җайлады. Телефон янына утырып, абонентлар кенәгәсен каршына куйды да, председательнең телефон номерын табып, шалтыратырга кереште. Һәй, беркатлы сабый да инде! Андый эшне телефоннан сөйләшеп кенә хәл итеп була торган булса, күпме кеше, эшләрен ташлап, башкарма комитетка чабарлар идеме, көн буе кабинет ишеге төбендә чират көтеп утырырлар идеме?

Курмашев инде ничә тапкыр председательне телефонда туры китерергә тырышып карады! Кайчан гына шалтыратса да, телефонны секретаре ала. Башта ул «Хәерле көн» дип әдәпле генә итеп исәнләшә,

аннары исемен әйтә дә тамагын кыргалап тора. «Әйтмәссез микән, миңа председатель белән бераз сөйләшеп алырга мөмкин булмасмы?» — ди.

Телефонның теге башыннан да шундук «Исәнмесез» дип җавап кайтаралар, ләкин аның үтенечен үти алмыйлар:

— Председатель юк шул... Эш белән китте, — диләр.

Маһирә ханым телефонның түгәрәк тимерен биш мәртәбә әйләндерде дә тамагын кыргалап бераз көтеп торды, чыбыкның теге очыннан: «Приемный тыңлый» дигән җавап ишетелгәч, боеручан кырыс тавыш белән:

— Камалов трубканы алсын әле! — диде.

— Председатель сәгать икедә генә була.

— Төштән соң аның эш программасы ничек? — дип сорады Маһирә ханым шул ук кырыс тавыш белән.

— Архитекторлар белән киңәшмә үткәрә...

— Киңәшмә башланганчы шушы телефоннан шалтыратып, безне тоташтырырсыз, — дип, Маһирә ханым телефон номерын әйтте, яңадан сорау биргәнне көтмәстән, трубканы урынына куйды.

Бик кызык булып китте бит әле. Ул көнне Курмашевның әллә ни эше юк иде, институтка шалтыратып, бүген мин өйдә генә эшләп утырам, диде һәм, хатынына шалтыратырлармы, юкмы? дип, кызыксынып көтә башлады.

Шалтыраттылар бит. Маһирә ханым, инде бу вакытка әзер булып, телефон тирәсендәрәк йөри иде. Шалтырау белән үк ул аппарат янына килде, ләкин трубканы шундук аласы итмәде, дүртме-бишме тапкыр чылтырагач кына алды.

— Әйе, — диде ул, бик зур эшеннән бүлгәнгә ачуы килгән кебек кырыс кына итеп. — Яхшы, тоташтырыгыз. Хәер, кирәкми, үзем шалтыратырмын. Эчке канал буенча аның номеры ничә әле? Тугыз-нуль-биш дисезме?.. Рәхмәт.

Трубканы колагыннан төшермичә генә, ул аппаратның рычагына басып алды да чәнти бармагы белән генә номер җыярга керешге.

— Исәнмесез, Кашшаф Сөләйманович, — дип, үз иткән ягымлы-йомшак тавыш белән Маһирә ханым телефоннан күгәрчен кебек гөлдерәп сөйләшергә керешге, шулай да бөтенләй үк балланып китмәде, үзен беркадәр җитдирәк тотты. — Сезне Маһирә ханым дигән кеше борчый иде әле, профессор Курмашевның иптәше. Үзенең хәлләре ничек дисезме? Рәхмәт. Хәзерге ирләрнең хәле ничек булсын инде! Муеныннан эшкә чумган. Үзегездән чыгып та беләсездер... Сез мине гафу итегез, Кашшаф Сөләйманович, без бит сезнең бернечә бөртек кенә булса да илтифатыгызга мохтаҗ бит!.. Безгә кайчанрак җайлы дип... анысы уңайсыз инде. Юк, юк, булмаганны! Бездән башка да сезнең тын алырлык арагыз юктыр. Әйдәгез, алайса, сезгә җайлырак вакытта. Болай да артык уңайсыз инде, билләһи. Ярый, яхшы. Алты туларак бик җайлы. Хушыгыз, зур эшләрегездән бүлгәнем өчен гафу итегез...

Маһирә ханым трубканы куйды да Курмашевка нәрсәдер әйтмәкче булды, ахры — аның кабинеты ишегенә килеп карады. Ләкин бер сүз әйтмәде, кире китте. Курмашев башын гына чайкады. Осталык та бар соң үзендә! Мондый таланты белән Маһирәгә өйдә ятмаска, берәр эшкә урнашырга кирәк!

Кичкырын, учреждениеләрдә эш сәгате бетеп килгәндә, Маһирә ханым башкарма комитетка китте һәм — әйтеп кеше ышанмаслык хәл — беренче баруында ук өч квартирлык өч бланк алып кайтты: ошаганын сайлап алып, ордерга исем-фамилияңне язарга да калган икесен кире кайтарырга иде.

— Менә, иртәгә барып карарбыз, — диде хатын, әллә нинди бик зур эш башкарып кайткан бер төс белән һәм, өс-башын чишенеп тә тормыйча, Курмашев алдына өч ордер китереп салды.

Башка вакытны булса, Курмашев мондый эш өчен хатынын мактаган булыр иде, гомумән, ирләр белән хатын-кыз арасында тигез хокук саклау мәҗбүри түгел, катлаулы, четерекле эшләрдә хатын-кыз үткенрәк, чаярак һәм остарак, андый эшләрне аларга тапшырырга кирәк, дияр иде.

Бүген исә хатынының әллә кем булып ирәеп кайтып керүе Курмашевның ачуын китерде, аның телефоннан ничек сөйләшкәнен хәтерләде: председательнең кабул итү бүлмәсендә утырган секретарь белән тәкәллефсез, дорфа сөйләште, председательнең үзе белән сөйләшкәндә инде тавышын уйнатып, үз иткән, бик зур хөрмәт күрсәткән булып кыланды. Аның председатель янында ничек сөйләшүен дә күз алдына китерергә тырышты Курмашев: ирем һич эштән бушый алмый, үз эше дә, депутат эшләре дә бик күп, шуңа күрә, кызганычка каршы, үзе килә алмады, дигәндер. Бу хатынның шуннан да зуррак эшләр эшләрлек кодрәте булса, ниләр генә кыланмас иде икән! дип уйлап куйды.

Курмашев арыган-талчыккан бер кыяфәттә:

— Бар, үзең генә карап кайт инде, — диде дә ордерларны читкәрәк этте. — Нигә кирәгем бар минем сиңа, барыбер үзеңчә эшлисең бит. Бу кәгазьләреңне җыеп ал әле. Күрәсем дә килми,— диде.

Шушы минутта Маһирә ханым ирендә моңарчы күзенә чалынмаган яңа бер сыйфат күрде, ахры — иренә әллә ничек сәер генә итеп карап куйды, ризасыз бер кыяфәттә, югарткан нечкә кашларын җыергалады һәм ялт иттереп ордерларны җыеп алды.

Гаҗәп кызык икән бу кеше дигәненнең табигате! Сайларга күп булган саен, сайлап алуы кыенлаша төшә икән. Маһирә ханым өч квартирның өчесеннән дә баш тартты. Барып квартирларның ниндилеген карады, көндез бүлмәләргә ничә сәгать кояш төшүен сорашты, күршеләрен белеште дә, аягымны да атламыйм, дип кырт кисте. Квартирларның берсендә ниндидер инженер яшәгән, икенчесендә зур заводның директоры торган, өченчесеннән бер сәүдә базасы мөдире күчеп киткән. Гөнаһ шомлыгына дигәндәй, бу семьяларның өчесе дә «яхшырак»ка күчкәннәр икән.

Маһирә ханым, шушы мәгълүматларны белгәч, һушын югалта язды.

— Кешеләр квартирларын начар дип, яхшыга күчеп китә, ә безгә нинди дә ярыймы?! Берсе — база мөдире, имеш! Кара син, андый квартир ярамый, ошамый аларга, ә безгә ярый! Юк, күчмибез! Җүнлерәкне табып бирсеннәр.

Ә көннәр уза торды. Курмашевка китәргә дә вакыт җитте. Ул, юлга җыенгач, Маһирә ханымга малайлары бүлмәсенә кагылмаска кушты, торак мәйданы артык дип әйтмәсеннәр, янәсе. Чит илгә ул бер елга дип кенә киткән иде — ике ел торып кайтты. Нишләсен, шулай килеп чыкты инде!..

Аһ, илтифатлы, ягымлы председатель нинди бәлага төшерде бит аны! Курмашевка нишләргә инде хәзер! Аның турында Дәүләтшина, Яхин, башка танышлары ни уйлый икән инде?

## 20

— Ә Дәүләтшинаның хәле ничек соң?— дип сорады Курмашев әллә нинди ят бер тавыш белән.

— Минемчә, ярыйсы. — Яхин, муены ойый башлаган сыман, баш артын ышкыштырып алды да, торып, форточканы япты.— Эшләп йөри, синең белән минем ярдәмгә мохтаҗ түгел. Нибары ике тапкыр гына күрдем мин аны. Бер тапкыр — культпоход оештырды, бөтен коллектив белән пароходта Ульяновскига барып кайттылар, Ленин мемориалын

караганнар, икенче тапкыр — партия җыелышында күргән идем. Аны кандидат итеп алдылар, бертавыштан узды. Көчле нәрсәкәй! Җыелышта үзеннән: «Киләчәккә нинди планнар корасыз?» — дип сораганнар иде, шундый программа, шундый хыяллар сөйләп бирде — гыйльми секретарьның хәтта пеләше тирләп чыкты. Гел хыял кебек кенә тоелса да, ышандыра үзе!.. Ә башка вакытны гел йөри, кайтып та керми: бүген өйдә, иртәгә әллә кайда... Миннән квартир даулап тузынганы да, хәтта чиратка язылыгыз дип килгәне дә юк.

— Үзе өчен йөри торган кеше түгел шул.

— Хәер, сиңа борчылмасаң да була. Синең ярдәм итәргә тырышуыңны белми ул. Бу мәсьәләдә директор белән мин гаепле. Без аны, квартир алачаксыз дип, юкка сөендереп куйдык. Әйтми торган булсак, берни белмәс иде, үзебезгә дә җайлырак буласы иде. Алдан ук кычкырып куйгач — уңайсыз хәзер.

— Әтәч шикелле алдан кычкырырга яратабыз шул.

— Шуннан мин аңа әйттем: «Документларыңны гадәттәге тәртип буенча оформить ит», — дидем. Үзе: «Ярый», — дигән булды да Самотлорга китеп барды. Аннары өч ай Мәскәүдә торып кайтты. Комитетта, министрлыкта, Госпланда ниндидер эшен уздырырга тырышып йөргән бугай. Минем аннан башка да мәшәкатем азмыни? Хәзер үзебез өчен, галимнәр өчен, йорт сала башладык. Тугыз катлы була, лифте, лоджилары, чүп түккеч торбалары була. Бәлки шуннан берәр квартир биреп булыр?

— Тиз буламы соң әле ул?

— Ай, башкасын сорасаң сора, бу хакта гына сорама! Подрядчыгын тапкан идек — акчабыз бетте, нигезенә көчкә-көчкә генә җиткердек. Акчасын юллаган идек — төзүчеләр юк, башка объектка күчеп киттеләр.

— Күтәргә каламы инде?

— Күтмичә нишлисең? Минемчә, ул күтеп тормас.

— Кооператив квартир алыр дисеңме?

— Мәскәүгә китәр. Анда квартирын да бирерләр, хезмәтен дә күрә белерләр. Акыллы кешеләрне күрә беләләр анда.

— Китәр дисеңмени?

— Нигә китмәсен?! Башкалага чакырудан баш тарткан кеше бар микән? Аңа монда ябышып ятарлык нәрсә бар? Квартиры юк, диссертациясен «батырдылар». Күрәсең, халыкара конгресска китте әнә, ә үзенең бернинди гыйльми дәрәҗәсе юк, гади бер хезмәткәр. Менә күрерсең: ул үзенең программасы белән анда да шаккатырыр әле. Сүз уңаеннан әйткәндә, сине анда җибәрмәделәр бит.

— Ничек җибәрсеннәр мине? Мин чит илдән әле кайттым гына ич.

— Кирәк булса — эзләп табарлар иде. Кайтканыңа атна булды инде. Сине уеннан читтә, аутта калдырдылар. Син анда, ул конгресста, нишләр идең соң? Иске чолгауларыңны чыгарып селкер идеңме?

— Син футболчы булып язылдыңмы әллә, спорт терминнары белән генә сөйләшәсең?

— Язылмадым — үзем язам. Үз командабызны оештырабыз. Менә югары лигага чыгабыз да «Спартаг»ын, «Динамо»сын, «Торпедо»сын, армеецларын да — барысын да әйләндереп салабыз! Югыйсә, хурлык бит! Футбол уйнамыйлар, йөз шакмаклы шашка уены уйныйлар. Тупка типкәнче ярты сәгать уйлап торалар. Монысы — минем программа-минимум, максимум дигән бурыч та бар: бөтен дөнья җыелма командасы белән дә уйлап карарга исәп. Мин инде кемнәрне чакырасын да уйлап куйдым. Иң элек — Пеле, Жаир, Эйсебио, Рива белән Ривера, Джаич, Любаньский, Бобби Чарльтон, Мюллер... Күрдеңме, нинди атаклы уенчыларны чакырабыз?! Оттырсаң да — зур мастерларга гына оттырырга кирәк, үзеңә оят килерлек булмасын...

«Нигә кәмит уйнап утыра әле бу? Кем өчен, ни өчен?»

Яхин янына килеп, шушындый ахмак сүзләр сөйләшеп утыруы өчен Курмашевның үз-үзенә ачуы да килә башлады. Дустының сүзе ничектер аңа су астыннан, тирән чоңгыл төбеннән килгән сыман тонык кына булып ишетелә, ләкин мәгънәсе, гаҗәпкә каршы, бик ачык аңлаешлы булып, аның аңына барып җитә иде.

Шушы минутта Яхинга ачуланып, өстәл сугып, хәтерен калдырырлык итеп үткәзеп әйтергә дә, үзенең кем икәнлеген исенә төшереп, урынына утыртырга кирәк — әллә кем булмасын әле.

Курмашев әйтүен әйтер дә, аңа карап кына хәл үзгәрерме соң? Үзган эшне барыбер кире кайтарып булмый бит! Ул чит илгә китте, анда эш белән шөгыльләнде, күңел салып, тырышып эшләде. Өйдә, туган илдә, аның якыннары, үзе аралашып яшәгән кешеләре калды. Хатыны, улы белән килене, Яхин, Дәүләтшина... Материя зур, иксез-чиксез, аның янында кешеләр тузан бөртеге шикелле генә тоелсалар да, үзара бер бөтен булып оешканнар бит.

«Бик ахмакларча килеп чыкты бу!» — Курмашев ни өчен болай килеп чыкканлыгын аңларга, сәбәбен төшенергә, үз-үзен акларга, дөрескә чыгарырга тырышты. Ул ни өчен Дәүләтшина диссертациясенә каршы чыкты соң? Көнләшүдәнме, үзенә файда эзләүдәнме, Яхин әйтмешли, үз-үзеңне яклап калыр өченме? Фәнне яклап шулай эшләде бит ул: «Фәнгә кем генә тыкшынмый хәзер — тегеннән-моннан фикер кисәкләре эләктереп, шуларны әллә нинди формула, схема, сызымнарга төреп күрсәтәләр дә гыйльми дәрәҗә сорыйлар. Эшләрен җентекләп, асылына төшебрәк карасаң — буш кибәк булып чыга, сынык бер бөртек тә таба алмыйсың!»

Бер Курмашев әнә шулай үзе турында түбәнчелек белән йомшак кына итеп фикер йөртә, икенчесе — каты бәгырьлесе, рәхимсезе исә бөтенләй башкача хөкем чыгара иде. Аның җанын иң борчыган, иң газаплаган нәрсә шул — икенчесенең логикасы көчлерәк, нигезлерәк, беренчесенең дәлилләрен бөтенләй юкка чыгара иде.

«Ташла әле, ташла! — дип каты итеп, авырттырып, аның башына төйгечләп тора икенче Курмашев. Суккан саен чигә тамырлары катырак тибә, кызыша бара. — Фән мәсьәләсен катнаштырма, дон-кихотларның анда ни катнашы бар? Икенче берәүнең үзеңнән талантлырак, сәләтлерәк һәм бәхетлерәк булуына, син ирешкән иң югары ноктаны үзе өчен башлангыч нокта итүенә ачуың килде. Аның нәрсәсенә шаккатасың? Һәр яңа буын эшне өлкәннәр тәҗрибәсенә таянып башлый ич. Чит кешенең уңышында үз өлешең дә булуына сөенергә, кешегә ярдәм итәргә кирәк иде, ә син мин-минлек шаукымына бирелеп киттең. Башкаларның кечкенә генә кимчелеген дә кичермисең, ә үзеңнең эчендә эшәке бер вакчыллык чәчәк ата. Нишләргә? Ни чара кылырга?..»

Курмашев Яхинның дәлилләре белән килешсә дә, чигенергә уйламады, үз күзе алдында акланыр өчен генә булса да, тотынырлык нәрсә эзләде. Шулай булмаганда дөньяда яшисе дә юк ич!

— Курмашев балаларының квартир алырга хакы юкмыни? — дип, Яхинга әчке бер ачу белән сорау бирде ул.

— Бар, әлбәттә. Сезнең улыгыз күчү сәбәпле квартир алмый калган башка семьяның да конституция буенча шундый ук хакы бар иде бит! Хәтта бокста да — катырак сугып, бер-берене идәнгә аудара торган спорт уенында да — билгеле бер кагыйдәләр бар, шуны бозган өчен рингтан төшерәләр. Нигә әле синең балалар өчен аерым кагыйдә булырга тиеш? Әтиләре атаклы кеше булган өченме?

Яхинның хаклы икәнлеген Курмашев сизә, ул үзе дә башкаларга нәкъ шулай дип әйтер иде. Нишләмәк кирәк, мондый сүзне хәзер ул үзе тыңлап торырга мәҗбүр. Аны хаксыз дип дәлилли алмаганга Курмашевның ачуы килә. Бары тик бер генә юл бар — үзеңнең гаебеңне тану,

ялгышканмын-хаталанганмын дип әйтү генә. Ләкин ничек әйтәсең аны? Кемгә әйтәсең? Яхингамы? Мыскыллап көләр үзеңнән!

Хәзер ул моннан соң нишләячәген белә инде. Яхин яныннан чыгып китәр дә Дания Дәүләтшинаны эзләп табар. Аның өенә барыр, юк, алай итмәс, аэровокзалга барып, пассажирларның билетларын терки торган стойка янына басар да Дәүләтшинаны көтеп алыр һәм шуннан соң аңа барысын да сөйләп бирер. Кичерегез мине, дип ялынмас, Дәүләтшина аңа каты итеп үткәзеп әйтсен — Курмашев башта ук аның һәр сүзен тыңларга әзер.

Ә Дәүләтшина аның белән сөйләшер микән соң? Сөйләшер. Хатын-кыз ул — ирләр түгел бит, хатын-кыз миһербанлырак, шәфкатьлерәк зат, табигать аны кешене җәзалар өчен түгел, бәлки гафу итәр, кичерер өчен яраткан, ул яхшыны гына түгел, яманны да аңлый белә.

Курмашев, берни булмаган кебек, сүз җаеннан гына:

— Аның самолеты кайчан китә? — дип сорады.

— Белмим. Сорыйсы сүзең калганмы? — диде Яхин коры гына.— Иртәгә аңа Мәскәүдә булырга кирәк. Берсекөнгә тагы да ары китәргә. Шулай булгач, кичке рейс кына кала инде.

— Ярый, мин киттем. — Курмашев, мөмкин кадәр тыныч-сабыр булырга тырышып, урыныннан кузгалды.— Идел буена бара алмавыбыз бик кызганыч. Бик шәп итеп бер сабан туй ясаган булыр идек! Табигать кочагына чыгам дип һаман җыенасың-җыенасың да менә шулай бармый каласың...

— Гафу ит инде. Икенче бер вакытны барырбыз. Идел беркая да китмәс әле, безнең гомергә җитәр.

## 21

Яхин бәхәстә мин җиңдем дип уйламасын дип, Курмашев, тыныч-сабыр булырга тырышып, ишеккә таба китте. Аннары кире борылып килеп, әле һаман ипи өмет итеп тәрәзә төбендә чыркылдашкан чыпчыкларны караган булды. Коридорга чыккач та ашыкмый гына атлап, кырыс бер чырай белән, карасу-яшел күзлек пыялалары аша як-ягына каранып барды. Берәрсе үзен танып эндәшмәгәе дип курыкты. Ләкин инде эш сәгате беткән, кешеләр кайтып киткән, коридорда беркем күренми иде.

Машинага кереп утыргач, инде сабырлык саклаган булып, тыелып азапланмаска да мөмкин иде. Курмашев утыру белән үк машинасын кабызды, моторның тигез-салмак эшли башлавын да көтмичә, педальгә басып кузгалып та китте.

Як-яктан елт-елт итеп кешеләр күренеп кала, йортлар бер-бер артлы әле машина өстенә килгән сыман тоелалар, әле янга авышып, урам, мәйдан, тыкрыкларга юл ачалар. Бер урам чатында Курмашев «кызыл ут» астына килеп керде, чак кына кеше тулы троллейбус белән бәрелешмичә калды. Ярый, бәхете бар икән әле! Курмашев бәла-каза булмый калуына сөенергә дә, үз-үзенә ачуланырга да өлгермәде — милиционерның чырылдатып сыбызгы сызгыртканы ишетелде.

Тормозга басып, машинаны туктатырга туры килде.

«Шул гына җитмәгән иде! Ашыккан чакта кирәк бит — менә хәзер туктап, акланып маташ инде!» — дип уйлап алды Курмашев.

Машина янына яшь кенә милиционер егет килде. Аның әле формасы да өр-яңа иде. Кояшта уңып та өлгермәгән погоннарына икешәр йолдыз тагылган. Мин — инспектор, юлның хуҗасы дигәндәй, лейтенант эре генә кыяфәттә честь биреп:

— Лейтенант Хэйруллин! — диде дэ уң ягына аскан карасу-көрән сумкасын ашыкмый гына ача башлады. Аннары, Курмашевка күз дә салмыйча: — Шул хәтле кая атылып-бәрелеп чабасың? Теге дөньягамы? Техталоның кая? — диде.

— Иптәш лейтенант, «син» дип сөйләшергә сез минем туганым да, әшнәм дә түгел. Мин үземнең шәхси эшем белән барам, сез хезмәт вазифагызны үтисез...

Лейтенантның документлар соравына ачуы килмәде Курмашевның: автоинспекциянең сорарга хакы бар. Япь-яшь инспекторның боеручан, кырыс тавыш белән үзенең көчен күрсәтергә тырышуы җенен чыгарды аның. Бу егетнең дежурга да беренче тапкыр гына чыгуыдыр әле, югыйсә! Курмашев күңеленнән лейтенантның авызын капларлык усал сүзләр эзләп карады, ләкин каршы әйтә алмады, чөнки монда ул үзе гаепле иде! Ярый әле, троллейбуска бәрелмәде!

— Ни өчен әле без «сез» дип сөйләшергә тиеш? — диде лейтенант Курмашевның әлеге сүзенә каршы. — Безне, безнең кагыйдәләрне санга сукмаучы кешеләрне ни өчен без хөрмәт итәргә тиеш? Катыргыңны чыгар!

— Кем белән сөйләшкәнегезне беләсезме сез? Мин... мин... профессор Курмашев...

— Булсаң соң! Миңа димәгәең академик Курчатов бул, тик тәртип кенә бозма. Син үзең гаепле бит, бер троллейбус кешене имгәтә яздың. Аларның ни гаебе бар? Мин синең талонны тишеп, праваңны алып калам. Иртәгә сәгать тугызга инспекциягә килерсең.

— Кайда ул?

— Кирәк булгач — эзләп табарсың. Минем иркемдә булса, синең ише «акай күз»ләрнең талонын тишү генә түгел, бөтенләй машинасын алып калыр идем...

Курмашев кузгалып китте. Башта машинасын кызуламады, спидометрның угы утыз чакрым тирәсендә генә селкенгәли иде. Әмма аэродромга якынайган саен, аягы газга катырак баса башлады. Ул инде хәзер машинасын тыймый, кызулаганнан-кызулый бара — соңга калмагаем дип курка иде.

Көн үзгәрде, һава болытлады. Кояш юкка чыкты, ул инде батканмы, әллә аны болыт кына каплаганмы — белерлек түгел иде. Озакламый яңгыр да явар, ахры.

Аэропортка җиткәч, Курмашев машинасын очу мәйданы читендәге койма буена ук китереп туктатты. Машинадан чыкмас борын ук ашыгуның инде файдасыз икәнлеген аңлады.

Пассажирларны утырта торган төштә районнарга очучы кечкенә самолетлар гына бар, аңа кирәкле зур «ТУ» соры бетон тасманың иң аргы башында, очарга хәзерләнеп, инде борылып ята, аэродром өстендә, таш-тау җимерелгән сыман, каты гөрелте тавышы тетрәп тора иде.

Самолет артыннан йөгерүдән ни мәгънә? Әйтик, йөгереп җитсен дә ди. Аны күреп пилотлар самолетны туктатсыннар да ди. Курмашев самолетка менеп, юк, Дания Дәүләтшинаны трапка чакырып чыгарып, аның өчен кирәкле мәгълүматлар теркәлгән куен дәфтәрен бирсен ди. Дәүләтшина менә шул чакта һич тә исе китмичә генә, дәфтәрне актаргалап карагач: «Миңа моның хаҗәте юк!» — дип кире бирсә?..

Самолет туктады, юл уңаена турылап басты, кисәк сикерергә әзерләнгән кебек, борын ягыннан койрыкка таба чайкалып куеп, чүгә төште дә алга омтылды. Тизлеген кызулаганнан-кызулый барып, пыяладан гына корылган аэровокзал бинасын чәлпәрәмә китерергә җыенгандай, туп-туры шуның өстенә йөгерде һәм аннары, алай итәргә ярамавын кинәт абайлап алган сыман, Курмашевка кайнар җилен өрдереп, җиңел генә, җитез генә итеп һавага күтәрелеп китте.

Курмашев аның артыннан карап калды. Башта самолетның тавышы ишетелмәс булды, аннары, болытлар эченә кереп эрегән шикелле, үзе юкка чыкты. Бик югарыда, самолет койрыгында, җирдә калучыларны үртәгән сыман, мелт-мелт итеп кызыл ут җемелди иде. Озакламый бу ут та югалды, болытлар арасында самолетның эзе дә калмады.

Курмашевка ни өчендер дөнья шыксыз, салкын булып тоелды. Ул соңгы көннәрдә нидер көтеп яшәгәнен, шушы Дания Дәүләтшина аркасында авылга да кайтмавын, дачасына да бармавын, Яхин янына да Дәүләтшина хакында белешер өчен барганлыгын бары хәзер генә аңлады. Чит илдән кайтканнан бирле бер атна вакыты шушы өмет белән юанып узган лабаса!

Вак кына яңгыр сибәли башлады. Озак яварга ниятли, ахры. Курмашев, болытлар арасында әлеге самолетның уты күренеп китмәсме дип, һавага карап һаман машинасы янында басып тора иде. Яңгыр басылып, болытлар таралса да, өмет иткәне барыбер булмаячагын, самолет уты күренмәячәген ул белә, шулай да күңеле, йөрәге якты нур теләгәнгә, чынга ашмастай хыялына, могҗизага ышана иде.

Яңгыр көчәйгәннән-көчәя бара. Курмашев, өсте манма су булып юешләнгәнен дә тоймыйча, салкын яңгыр астында басып тора бирде. Кайчан да булса яңгыр туктар, чалт итеп кояш чыгар, кояш җылысында өс-баш кибәр, аларын яңадан үтүкләп кияргә дә була. Тик шунысы гына аяныч: яңгырны ул туктата алмый, самолетны кире кайтарып булмый, Дания Дәүләтшинаның диссертациясен яклауны да ул оештыра алмый — бу эшне башкалар эшләячәк. Госман Курмашевны да яңадан күтәрмәсләр, кешеләр аның турында: менә бит, үзенә дә, лабораториясенә дә кагылышы-катнашы булмаган чит бер кешене табып, күтәреп чыкты, дип сокланып сөйләмәсләр. Гамәлдән чыккан кирәксез бер әйберне оныткан кебек, аны да онытырлар, бөтен эш аның теләгеннән, аның ихтыярыннан башка гына эшләнер... Курмашев бу минутта үзен иксез-чиксез галәмдәге бер тузан бөртеге сыман бик бәләкәй дип хис итте. Бу дөнья, бу галәм аны теләсә ни эшләтә ала, ә ул аны берни дә эшләтә алмый, аңа фәкать коры өмет белән генә юанырга кала иде...

## Зәки Нури

# ЯҢА ҖЫР АЛЫП КИЛ, ЯКТЫ КӨЗ

*Хатирәләр дәфтәреннән*

### Ике командир турында

Мин Заслонов һәлакәтен күрдем, —
Пуля екты аны һөҗүмдә.
Сүнде батыр... Ләкин бөек җиңү
Нуры калды аның йөзендә.

Җилкәләргә тимер йөген салып,
Сугыш безне дүрт ел тилмертте.
Төбәп атты безнең йөрәккә ул,
Якыннарны бездән күмдертте.

Фронт сызыгы аерым итте илдән,
Килми торды хәтта хатлар да.
Туры килде, үлем үлсен өчен,
Күкрәк белән дотлар капларга.

Атна буе кайчак ач булдык без,
Кайчак патрон биштән артмады.
Дошман узар юлда ләкин көн-төн
Мина арты мина шартлады.

Һәм мундиры бик күп гитлерчының
Янды безнең үчле учакта...
Эх, күрмәде моны — Муса бездән
Бик еракта иде ул чакта.

Юк, күрмәде... Ләкин ул бит үзе
Баш партизан иде Берлинда!
Әйтте хәтта кулы богаулангач:
«Бар бит әле бомба-җыр миндә!»

Ул Ковпак та, Заслонов та иде,
Утка керде чыгып уттан ул.
Нәфрәт утын әйтерсең лә сипте
Күп көпшәле минометтан ул.

Һәм утыртты мәңге күренсенгә
Язмыш аны тарих түренә.
Партизанның сүнмәс дан учагы
Еракларда балкып күренә!

Тормышыма минем алар икәү
Бергә керде — җиңү эшенең
Остазлары булып. Димәк ки, мин
Ике командирлы кешемен.

Дядя Костя[1] күз алдымда тора,
Кулларында мина уйнатып.
Җәлил исә йөрәгемдә яши,
Иң җаваплы җырны уйлатып.

1975

## Егет һәм җыр

*Баллада-монолог*

Мин — якты. Мин — маяк.
    Мин — сүнмәс йолдызмын.
Ялдым-шыттым мин
    ялкынлы йөрәктә.
Иҗатчым минә ул —
    какшамас ир-егет!
Без тагын походта —
    юл алдык еракка.

Ул дәшми. Тып-тын ул:
    башында уе күп.
Сукмакка санаулап
    пичәтли адымын.
Бер күпер... ике яр... —
    Сулышын тыңлый ул
Һәм аргы ягының,
    һәм бирге ягының.

Җилкәдә — зур биштәр.
    Биштәрдә — миналар...
Бер төнне тетрәтер
    мең утка тиң алар!
Пышылдый шикелле:
    «Җилкәмдә үлем күп —
Көтегез! Һәм, фриц,
    һәм, Гитлер, сиңа бар...»

Егетем буш түгел...
    Бу юлда әлегә
үземне-үзем мин
    тиешмен көйләргә.

1975

---

[1] Белоруссия партизаннары берләшмәсе командиры, Советлар Союзы Герое Константин Заслоновның партизанча кушаматы.

Бар микән дөньяда
монннан да кыен эш:
Тавышсыз моңаеп,
дәшмичә сөйләргә?!.

Ул мине тудырды.
Мин — төнге юл башы.
Мин — аңа көрәштәш.
Мин — аның юлдашы.

Кып-кыска бу бер төн
ел булып тоелды.
Һәм... аның ноктасы
җыр белән куелды!

«Таң атар. Күпер юк —
ул күккә чөелер.
Танклар ишелеп
елгага өелер!»

Тик шундый идем мин —
ул төнге кыска җыр.
... Егетем мактады:
«Җиңүгә оста җыр!»

Мин — аның иҗаты,
мин — аның сүзе бит.
Дөресен әйткәндә,
мин — аның үзе бит.

1975

## Якут җирендә сөйләшү

— Ник монда син, әй, көн, иртәләп
Алты сәгать алдан туасың?
— Чал Иделгә тизрәк җитим дип
Ашыга минем Лена кояшым.

— Ник сез монда, ник сез, ак төннәр,
Айлар буе дәвам итәсез?
— Күреп булмый чиксез киңлекне
Безнең якты, безнең иртәсез.

— Күмелгәнсез карлар астына,
Ник, каеннар, шундый кәрлә сез?
— Озын кышның зәһәр суыгын
Җиңеп булмый шундый хәйләсез.

— Каян килә сезгә бу тизлек,
Җилне узып чапкан боланнар?
— Олауларда безнең — ашыгыч йөк,
Көтүләрдә көтә оланнар.

— Күлләр күзе, ничек бу хәтле
Нурлы булып безгә карыйсыз?
— Безнең сафлык — сезнең шатлык ул,
Саф сакларсыз безне бары сез.

— Һай, күбәү сез, дуслар-җәнлекләр!
Ник бик йомшак сезнең йоныгыз?
— Чөнки без бит сезнең бүрекләр,
Чөнки без бит сезнең туныгыз.

— Олонхоны кем ул, кем анда
Кушып җырлый мотор көенә?
— Якут җырлый! Алтын һәм алмаз
Балкышына карап сөенә!..

— Ә син үзең, Идел егете,
Ник килмәдең безгә моңарчы?
— Юк, түгел бу юлдан куркуым,
Юк, булмаудан түгел сунарчы.

Бар икәнен күптән белсәм дә
Бу якларда минем буш урын,
Киләлмәдем... Ахры, көткәнмен
Йөрәгемнең катгый кушуын.

1975

## Җырлы урман

И томаннар! Якын якның
Таныш томаннары... Көз...
Такташ яратып мактаган
Тамбов урманнары, сез

Сәламнар кабул итегез
Киң Идел буйларыннан.
Шавыгыз — йөрәк түрендә,
Чыкмыйсыз уйларымнан!

Буйларым шуңа озындыр —
Урманга карап үстем.
Теләдем: «Имән, тамыр җәй!»
Теләдем: «Нарат үссен!»

Урман, синең хәзинәңнең
Мең төрле төрен беләм.
Яфраклар шыбырдавының
Тылсымлы серен беләм.

Олы юлга чыксам — синнән
Китәм кебек кузгалып.
Төшләремә балан керә
Балланып һәм кызарып.

Миләшең... Кара җиләгең...
Шомыртың... Тавык күзең...
Җанга якын җыр көйләдең,
Булмады авыр сүзең.

Ул синең олы җанварлар,
Ул синең бөҗәкләрең! —
Шуларны күрмәсәм, никтер,
Өзелә үзәкләрем.

Иң матур сурәт ул — синең
Бәскә төренгән чагың.
Ә җәең... Язың... һәм көзең? —
Аннан да матур тагын!

Теләсә кай як урманы
Дус та миңа, якташ та.
Урман! Синең шавың белән
Җыр багышлыйм Такташка.

Олы җанлы һәр зат сине
Яратыр һәм кадерләр...
Юкка сине зурламаган
Такташ кебек шагыйрьләр!

1976

## Әйдәгез

Очыш бар — күтәрә ул безне күкләргә.
Кочыш бар — бер итә йөрәкләр тибешен.

Әйдәгез, киәксез күкләрдә очмыйк без,
Әйдәгез, җан сөймәс затларны кочмыйк без!

1975

## Ветеран сүзе

Бик күп әле без тартасы йөкләр, —
Тартканыннан бәлки күбрәктер...
Йөрәк әйтә: «Заман юлларында
Үрдән-үргә менеп күбрәк йөр!»

Олау — олы. Белә, яшьләр белән
Бергә аны нинди ат тарта.
Җыр белән чор — безнең ике маяк,
Шулар алга кыю атлата.

1975

## Кунак көткән кебек

Уйланасың кунак көткән чагында.
Бар да аңа — ни нәрсәң бар табында!
Уйланасың, кичерәсең бик күп хис:
Зар-интизар икәнемне белерме?
Тәрәзәмне еракларда́н күрерме?
Соңгармыйча килеп сәлам бирерме?
Күрешкәндә ошамасмы, ошармы?
Йөрәккәем кул кысарга кушармы?
Ошармынмы икән аңа мин үзем? —
Читкә төбәп пар йолдызга тиң күзен,
Күзләмәсме икән ерак-еракны,
Парә-парә телмәс микән йөрәкне?..

И мәхәббәт! Сине шулай кем көтмәс?!
Шуны уйлап нинди күңел интекмәс?!

1975

## Җәй үтте

Җәй үтте. Бар иде — юк инде.
Зур кояш утында янды ул.
Алмалар эченә керде җәй,
Кәрәздән бал булып тамды ул.

Бакчада балкыды гөл булып,
Шатлыгын — чишмәләр җырлады.
Таңнары кырларга чакырды —
Тарсынып, тартынып тормады.

Җәй китте. Бар иде — юк инде.
Аерылу капкасын япты көз.
Җәй эшен табында зурларга
Яңа җыр алып кил, якты Көз!

1975

## Дәшми карап тордың миңа

Куакларда кыштырдады,
Пышылдады сары көз,
Әйткән төсле: «Ник саргайдың
Көз утыннан, таныш йөз?»

Шул ук ут төсе чагылды
Синең кайнар йөзеңдә.
Теләктәш хисең шаулады
Дәшми әйткән сүзеңдә.

Тәсләрне көз куплап койды...
Яфрак булып яуды көз.
Җылысы аз булгангадыр,
Тик пышылдап янды көз.

Истә көзнең уфтанулы
Сулышыңа тиң җиле.
Әллә, чынлап, саргайган дип
Кызгандыңмы син мине?

Саргая-кызара бара
Торган саен әмма көз.
Суынып шулай арага
Керә микән әллә көз?..

Дәшми карап тордың миңа...
Саргайган дип белепме?
Ник уфтандың тып-тын гына?
Әллә... хәлгә керепме?!

1975

## Укучы дуска, тәнкыйтьче дуска

Ачам сиңа китап битләремне
Йөрәгемне учка салган төсле.
Шәфкать көтмим: әгәр алдаласам,
Чын дип әйтеп бирәр ялган төсне.

Балык судан, су балыктан курыкмый!
Сүзеңне әйт дус һәм якын итеп:
Күңел аны киңәш диеп аңлар,
Кирәк икән — санар закон итеп.

Ләкин, зинһар, чыгып чыгырыңнан,
Ялгышма һәм күккә чөя күрмә.
Иң яманы шулдыр: яманымны
Яхшы белән бутап сөя күрмә.

Хис ятмасы — серле, тирән ятма,
Дөрес юллар салып үтә белик.
Гадилекне катлауландырмыйча,
Катлаулыны гади итә белик.

1974

------------

# Рафаил Төхвәтуллин

# КАР КҮЗЕ

хикәя



Әнием! Кар ява! Кил инде тизрәк, әни, күр, нинди матур.

— Игелеккә-иминлеккә булсын, улым. Болай булгач, бик вакытын белеп киләчәк быел кыш.

— Нигә «киләчәк» дисең, әни? Әнә, килә бит инде.

— Юк әле, улым, бу кышның үзе түгел. Кар күзе бу.

— Карның күзе буламыни?

— Була икән шул, улым. Бабайлар әйткән, кар, җир өстенә ак юрган булып ятар өчен, менә шушылай башта карап китә, дигәннәр. Барысы да әзерме кышны каршыларга? Шуны карап китүе икән.

— Ә киткәч кайчан килә?

— Әгәр барысы да кышны каршыларга әзер булса, нәкъ утыз көннән соң килеп җитә. Башта сабый кар ява, аннары егет карлар, кыз карлар. Ә Яңа елда Кар бабай килә. Сезгә, нәниләргә, бүләкләр алып килә. Кайсы өйдә нинди малай, нинди кыз яши? Әйбәтләрме, әллә кайберләре бик әйбәт түгелме? Шуларны да карап китә Кар күзе.

— Әй, Кар күзе-е! Мине дә күрәсеңме? Әйт әле, мин нинди малай?

Рәфгать, уянып китүгә, үзенең кайда икәнлеген абайламыйчарак ятты. Бүлмә эче ярым караңгы, түшәмдәге зур абажурның дугай-дугай алтынсу җәпләре ялтырый да, почмактагы телевизорның карасу экранында ялгыз йолдызчык җемелди. Ә үзе ул йомшак диванда ята. Гомуми торакның шыр бүлмәсе түгел дә түгел инде бу, әмма авылдагы өйләренә дә охшамаган. Кайда соң ул?

Стена артында таныш тамак кыру ишетелде дә, хәтер кинәт уянды. Ах, әйе, Сәгыйть абый квартирында бит ул. Тәки йоклап калган икән, хәерсез. Юкса, кайтырга кузгалган да иде бит... Хуҗа аны кунарга кыстады. Неужели, башка китте икән? Антыңны бозгансың бит, эт җан!

Анысы бер сәбәпсезгә түгел инде түгелен. Сәбәбе бар. Тегендимондый гына да сәбәп түгел әле, әйтергә кирәк, җитди сәбәп. Скважиналарын бу юлы сигез көнгә срогыннан алда бораулап бетерделәр

алар. Соңгы метрларны нәкъ минә Рәфгать вахтасы бораулап төште. Сигез көн алда... Мондый уңыш сирәк эләгә бораулаучыларга. Бу урында газетага да язып чыгармагайлары. Премиясе дә тияр. Кара исәп белән генә дә йөз кырык сум чамасы.

Егетләр автобуста кайтканда ук мондый уңышны бераз «юып алу» хәстәренә керештеләр. Рәфгать тә арт кесәсеннән сигезгә бөкләнгән өчлекне тир сеңгән ялтыр эчле бүреккә китереп салды. «Өлешемне салам, егетләр, әмма мәҗлестә катнаша алмыйм», — диде. Юк, үзенең «авызга да алмаска, бик-бик хаҗәте чыкканда да чамадан артыгын тамчы да капмаска» дигән анты турында әйтеп маташмады. Үзе дә көтмәгәндә, бүтән сәбәбен тапты. «Авылга, әни янына кайтып киләсем бар», диде. Кинәт теленә килгән мондый сәбәпкә үзе үк бик куанды. Чыннан да, нигә кайтып килмәскә? Иртәгә аның ял көне, берсекөнгә дә төнге сменага гына чыгасы. Әлбәттә, кайтып килергә кирәк. Юкса, әдәм мәсхәрәсе, кайтмаганына ел тула бит инде. Һич бушый алмас эшем кешесе диярсең, хәсрәт! Автобуста ике сәгатьләп барасы да җидесигез чакрым җәяү атлыйсы — әнисе янына мондый юлны, кеше булган кеше, атна арасында да әйләнер, валлаһи.

Автовокзалга җитүгә, Рәфгать машинадан иң беренче сикереп төште дә тизрәк моннан шылды. Егетләрнең үгетләп-кыстап, үртәп-көлеп маташачакларын сизенә иде ул. Гомуми торакта өстен алмашып, юл уңаенда күчтәнәчләр алып, яңадан автовокзалга килде.

Бөтен дөньясы аңа елмая, егетнең дә гел елмаясы гына килеп тора иде.

«Чибәркәем, әни янына кайтышым, конфетның иң тәмлесен, әчкелтем-төчкелтемен, чәйнең иң высший сортын, дегет кебеген бирә күр» дигәч, ни җитди-усал йөзле юан сатучы кыз да елмаеп куйды.

Касса янындагы озын чират тирәсендә: «Их, туганнар, белмисез бу сабыйның хәлләрен! Өзелеп тә сагындым әнине, бу рейска эләгә алмасам, егылып үләргә генә кала миңа», дип, теленә салынып йөри торгач, йомшак мамык шәлле бер апа, көлемсерәвен яшереп кенә: «Кая, бир акчаңны, әдәм бөлгач әрәм була күрмә»,— дип, аңа билет алып бирде.

Автобус китәргә ярты сәгатьләп вакыт бар иде әле. Рәфгать өстенә тундра халыкларыныкы кебек чуар йонлы тун кигән, иреннәрен шәмәхә төскә, күз төпләрен зәңгәргә буяган бер кыз янына килеп утырды. «Чибәркәем, күңелем сизә, без юлдашлар булмагаек, кая барыш?» дип әңгәмә башлап җибәрмәкче иде, шәмәхә ирен, маңгай бөдрәләрен хәтәр тетрәтеп, йөзен читкә борды. «Синең ишеләргә юлдаш түгел мин», янәсе.

Әмма Рәфгатькә кем белән булса да сөйләшергә кирәк, шунсыз мөмкин түгел иде. Әйтәсе иде бу кызыйга... Синең кебек, бүтәннәрнең дә аннан, Рәфгатьтән, йөз чөергән чаклары булды, апакаем. Имеш, Рәфгать хәвефсезлек кагыйдәләрен санга сукмый, имеш, тәртибе дә чамалы... И менә шушы егет бүген нишләтте? Бүтәннәр срокка да көчкә-көчкә сыешканда, алар скважинаны срогыннан сигез көн алда бораулап бетерделәр. Уен түгел бу, җан кисәгем! Моның өчен шушы егетнең маңгай тире аз акмады. Иң күп проходканы минем вахта бирде. Ягъни мәсәлән, аңламасаң, аңлатып бирим. Җир астында ике чакрым тирәнлектә ята ул нефть дигәнең. Шул юлның яртысыннан күбрәген менә шушы куллар бораулады, беләсең килсә. Алмаздан каты ташлар кисеп, иң мәкерле ком-су дәрьялары кичеп үттек!

Аннары килеп, шуны да бел, апакаем. Бүтән егетләр шушы минутларда, юәрләнеп, бу уңышны юып утырсалар, абзаң, ап-аек көе, әнисе янына кайтып бара. Белдеңме инде, чибәркәем, янында кем утырганын?

Ә син, тәгаен генә, болайрак уйлыйсыңдыр әле. Янәсе, бу иләмсез зур куллы, куактай кашлы егет минем матурлыгыма ушы китте дә

итəгемə чат ябышмакчы була, дисеңдер. Юк, тəкəбберкəем, тамчы да юк андый нияте бу егетнең. Андыйга китсə, əйтсəм əйтим. Дөньяларда бер үз матуркае, үз кадерлесе, үз бердəнбере бар бу егетнең. Күзлəре чүт-чүт синекенə охшаш аяз зəңгəр аның да. Əмма лəкин синеке күк тəкəббер-усал карамый ул күзлəр. Мең-мең нур чəчеп, шундый да җылы, шундый да ягымлы, шундый да сөйкемле итеп карый минем бердəнберемнең күзлəре.

Исеме ничек бердəнберенең дисеңме? Юк инде, анысын син сорама, мин əйтмим. «Нəзирəм, Нəзирəм» дип көн-төн күңелемдə кабатланса да, бер теленə хуҗа була белə абзаң. Шундый да матур, шундый да кадерле исемне əрəм итеп, телəсə кайда кычкырып йөрүчелəр без түгел...

Рəфгать күршесе белəн əнə шундыйрак əңгəмə башлап җибəрер өчен башта тыйнак кына тамак кыргалап куйды, чыраена мөмкин кадəр җитдирəк кыяфəт кертергə тырышып, инде авызын да ачкан иде... Шул чак залның аргы башында автоматтан су эчеп торган Сəгыйть абыйсын күреп алды. Бу тəкəббергə тел əрəм итеп торганчы, əнə кем белəн эчне бушатырга була! Рəфгатьнең беренче остазы Сəгыйть, буррабочийдан помбурга кадəр аның кул астында эшлəде ул, аннары гына, ШБР [1] да укып чыккач, бүтəн бригадага бораулаучы булып күчте. Менə бит! «Остазын онытты бу егет» дип, үпкəлəп тə куядыр əле Сəгыйть абыйсы, җыелышларда аны яман яктан телгə алганда, «бик рəт чыкмады, ахры, бу егеттəн» дип, аңа кул селтəгəн чаклары да булмый калмагандыр. Инде менə сөйлəр сүзе, əйтер шатлыгы да бар чагында бигрəк мач очрап торуын күр.

Рəфгать, җəтмə сумкаларга, чемоданнарга, иңбашларына бəрелгəлəп, очынып кына Сəгыйть абыйсы янына килеп җитте һəм... шып туктап калды. «Əллə Сəгыйть абый түгелме бу? Ошатам гына мəллə?» дигəн уй күңеленə килде аның. Йөзе иң түбəн сорт цемент оны сипкəндəй көлсу-соры иде монның, кечерəеп калган күзлəре хəлсез карый, ə маңгаенда, бүрек астыннан ак бинт күренеп тора иде.

— Сəгыйть абый... ни хəллəр?

Тегесе дə, егетне танымагандай, бермəлгə сүзсез генə аңа карап торды.

— Сорама, малай. Хəллəр шəптəн түгел.

— Ни-нəрсə булды?

— Үлемнəн калдык, малай.

— Ə?!. Ничек?

— Кайтканда машинабыз туң юлда чалулап китте дə КрАЗ белəн бəрелеште. Икебезне больниска салдылар. Мидхəт скорый помычта гына аңына килде. Федя биленə түзə алмый... Мине дə салмакчылар иде, ыгы-зыгы арасында тизрəк чыгып шылдым. Башта зыян бар да, менə, тезне бəрдем. Үтəр əле...

— Менə син, ə!..

Сəгыйть, буш стаканны кулында əйлəндергəлəп, тагын сүздəн калды. Стаканны əйлəндерə-əйлəндерə дə бик җентеклəп төбенə карап тора, гүя шуннан ниндидер җавап эзли кебек иде.

— Алай да, əҗəл җитмəгəн икəн, малай. Машинабыз, бер җир буе əйлəнə-əйлəнə шуып барып, инде яр астына мəтəлəбез, инде беттек дигəндə юл баганасына төртелеп калды. Ничəмə кешенең гомере бер шул баганага элəгеп торды, белəсеңме шуны...

— Менə син!..

Сəгыйть стаканны бик каты шакылдатып, автоматтагы оясына куйды.

---

[1] ШБР — школа буровых рабочих.

— Карале, ниме... Вакытың булса, закусочныйга кереп чыгыйкчы? Сызламаган җир юк, малай. Берәр йөз грамм белән тәннәр язылып китмәсме? Үлемнән калу шәрәфенә бер гөнаһысы да булмастыр.

— Бик дөрес, Сәгыйть абый, — дигәнен Рәфгать үзе дә сизми калды. Остазының хәленә кереп, бик җылы сүзләр әйтәсе килә иде аның, әмма андый сүзләр телгә килми, болай тиле сымак «эһе-меһе» килеп басып торулары аңа бик уңайсыз иде. Менә бит ул дөньялар! Берәүләр шатлык-куаныч канатында тирбәлгәндә, икенчеләргә әҗәл үзенең сөяк-чел кулларын сузган. Кем әйтмешли, берәр нәрсә кабып алмыйча, һич очына чыгышлы түгел монда. Ә инде теге антка килгәндә... Ул антның бит икенче өлеше дә бар: «Бик хаҗәте чыкканда, артыгын тамчы да капмаска...» Аннары килеп, гадәттә хәмерише белән һич чуалмый, исерекләрне җене сөйми торган Сәгыйть абыйсы үзе чакырып тора икән, бу инде нәкъ шулай кирәктер дә...

...Закусочныйдагы озын чиратны да Рәфгать үзенең җор теле белән бик тиз әйләнеп узды. Сәгыйть абыйсы стаканны, ниндидер хәшәрәткә орынырга дучар булгандай, йөзен бик яман чытып, ике бармагы белән генә кулына алды, шәкерте белән чәкешеп-нитеп тормыйча, тиз генә тамак чылатып куйды.

— И малай...— диде авыр сулап.— Бәла анасы буаз, дияр иде безнең әти. «Бәла артыннан бәла атын камчылап куа килә» дип тә өстәр иде. Шуның ише, төште минем башларга бу көннәрдә... Өченче көн генә хатынны больниска салдым. Әллә бавыр, әллә бөер чире. Врач әйтә, операциясез булмас, ди. Бик авыр, бик катлаулы операция икән. Шул хәсрәттән миңгерәүләнүем булгандыр инде, кичә скважинада... күңелсезлек.

— Нәрсә булды?

— Пласт ярылды. Нибары алтмыш метрлап бораулыйсы калгач бит... Үзем гаепле, малай. Бары үзем. Шунда турбинны җайлап кына иплэп кенә төшерсәм соң инде!.. Юк бит, әллә кая, җәһәннәмгәме ашыгам... Ни шома, стакан күк ствол үзе. Каротажниклар да шаккатып киткән иде. Инде болай булгач, иртәләргә эшен бетерербез моның дип торганда... Ярылды... Ямарга күпме кожгорох [1], күпме соляркалы балчык тутырдык, юк, барысын да, аждаһа кебек, йотып кына бара... Савельев буровоендагы кебек, айлар буе утырмасак ярый инде... Чүп өстенә чүмәлә, син дә килеп чүгәлә, ди...

— Менә бит ул безнең хәлләр! — дип Рәфгать тә Сәгыйть абыйсы кебек авыр сулап куйды, ә иреннәр нигәдер колакка таба ерылып китте. — Болай булгач... Кая соң...

Ул буфетка таба борылуга, Сәгыйть аның җиңеннән тотты.

— Ярамый, малай. Минем әле карчык янына да кереп чыгасым бар, өйдә балалар да көтәдер.

Больницага бергәләп киттеләр. Рәфгать: «Мин бит, ни... Ишеткән идем Гөлсем апаның авырганын. Конфетлап Һиндстан чәе эчеп җибәрсә, шифасы тимәсме» дип, Сәгыйтькә үзенең юл сумкасын биреп кертте.

Шактый озак көттереп чыкты аннан Сәгыйть. Чыгуга, ишек төбендә басып торган Рәфгатьне бөтенләй дә күрмичә, тагы да битәр аксаклый-титаклый китеп тә барды.

Рәфгать сүзсез генә аның артыннан иярде.

— Бу врачларны да әйтер идем. Ни тизрәк операциясен ясамыйлар, ни өзеп кенә чирен әйтмиләр... — дип, үзалдына сукранды Сәгыйть хутлыдан-хутлырак титаклый барып.

— Алар кулына эләгергә язмасын инде, — диде Рифгать нәкъ остазы көенә тәңгәшләп.

[1] Бораулауда катлам ярыкларын ямау өчен кулланыла торган, борчак сыман бөтерелгән күн-мех калдыклары.

— Ярый әле, янына кертмәделәр. Анысын дөрес иттеләр, малай. Юкса, минем аякны, башны күреп, ишчу да хәстәләнер иде. Болай да, кая кирәк чуар йөрәк... Дөрес иттеләр, янына кертмичә.

— Врачлар белә инде ул, — диде Рәфгать тагын нәкъ остазы көенә.

Сәгыйть, юлдашына ялт борылып карап куйды да, кайтып җиткәнче бүтән бер сүз дә дәшмәде.

Өендә дә Сәгыйть абыйсының теле алай ачылып китмәде. Сүзнең инде дә тәмен белеп, әңгәмәнең очын-җебен инде дә оста тотып гәп сугарга ни маһир кеше үзе!..

«Соң инде... Борчу-хәсрәте, авырту-сызлануы баштанаяк чагында, ничек сине күрәсе килеп торсын аның» дип, Рәфгать, хуҗа кухняда чакта, плащын да кулына алган иде... кире элде. «Юк инде, нәкъ шушындый чагында ялгыз калдырма син аны. Бар борчуын, бар авыртуын оныттырырдай шундый да шифалы-җылы сүзләр тап. Аннары килеп, син үзеңнең остазыңа бүгенге уңыш-шатлыгың турында да сөйләмәдең ич әле. Сөйлисе иде бит.. Сөйләргә кирәктер».

Сөйләде ул остазына бу турыда. Моннан башка да бик күп матур сүзләр сөйләшенде. Ләкин... Нигә моның өчен, әүвәле, кибеткә йөгерергә кирәк булды соң әле? «Тел ачкычы», имеш. Бүтән чакта андый «ярдәмче»дән башка да, сүз эзләп кесәңә керми идең ич... Антын бозган эт җан син!..

Рәфгать, одеалны кушаяклап күтәреп, мәтәлчек атарга җыенгандай сикереп торды. Ярар, үткән эшкә салават, моннан ары акыллырак булырга сабак булсын. Болар кузгалганчы, тизрәк ычкынырга кирәк. Рейсовый автобусны да көтеп тормастан, берәр юл уңае машинага чамалыйсы булыр.

Ул, сәгатенә күз төшерер өчен, тәрәзә пәрдәсе читен күтәрде. Күтәрде дә, шунда ук пәрдәне бөтен киңлегенә ачып җибәрде.

Тышта кар ява иде.

Кичә генә кара-соры булган җир өсте ап-ак... юк, ап-ак түгел, аз гына күксел, хәтта, әнә, тәрәзәләрдән яктылык төшкән урыннарда алтынсу, алсу. Ә һавада, бөтен җир-күк арасын тутырып, шундый үк ак, зәңгәрсу, күксел, алтынсу, алсу күбәләкләр очына.

Кар ява. Беренче кар.

Кыш килә.

«...— Юк әле, улым, бу кышның үзе түгел. Кар күзе бу.

— Карның күзе буламыни?

— Була икән шул, улым. Бабайлар әйткән, кар, җир өстенә ак юрган булып ятар өчен, менә шушылай башта карап китә дигәннәр...»

Кайчан булды соң әле мондый сөйләшү? Аермачык хәтердә... Ул тәрәзә төбенә аякларын бөкләп менеп утырган, үзе артында басып торган әнисенең кочагына сыенганнан-сыена... Кичә генә кебек. Әллә, чыннан да, кичә генә булдымы бу? Әллә бүген шулай төшендә кабатландымы?

Көтәсеңдер улыңны, әнием. Шуңа көтүләрең миңа төш булып хәбәр саладыр. Көттердем шул... Инде менә күп булса өч сәгатьтән янында булырмын, әни. Үзем дә бик-бик сагындым сине...

«...— Башта сабый кар ява, аннары егет карлар, кыз карлар. Ә яңа елда Кар бабай килә. Сезгә, нәниләргә, бүләкләр алып килә. Кайсы өйдә нинди малай, нинди кыз яши? Әйбәтләрме, әллә кайберләре бик әйбәт тә түгелме? Шуларны да карап китә Кар күзе».

Әнисе, аны күтәреп алып, тәрәзә төбеннән төшерде. «Ату тәрәзә төбендә утырган малайлар үсмиләр, бәләкәй булып, карсак булып калалар», диде. Әнисенең муеныннан кысыбрак кочаклап, шулай озаграк күтәрттереп торасы бик килә иде Рәфгатьнең, ләкин тизрәк идәнгә төшеп басты. Юкса, әнә, Кар күзе карап тора бит. Кар бабайга ни дип хәбәр итәр?..

Рәфгать, нидәндер качкандай иелә төшеп, кинәт тәрәзә яныннан китте, диванга килеп утырып, ике куллап башын учлады.

Инде менә Кар бабайга ни дип хәбәр итәрсең икән син, Кар кызе, бу егет турында? Әйт, Кар кызе, дөресен әйт: «Әйбәт малай түгел ул Рәфгать, антын бозды» диген. Теләсә ничек хөкем итсен.

Үзенең шулай нәкъ сабый вакытларындагыча уй йөртүеннән рәхәтләнеп бер көләсе килә иде Рәфгатьнең, ләкин көлеп булмады — иреннәр бары мыскыллы бер кыйшаеп кына куйды.

Ярый әле, Сәгыйть абыйсы аны кичә өйдән чыгармаган. Аяклар тәки үзеннән-үзе Тимирязов урамына таба атлап китәр иде. Ярты стена тотырып «Акчагызны саклык кассасына салу уңайлы һәм файдалы» дигән галәмәт зур плакат эленгән йорт янына җиткәч тә, туктап калмас иде аяклар. Икенче катка күтәрелеп, саңакларына киез тасмалар кадакланган ишекне дә шакыр иде. Бусаганы атлап керер идеме — анысы билгесез. Хәер, көн кебек ачык... Борын төбендә ишекне шап итеп ябып куймагае Нәзирәң. Хур булырга тагын күпме кирәк?!

Шулай да... Нигә ачулануларына кадәр бу тикле дә сөйкемле соң ул кызыйның? Алай гынамы! Ул һәр көн атлап уза торган урамнар ук күңелгә якын, ул яшәгән кызыл путалы йорт нинди матур, киез тасмалы ишек никадәр ягымлы. Тупса янында ул тасма, кубып, сорау галәмәте кебек бөгелеп төшкән — шунысына кадәр нинди мөлаем.

Беләсе иде... Ишетте микән Нәзирә безнең бригаданың кичәге уңышы турында? Ахирәте Мөзәния белән очрашсалар, ишетми калмас калуын. РИТСта үзенең исәп-хисап вазифасын ничек үти торгандыр ул Мөзәния — анысын шәйтан белсен, — әмма төлке койрыгыдай кызгылт чәчле — буяткан булса кирәк! — шушы бөтерчек кыз Рәфгатьнең эштәге һәр гамәлен-кылмышын белеп тора. Белеп тора, ахирәте Нәзирәгә җиткерә тора. Кичә дә очраштылар микән?

— Әй, юлчы егет, кузгалмыйсыңмы әле? Без монда таралышып бетәбез.

Сәгыйтьнең ипләп кенә, кычкырмый гына дәшүе Рәфгатьне сискәндереп җибәрде.

— Кузгалдым, Сәгыйть абый. Ычкынам.

...Сәгыйть ике улын мәктәпкә озатып җибәргәч, шунда, ишек катындагы ук тәбәнәк урындыкка чүгәләп утырды. Аннары, авыр гына күтәрелеп, чөйдән брезент тышлы кыска тунын алды, селтәнеп, кулын жиңгә тыкканда, тын гына ыңгыраşты шикелле... Һәрхәлдә, тунын киюгә, ике куллап чигәләрен тотып куйды.

Рәфгать кухня яктан остазының һәр хәрәкәтен күзәтеп утыра иде. Кинәт аның күз кабаклары ачыттырулы җылынып китте. «Нигә эшкә бара соң әле ул? Чирли бит... Кичә кереп кенә ятасы калган аңа больниска. Анысы, икәүләшеп ятасылары килмәгәндер инде. Балалар ялгыз кала бит. Нихәл итәсең...»

Рәфгать ничектер үз-үзен белешмәстән генә шешәгә үрелде дә, кинәт кызган двигатель яңагына орынгандай, кулын тартып алды, урыныннан ук торды.

— Сәгыйть абый, беләсеңме нәрсә... Сал әле син туныңны. Бармыйсың бүген вахтага! Әйдә, пәлтәңне ки дә, больниска киттек.

Сәгыйть табаннарын куллары белән сыпыра-сыпыра бик пөхтәләп аякчу чолгап утыра бирде.

— Кайчан нәчәлник булып алдың әле син болай? Боерыкны оста бирәсең үзең,— диде ул күтәрелеп карамыйча гына.

— Мин чынлап сөйләшәм, Сәгыйть абый. Кереп ятырга теләмисең икән, больничный ал. Балаларың янында булырсың. Гөлсем апа янына йөрисең бар. Мидхәт белән Федя янына да кергәләргә кирәктер. Ал больничный.

Сәгыйть, урыннан торып, бүреген кулына алды.

— Юк, малай, бармыйча һич ярамый миңа вахтага. Авариягә мин үзем гаепле... и үзем үк төзәтергә тиеш мин аны. Үзем! Аңлыйсыңмы шуны?

— Аңламыйм, аңларга да теләмим! Эшкә бармыйсың бүген. Точка. Беләсең килсә, вахтага синең урынга үзем китәм. Ә син — әйдә, выжт! — больниска! Җәтрәк туныңны салып бир дә, киттем мин.

— Изге ниятләрең өчен рәхмәт, энем. Син бит авылга, әниең янына кайтырга чыккан кеше, юлларың уң булсын!.. Ә без... Без алай бүтән бригадалар ярдәменә калмаган хәзергә. — Һәм ул, үрелә төшеп, егетнең иңбашыннан шапылдатып алмакчы иде, тегесе, кирчегә баладай, иңен читкә тартты.

— Ярдәмгә дип... Мин ярдәмгә дип барам мәллә? Синең урынга барам мин. Бары шул гына. Ә авылга кайтырга өлгерәм әле мин. Иртәгә миңа төнге сменага гына чыгасы, запаска тагы ике көн отгулым бар.

Сәгыйть дәшмичә генә каршындагы урындыкка килеп утырды.

— Ышанмыйсың син миңа, Сәгыйть абый. Үзеңнең шәкертеңә ышанмыйсың. Эш менә нәрсәдә...— Рәфгать карлыгулы кычкырып ук җибәрде.— Андый гына аварияләрне күрмәгәнме без!..

— Вәйт, иске авыздан яңа сүз. Нигә ышанмыйм ди мин сиңа? Ничә ел бергә эшләп... Ни хакым бар ышанмаска? — Сәгыйть, торып, тун төймәләрен тиз-тиз каптыра башлады.— Алайса, без болай итик, Рәфгать. Хәзер үк РИТСка элдерик. Хәлне сөйләп бирик. Анда ни әйтсәләр, шул булыр. Юкса... Алай үз вуле йөрергә, әбиеңнең сыер абзары түгел ул сиңа буровой!

— Соң! Кем әле монда үз вуле йөрергә җыена? Мин диспетчерга телефоннан гына шалтыратырмын дигән идем. Икәүләп барып сөйләшү әйбәтрәк булыр ул, — диде Рәфгать. Ә эченнән: «Шунда теге кызыл чәчне дә сөйләндереп аласы булыр. Нәзирә турында берәр хәбәр җиткерми калмас», дип уйлап куйды да, турсайган иреннәр, ирексездән, җылы-рәхәт җәелеп китте.

Алар урамга чыкканда, кар инде яуудан туктаган, асфальт тротуарлар ялтыр-юеш каралып та өлгергән, түбәләрдән чут-чут тамчылар тама иде.

«Китәсең дәмени инде, Кар күзе? — дип уйлады Рәфгать тамчыларга учын суза-суза. — Бу егет турында Кар бабайга ни дип хәбәр итәрсең икән? Әйтче, Кар күзе!..»

## Зиннур Мансуров

### Иделгә хат

*Солдат дәфтәреннән*

Чык янамы җиләк яфрагында —
җемелдиме кояш тамчысы?
Арышларны кыйнап үстерәме
аҗаганнар — арыш камчысы?
Исән-саумы минем кендек әби,
чилләләрдә үлән пешәме?
Сабан туе батырлары кемнәр,
игеннәргә сөт мул төшәме?
Әнкәй туфрагында йорт салырга
бармы әле яңа урыннар?

...Буразнаңнан бүз тургайлар итеп
Күккә күтәрәсе җырым бар.

●

Кул астыңа шәфәкъ агып кергән...
(Җөй эшем дип күз дә йоммадың).
Ак энәңнән ай нурлары аккан
тәгәрәтеп якты йомгагың.
Кул астыңа төннәр агып кергән,
Көннәр агып кергән бүз булып.
...Энәңдә дә, әни, гомереңдәй
кояш нуры калган өзелеп...

### Яшьлек кайтавазы

Кай уемнан ваз кичәрдәй булсам,
йолкып ала мине хыял-ат!
Ятим калган яшьлек кайтавазы:
«Хыялларга итмә хыянәт...»

Хыялларын барлап, «Кем булдың?!» дип
Әйтер күк ул бәреп маңгайга.
Ул чак кояш якынрак булган
каен башындагы малайга...

●

И бала чак... Каен иле
суын биреп эчергән чак.
Телдә җир һәм кояш тәме —
чык исеннән исергән чак;
Җир өстендә кабак кебек
аунап үскән,
уй кергән чак.

И бала чак —
хәр утрау —
татлы гомер кичергән чак, —
Хыялларны гына алып
бирге ярга күченгән чак.

## Соңгы акчарлак

Канатларың — күккә ашкан
ярсу дулкын теледәй.
Сыйган аңа Иделемнең
давылы да, җиле дә.

Төш, акчарлак, кочагыма,
канатыңны, кил, сыйпыйм.
Кызыл тәлгәш-тәпиеңне
куенымда җылытыйм.

Зәңгәр төшләр күрер Идел:
давыл алда, яз алда.
Бир, акчарлак, каурыеңны,
сагынып җыр язарга.

Дулкын сине, сулгып-сулгып,
юксынып елар менә.
Алып киттең Иделемнең
давылын йөрәгеңдә.

●

Адым саен хатирәләр
җиргә гөлдәй түгелгәнме?!
Я гөләп күк чәнчеп ала,
я назлый ул күңелләрне;
я күгәрчен күзе булып
бага кебек яшь чаклары:
аланнарга сибелешкән
авылымның карчыклары...
Бөтнек эзләп йөриләрме,
онытып алар бар гамьнәрен,
әллә — эзләп
кыз чагында җиләк арасына
тәгәрәгән мәрҗәннәрен?!

## Тарихи заповедникта

«Вакытлар табылмыйдыр якут белән...»

Г. Кандалый

Һавадан кош моңы иңсә дә,
тузганак тоталмый үз таҗын.
Ап-ачык күрдем мин бу илдә
көннәрнең таҗ кебек тузганын.
Йөрәккә давыллар кагылган,
чәчләрне агартып узган моң...
Вакытны узсак та, бер күмәр
безне дә вакытлар тузаны.

Күмә дә актара... Вакытлар
елларны күмә дә актара.
Җәүһәрләр йөзендә нур һаман,
гасырлар төбендә ятса да.
Дәверләр катламы астыннан
яктыра кояшлы алкалар...
Ярый ла, безне дә бер шулай
хәтердән актарып алсалар.

## Ышаныч

Картлар китә соңгы юлга,
фатихалар кала: — Хуш, бала...
Сезнең кулда шушы Җир кала,
бездән калган үксез хыялларны
үзеңнекеләргә куш, бала...
Хуш, бала!

## Күзге кичтә

Чү! Тирәкнең яфраклары
дәррәү очып китте, дисәм...
Кошлар икән! Бер гаилә...
Чү! Тирәктән дәррәү кубып,
кошлар очып китте, дисәм...
Яфрак икән... Бер гаилә...

## Үзбәк Саттаров

# КЫЗЫМ ХИКӘЯЛӘРЕ

### «...Идән ватылмады»



Гүзәл йөри башласа, шатлыгымның чиге булмас, кешеләр сыман мин дә кызымны ияртеп, урам буйлап масаеп йөрермен кебек тоела иде. Хәзер менә Гүзәл йөри генә түгел, йөгерә дә башлады инде. Шулай да күңел тыныч түгел әле. Йөгерер хәлгә килгәч, бала гел йөгереп тора икән: кая барып бәреләсен, кайда лапылдап егыласын уйламый да. Ачуланып та, үгетләп тә булмый үзен. Берничә тапкыр башын бәрде, егылып тезләрен дә сыдыртты инде. Бәлки шулар сабак булыр дигән идек, аларның файдасы тимәде. Әнә тагын лапылдап, башы белән идәнгә егылды.

— Тукта әле, әнисе, — мин әйтәм, — моны башкача «үгетләп» карыйм.

Гүзәл сикереп торды да, иреннәрен турсайтып, башын тотты. Янына барып: «Әй, минем кызым башын бәргән икән!» — диюгә, мөлдерәтеп елап җибәрергә хәзер иде. Әмма бу юлы алай итмәдем: янына килеп, баланы кызганасы урынга, идәннең аның башы бәрелгән җирен капшап карадым. Гүзәл аптырап бер миңа, бер әнисенә, бер идәнгә карап куйды. Олы кеше булса, «баш шундый нык бәрелгәндә, боларда нинди идән кайгысы?» дияр иде дә бит, бала — беркатлы. Мин аңа бик җитди кыяфәт белән:

— Егылып, башың белән бәреп идәнне ватсаң, кирәгеңне бирермен! — дидем дә, ышанычлырак булсын өчен, бармак та янап куйдым. Гүзәлнең башын тотып торган кулы акрын гына шуышып төште. Ул бераз аптырап басып торды да тагы йөгерә башлады.

Озак та үтмәде, Гүзәл тагы егылды. Бу юлы инде башы шактый шәп бәрелде бугай, чөнки шапылдаган тавыш ныграк чыкты. «Нишләр икән» дип карап торам. Торып утырды. Кулы белән башын капшый башлаган иде, мине күрде. Күзләре юешләнеп барса да, еламый әле. Мин аңа таба бер-ике адым ясауга, Гүзәл идәнне капшый башлады. Аннары шатлыклы тавыш белән:

— Әти, курыкма, идән ватылмаган! — диде.

## «Конфет пычрак түгел инде!»

Әниләре, «мин хәзер кайтырмын!» дип каядыр чыгып китте. Кызларым Гүзәл һәм Гөлнара белән без өчәү өйдә калдык. Минем белән калганда, алар үзләрен иркенрәк сизәләр, теләсә ничек уйныйлар: мине ат итеп атланып йөрергә дә, курчак итеп төреп диванга яткырырга да ярый... Шуңадыр инде, Гөлнарасы әнисе чыгып китүгә үк:

— Әйдә, әти, атлы уйныйбыз, син ат бул! — дип, йөгереп, минем янга килеп тә җитте.

Ашыгыч эшем бар иде — баланың тәкъдимен кабул итә алмадым. Шулай да күңелен кайтармас өчен, бер төргәк конфет китереп бирдем дә:

— Мә, апаң белән курчакларыгызга конфет ашата торыгыз, — дип, эшемә тотындым.

Шактый вакыт узды. Балалар да мине борчымадылар, мин дә аларга игътибар итмәдем. Тик әниләре кайтып кереп:

— Кара әле, кызларың пычракка батканнар! — дигәч кенә күтәрелеп карадым. Кызларым да, аларның курчаклары да конфетка буялып беткәннәр иде.

Дүртебез дә, баскан килеш, бер-беребезгә сүз кушмыйча карашып тордык. Тынычлыкны Гөлнара бозды:

— Конфет пычрак буламыни. Пычракны ашамыйлар, конфетны ашыйлар! — диде дә, һич тә исе китмичә, эре-эре атлап кухняга кереп китте.

## «Юк, мин үзем егылдым!»

Гөлнара тышта егылган. Күлмәгенең пычранган җирен безгә күрсәтмәскә тырышып, шыпырт кына өйгә кергән. Ул ишекне ябып бетергәнче, әнисе эшнең нидә икәнен аңлап өлгерде. Хәзер эләгәчәк аңа. Бала үз хәлен үзе җиңеләйтергә тырыша:

— Мине Гөлшат төртеп екты бит.

Әмма кызымның тавышы шикле, җитмәсә, песи баласы мияулаган кебек, бик йомшак чыга. Күзләре дә идәнгә караган. Алдашканы көн кебек ачык.

Әнисе дә хәйләкәр бит, баланың сүзенә ышанган булып:

— Ярар, алай булгач башка вакытта Гөлшат белән уйнамассың! — диде.

Гөлнара дәшми. Бик ялварулы чырай белән әнисенә карап тора.

— Ярар, кызым, борчылма, Гөлшатны әнисенә әйтербез — кеше балаларын урамда төртеп егып, өсләрен пычратып йөрмәсен, — диде безнең әниебез.

Гөлнара тагы да ныграк уйга калды. Җитдиләнде.

— Юк, мин үзем егылдым! — диде ул.

Үзендә дөресен әйтерлек көч тапты.

## «Анда суган әрчиләрмени?»

Ял көннәренең берсендә авылдагы Хәйрулла абзыйларга килеп төштек. Күршеләрендә генә туй икән. Туй бара торган йортның тәрәзәләре ачык, өй эчендә гармун уйный, җыр яңгырый. Музыка

аралаш аерым-аерым гына «әче-әче!» дигән авазлар ишетелеп китте, ә аннан соң җыйнаулашып, иҗекләп, «ә-че! Ә-че!» — дип кычкыру яңгырады. Балалар тынып калдылар, ни булганны аңламыйча бер миңа, бер туй бара торган йортка карап куйдылар. Гөлнара аптырап:

— Әти, анда суган әрчиләрмени? — диде.

## «Халыклар киткән»

Балалар белән җыенып әбиләренә барырга дип урамга чыккан идек тә автобуска утыра алмыйча кире кердек. Автобуслар да сирәк йөри, кеше дә бик күп. Балалар белән түгел, үзең генә дә утырырлык түгел.

Күрәм, балаларның әбиләренә барасылары бик килә. Бераз гына уйныйлар да балконга чыгып автобус тукталышын күзәтәләр. Менә бервакыт Гүзәл йөгереп килде дә ашыга-ашыга әнисенең итәген тарта башлады:

— Әни, дим, әни, тизрәк әйдә әбиләргә барабыз! Халыклар киткән!

## «Ул добавка сорый бит!»

Бакчага йөри башлагач, балалар теленә рус сүзләре керә башлады. Менә бүген дә Гөлнара бакчада өйрәнгән һөнәрләре белән мактанып утыра:

— Әти, мин добавка сорый беләм, — ди.

Гөлнара миңа карап куя: ничек инде әти булып әти добавканы белми? Мин, баланың шиге калмасын өчен, башымны селкеп, андый сүзне аңламаганымны белдерәм. Ул тырыша-тырыша аңлата башлый:

— Добавкамы? Добавка бирсеннәр өчен кулны күтәрергә кирәк!..

Шушы мәлне телевизорда бер футболист тупны капкага тибеп кертте дә, шатлыгыннан кулларын күтәреп, футбол кыры буйлап йөгерә башлады.

Гөлнара ашыга-ашыга сүзен дәвам итте:

— Әти, күрдеңме? Ул добавка сорый бит! Аңа капкага тагы бер туп кертергә кирәк, ә тупны башка абыйлар алып китте, — ди.

## «Мин дә сезнең белән бармыйм әле!»

Өлкән кызым Гүзәл мәктәпкә йөри башлады инде. Кечкенәсе Гөлнара әле һаман балалар бакчасында. Әлек тә үзенең өлкәнләгән сизгән Гүзәлгә бу аерма җитә калды — ул үзен Гөлнара алдында тагын да эрерәк тота башлады. Гөлнара да апасы алдында бәйсезләгән күрсәтергә тырыша.

Бер көнне кичкырын безгә Гүзәлнең иптәш кызы Әминә керде. Әминәне каршы алырга Гүзәл, аның артыннан Гөлнара чыкты. Әминә белән пышылдашып нидер сөйләштеләр. Гүзәл, күрәсең, Әминә белән чыгып китәргә уйлап, тиз-тиз киенә башлады.

Гөлнара да аларга ияреп киенергә тотынган иде. Гүзәл кырт кисеп:

— Без сине алып бармыйбыз! — диде.
Гөлнара киенә башлаудан туктап:
— Мин үзем дә сезнең белән бармыйм әле! — диде.

## «Нигә синең правоңны да алмыйлар?»

Күршебез Наил кергән безгә. Ул күптән түгел генә «Жигули» сатып алды. Кызларымны үз малае белән бергә машинада йөртә. Шуңадыр инде, кызларым Наилне бик яраталар. Гөлнарасы аның алдына ук менеп утыра.

Чәй янында Наил шофер булып эшли торган энесен исенә төшерде һәм сүзен:

— Юньсез малай, эчкән булган — правосын алдылар, — дип тәмамлады. Гөлнара бераз Наил абыйсына карап торды, аннан соң миңа карап куйды:

— Наил абый, син дә эчәсең бит, нигә синең правоңны да алмыйлар? — диде.

## «Алайса, миңа да калдырыгыз...»

— Әйдә әле, кибеткә барып кайтыйк, — дип кычкырыбрак әйтте шул әнисе — балалар ишеттеләр. Шуннан соң аларны өйдә калдырып чыгып китә алырмын дип уйлама да инде, чөнки алар кибеттә йөрергә бик яраталар. Сорап җанга тиярләр дип, аларны өйдә калдырырга тырышмадык та, ияртеп кибеткә киттек.

Кибеттә йөрү рәхәт. Нинди генә уенчыклар юк анда! Күлмәкләр, тасмалар, эшләпәләр! Рәт-рәт тезелеп тора. Берсен карап бетермисең, икенчесенә күз төшә. Тик менә Гүзәлнең буе гына җитми, прилавканы биегрәк ясаганнар. Ул минем чалбардан тарта: әти, күтәр, янәсе!

Әнисе миңа:

— Ошыймы сиңа менә шушы күлмәк? — диде.

— Ошавын ошый да бит, кесәдә ул кадәр үк акча юк! — дидем.

Әнисе җаен тиз тапты:

— Калдырып торыгыз, бераздан акча алып килермен, — дип, сатучыдан үтенде.

Шул вакыт Гүзәл:

— Миңа да алыйк шундый күлмәкне! — дип, итәктән тарткалый башлады.

— Ул бит сиңа зур, — диде әнисе.

— Әнә, бәләкәйләре дә бар бит, — ди Гүзәл, үзе күлмәктән күзен дә алмый. Бик ошады, күрәсең, аңа бу күлмәк. Хәзер инде сүзгә мин кысылдым:

— Кызым, ул күлмәк бит олы кызлар өчен тегелгән!

— Үзең бит миңа «зур кызым» дисең.

Мин баланы ышандырырлык, ул каршы килә алмаслык дәлил эзли башладым.

— Мондый күлмәкне паспортлары булган кызлар гына кия, ә синең әле паспортың юк! Паспортың булгач алырбыз сиңа бу күлмәкне, яме, кызым! — дидем.

Гүзәл пошаманга төште. Ләкин аның шиге озакка бармады:

— Ә паспорт кайчан бирәләр соң?

— Уналты тулгач.

Гүзәл бер күлмәккә, бер миңа, бер сатучыга карап куйды. Аннары сатучыга:

— Алай булгач, миңа да бер күлмәк калдырыгыз, без аны миңа уналты тулгач килеп алырбыз, — диде.

## «Нишләп мин сөт тешләре белән йөрим ди?»

Ике кызымны да ияртеп, өлкән кызым Гүзәлнең тешен алдырырга больницага киттек. Гүзәлнең беренче тапкыр теш алдыруы әле. Юл буе шул турыда сөйләшеп барабыз:

— Тешләр кайчан төшә башлыйлар?

— Тешләр үзләре төшәме, әллә аларны гел алдырырга кирәкме?

— Тешне алдыргач, авыз гел каныймы?

— Тешне авырттырып алса да, врач апага рәхмәт әйтергәме?

Больницага бик дәртләнеп, зур кыюлык белән килеп кердек. Чират алып, чакырганны көтеп, тыныч кына утырабыз. Әмма врач бүлмәсеннән тешен алдырып коридорга чыккан беренче малайны күрү белән хәл үзгәрде. Гөлнара бер апасына, бер яңа гына тешен алдырган малайга, бер миңа карап куйды. Аның күзләрендә «Гүзәлне дә шушы малай хәленә калдырабызмыни инде?» дигән сорау бар иде.

Гүзәл дә шикләнеп:

— Әти, минем теш бәлки үзе төшәр, — дип куйды.

Гөлнара:

— Мин тешләремне беркайчан да алдырмыйм, — диде дә, борылып, ишеккә таба китә башлады.

Аны, җитәкләп алып килеп, урынына утыртырга туры килде. Көч-хәл белән, сөт тешләре вакытлы тешләр, иртәме-соңмы аларны алдырырга кирәк, алар урынына нык тешләр чыга икәнен аңлатып, аларны көйли алдым. Чират җиткәч, Гүзәл, безне калдырып, врач бүлмәсенә үзе генә кереп китәргә риза булмады. Рөхсәт белән, өчәү бергә кердек. Читтән генә карап торуыбыз да аңа көч бирә, күрәсең. Озак та үтмәде, врач апасы аның селкенә торган тешен алды. Ул, мамык белән авызын каплап, безнең янга килде.

Көтмәгән хәл, Гөлнара врач бүлмәсеннән чыгып китәргә уйлап та карамый, киресенчә, Гүзәлне утыртып тешен алган урындыкка таба бара, үзе врач апасына:

— Минем тешне дә алыгыз, — ди.

Врач белән бергәләп аның тешләрен алырга әле иртә икәнен аңлатырга тотындык. Аңлаган кебек тоелды. Әмма юл буе безне әрләп, әле миңа, әле апасына бәйләнеп кайтты. Өйгә кайтып кергәч тә бәйләнүен дәвам итте:

— Мине берәү дә яратмый. Гүзәлнең тешен алдырттыгыз, минем тешне алдыртмыйсыз. Мин дә зур бит инде, нишләп мин сөт тешләре белән йөрим ди!

## «...Ничек кайттың?»

Әниләре озаграк кайтмый торган иде, балалар чын-чыннан пошаманга төштеләр. Аның кайчан кайтасын әле берсе, әле икенчесе минут саен сорашып кына тора. «Уйный торыгыз, әниегез хәзер кай-

тыр», — дип юатам үзләрен. Бераздан соң үзем дә: «Кара син аларны, мин атналар буе командировкада йөрим, әниләре белән үзләре генә торалар, әниләре юкта минем белән бер-ике сәгать тә тыныч кына утыра алмыйлар», — дип көнләшеп тә куйдым. Гөлнарасы һаман чалбар балагын тарта:

— Әти, әйт әле, әни нигә кайтмый ул?

Ачуым да чыга башлады бугай, бу юлы уйлап-нитеп тормыйча:

— Әниегез олакты! — дидем.

Гүзәл бу сүзне ишетеп кулыннан курчагын төшереп җибәрде, Гөлнарасы минем күзләремә карап катып калды. Шул вакытта ишек шакыдылар. Барып ачсам, әниләре кайткан. Гөлнара әнисенә тын алырга да бирмичә:

— Әни, дим, әни!.. Син олаккан идең бит, ничек кайттың? — дип каршы алды.

## «Мин бүген яңа күлмәк кимәгән бит!»

Кызым кечкенә булса да, «тәти булырга» ярата. Без үзебез өйрәтмибез дә кебек инде өйрәтүен, әмма өстенә берәр матур нәрсә киде исә, шунда ук көзге янына йөгереп килеп җитә дә боргалана-сыргалана карый башлый.

Кичә яңа күлмәк алган идек, шуны киеп, көзге алдында шактый озак бөтерелде. Әнисе: «Болай кылансаң, яңа күлмәк алмыйбыз»,— дип, көзге яныннан берничә кабат куып та җибәрде. Күрәсең, кичәге «сабак» онытылган, — кызыбыз бүген янә көзге алдында. Бу юлы чәченә таккан тасманы рәтли: бер сүтә, бер җыя, бер тегеләй, бер болай боргалана.

Әнисе:

— Кемгә охшап кылтым була икән бу бала? — диде дә Гүзәлне яңадан шелтәли башлады: — Тагы көзге алдында бөтереләсеңмени әле син?

Гүзәл тыныч кына:

— Күрмисеңмени — мин бүген яңа күлмәк кимәдем бит! — диде дә, бернәрсә дә булмаган кебек, тасмасын рәтләвен дәвам иттерде.

## «Андый вакытта сәгать ничә була?»

Кичә балаларга сәгатькә карап вакытны белергә өйрәттем. Кыска, озын телләре белән таныштык. Уенчык сәгать алдык та аның телләрен төрле саннар өстенә куеп, сәгатьнең күпме күрсәтүен сораштым. Дөрес җавап бирделәр. Бүген кичен кухняда ашап утыра идем, кече кызым Гөлнара йөгереп килде. Ниндидер куркыныч хәл күргән кебек, ашыгып сөйли, үзе мине залга өстери:

— Әти, әйдә тизрәк, сәгатьнең бер теле икенчесе өстендә! Андый вакытта сәгать ничә була?

# ТАУЛЫ АЛТАЙ ПОЭЗИЯСЕ БИТЛӘРЕННӘН

## Борис Укачин

### Аргамак

Аргамак!
Син зыңлап тартылган кыл сымак!
Бу Биек Алтайда, бу туган ягымда
Дастан я җыр диеп, хыялга тиң диеп,
Дан йөри акыллы чапкын ат хакында!

Аргамак!
Йөгәнең ялтырый таң сымак.
Җиңүгә илттең син, коткардың мең тапкыр.
Халкымның сүзе бар: ир-егет җанында
Йөгәнле-иярле, канатлы ат ятыр...

Электән-электән шөһрәтле җырчылар
Багышлап җыр әйтсә аргамак турында,
Иң назлы моңнарга төргәннәр сүзләрен —
Булгандыр андый моң тик сөю җырында!

Кузгалса кинәттән олы юл тузаны
Һәм җайдак күренсә томаннар артыннан,
Нихәлләр икән дип, ни хәбәр икән дип,
Тау халкы йөрәге бер булып талпынган.

Саф шәраб әзерләү кирәкме туйларга?
Бер дусмы табылган? Дошманмы якында?
Бәхет тә, кайгы да, өмет тә, сагыш та
Килгән гел язмышның аргамак атында.

Аргамак!
«Аврора» аткан ут хакында
Хәбәрне син алып кайттың бит тауларга!
Хәсрәттән, күз яшьтән арыну өмете
Кузгатты, күтәрде халкымны яуларга.

Тик туган ягымда мылтыкның һәм атның
Кирәге бетмәде — егылды батырлар,
Егылды җыр белән — киләчәк турында! —
Бәхетем хакына, хөррият хакына...

Аргамак!
Аһ, кырык беренче... Әтием!..
Сугышка бергәләп киттегез сез тагын,
Онытмам әнинең йөгәнгә ябышып,
Сиңа һәм әтигә: «Хуш...» — диеп калганын.

Яшь түгел инде мин... Каракүл тавында
Атымны бәйләдем, уйланып тын калдым.
Бу бәйне — ат бәен — әтием куйган бит!
Әрнүем, сагышым берьюлы кузгалды.

Очкычлар өн сала галәмнең түреннән,
Җирдәге һәр юлда машина гөр килә.
Тик минем ритмым һаман син, аргамак,
Дагалар авазын алмашмам бернигә.

Бу җитди һәм катгый техник чор-дәвердә
Очышка, биеккә юнәлгән бары да —
Әмма да туктамас тупырдап чабуың;
Дастаным, җырым син, хыялым, аргамак!

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәсе.

## Эркемен Палкин

### Туган як

Яратам мин зәңгәр тауларыңны,
Үләннәрдән откан җырыңны.
Йөрәгемдә йөртәм, и Алтаем,
Синнән алган изге җылыны.
Кул болгыйлар кара эрбетләрең,
Әйтәләрдер миңа: «Онытма!»
Ә биектә әнә зәңгәр күкнең
Кунаклары — зәңгәр болытлар.
Һәммә җирдә — кыя табуннары,
Көтүчеләр монда куганмы?
Биредәге зәңгәр тау күлләре
Якты күккә генә тугандыр.
Ап-ак яллы елгаларың дулый.
Керфеккә дә, ап-ак чәчкә дә
Ак тамчылар чәчри дулкыннардан...
Бартырганнар ап-ак чәчкәдә!
Шундый рәхәт җаныма: ак чәчкәләр
Яктырталар барыр юлымны.
Туган ягым! Бүләк итәрмен мин
Кешеләргә синең җылыңны.

РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Лазарь Кокышев

# Чабан кызы

— Ничек шулай
Гүзәл булып тудың, кызый?
Җилдәй саф син, гөлдәй назлы.
Әллә соң син су кызымы,
Урмандагы кайтавазмы?

— Юк, мин бары чабан кызы,
Исемем — Чәчәк,
Нәселемнең исеме — кыпчак.
Мин —
Алтайда туып-үскән чабан кызы.

— Син, мөгаен, зәңгәр күктән
Төшкәнсеңдер,
Су кызыдай, саф елгада
Үскәнсеңдер.
Җиңел җилләр шәүләсеме
Синең чәчең?
Син йолдызлар телендәме
Сөйләшәсең?

— Мин — гади кыз, чабан кызы,
Үстем Алтай тауларында, үрләрендә;
Минем белән Ай үзе дә су коенды
Иркен, тирән күлләремдә.

— Йолдыз булып балкырсың син
Кем күгендә?
Бәхет булып ташырсың син
Кем күңелендә?

— Мин — әнинең бердәнбере,
Һичкем өчен йолдыз түгел.
Ташлыйсым юк туган йортны,
Беркая да тартмый күңел.
Исемемме? Бел, исемем —
Чәчәк минем...
Нәселемнең исеме булыр
Кыпчак минем.

ЗИННУР НАСЫЙБУЛЛИН тәрҗемәсе.

## Аржан Адаров

### Бөек күчеш

Без мең еллар буе күченеп килдек,
Күрдек кыйтгаларны, илләрне...
Еракларны иңләү гадәтеме
Әллә — кысып карау күзләрне?

Юлда туганбыз без. Булган хәтта
Бишегебез — дөя сыртында...
Озын, моңлы булып сызылып чыккан
Йөрәктән җыр — язмыш турында.

Җырлар хәтерләгән — диңгез булган,
Мәңгелек җәй булган якларны...
Шунда, имеш, Ватан....
Без шул илдән — яше, картлары.

...Без күчендек озак. Кыйтгаларның
Барысы да, ахры, кичелгән.
Качтык гүя кара гасырлардан,
Куркынычтан, шомнан, сихердән.

Язмышыбыз кебек иде дала...
Артта калды инде ул юллар.
Алар — Тарих! Сукбай түгел хәзер
Үз Ватанын тапкан буыннар.

Горур халык балалары булып
Күтәрелдек яуга, хезмәткә.
...Күзләр тулы бәхет инде хәзер,
Ирек җыры инде йөрәктә!

## Сазон Суразаков

### Алтын күл

Яшеллеккә чумган таулар иле,
Күлләрең дә алтын, әй, Алтай! —
...Башка тауларга баш түгелме ул
Әткәм кебек горур Алтын Тау?!

Күк кыялар, яшькелт тау битләре...
Һәрбер җирең, тавым, җыр-бәхет.
Һәм әнкәмдәй Алтын Күл дулкыны
Йөзәр өчен шундый җәй, рәхәт.

Ак бүрекле Алтын Тавым һаман
Челем тарта төсле тын гына.
Ә Алтын Күл һаман сорый миннән:
— Син кайларда булдың, улгынам?

Күренмәдең озак, көтсәм дә мин
Иртәсен дә, көндез, кичен дә...
Ник кайтмадың?
— Булдым, әнкәй, һәр чак
Мәшәкатьле дөнья эчендә.

Кызгылт ярлар, яшел тау битләре...
Тиңсез бәхет җире алдымда.
...Мин гел синең белән, Алтын Күлем,
Мин гел сиңа багам, Алтын Тау!

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН тәрҗемәләре.

## Александр Ередеев

### Кояшлы җыр

Болыннарда көтү һәм томаннар,
Инешләрнең җыры тукталмый.
Таулар булып таулар сихерләнгән,
Түзәрсеңме җырга сокланмый?

Комач кебек янып, ялкынланып,
Кайный җилдә чәчәк дулкыны.
Салкын чыклар юган күлмәгеңне
Кояшка куй, кибәр... Нур — җылы.

Кинәт — яшен! — агач тамырыдай...
Җирдә ярсу яңгыр тавышы.
Әй, җилферди биек тау башында
Синең яулык... якты нәкыше...

Синең җырың — болын өсләрендә.
Ә җыр белән яшәү күңелле.
...Авыр юлда гади җыр ярдәме —
Туган якның сүзе түгелме!..

Таулар. Тауда — көтү кебек томан.
Йоклый тынлык агач башында.
Һәм оча җыр иртә таңда туып,
Кочак җәеп, көннәр каршына!

ФӘННУР САФИН тәрҗемәсе.

## Паслей Самык

### Безнең күке

Аптырадык, аңламыйбыз,
Кем аңласын мондый эшне?!
Май уртасы, ә кырларга
Тездән булып ак кар төште.

Алдандылар агачлар да —
Бөреләре куркып калды.
Кырда сарык төркем-төркем,
Бәрәннәрне кулга алдык.

Инде үлән кар астында,
Җылы майны кар каплады.
Күктә хәзер бәйрәм итә
Бөдрә болыт куаклары.

Җирдә шәрә карагайлар
Борчылалар безнең сыман...
Шунда күке тавышы килде
Карагайлар арасыннан.

...Ишетелә күке тавышы,
Алдамый ул безне күке:
Тиздән карлы болытлардан
Йолып алыр кояш күкне!

РӨСТӘМ МИНГАЛИМОВ тәрҗемәсе.

# ОЧЕРКЛАР

## КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**АВГУСТ, 1975**

Шауляй заводының Е. Винграс һәм Г. Мансуров җитәкчелегендәге бригадалары Кама автомобиль гиганты өчен аеруча төгәл эшли торган автомат-кыру станоклары җыя башладылар.

КамАЗның махсус заказы буенча шауляйлылар җыячак 36 станокның һәркайсы билгеле бер әһәмияткә ия булган детальләр җитештерәчәк. Шауляй заводында эшләнгән шундый типтагы станоклар Загреб һәм Лейпциг шәһәрләрендә уздырыла торган халыкара күргәзмәләргә куела.

**«Известия», Мәскәү.**

«Яр-Чаллы» — Мәскәүдә «Известия» нәшрияты бастырып чыгарган китап әнә шулай дип атала. Аңа кереш сүзне Георгий Марков язган. Анда мондый юллар бар:

— Бишьеллыклар тарихы — Ленин партиясе җитәкчелегендә социализм төзегән һәм бүгенге көндә уңышлы рәвештә коммунизмның материаль-техник базасын тудыручы совет халкының бөек эшләре тарихы ул, дип билгеләп үтелгән иде КПССның XXIV съездында. Бу тарихи елъязмага тугызынчы бишьеллык үзеннән тагын бер гүзәл сәхифә өсти. Узган барлык бишьеллыклар белән чагыштырганда ул киләчәккә билгеләнгән бурычларның зурлыгы белән аерылып тора. Аларны үтәү өчен көрәштә актив катнашу — совет язучыларының мөһим бурычы, һәркайсыбызның гражданлык һәм партиялелек бурычы. Язучының җәмәгать активлыгына, аның социалистик чынбарлыгыбызның актуаль проблемаларына игътибарлы булуына искиткеч зур әһәмият бирелә. СССР Язучылар союзы идарәсенең 1973 елның мартында уздырылган пленумында, шулай ук очерклар һәм публицистика советының 1974 елның июлендә совет җәмәгатьчелеге вәкилләре катнашы белән уздырылган пленумында публицистларның эшләренә кайбер нәтиҗәләр ясалды, киләчәктә алар алдында торган бурычлар турында сөйләнде.

Шунысы куандыра: коммунистик әхлак, тормышның яңа этик нормалары, кешеләрдә эшләренә мәхәббәт тәрбияләү өчен көрәш публицистика жанрында эшләүче язучыларның игътибарын үзенә көннән-көн ныграк тарта. Бу жанр тормыштагы өлгер, ашыгыч вакыйгаларны кичекмәстән терки бара. Теркәп кенә дә калмый, тормыш эченә актив үтеп керә, аның үсешенә йогынты ясарга омтыла. Публицистика бүген дә, В. И. Ленин билгеләвенчә, массаларны тормышның барлык өлкәләреннән алынган конкрет мисалларда һәм үрнәкләрдә тәрбияләүне үзенең төп бурычы итеп саный.

Безнең героик чорыбызның елъязмасын иҗат итүдә «Новый мир» журналының редакция һәм авторлар коллективы шактый эш башкара. Журналның күп кенә битләре илебездә социалистик төзелешнең беренче еллары документлары итеп кабул ителә. Күренекле язучылар һәм публицистлар коммунистлар партиясе эшчәнлегенең елъязмачылары булдылар. «Новый мир» журналында «Совет

җире», «Кешеләр һәм фактлар» дигән рубрикалар белән Днепрогэс, Магнитогорск, Фергана каналы һәм бишьеллыкларның башка күп кенә төзелешләре турында очерклар басылды.

1971 елның сентябрендә «Новый мир»да яңа рубрика — «Яр-Чаллы» рубрикасы барлыкка килде. Журнал үз коллективы һәм авторлар көче белән тугызынчы бишьеллыкның зур төзелешләреннән берсе булган Кама автомобиль заводлары комплексы елъязмасын иҗат итә башлады. Бу елъязманы иҗат итүгә язучылар һәм журналистлар гына түгел, КамАЗның танылган төзүчеләре, төзелеш җитәкчеләре, партия работниклары да тартылды.

Укучыларга тәкъдим ителә торган «Яр-Чаллы» китабы КамАЗ елъязмасының беренче өлеше булып тора.

«Яр-Чаллы». «Известия» нәшрияты, Мәскәү.

Партиянең Чаллы шәһәр комитеты карары белән өченче квартал КамАЗда технологик җиһазларны монтажлау өчен мәйданнар әзерләүне тизләтү һәм төгәлләү буенча удар өч айлык дип игълан ителде.

Шушы карарны үтәп, В. Минкин, В. Колесник һәм Г. Федосеев җитәкчелегендәге монтажчылар бригадалары Бөтенсоюз удар төзелешнең барлык төзүчеләренә ачык хат белән мөрәҗәгать иттеләр.

— Безнең бригадалар, — диелә бу мөрәҗәгатьтә, — җиһазларны монтажлауның беренче көннәреннән үк югары хезмәт темпы алдылар. Шуңа да карамастан, без хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен резервлар әле тулысынча файдаланылып бетмәгән дип исәплибез һәм җиһазларны монтажлау срокларын, барысын бергә кушып, 134 көнгә кыскартырга дигән күтәренке йөкләмә алабыз.

Монтажчылар КамАЗның барлык төзүчеләрен производство мәйданнарын срогыннан элек файдалануга тапшыру өчен эшкә актив кушылырга чакырдылар.

«Советская Татария», Казан.

А. С. Пушкин исемендәге театр сәхнәсендә бер ай буена Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театры спектакльләре барды. Театр репертуарында татар һәм башка тугандаш халыклар драматургларының әсәрләре бар иде. Совет драматургларыннан И. Дворецкий пьесасы буенча эшләнгән спектакльдә Чешков ролен Р. Таҗетдинов башкарды. Бу рольнең уңышлы башкарылуын артистның әйбәт уйнавына гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде. Спектакльнең тулаем уңышын Ринат Таҗетдинов һәм әсәрне сәхнәгә куючы, театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗановның тыгыз иҗади бәйләнештә булуы хәл иткән.

Әлеге әсәрне сәхнә теленә күчергәндә Г. Камал исемендәге театрның үзенчәлеге нәрсәдә соң? Режиссерның игътибар үзәгендә — сюжет төзелеше түгел, барыннан да элек, Чешков һәм ул алып барган идея бәхәсе тора. Калган бөтенесе: заводта уздырылган бәйрәм кичәсе, Манагуров һәм Щеголева арасындагы мөнәсәбәтләр һәм башка шундый бик күп нәрсәләр — боларның барысы да арткы планга күчерелә. Бу исә конфликтларны соң чиккәчә кискенләштерүгә, спектакльнең төп мотивын көчәйтүгә ярдәм итә.

... «Чит кеше» спектаклен беренче булып КамАЗ төзүчеләре карады (алар премьерага Бөтенсоюз театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге тарафыннан чакырылганнар иде).

— Спектакль безгә бик ошады, — диде әсәр буенча фикер алышуда чыгып сөйләгән комсомол-яшьләр бригадасы бригадиры Николай Шемягин. — Ул дулкынландыра һәм бик күп нәрсә турында уйланырга мәҗбүр итә. Чешков — искиткеч шәп! Шундый кешеләр күбрәк булсын иде.

«Литературная Россия», Мәскәү.

Косиор исемендәге станоклар төзү заводы коллективы КамАЗ өчен кирәкле җиһазлар җитештерүнең еллык планын срогыннан элек үтәде. Чаллыга зур йөк күтәрешле машиналарның двигательләре детальләрен эшкәртүне тизләтүче 22 шомарткыч автомат җибәрелде.

**ТАСС, Харьков.**

Чаллыда студентлар төзелеш отрядларының фашистик Германияне җиңүнең 30 еллыгына һәм КамАЗда Мәскәү студентларының төзелеш отряды эшли башлауга биш ел тулуга багышланган слеты уздырылды. Анда республикабызның шушы төбәгендә төзелештә эшләүче студентлар һәм химиклар шәһәре Нижнекамск төзелеш отрядлары вәкилләре почетлы кунак итеп чакырылган иде.

Һәр ике шәһәрнең төзүчеләре кебек үк, Чаллы һәм Нижнекамскидагы студентлар төзелеш отрядлары да үзара ярышалар. Бу ярышта Мәскәү, Ленинград, Татарстан, Свердловск, Куйбышев югары уку йортлары студентлары катнаша.

Производство планының үтәлеше буенча эш чорының беренче яртысына ясаган йомгаклардан күренгәнчә, студентларның Чаллыдагы төзелеш отряды алда бара. Ул капитал салуны дүрт миллион сум күләмендә үзләштергән.

**«Комсомолец Татарии», Казан.**

Камадагы автогигантның баш конвейерыннан зур йөк күтәрешле беренче автомобильләр төшәр көн якынлаша. Ә хәзергә әле заводның һәр корпусында технологик җиһазларны монтажлау бара. Автомобиль җыю заводында баш конвейерны җыюда эшләүче 7 нче номерлы бөтенсоюз тресты монтажчылары аеруча зур тырышлык күрсәтәләр. КПССның XXV съезды хөрмәтенә киң колач алган социалистик ярышны В. Осипенко бригадасы җитәкли. Нәкъ менә шуның өчен дә җыю эшләрен башкарачак баш конвейерны монтажлау шушы коллективка ышанып тапшырылган.

**«Социалистическая индустрия», Мәскәү.**

... Күпчелек камазлыларда чаңгы буенча ГТО комплексы нормаларын тапшырганда бирелгән грамоталар әле хәзер дә саклана. Шулай булмыйча мөмкинме соң?! Ул грамоталарда бит Л. Турищева, В. Борзов, А. Мальцев, В. Харламов кебек олимпиячеләрнең автографлары ярылып ята. Җирле хоккей ветераннары җыелма олимпия командасының КамАЗ командасы белән иптәшләрчә очрашуын әле дә булса хәтерлиләр.

Ул истәлекле очрашудан соң инде күп нәрсә үзгәрде. Шәһәр бик нык үсте, андагы заводлар эшкә башлау алдында тора. Камазлылар партиянең XXV съезды ачылуга беренче автомобильләрне чыгару өчен бөтен көчләрен бирәләр. Әйе, эш күп, эш тыгыз. Ләкин шефка алынган мәктәпләрнең спорт мәйданчыкларында, эшчеләрнең тулай тораклары янында кичләрен волейбол, баскетбол буенча ярышлар кыза, ГТО нормаларын тапшыру бара.

Автомобиль төзүчеләрнең спорт коллективы әнә шулай үсә. Бу үсешкә администрация, партия һәм завод комитетлары даими булышлык күрсәткән физкультура коллективы советының эшчәнлеге аркасында гына түгел, спорт сөючеләрнең үзләренең тырышлык куюлары нәтиҗәсендә дә ирешелә.

Яшь тренер Петр Любимовның коллективка килүенә әле бер ел да юк. Ә аның җитәкчелегендә инде 150 боксер шөгыльләнә. Алар арасыннан Валерий Чураев Татарстан чемпионы исеменә лаек булды, ә өч боксер приз яулап алды.

КамАЗ туристлары клубы республикабыздан читтә дә билгеле. Узган кышта гына да ул Көньяк Уралга, Кольский ярымутравына һәм Татарстан районнарына унике поход оештырды. Туристларның КамАЗда уздырыла торган слетлары һыклы хәзерлек һәм яхшы оештырылулары белән аерылып тора. Шәһәр урамнары буйлап эстафеталар, җиңел атлетика ярышлары, турнирлар уздыру матур гадәткә керде.

Хәзер КамАЗ спортчылары алдында яңа бурычлар тора. Ул бурычларның иң зурысы — КамАЗда спортны массовый итү. Ә моның өчен биредә бөтен мөмкинлекләр бар.

**«Труд», Мәскәү.**

## Дамир Гарифуллин

# ИГЕНЧЕ УЛЫ



Тәрәзәләрдә соңгы нурларын уйнатып, кызарып кына кояш бата. Кичке тынлыкка шом салган кара болытлар кызган тимер белән читләтелгән төсле. Әйтерсең җир үзе дә, алдан ук сизенеп, ниндидер дәһшәт көтә. Авыл өйләре, ничектер, сагаеп калган сыман...

— Көчле яңгыр булыр, ахрысы. Шулай да чалгыны кичтән чүкеп куярга кирәк,— дип, Нурмөхәммәт абзый, бүкәнгә кагылган сандалны алып, баскыч төбенә чыгып утырды. Менә шул чакта ил өстенә таралган кара хәбәр аңа да килеп иреште. Ул чалгы йөзен тагын бераз чүкеде дә урыныннан кузгалды. Җилдән, эсседән ярылган иреннәрен чак-чак кыймылдатып, «Сугыш...» дип кабатлады. Башка сүз әйтергә теле әйләнмәде аның. Чалгысын җиде яшьлек улы Фәүҗәткә биреп, аны иңнәреннән сөеп алды. Аннары кеше күтәрә алмаслык ком капчыклары кебек авырайган аякларын өстерәп өйгә керде.

Хатыны Маһирә җиңги мич тирәсендә кайнаша иде.

Өй эчен аңкыткан яңа пешкән икмәк исе Нурмөхәммәт абзыйның күңелен әллә нишләтеп җибәрде. Ул сәкедәге ашъяулыкка сындырып куелган икмәк кисәген алып авызына капты да, бераз тын торгач, сүз башлады:

— Карчык, герман сугыш башлаган...

Калганы сүзсез дә аңлашыла иде. Өй эченә авыр тынлык урнашты. Шунда бишектәге ай ярымлык Илгизәр генә мышкылдап елап җибәрде.

— Елама, улым, елама,— дип, Маһирә җиңги аңа бу минутта кинәт кенә сөте качкан күкрәгеннән якын китерде...

Берничә көннән Нурмөхәммәт абзый сугышка чыгып китте. Гаиләсе белән хушлашканда ул шүрлектәге иң изге төенчекне алды. Аны саклык белән генә чишеп, күпереп пешкән арыш икмәген күкрәгенә терәп кисте. Аны башта үзе зур гына итеп капты һәм калган телемне бишектә яткан улы Илгизәр кырына куйды.

— Игенчеләр нәселен корыта алмаслар,— диде ул һәм, күз яшьләрен өйдәгеләргә күрсәтмәс өчен, ишеккә таба атлады.

Ата — терәк, ана — йөрәк, диләр халыкта. Ата кеше гаилә өчен генә түгел, авыр минутта бөтен ил өчен терәк була. Маһирә җиңги берсеннән-берсе вак балалары белән япа-ялгызы торып калды. Үзе



Илгизәр Әгъләмов.

теләк, үзе йөрәк булды. Мондый чакта дуслар кирәк. Бөтен авырлыкны авыл белән бергә күтәрделәр, сугыш елларын бергә кичтеләр.

Балаларының үсеп, кеше булып җитүләрен Нурмөхәммәт абзыйга күрергә насыйп булмады.

...Сугышта хәбәрсез югалган әтисенең: «Игенчеләр нәселен корыта алмаслар»,— дигән сүзләрен әнисеннән еш ишетеп торгангамы, комбайн белән кырга чыккан саен: «Игенчеләр нәселе яшәвен дәвам итә!» — дип, күңеленнән кабатларга ярата Илгизәр. Уллары Ленар белән Илдарны тезләренә утыртып сөйгәндә дә шул ук сүзләрне кабатлый. Бу сүзләр аның хисләренә канат бирә, күңелен дәртләндереп җибәрә, игенче дигән сүзнең чын мәгънәсен тирәнрәк аңларга ярдәм итә. Кыр корабы белән басуларның иң үрге җиренә, авыл каршындагы таулар башына күтәрелгәч, мондый тойгылар аеруча көчәеп китә.

Таулар...

Күз күремен ерагайта алар, офыклар пәрдәсен күтәреп, җәйрәп яткан басуларны, шаулы урманнарны, зәңгәр тасма булып сызылган инешләрне уч төбендәгедәй күз алдына китереп бастыра.

Петровка авылы тауларыннан да ерак-ерак киңлекләр ачыла. Аяз көннәрне моннан республикабыз энергетикасы флагманы, мәһабәт Зәй ГРЭСының торбаларын күрәсең, әнә тегендәрәк, Ләке таулары артында, данлы КамАЗ... Сарман — Зәй юлы өстендәге күксел урманнар аръягында Түбән Кама шәһәре, ә бирерәк хәтта чит илләрдән килгән самолетларны да кабул итә торган Бигеш аэропорты...

Тауларга күтәрелгәч, күңел күзе офыклар артындагы әнә шул бөек төзелешләрне барлап чыга. Аннан соң инде карашын иңләгән кырлар да, урманнар да ничектер тагын да якынрак, тагын да газизрәк булып тоела.

Илгизәр, комбайнын Петровка авылы тау башына туктатып, тирә-якка күз салды. Табигатьнең матур бер почмагына урнашкан бу авыл башка авыллардан алай әллә ни аерылып та тормый. Елгасы да, Тукай әйтмешли, кечкенә инеш кенә...

Патша заманында бу авылда 12 нче вино заводы салынган. Шуңа авылга да «12» саны тагылып калган: Петровка-12. Сәүдәгәр Стахеевның вино заводы булган анда. Аннан ике-өч чакрым ераклыктагы авылда әлеге «комсыз Әстәхи»нең фермасы булган. Якындагы Юлтимер авылыннан шул фермага кешеләр күчеп утырган һәм монда хутор барлыкка килгән. Хәзер исә аны Ферма Сәвекле авылы дип йөртәләр. Ул — Илгизәрнең туган авылы. Шунда үсте, шунда тормыш юлын башлап җибәрде Илгизәр.

1955 елда җиде классны тәмамлагач, колхозда ат җигеп эшләргә калды. Исәпләп карасаң, ул чаклардан бирле инде күпме гомер үткән...

Илгизәр, комбайныннан төшеп, арыш басуы эченә атлады. Алып батыр кебек зур гәүдәле, киң җилкәле, җирнең үзеннән үсеп чыккан

шикелле таза бу игенче көрәктәй зур учларында кантамыр хәлендәге бөртекләрне уып, уйга калды. Аның күз алдыннан ерак еллар пәрдәсе артында калган көннәр йөгереп үтте.

Күңел ялан тәпиле бала чак эзләрен үзендә саклаган сукмаклар буйлап әллә кайлардан урап кайта да уйлар йомгагының очын учтагы шушы бөртекләргә китереп бәйли.

Әйе, шул бөртекләрдән башка аның тормышының мәгънәсе кечерәя. Хәтердә калган һәр истәлек менә шушы үзәннәр, шушы таулар белән бәйле. Ундүрт яшеннән зурлар белән иңгә-иң торып шушы басуларга эшкә чыкты ул. Ышанып, башта аңа ат тапшырдылар, чытыр арба бирделәр. Урак өстендә комбайннан ашлык, кыш көннәрендә бастырыклап салам ташыды.

Ә техникага утыруының сәбәпчесе хатыны Фәһимә булды. Әле ул чакта алар икесе дә буйга җитеп кенә киләләр иде. Кичке уенда кызлар белән егетләр арасында кара-каршы әйтелә торган такмакларның берсен:

«...Трактор да йөртә белми,
Кызлар сайлаган була»,—

дип төгәлләде Фәһимә.

Илгизәргә төбәп әйтелмәсә дә, бу сүзләр егетнең йөрәгенә барып кадалдылар. Ә кем белә, бәлки Фәһимә үзенең уен шулай читләтеп белдерә торгандыр?

— Тракторга өйрәнәм! — сүз бирде Илгизәр үз-үзенә.

Шул көннән ул буш вакытларында Языково авылы тракторчысы Алексей Семин тирәсендә кайнаша башлады. Майга батып булышып йөргән чакларында аның күңелендә корыч айгырны йөгәнләү хисе үскәннән-үсә барды:

— Их, бер генә тапкыр булса да үзең кабызып, үзең йөртеп карасаң иде шуны!

Илгизәрнең техникага өйрәнүен әнисе дә, апалары белән абыйсы да хуп күрделәр.

— Әтиең, дустың рус булса, юлың дөрес була, ди торган иде. Алексей абыеңның сүзен тыңла, киңәшләренә колак сал,— дип куанды Маһирә җиңги, улының майланып беткән кулларына чүмечләп су салып торганда.

Ә бервакыт һич көтмәгәндә шундый бер уңайлы очрак килеп чыкты. Тракторчы Миңнәхмәт абзый «КДП»сын юлда сүндереп, авылга җәяүләп кенә кайтты. Дусларын очратып бераз «сыйланган» да, хәвеф-хәтәрдән шүрләп, шулай эшләргә булган икән.

Вакыт инде бик соң булуга да карамастан, Илгизәр кирза итекләрен киде дә сибәләп торган яңгыр астында юлга чыгып китте.

Тракторны кабызып җибәргәндә йөрәге очар кош кебек җилкенде. Ә руль артына утырып кайтканда аның башында бер генә уй булды: «Фәһимәләрнең капка төбеннән үк узарга... тәрәзә турыларыннан ук!»

Трактор тавышы озаккарак сузылгач, Фәһимәләрнең өй эчендә ут кабынды. Ул арада тәрәзә пәрдәсе тартылып, кыз үзе дә күренде. Ул, кулы белән изәп, Илгизәргә читкәрәк китәргә ымлый иде.

Илгизәр тизлекне алыштырды һәм тракторны тагын да көчлерәк гөрләтеп китеп барды. Шунда ул капкадан чыгып килүче Миңнәхмәт абзыйны күреп алды һәм эсселе-суыклы булып китте.

Миңнәхмәт, тамак кырып, бармак янап калды. Үзе эчтән генә: — Их, яшь чак, юләр чак,— дип, трактор ферма ягына китеп югалганчы карап торды.

...Чаллы механизаторлар мәктәбен тәмамлап кайткач, Илгизәр «СК-4» комбайнына утырды. Алты ел буена «Мир» колхозының ал-

дынгы комбайнчысы булып исәпләнде. Тимофей Аксаков белән ярыша-ярыша көч сынаштылар. Бөртекне югалтуларга каршы комбайнга әллә нинди җайланмалар уйлап таптылар. Комбайнны бөтен нечкәлекләренә кадәр бергәләп өйрәнделәр. Ә бер елны, үзләренә өйрәнчекләр алып, хәтта икешәр комбайнда эшләделәр. Ул елны аларны ВЛКСМ өлкә комитетының «Чәчү батыры» мандаты белән бүләкләделәр.

1968 елда Илгизәр Петровка совхозының үзәк усадьбасына килеп утракланды. Группалап эшләү дәвамында көчәйгән үзара ярдәмләшү хисе механизаторлар арасында хезмәт дисциплинасын ныгытуга ярдәм итте. Елның-елында ныгый барган бу тәртип совхозга зур уңышлар китерде.

1974 елда район буенча һәр гектардан 15,9 центнер уңыш җыеп алынган булса, Петровка совхозында бу күрсәткеч 27 центнердан артып китте. Былтыргы корылык елында да совхоз эшчәннәре һәр гектарда 14,5 центнер бөртек үстерделәр. Быел исә кырлар куанדырлык уңыш вәгъдә итәләр.

Ләкин механизаторлар хәзер сүзне мул уңыш үстерү турында гына түгел, һәр карыш җирдән рациональ файдалану турында да алып баралар. Бер-берсендә туфракны күз карасы кебек саклау буенча җаваплылык хисе тәрбиялиләр, җитәкчеләрне бу мәсьәләдә төрле чаралар күрергә мәҗбүр итәләр.

Әле күптән түгел генә, яңгыр явып үткәч, механизаторлар өйләгә иртәрәк туктаганнар иде. Тик көн файдасызга узмады. Совхоз директоры белән партия оешмасы секретаре да терлек азыгы әзерләүчеләр янына килделәр. Бераздан совхозның баш агрономы Марс Шакирҗанов та килеп җитте. Зур, бик зур сөйләшү булып узды басуда. Каядыр, бүлмәдә булса, ул кадәр фикерләр әйтелмәгән дә булыр иде, ә биредә һәркем үзенең күңелендәгесен ачып салды.

Илгизәр анда сөйләнгән сүзләрне тагын бер тапкыр күңеленнән кичерде. Менә ул печәне чабып алынган басу буйлап кайтып килә. Баш агроном белән бәхәскә кергәненә дә үкенми, чөнки ул бәхәстә игенчене игенче иткән, ләкин төгәл генә исемен әйтеп булмый торган нәрсәдер бар иде. Аның белән ярышып эшләүче Владимир Стоянов та бик төпле фикерләр әйтте. Сыйфат бабай сүзләрендә дә хаклык күп. Сүзен ул ниндидер мәзәкләрдән генә башлап җибәрде дә кинәт кенә совхоз хуҗаларына мөрәҗәгать итте:

— Шулай да җирнең кадерен белеп бетермибез бит, оланнар. Барыбызны да чыбыркыларга кирәк безнең.— Аннан ул иелеп кулына туфрак алды һәм сүзен дәвам итте: — Менә бу туфрак безгә бабаларыбыздан калган, аны алтын-көмеш тауларына да алыштырырга мөмкин түгел. Аның менә бусы — гөл балчыгына ярардае — иң кыйммәтлесе. Җиребезне гөлбакча итәсебез килә икән, менә шул гөл балчыгын күз карасы кебек сакларга тиешбез. Ә саклыйбызмы соң без аны? Юк, балалар, бу мәсьәләгә игътибарыбыз җитми. Инде элегрәк техникасы, тегесе-бусы юк дип тынычландык. Ә хәзер бит... Шушы уңдырышлы туфракны юл полотносына да салдылар, чокырлар астында да калдырдылар. Әнә хәзер олы юл кырыйларына күз салыгыз әле, утыз-кырык сажин киңлектә кашык буе бодай, арпа яки арыш үсә. Ә бит безнең бу җирләрдә аның башагы гына да кашык буе булырга тиеш.

Моннан ике йөз еллар элек ата-бабаларыбызның бакыр чыгарган базлары әле бүген дә файдасыз чокырлар, иңкүлекләр булып ята. Аларны күп җирдә рудниклар дип атыйлар. Ярый әле, табигать үзе ике гасыр эчендә әлеге иңкүлекләрдә үлән үсәрлек шартлар тудыра алган. Ә менә хәзерге таш, ком карьерлары урыннары болай калса,

алар урынына өч гасырдан соң да үлән-мазар үсә алмаячак... Иске заман чире бу...

— Менә шул чирдән арыну безнең бурычыбыз да инде,— диде агроном Риф Шакирҗанов.— Син, бабай, табигать ике йөз ел эчендә ташландык җирләрне яңадан үлән үсәрлек итә алган дисең. Ә хәзер андый җирләрне комын-ташын алганнан соң ук файдалануга яраклы итеп калдырырга, икенче төрле әйткәндә, аның уңдырышлылыгын кайтарып була.

Нәкъ менә шушы урында Илгизәр үзе дә сүзгә кушылды:

— Бөтен бәла да шунда шул, без аларны күмәбез дә китәбез. Тагын шул баз авызыннан ике-өч тапкыр киңрәк җирне иген икмәслек итеп калдырабыз. Кем әйтмешли, гөл туфрагын шул базга тутырып күмү, кызыл балчыклы мәйдан ясау. Бу инде җирне терелтү түгел, аның йөзенә яра салу. Кайда канау казып торба салына, шунда җирнең йөзендә җөй кала. Ул җөй еллар узгач та бетми. Ә торбаларны салырга кирәк... Һаман болай эшләсәк, үз җиребезне үзебез таный алмаячакбыз. Үзебездән соңгы варисларга нинди мирас калдырырбыз? Хәер, соңгы вакытта нефтьчеләр җирнең кадерен азмыкүпме белә башладылар. Ә бит беренче чорда җибәрелгән хаталар никадәр... Нефть сеңдерелгән урыннар кабат сөрүлек җирләренә әйләндерелсәләр дә, анда бит иң яхшы сортлы бодаең да Степан дәдәйнең трубкасы буе гына булып үсә.

Ул костюм кесәсеннән блокнотын чыгарды да, аның битләрен актара-актара, сөйләвен дәвам итте.

— Миңа Леонид Ильич Брежневның партиянең XXV съезды трибунасыннан әйткән менә бу сүзләре бигрәк тә ошады. Менә ул нәрсә ди:

«Игенче һәм терлекченең хезмәте — асылда кеше ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен җанлы табигатьтән, безне әйләндереп алган табигый мохиттан файдалану ул.

Әмма табигатьтән төрлечә файдаланырга мөмкин. Үзеңнән соң уңдырышсыз, җансыз, кешегә дошман бушлык калдырырга да мөмкин, һәм кешелек дөньясы моның байтак мисалларын белә. Ләкин, иптәшләр, табигатьне яхшырту, яшәү көчен тулырак ачу өчен табигатькә ярдәм итәргә мөмкин һәм кирәк. «Чәчәк атучы край» дигән гади генә, барыбызга да билгеле булган әйтем бар. Кешеләрнең белеме, тәҗрибәсе, аларның табигатьне якын күрүе, яратуы чыннан да могҗизалар тудырган урыннарда җирне шулай атыйлар. Бу — безнең социалистик юл. Димәк, без авыл хуҗалыгын җанлы табигать байлыкларын саклауның, культуралаштыруның гаять зур, даими эшләп торган механизмы итеп карарга тиешбез. Һәм табигать безгә моның өчен йөзе белән кайтарыр».

— Менә шул, иптәшләр.— Эчендә булганны тышына чыгарып бетергән кешегә хас бер төс белән Илгизәр иркенләп сулап куйды.— Ә без менә җирнең кадерен белеп бетермибез. Плотиналар, буалар астында кала торган кара туфрак та бик кызганыч. Байлыкны суга ташлау белән бер. Юк дигәндә өске чирәм катламын булса да алып каласы иде.

— Карабаштан узганыгыз бармы сезнең?— дип сүзгә кушылды механизаторларның берсе.— Илгизәр дөрес әйтә. Әнә, диңгез кебек сусаклагыч хасил булган, ә Карабаш урамында ком, тузан, анда чирәмнең әсәре дә юк.

Аннары сүз уңыш турында барды. Совхоз директоры Мәхмүт ага Якупов алда торган бурычларны аңлатты.

— Авыл хуҗалыгын текә күтәрү бөтен халык эше,— дип, партиябез бик дөрес әйтә. Уңыш өчен көрәш илебезнең һәр почмагында

бара. Унынчы бишьеллыкта авыл хуҗалыгына 172 миллиард сум, ягъни үткән бишьеллыктагыдан 41 миллиард сумга күбрәк акча бирү билгеләнгән. 160 миллион тонна ашлама күбрәк алыначак. Җирнең уңдырышлылыгын күтәрү механизатор кулында. Авыл хуҗалыгындагы уңышларыбызга Илгизәр, Владимир, Сәетҗан, Шәрәфетдин кебекләрнең көндәлек, гадәти эшләре нәтиҗәсендә ирешелә.

Илгизәр директорның сүзләрен бирелеп тыңлады. Уңыш үстерү буенча булган җитешсезлекләрдә үзенең дә гаебе барлыгын тою анда яңа уйлар, яңа хыяллар кузгатты.

Учларда гади генә арыш бөртекләре. Ә күпме өмет-ышаныч тудыра алар. Партия оешмасы секретаре килеп чыкмаса, Илгизәр әле тагын бик күп нәрсәләрне исенә төшергән булыр иде. Азмыни тормышта булып узган вакыйгалар...

— Җирне, басуны яратасың да соң инде,— дип исәнләште парторг аның белән. Хәл-әхвәл сорашты, урып-җыю мәсьәләсе буенча КПСС райкомында үткәреләчәк киңәшмәгә барышы икәнлеген әйтте.

— Минемчә, җирне яратыр өчен иң элек аның белән якыннан таныш булырга кирәк,— дип җавап кайтарды аңа Илгизәр. Менә инде ничә ел күзәтәм: һәр басуның үз сере бар. Берсендә дым да шактый саклана, ә икенчесендә юк. Бер басу органик ашлама кертмәсәң үлеп бара, ә икенчесе әле түзә, байтак вакыт үз хәлендә кала.

«Ир-егетнең йөрәгендә иярләнгән ат ятар, дип менә шушындый кешеләргә әйтәләрдер инде»,— дип уйлады партия оешмасы секретаре үзенең иң яшь коммунисты, район советы депутаты Илгизәр Әгъләмов турында.— Менә ни өчен ул комбайнын куя да тракторга утыра. Ашлама чыгару өчен елның-елында бульдозер белән басуга юллар ача. Әйе, бу тырыш игенченең рәсеме район Мактау тактасына тикмәгә генә куелмаган...»

Шул уйлар белән ул Сарманга юл тотты, ә Илгизәр комбайнына таба атлады.

...Тәрәзәләрдә тәүге нурларын уйнатып, кызарып кына кояш чыга. Иртәнге тынлыкта каршыдагы урманда кошлар сайраганы ишетелә. Юл кырыйларында пар-пар булып күгәрченнәр гөрләшә. Үләннәрнең иртәнге чыгын коеп басу ягына узган комбайннарның киң эзләре ярылып ята. Әнә, зур рейска чыгарга хәзерләнгән кыр корабларын көтеп, иген диңгезе дулкынлана. Кырларда унынчы бишьеллыкның беренче елы ашлыгы өлгереп җиткән.

Сарман — Зәй — Чаллы юлы да шул диңгезгә кереп югала. Шул юлдан әле кайчан гына беренче төзүчеләрне зурлап-олылап, КамАЗга озатканнар иде. Бүген шул ук юлдан быелгы уңышны түкми-чәчми җыеп алырга чакырулы транспарантлар белән бизәлгән яңа машиналар колоннасы уза...

— Һөҗүм башланды! — диде Илгизәр һәм, комбайнын кабызып, зур уңыш өчен көрәш барган басуларга карап юл тотты.

## Сәгыйть Закиров

# ТУГАН ЯКТАН КӨЧ АЛЫП



Кояш нурлары яшьлек шәһәре — Түбән Камаһың киң яшел проспектларында уйный, нефтьхимия комбинатының күкләргә ашкан мәһабәт ак колонналарында чагыла, цехлардагы йөзләрчә аппаратларның салмак кына тигез ритмдагы эш авазлары җанга рәхәтлек бирә, күңелләрне иркәли.

Республикабызның Түбән Камадагы нефтьхимия комбинаты, Чаллыдагы Кама автомобиль комплексы корылмалары көнләп түгел, сәгатьләп үсә. Алар чын мәгънәсендә бөтен халык төзелеш мәйданнарына әверелде. Биредә киң илебезнең һәр өлкәсеннән, һәр республикасыннан алдынгы хезмәт вәкилләрен очратырга мөмкин. Татарлар, руслар, украиннар, казакълар, башкортлар һәм башка күп төрле милләт кешеләре чал тарихка алтын хәрефләр белән язылырлык гасырыбызга тиң олы эшләр башкаралар.

Ә тугандаш республикалар бөтен союз удар төзелешләрне төзү материаллары, җиһазлар, аның хезмәт батырларын көнкүреш кирәк-яраклары белән тәэмин итүгә булышалар, ул заказларны үтәүдә кулларыннан килгәннең барысын эшлиләр.

Шуларның берсе — Казагыстан ССР. Республиканың башкаласы Алма-Ата шәһәрендәге ул заказларның үтәлешен анализлау, әзер булганнарын кабул да итү мәсьәләләре бу очракта миңа тапшырылган иде.

...Юлга чыктым. Казан — Алма-Ата рейсындагы Ил-18 самолетының корыч канатлары астында чиксез киң казакъ далалары, республиканың эре промышленность гигантлары, яңа калалары чагылып узды. Аның иксез-чиксез иген кырлары өстеннән очабыз. Ә кайчан гына ул җирләр яткын хәлендә генә иде бит әле. Аларны үзләштерүдә ярдәмгә дип Казагыстанга Татарстаннан комсомол-яшьләр, хезмәт алдынгылары агылды. Республиканың металлургия, күмер промышленностен үстерүдә, аның халык хуҗалыгының башка тармакларында да алар бик күп эшләр башкаралар. Казагыстанның мех промышленносте үсешендә ул аеруча ачык чагылды. Биредә инде Татарстан — Казан мехчылары төп рольне уйнады дип әйтсәк, һич тә ялгышмабыз. Бүгенге көннәрдә дә белгечләр белән тәэмин итү, я булмаса алдынгы тәҗрибәне пропагандалауда, үзләштерүдә Казан

мехчыларының Казагыстанга, бигрәк тә Алма-Ата мехчыларына ярдәмнәре зур.

Казагыстан да үз чиратында җавапсыз калмый. Менә республикабызның удар төзелешләренә аның актив ярдәме дә шуның бер билгесе. Ә безнең халыкларыбыздагы бу ярдәмләшү, бу бергәлекнең искиткеч чагылышы узган тарихыбызга барып тоташкан. Бигрәк тә ул культура өлкәсендә ачык чагыла.

Әле казакъ халкының үз басма китаплары, типографияләре булмаган чорларда Казан шәһәре алар өчен дә китаплар бастырып чыгарды. Бөек Октябрь революциясеннән соң казакъ балаларын укыту, аларга белем, тәрбия бирү эшенә дә бик күп татар хатын-кызларыбыз, алдынгы укытучыларыбыз алынды. Бөек әдипләребез Тукай һәм Абайлар иҗаты һәр ике халыкның уртак рухи хәзинәсе булып хезмәт итә. Якташларыбыздан Сабир Шәрипов — Казагыстанда Совет власте урнаштыруда актив көрәшче — аның социалистик промышленностен үстерүдә күп эш башкару белән бергә, казакъ халкының талантлы язучысы да булып танылды. Мохтар Ауэзов, Сабит Моканов, Сакен Сәйфуллин, Габиден Мостафин, Олжас Сөләйманов, Әнвәр Галимҗанов һәм башка казакъ язучыларының әсәрләрен татар укучылары да яратып укыса, Г. Ибраһимов, Г. Бәширов, Х. Туфан, С. Хәким, Ф. Хөсни, З. Нури, Г. Ахунов, Н. Арсланов кебек әдипләребезнең иҗатларын Казагыстанда үз итәләр, якын күрәләр.

Шулай ук сәнгать өлкәсендәге мөнәсәбәтләр дә киң. Һәр ике милләт культураларының аралашып, бер-берсен баетып яшәүләре дә күркәм күренеш. Шушы елларда гына Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары Алма-Атадагы уңышлы иҗат чыгышлары белән казакъ дусларны сөендерсәләр, М. Ауэзов исемендәге казакъ дәүләт драма театры сәнгать көчләренең оста уеннары Казан тамашачыларының күңелләренә хуш килде.

Әнә шундый уйларга бирелеп оча торгач, җиде сәгать вакытның ничек үткәне дә сизелми калды. Менә самолет иллюминаторлары аша Тянь-шань биеклекләренең дәвамы булган Алатау итәгендәге үзәнлектә, көньяк агачларының яшеллегенә күмелеп утырган Казагыстанның башкаласы Алма-Ата шәһәре күренде.

...Шәһәрнең предприятиеләрендә, учреждениеләрендә төп килүемнең максаты булган эшләрем бетеп килә инде. Республиканың җиңел промышленность министрлыгында гына буласы бар. Министр, Казагыстан ССР Верховный Советы депутаты Вәгыйз Ибраһимов мине җылы каршылады. Татарстаннан икәнлегемне белгәч, тагын да җанланып, ачылып китте. Чөнки ул, бердән, үзе дә татар егете, икенчедән, республиканың җиңел промышленносте өлкәсендә генә дә бик күп милләтләр: казакълар, руслар, уйгурлар, украиннар, башкортлар, чувашлар һәм башка халык вәкилләре белән бергә иңгә-иң торып, татар халкының хатын-кызлары һәм ир-егетләре дә эштә өлгерлек, уңганлык, булганлык күрсәтәләр, матур яшиләр икән. Республика җиңел промышленностенең еллык планнарын уңышлы үтәп баруында аларның да хезмәт өлеше зур.

Алма-Ата мех комбинаты директоры Курманов Сарсекен Курманович эш кәгазьләре белән мәшгуль булып утырган җиреннән:

— Ә безнең мех комбинатын Казан җиңел промышленность техникумын тәмамлап килгән белгечләр әйдәп баралар дисәм дә һич ялгыш булмастыр, — дип сүзгә кушылды. — Шуларның берсе Равия Җәләлиева мехчы һөнәренең чын остасы, кешеләр белән игътибарлы эшли белә торган киң карашлы җитәкче булып бөтен республикага танылды инде. — Каратут йөзле, урта яшьләрдәге бу кеше казакъларга гына хас гадилек, самимилек белән сүзен дәвам итте: — Мех производствосының химиягә бәйләнешле тармакларында Равия Си-



Равия Җәләлиева.

ражетдиновнаның уйлап табу эшләре, камилләштерү тәкъдимнәре күп файда бирә. Алар предприятиенең техника прогрессы юлындагы үсешенә зур ярдәм иттеләр. Ул эшләр, яңалыклар, гомумән, безнең комбинат белән танышып китсәгез икән. Җитмәсә, үзегез дә Казан химиклары мәктәбендә тәрбияләнгән инженер икәнсез,—дип, минем күкрәктәге КХТИ значогына ымлады.

Директор телгә алган Равия Җәләлиева минем авылдашым, бала чактагы авыр көннәремдә миңа якты маяк булган, үз көчемә ышаныч өстәгән, тормыш матурлыгы өчен көрәшләргә әйдәгән иң якын кешеләремнең берсе бит.

Күңел түремдә бала чак хатирәләрем, үсмер чакларым, үткән елларым яңарды.

...Ике яшьлек чагымда мин әтиәнисез калганмын. Шул вакыттан мине тәрбиягә алып, укытып, миңа тормыш яктылыгы биреп үстерүчеләр Равия апаның әтисе Сираҗетдин ага белән әнисе Гафифҗамал апа булдылар. Шулай итеп, алар минем дә кадерле әткәем белән газиз әнкәемә әверелделәр.

Аларның балалары да мине үз күрделәр, якын иттеләр. Шулар арасыннан Равия апаның аеруча игътибарлы, ярдәмчел, киң күңелле булуы хәтеремдә якты истәлекләр калдырган. Әллә үзе дә кечкенәдән укуга бик хирес, бик маһир булганга, аның һәр вакыт белемгә омтылырга әйткән киңәшләре шулай ук күңелемдә саклана.

Урта мәктәпне тәмамлагач, киләчәк укуым итеп С. М. Киров исемендәге Казан химия-технология институтын сайлавымда да Равия апаның йогынтысы аз булмады, билгеле. Ә студент елларымда хатлар аша, я булмаса ерак Казагыстан җирләреннән туган якларын сагынып килүләрендә мине күреп сөйләшергә тырышыр, укуымның барышы белән танышып, яшәвем белән кызыксынып, төпле киңәшләрен әйтеп рухыма яңа көч, яңа дәрман өстәр иде. Институтны тәмамлагач, республикабызның Түбән Кама нефть-химия комбинатында инженер булып эшли башладым.

Менә шуңа күрә, хезмәтемә бәйле эшләр белән Равия апа яшәгән, көн иткән Алма-Ата каласына юлга чыгуым мине дулкынландырды.

Министрлыктагы, гомумән, Алма-Атадагы эшләрем Казагыстан мехчыларына бәйләнешле булмаса да, биредәге иптәшләрнең, казакъ дусларның тәкъдименә бик теләп кушылдым.

...Җиңел машина шәһәрнең төньяк-көнчыгыш өлешенә карап юл алды. Казакъ халкының милли герое, революционер Амангельди Иманов һәйкәле, Абай, Пушкин исемендәге проспектлар да артта калды. Алда мех комбинаты производство объектларының зур биналары күренде.

Килеп кергәч тә, иң башта андагы тәртип, чисталык игътибарны үзенә җәлеп итә. Арырак производство цехлары тезелеп киткән. Комбинатның кадрлар бүлеге мөдире Лидия Петровна Пытманова белән тирәне эшкәртү, буяу, киптерү, сортларга аеру, тегү һ. б. цехлар буйлап үтәбез. Лидия Петровна комбинатның узганын, бүгенгесен

һәм киләчәген генә сөйләп калмый, аның кешеләре, хезмәт геройлары, шул җөмләдән безнең якташларыбыз хакында да тулы мәгълүматлар биреп, алар белән таныштырып барырга да өлгерә.

Предприятиедә элек кул көче белән башкарыла торган бик күп эшләрнең автоматлаштырылганлыгы, хезмәтнең фәнни оештырылганлыгы күренеп тора. Цехларда конвейерлар эшли. Продукцияне бер цехтан икенчесенә илтү өчен үзйөрешле вагонеткалар киң кулланыла. Производство эстетикасына да күп әһәмият бирелә: цехларда гөлләр, чәчәкләр үсеп утыра, стеналар матур итеп бизәлгән.

Мех әйберләрне эшкәртү-буяу производствосы аша узганда, андагы тәртип аеруча күзгә ташлана. Һәр нәрсәнең үз урынында булуы, механизмнар гөрелтесеннән үк биредә эшләрен сөеп, яратып башкаручы алтын куллы кешеләр эшли икәнлеге күренеп тора. Алар эшкәрткән чимал, ягъни тиренең шактый өлеше Казан мех производствосы берләшмәсенә дә озатыла икән. Ә ул тиреләрдән Казан мехчылары тегеп биргән җылы эш курткаларын киеп, Кама автомобиль заводы төзүчеләре һәм Түбән Кама нефтехимиклары да удар хезмәт вахталарын алып баралар. Шулай итеп, безнең республикабыздагы удар төзелешләргә биредә эшләүчеләрнең, димәк, биредәге якташларыбызның да шактый ярдәмнәре бар булып чыкты. Бу яңалык минем күңелгә тагы да шатлык, җылы хисләр өстәде. Комбинатның шушы производствосында гына да уннан артык милләт кешеләре эшли икән. Әнә Казагыстан республикасының алдынгы мех осталары: Ленин ордены кавалеры Лүбинә Кулҗанова һәм Карлыгач Айдинова, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнгән Нурга Казакъбаевалар белән бергә рус хатын-кызлары Раиса Хлебникова, Валентина Ротанова, Зоя Аширова, татарлардан Әлфия Бикметова, Наҗия Галиуллина, Исмәгыйль Хәсәнов һәм башка бик күпләр — һәммәсе бердәм дус коллективта эшлиләр.

...Эх, безнең мехчылар!
Алтын икән куллары ла,
Ут икән йөрәкләре.
Бөтен илгә мактаулылар
Кызлары, егетләре.

Казан мехчыларына багышланган бу җыр сүзләрен үзеннән-үзе аларга, Алма-Ата мехчыларына карата да әйтәсе килә башлый. Предприятиенең дәүләт планнарын елдан-ел арттырып үтәп баруында эшкәртү-буяу производствосы коллективының да өлеше зур, билгеле. Комбинатның дәүләт планын даими алдан үтәп чыгуы илебезнең халык хуҗалыгы тармагына өстәмә рәвештә бик күп продукция: балалар һәм хатын-кыз пальтолары, баш киемнәре, су үткәрми торган костюмнар, мех якалар һәм башка бик күп төрле әйберләр эшләп чыгарырга мөмкинлек биргән. Ә алардан алынган экономик эффект бер миллион сумнан да артып киткән. Тугандаш республикаларга багышлап үткәрелгән удар хезмәт атналыклары да уңышлы узган. Министрлык буенча җиңел промышленность предприятиеләре арасындагы социалистик ярышта да коллектив җиңүче дип табылган.

...Үзенең күләме, конструкциясе белән башкалардан шактый аерылып торган тирене эшкәртү аппараты янына производствога яңа килгән бер төркем яшь эшчеләр җыелган. Ә эшчеләргә карап бер ханым «АЖК-2» маркалы бу аппаратның кайбер үзенчәлекләрен аңлата. Сабыр холыклы, ачык йөзле, һәр сүзендә үз эшен яхшы өйрәнгән белгечләргә генә хас төгәллек күренеп торган ул кеше мех комбинатының эшкәртү-буяу производствосы җитәкчесе, минем авылдашым Равия апа Җәләлиева иде.

...Буа районының уралып аккан көмеш сулы Бола елгасы буендагы Исәк авылында туып үсә Равия апа. Җырларда җырланган Зөя суларына кушыла торган Бола елгасының чәчәкле тугайлары, кичке авыл өстендә балкыган йолдызлар, алар яктылыгында — зәңгәр тынлыкта яңгыраган халык моңнары, сызылып аткан алсу таңнары — һәммәсе үсмер елларының якты хатирәләре булып күңелендә саклана аның.

Семьяда алар алты бала үстеләр. Бөек Ватан сугышы еллары. Әтиләре Сираҗетдин ага ялын да, йокысын да онытып еш кына хәтта өйгә кайтып ашап китәргә дә өлгерә алмый. Кичләрен «сукыр» лампа яктысында дәресләрен хәзерләргә дип тезелешеп утырган балаларга карап, Сираҗетдин ага матур киләчәк хакында хыялланырга ярата. Аның изге теләкләреннән берсе — балаларын белемле итү. Күркәм эшләренә карап туган җирләре, халкы сокланып карый торган, илгә кирәк чын кешеләр булсыннар алар. Башкаларга караганда иң соңыннан гына китап-дәфтәрләреннән аерылып йокыга китә торган уртанчы кызы — Равиясенә аның ышанычы бигрәк тә зур иде.

Исәк авылының җидееллык мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан мех комбинаты каршындагы мехчылар техникумына керде ул. (Хәзерге җиңел промышленность техникумы).

Студент чак. Ул — техникумның химия бүлегендә укый. Теоретик һәм лаборатор дәресләр. Ә практик дәресләргә — мехчы һөнәренең серләренә өйрәнергә Казан мех комбинатына йөриләр. Беренче производство һәм тормыш чыныгуын да шунда ала Равия апа.

Менә техникумның соңгы курсы. Эшкә билгеләү буенча дәүләт комиссиясе белән чыгарылыш елы студентларының очрашып сөйләшү кичәсе аның хәтерендә аеруча сакланып калган. Бу кичәгә илебезнең бик күп тугандаш республикаларыннан да вәкилләр килгән иде. Алар студентларга союздаш республикалар промышленностеның ул вакыттагы кыенлыкларын, белгечләрнең җитмәвен сөйләделәр, булачак белгечләрне тугандаш республикаларның промышленностен торгызуда ярдәмгә килергә, аны үстерүдә, алга җибәрүдә актив катнашырга чакырдылар. Ә уртача буйлы, кара чәчле, сөйләвендә казакъ акценты беленеп торган вәкил:

— Казагыстан индустриясенең мех промышленносте утлары да балкып кабынуын теләп янган яшь йөрәкләр — Татарстан егетләре һәм кызлары, рәхим итегез! Республика сезне көтә, — дип сүзләрен тәмамлады.

Һәм Равия бер төркем иптәшләре — курсташлары Елена, Матвей, Саша һәм Анна белән Казагыстанга китәргә риза булды.

Яшь белгечләрне республиканың башкаласы Алма-Ата шәһәренең мех комбинатына эшкә билгеләделәр. Бу 1949 ел иде. Шуннан бирле аларның гомер юллары бу предприятие белән аерылгысыз бәйләнгән.

Мех әйберләрен эшкәртү цехында хезмәт юлын техник-химик булып башлаган Равия апа алдына катлаулы мәсьәләләр килеп баса: продукциянең эшкәртелү сыйфаты Дәүләт куйган стандартларга, таләпләргә һич тә җавап бирә алмый әле ул вакытта. Четерекле хәлдән ничек чыгарга?

Техникумда алган белем, һаман да эзләнүгә, яңалыкка булган омтылыш ярдәмгә килә. Исәп-хисап, сызымнар, математик формулалар белән төннәр буе утырулар... Үзлегеннән укып мех эшкәртү, техника өлкәсендәге яңалыкларны үзләштерү — производство, фән серләренә тирәнрәк төшенүнең, үтеп керүнең беренче баскычлары булалар. Ә аның күркәм нәтиҗәсе — производствоның бу четерекле участогында яңа эшкәртү машинасы — «АЖК-2» маркалы аппарат

барлыкка килә. Производстводагы хәлләр дә күзгә күренеп үзгәрә башлый. Продукциянең сыйфаты яхшырганнан-яхшыра бара.

Беренче иҗат шатлыклары Равия апага яңа канатлар куйгандай итә. Аны башка уйлап табу, рационализаторлык эшләренә рухландыра. Шуларның берсе — мех әйберләрен буяу процессында яңа препарат куллана башлау. Ул әһәмиятлелеге ягыннан бигрәк тә аерылып тора. Равия апаның уйлап тапкан бу химия тылсымы продукциянең буялу сыйфатларын тагын да яхшыртуга күп ярдәм итә. Предприятиегә, алдынгы методлар, яңалыклар белән танышырга, өйрәнергә дип, илебез шәһәрләреннән белгечләр, производство алдынгылары ашыга. Ә Казагыстан Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә Алма-Ата мехлары иң югары бүләккә — Алтын медальгә лаек була. Озакламый ул мехлар ил һәм дөнья күләмендә дә үзләрен танытып өлгерәләр. Башкалабыз Мәскәүдә үткәрелгән халыкара модалар күргәзмәсендә комбинат эшләп чыгарган әйберләр көмеш медальләр һәм грамоталар белән бүләкләнә.

Лейпциг, Брюссель кебек Халыкара ярминкәләрдә, Болгария, Польша һәм башка күп илләрдәге СССРның Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсендә Казагыстан мех осталары тәкъдим иткән көнкүреш әйберләре бик күпләрнең игътибарын җәлеп итә, мактала, бүләкләнә. Бу уңышларда Равия апаның хезмәт җимешләре дә бар, әлбәттә.

Равия апага комбинат коммунистларының да ышанычы артка478нан-арта бара. Ә 1957 елны инде алар аны үз сафларына — Ленин партиясе сафларына кабул итәләр. Күрсәтелгән олы ышанычка коммунист Равия апа Җәләлиева яңа хезмәт уңышлары белән җавап бирә.

Ул җитәкләгән эшкәртү-буяу производствосы коллективы Казагыстанның 50 еллыгы һәм Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә алган социалистик йөкләмәләрен дә уңышлы үтәп чыга. Аның истәлеге булып хезмәттәш иптәшләре белән бергә Равия апаның күкрәгендә дә «Ленинның тууына 100 ел тулу хөрмәтенә хезмәттә ирешкән уңышлар өчен» медале балкый.

Ә сигезенче бишьеллыктагы хезмәт уңышлары өчен Равия Сираҗетдин кызы Җәләлиева хөкүмәтебезнең югары бүләге — «Почет билгесе» орденына лаек була.

Равия апа — Мәскәү җиңел промышленность институтын читтән торып тәмамлады. Аңа кадәр Казагыстан компартиясе каршындагы югары партия мәктәбен бетергән иде. Шул ук вакытта Равия апа зур җәмәгать эше алып барырга да вакыт таба. Ул комбинатның партия комитеты члены.

Казан уку йортын тәмамлап бергә эшкә килгән иптәшләренә дә комбинатның җаваплы участоклары ышанып тапшырылган. Елена Боткина һәм Матвей Чубатовлар цех начальниклары, Александра Зотова предприятиенең сортларга аеру-тегү производствосын җитәкли. Ә Анна Мозаффаровада комбинат коммунистлары әйдәп баручыларын күргәннәр. Ул — партия оешмасы секретаре.

Гомумән, элеккеге Казан студентлары — хәзерге талантлы инженерлар — уйлап табу-рационализаторлык буенча да, оештыру өлкәсендә дә предприятиенең алга китешендә, техника прогрессы үсешендә актив эшлиләр.

Тагын шунысы куанычлы: кичәге укучылар үзләренә белем биргән, олы юлга чыгарган техникумнарын онытмыйлар. Хатлар алышып торалар. Күптән түгел уку йортының юбилее — 50 еллыгы шаулап узган. Бергәләшеп ул бәйрәмгә кайтып килгәннәр. Олы шатлыкка союзның башка республикаларыннан да кунаклар җыелган. Алар да производство, фән өлкәсендә алдынгы новаторлар, үз эш-

ләренең осталары, талантлы җитәкчеләр — ил байлыгын арттыруда башлап йөрүчеләр, аны алга әйдәүчеләр булып танылганар. Соңгы елларда гына Казан җиңел промышленность техникумын тәмамлап шул ук Казагыстанга эшкә килгән Фәния Галимова, Галина Гладкина, Фаик Гобәйдуллин һәм башкалар да алдынгы производство командирлары булып җитлеккәннәр инде.

Ә техникум бүген дә үзенең матур традициясен — тугандаш республикаларга белгечләр җибәрүен дәвам итә. Узган ел бер Казагыстан җиңел промышленностена гына да Казан техникумын тәмамлап егермеләп яшь белгечнең эшкә килүе шул хакта сөйли.

Ә Алма-Ата мех комбинаты коллективы Хөсәен Ямашев исемендәге Ленин орденлы Казан мех производство берләшмәсе белән элек-электән ярдәмләшеп яши, ярышып эшли. Күркәм традициядә башлап йөрүчеләр, аны дәвам итүче инициаторлар шул ук Равия апа һәм аның иптәшләре, әлбәттә. Күптән түгел алар — комбинатның бер төркем алдынгы белгечләре — Казан мех комбинатында булып, тәҗрибә уртаклашып, якташларының хезмәтләре белән танышып кайтулары да шуның бер билгесе. Үзләрен беренче тапкыр мех эшкәртү һәм производство серләренә өйрәткән тормыш мәктәпләре шулай итеп аларга һаман да көч өсти, рух бирә.

Комбинат коллективының яулаган уңышлары мактаулы булса, алда торган бурычлар тагын да зуррак һәм җаваплырак. Тугызынчы бишьеллыкта гына да Казагыстан җиңел промышленностеның үсеше узгандагыга караганда 70 процентка артты. Алма-Ата мех комбинатында гына да бик күп реконструкция эшләре белән бергә, яңа цехлар, объектлар калкып чыкты.

*
* *

Алатау итәкләрен нурга төреп кичке караңгылык сарды. Ял сәгатьләре якынлашты. Ленин исемендәге культура сараенда бүген Татарстанның халык артисты Илһам Шакиров концерты. Ире Мидхәт, уллары Дамир һәм Рафаэль белән Равия апа да шунда ашыга...

Туган якларына да еш кайта Равия апа — ара меңнәрчә чакрым булса да, хәзерге заманда юл мәшәкатьләре юк дәрәҗәсендә аз, вакыт дигәнең дә күп кирәкми. Әмма узган елны кайта алмады ул туган якларына — республиканың дуслык-хезмәттәшлек делегациясе составында Японияга барырга туры килде.

Ә туып-үскән якларында яшьлек дуслары, туганнары ни хәлдә яши икән? Республиканың кооперация өлкәсендә хезмәт отличнигы Нәгыймә апасы, илебезнең авиация промышленностенда мактаулы слесарь — алтын куллы Әһелтин энекәше, Казан заводларының берсендә алдынгы эшче Мәүдә сеңелкәше — һәммәсен күрәсе килә. Якташларының, Татарстанның тормышы, быелгы хезмәт уңышлары бик кызыксындыра аны.

Газиз анасы өзелеп искә төшә. Сәламәтлеге бик какшамадымы икән? Бөек Ватан сугышында ил азатлыгы өчен барган көрәшләрдә Гыйлләҗетдин абыйсының Мәскәү янында батырларча һәлак булу хәбәре күптән килгән булса да, әниләренең күңеле моңа ышанып бетә алмый әле. Өлкән улының кайтып килүен көтеп анасы хәзер дә юлларга һаман чыга микән? Ике дөнья сугышы ветераны әтиләренең дә фронт яраларының әрнүеннән сулышы өзелде...

Беренче мөмкинлек булу белән кайтыр ул, барысын да күрер, хәлен белер... Илһам Шакиров җырларын тыңлаганда әнә шулар турында уйланды Равия Җәләлиева.

Тәүфикъ Әйди

# ИГЕЗӘК АБДУЛЛИННАР

Моннан берничә еллар элек Ришат Абдуллин башкаруында татар халык җырлары аерым пластинка булып чыккач, бик күпләр: «Бу нинди җырчы соң әле? Моңа кадәр ишетелгәне дә юк иде, көтмәгәндә менә сиңа мә — пластинка! Үсеп килүче яшь талант микәнни?» — дип баш ваткан иде.

Татар тамашачыларының аны аз белүе Ришат Абдуллинның казакъ музыкасына хезмәт итүенә бәйле. Әмма аңа карап кына ул безнең өчен «ят сөяк» булып кала алмый. Артистның репертуарында утызлап татар җыры булу, концерт программаларында татар җырларының даими урын алып торуы безгә әнә шул хакта сөйләсә кирәк.

Ришат һәм аның туганы Мөслимнең тормышы, иҗат юллары Абай исемендәге казакъ дәүләт опера-балет театры белән бәйләнгән. Монда алар тәҗрибәсез яшь җырчы булып сәхнәгә күтәрелгән һәм беренче чиркәнлек алган, иҗади җитлегү кичергән, тамашачыларның алкышы астында бик күп опера партияләре башкарып, Казагыстанның халык артистлары исеменә лаек булган.

Театр бинасы матур сквер эчендә утыра. Бакчаны мул сулы фонтаннар, Абай һәм Җамбул һәйкәлләре бизәп тора. Игезәк Абдуллиннар өчен истәлекле урын бу. «Абай» операсында менә инде утыз сезон буе Абай ролен башкаручы Ришат сәхнәгә күтәрелер алдыннан да, спектакльдән соң да һәйкәл янына бер генә мәртәбә килмәгәндер. 1973 елның сентябрендә мин Абдуллиннарны менә шушы скверда очраттым һәм без бергәләп аларның кызыклы тормыш һәм иҗат юлына сәяхәт ясадык.

Алар 1916 елның мартында Усть-Каменогорск шәһәреннән ерак түгел бер җирдә татар шахтеры Мөким ага һәм Хәмидә апалар гаиләсендә дөньяга килгәннәр. Балалар бик яшьли эшкә өйрәнеп үсәләр. Унике яшендә икесе дә Белоус руднигына йөкче булып хезмәткә керә. Бу вакытта алар руда төялгән арба, җигүле ат артыннан күренмиләр дә. Таш, тузан арасында ертык ботинкалы малайлар үз ипекәйләрен табу өчен тир түксә, кичләрен киндер маен яндырып укырга-язарга өйрәнә, башлангыч мәктәп тәмамлый. Аталарының авырып китүе яшүсмер Ришат белән Мөслимгә укуны дәвам итәргә мөмкинлек бирми, тагын да ныграк билне буып, җиңне сызганып эшкә ябышырга туры килә. Мөслим рудниктагы хезмәтен дәвам итә, Ришат исә унбиш яшендә көтү көтә, уналтыда җир сөрә башлый.

Абдуллиннар гаиләсенең ял сәгатьләре электән үк җыр-музыкасыз үтмәгән. Иртыш буендагы Мөким ага алачыгыннан еш кына татар,

казакъ, рус җырлары ишетелә. Моңлы Мөким агага Ришат белән Мөслим дә кушыла. Сабый чакларыннан ук музыкага мәхәббәт кабызылган игезәкләр озакламый Белоус рудннгы үзешчән сәнгать түгәрәгенең алыштыргысыз артистлары булып китәләр. Аларны тыңлап сокланган шахтерлар һәм терлекчеләр, Мөким аганы үзләре эзләп табып, балаларны укытырга киңәш итәләр. Әмма авыру ата ике улын да җибәреп, тәрбиячесез калырга риза булмый, башта Мөслимгә генә юлга чыгарга хәер-фатиха бирә. 1932 елда Мөслим Казагыстанда яңа ачылган беренче музыка техникумына кабул ителә, ә бер елдан Ришат та шушы ук уку йортында белем ала башлый.

1935 елда Мәскәү консерваториясе каршында казакъ студиясе ачыла һәм Мөслим шунда укырга җибәрелә. Ришат исә музыка техникумында укуын дәвам иттерә. Шул ук вакытта ул беренче казакъ милли опералары «Кыз Ефәк», «Җалбыр»ның хорында җырлый башлый. 1936 елда ул да Мәскәү консерваториясенә килеп, Мөслим белән бергә профессор А. И. Вишневский классында белем алырга керешә.

Абдуллиннарның рухи үсешендә Мәскәү күренекле роль уйный. Алар башкаланың картина галереялары, театр, музейлары белән танышa, үзләре дә студентлар концертында чыгышлар ясый. Мәскәү консерваториясендә тавышлары тәмам формалашып җитә: Ришат — йомшак тембрлы көчле куе баритон, Мөслим — йомшак лирик көмеш сыман тенорга ия була. Тавышларындагы бу аерымлык аларга дуэт булып чыгыш ясау мөмкинлеген бирә.

Утызынчы еллар ахырында казакъ опера театры артистларга зур мохтаҗлык кичерә. Шунлыктан 1938 елда Мөслим, 1939 елда Ришат та Алма-Атага чакыртып алына һәм опера театрына солист итеп кабул ителә.

Мөслим Абдуллинның беренче роле «Кыз Ефәк» операсында Түләгән партиясе була. Габит Мөсрипевнең фольклорга нигезләнеп язган либреттосы казакъ феодаль җәмгыяте шартларында мәхәббәтнең трагедиягә китерүен сурәтли. Ефәк белән Түләгән үз мәхәббәтләре өчен көрәшеп һәлак булалар.

Композитор Брусиловский операда халык көйләреннән киң файдалана. Дастанны сәхнәләштерү башкаручылардан чорны, казакъ халкының җыр мирасын тирән белүне таләп итә. Мөслим Абдуллин барлык бу кыенлыкларны уңышлы рәвештә җиңеп чыга — Түләгән хисләренең тирәнлеген, аның әчкерсезлек, батырлык сыйфатларын ышандырырлык итеп ача.

Ришат Абдуллин беренче тапкыр сәхнәгә А. Зильберның «Бикән» операсында Олҗай ролендә чыга һәм вокаль осталыгы, артистлык хасиятләре белән яхшы тәэсир калдыра.

Озакламый театрда сәләтле иҗади коллектив туплана. Абдуллиннар анда күренекле урын ала. Алар «Айман-Чулпан», «Ир Таргын» операларында осталыкларын камилләштерәләр, матбугатта иҗат эшләренә уңай бәя бирелә.

Сугыш елларында бертуган Абдуллиннарның концерт эшчәнлеге киң җәелә. Шул ук вакытта алар яңа куелган операларда төп партияләрне башкаралар. Казакъ театры бу елларда кардәш халыклар сәнгатенә мөрәҗәгать итә башлый — әзербәйҗан композиторы М. Могамаевның «Нәркис», грузин композиторы З. Палиашвилинең «Әңгер-меңгер» әсәрен сәхнәгә куя. Грузин милли музыкасын башкару, гореф-гадәте, тарихы үзенчәлекле грузин тормышын казакъ сәхнәсендә гәүдәләндерә алуга кайберәүләр шик белән карый. Әмма театр сынауны уңышлы үтә. Төп партияләрдән булган Киазо ролен Ришат Абдуллин башкара. Соңрак бу спектакль Алма-Атада грузин сәхнәсе осталары П. Әмирәшвили һәм Д. Ангуладзе катнашында да куела. Бу культура эшлеклеләре белән иҗади аралашу Абдуллиннарның сәхнә осталыгын үстерүгә



**М. Абдуллин «Биржан һәм Сара» операсында Серик ролендә.**

ярдәм итә һәм дөнья опера классикасының үлемсез әсәрләрендә уйнау өчен җирлек әзерли. Андый әсәрләрнең беренчесе Пуччининың «Чио-Чио-сан» операсы була.

Ришат Абдуллин бу спектакльдә Нагасакидагы Америка консулы Шарплес ролен башкара. Бу партия операда башкару өчен иң катлаулыларның берсе. Җырчы аны тел тидермәслек итеп җырлый һәм консулның гаять тормышчан образын тудыра.

Мөслим Абдуллин Горо партиясен җырлап шулай ук зур уңыш казана.

Казакъ алдынгы иҗтимагый фикеренең байрак йөртүчесе Абай образын гәүдәләндерү зур җаваплылык сорый. Шагыйрь шигырьдән тыш музыканы да яхшы белә һәм көйләр иҗат итә. Аның образын тудырыр өчен грамоталы җырлау, яхшы тавышка ия булу гына җитми, ә бәлки Абайга хас йомшак, кешелекле хисләрне чагылдыра белү кирәк иде. Тарихи шәхеснең тормышын һәм характерын күзаллау таләп ителә. Ришат Абдуллин Ауэзов әсәрләреннән тыш архив чыганаклары, музей экспонатлары һ. б. материаллар белән дә таныша.

РСФСРның атказанган артисты Н. Сац премьерадан соң:

— Абай партиясен Казагыстанның атказанган артисты Ришат Абдуллин бик шәп башкара, — ди. — Кызыклы һәм үтә авыр диапазонлы Абай партиясен ул бик яхшы үзләштергән, вокаль ягыннан алга зур адым атлаган. Тавышының матур тембры, төсмерләргә бай булуы, яңгырату көче, сузу сәләте һәм олы вокаль хиссият — боларның барысы да, шөбһәсез, җырчының казанышы».

Ришат Абдуллинның Абай ролендәге уены күп тапкырлар җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәя алган. Олы хисләр һәм фикерләр иясе, халыкның иң матур идеаллары өчен көрәшүче демократ шагыйрь образын артист күпкырлы һәм тормышчан итеп гәүдәләндерә.

Беренче актта Абай-Абдуллин мәһабәт, тыныч, бөтен кыяфәтеннән зирәклек, кешелеклелек бөркелеп тора. Абай киләчәккә, яхшының яманны җиңәчәгенә ышана һәм гаделсезлек корбаннарына ярдәм кулы суза. Абайның Аҗар һәм Айдар мәхәббәте, аларның бәхете өчен көрәшергә карар итүен Абдуллин психологик яктан гаять нечкә рәвештә «Күземнең карасы» көенә башкарган ариясендә күрсәтә. Башта артистның җырлавы уйчан, моңлы. Аннары әкренләп ария үсә, башкаручының тавышында язмышка ачу-нәфрәт яңгырый башлый, кискен драматик шартларда Абайның явызлыкка каршы калкан булып күтәреләчәк нык ихтыяр көче сизелә.

Икенче акт. Айдар белән Аҗар өстеннән суд бара. Бу җирдә Әҗемне уйнаучы Мөслим Абдуллин традицион әйтеш — чичәнлек ярышында үз героен гаять оста гәүдәләндерә. Дошманы Җирәнчәгә каршы чыгып, Әҗем Ефәк, Баяннарның риясыз мәхәббәтләрен мисалга китерә, Пушкинның Татьянасын, Шекспирның Джульеттасын хәтергә төшерә. Ул

йомшак һәм моңлы җырлый. Җырчының хәрәкәтләре темпераментлы, мимикага бай.

Суд Абай һәм байлар арасындагы киеренке сүз көрәштерү белән тәмамлана. Бу күренештә Ришат Абдуллинда көчле нәфрәт кайный. Икенче акт Абай һәм аның яклыларның җиңүе белән бетә.

Операның өченче пәрдәсе үткен драматик ситуацияләрдән корылган һәм ул артистлардан зур эчке киеренкелекне таләп итә. Монда Мөслим Абдуллин көнчелектән сатлыкка әверелгән героеның яңа сыйфатларын, аның икейөзлелеген ача.

Соңгы күренешләрдә Ришат Абдуллинның уенында сөекле шәкертен югалткан Абайның авыр эчке хисләрен сурәтләүче яңа буяулар өстәлә. Шагыйрь кайгыра, әмма халкына, аның якты киләчәгенә ышана.

«Абай» операсы 1958 елда зур театр сәхнәсендә казакъ сәнгате һәм әдәбияты декадасында Мәскәү тамашачылары игътибарына да тәкъдим ителә. «Известия» газетасында СССР халык артисткасы В. Пашенная «Р. Абдуллин тарафыннан тудырылган Абай образы казакъның гына түгел, бөтен совет сәнгатенең күренекле казанышы булуы бәхәссез», — дип яза.

Ришатның сәхнә осталыгын, тавыш төсмерләренең байлыгы, вокаль көчен чит ил культура эшлеклеләре дә билгеләп үтә. Прогрессив төрек язучысы Зәкәрия Сиртел үзенең «Советлар Союзында 45 көн» исемле китабында «Абай ролен башкаручы Ришат Абдуллин дөньяның теләсә кайсы опера театрында чыгыш ясый ала. Ул сәхнә сәнгатен камил үзләштергән, ролендә образны дөрес ача. Аның баритон тавышы гаять ягымлы яңгырый», ди.

Игезәк Абдуллиннарның барлык рольләренә дә тукталу мөмкин түгел. Казакъ опера театрында алар катнашмаган бер генә әсәрне дә атап булмый. Е. Брусиловский һәм М. Түләбаевларның «Аманкилде»сендә революционер Аманкилде, П. И. Чайковскийның «Евгений Онегин»ендә Онегин, А. Г. Рубинштейнның «Демон»ында Демон, беренче уйгыр операсы «Назугум»да Гөлмәт партияләрен Казагыстанда беренче мәртәбә Ришат Абдуллин җырлады. Аның башкаруындагы Демон партиясе иң яхшылардан исәпләнеп, Мәскәү тавыш язу студиясендә репертуарга алынган.

Д. Верди, Ж. Бизе, Ш. Гуно, Н. Җиһанов, Е. Рәхмәдиев һ. б. композиторларның операларында да бертуган Абдуллиннар тормышчан һәм матур образлар иҗат итеп, тамашачыларга бик күп ләззәтле минутлар китерә.

Абдуллиннарның концерт эшчәнлеге исә бер олы тармак. Алар ялгыз да, дуэт белән дә чыгыш ясый. Казакъ композиторларының байтак әсәрләрен тамашачыларга беренче тапкыр Абдуллиннар җиткерә. Казакъ җырын дуэт белән җырлауны да беренче мәртәбә алар кертә.

Абдуллиннар репертуарында 300 ләп җыр бар. Чит ил һәм рус классик музыкасыннан арияләр, казакъ, татар һ. б. халыкларның җырлары һәм композиторларының әсәрләрен Абдуллиннар җырны, стилен һәм характерын табып, зур зәвык, яхшы дикция һәм югары вокаль осталык белән башкара. Алар яңгыраткан «Ике җирән», «Кызыл бодай», «Сырымбәт», «Зәүрәш» һ. б. казакъ халык көйләре инде менә күпме еллар тыңлаучылар күңелен әсир итә. Алар башкарган М. Глинка, П. Чайковский, С. Рахманинов, А. Бородин, Н. Римский-Корсаков, А. Доргомыжский, Ф. Шуберт романсларын тамашачыларның инде ничәнче буыны тыңлый... А. Еспаев, Ш. Калдаяков, Б. Кожагулов, Х. Дусемалиев, С. Мөхәммәтҗановлар җырларының атаклы Абдуллиннар башкаруында яңгыравы бу авторларның халык арасында популярлашуына сәбәп булды. Казакъ тамашачылары Е. Родыгин, М. Блантер, В. Мурадели, В. Булгаровский, Б. Мокроусов,

А. Еспаев, Е. Брусиловский, М. Байкадамов һ. б. композиторларның дуэтларын да Абдуллиннар башкаруында яратып кабул итте.

Абдуллиннар репертуарында төрле халыкларның музыкасы мактаулы урын алган. Әмма алар арасында бигрәк тә кадерлеләре, яратып, аеруча бер дәрт белән бирелеп җырлана торганнары татар халык җыры, татар композиторларының әсәрләре булуы Казагыстанда берәүгә дә сер түгел. Чөнки бу моңнар ана сөте белән кергән, чөнки заман һәм тормыш үзе Абдуллиннарны туган халкының музыкаль иҗаты белән әледән-әле сугарып тора.

Билгеле булуынча, утызынчы елларда Мәскәү консерваториясе каршында сәнгать кадрлары әзерләү өчен милли студияләр ачыла. Фәхри Насретдинов, Ситдыйк Айдаров, Галия Кайбицкая, Мәрьям Рахманкулова кебек сәләтле яшьләр татар студиясендә укый башлый. Безнең студиячеләр башка кардәшләренә караганда да киеренкерәк, кызыклырак тормыш белән яши. Чөнки Мәскәүдә татар хезмәт ияләре бик күп тупланган, монда татар мәктәпләре, клублары эшли, газета-журналлар чыгарыла, үзешчән сәнгать үсә. Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, М. Җәлил һ. б. язучылар, артист, композиторлар катнашлыгында әдәби-музыкаль кичәләр оештырыла. Бу кичәләргә бүтән милли студияләрдә укучылар да чакырыла. Тулай торакта татар артистлары һәм булачак композитор Рөстәм Яхин белән бергә яшәгән Абдуллиннар да ул кичәләргә йөри, тамаша итә һәм чыгыш ясыйлар.

Бу куәтле яшь әдәбият һәм сәнгать көчләре белән аралашып яшәү, Фәхри Насретдинов, Рөстәм Яхиннар белән булган иҗади дуслык Ришат белән Мөслимнең Мәскәү чоры тормышында якты сәхифә булып уелып кала. Киләчәктә дә алар бер-берсенең иҗаты белән кызыксынып яшиләр.

Абдуллиннарның татар музыкасы белән элемтәсен ныгытуда Алма-Атага эшкә чакырылган композитор Латыйф Хәмидинең дә уңай йогынтысы кечкенә түгел. Аның күп кенә әсәрләре җырчыларның репертуарында даими урын тота. Ниһаять, Н. Җиһановның «Алтын чәч» операсын кую Абдуллиннарның иҗат биографияләрендә җуелмаслык эз калдыра. Кайчандыр тыйнак пианиночы буларак кына таныш булган яшьлек дуслары Р. Яхинның композиторлык даны чыгу белән Мөслим һәм Ришат аңарга хат юллыйлар. Автор җибәргән ноталарны алып, эшкә керешәләр һәм озакламый сәнгать сөючеләр яраткан җырчылары башкаруында «Дулкыннар, дулкыннар», «Үткәндә кичергән кайгылар» һ. б. җырларны тыңлап кинәнә.

Абдуллиннар башкаруында барлык татар җырлары диярлек радио аша яңгырый, ә «Озату», «Әниемә хат»ны алар Швеция, Финляндиядә гастрольдә йөргәндә дә башкаралар.

Р. Яхин Абдуллиннарның татар җырларын хисси яктан бай һәм тәэсирле итеп, моңны тирән тоеп җырлауларына соклана. «Аларда формаль җырлау юк. Бик матур, нәфис тембрлы, риясыз тавыш. Моңлы итеп җырларга омтылалар һәм моңа ирешәләр. Әсәрең шундый кешеләр тарафыннан җырлану, әлбәттә, зур сөенеч»,— ди композитор.

Соңгы вакытларда гына да татар сәнгать осталары ике мәртәбә Алма-Атага барып, шәһәрнең иң олы залы — спорт сараенда зур концертлар биреп кайттылар. Һәр юлы аларны утызар мең кеше тыңлады. Бу уңышлы чыгышларны оештыруда «Казакъконцерт»ның художество җитәкчесе Мөслим Абдуллинның да өлеше бар. Алкышлар тынып, тамаша залы бушауга, татар артистлары янына Ришат белән Мөслим күтәрелә, В. Шәрипова, Ф. Насретдинов, И. Шакиров белән алар арасындагы эчкерсез әңгәмәләр монда гына бетми, спорт сараеннан Ришатлар квартирасына күчә, сәнгатьтәге яңалыклар, казанышлар һәм планнар белән уртаклашу озак дәвам итә.

Абдуллиннар илебезнең Мәскәү, Ташкент, Фрунзе, Уфа, Казан кебек шәһәрләрендә, йөзләрчә авылларда, Монголия, Һиндстан, Кытай, Канада, Чехословакия һ. б. илләрдә чыгыш ясап, казакъ музыка сәнгатенең данын ерак-еракларга яңгыраттылар. Аларның бу олы хезмәте дәүләтебез тарафыннан югары бәяләнде — һәр икесе Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде, Казагыстанның халык артисты исемен алды, ә Ришат СССР халык артисты дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Без скверда сөйләшеп утырганда Ришат, Мөслим агалар белән байтак кеше исәнләшеп үтте. Шул вакыт мин Күкчәтау, Караганда һ. б. җирләрдәге танышларымның «казакъ артистлары арасында тел ягыннан булсын, моң ягыннан булсын, игезәк Абдуллиннарга житкән җырчы сирәк» дигән сүзләрен исемә төшердем һәм бу фикергә Ришат аганың үз мөнәсәбәтен белергә теләдем.



Р. Абдуллин Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсында Хан ролендә.



— Мондый сүзләрне ишетү бик күңелле, билгеле,— диде ул елмаеп.— Казакъ халкы безгә чыннан да зур мәхәббәт белән карый. Сыйлау дисеңме, бүләк бирүме — игътибар күрсәтүнең бер генә формасы да онытылмый. Безгә савыт-саба да, келәм дә бүләк иттеләр, чапан да кидерделәр, Көнчыгыш Казагыстан өлкәсенең Зайсан районында атка да менгезделәр. Казакъның җыр яратуы, кунакчыллыгы искиткеч. Әмма без, мин-минлеккә бирелеп, алданырга тиеш түгел. Казакъ халкы бик күп талантлы җырчыларны үстереп чыгарды. СССР халык артистлары Көләч Байсәетова, Роза Багланова кебек хезмәттәшләребез бөтен Союзга билгеле. Без ошаткан һәм яраткан җырчыларны дистәләп санарга мөмкин булыр иде.

Ришат ага уйланып торды да өстәде:

— Иң дәрәҗәле, иң мактаулы исемнәрне йөртергә лаек талантлар сездә дә бар. Татарстан җәмәгатьчелегенә бер теләгем: әнә шул талантларны тагын да үстерәсе, СССР һәм дөнья күләмендә танытасы иде...

Ришат Абдуллин минем белән очрашкан көннәрдә халыкара музыкаль симпозиумда катнашучылар алдында Абай партиясен башкарырга әзерләнә иде. Утызынчы ел җырлауга карамастан, кат-кат репетиция ясый.

Мөслим агадан аерылгач та, без әле Ришат Абдуллин белән әңгәмәбезне озак дәвам иттердек. Ул миннән 1972 елда беренче тапкыр килеп күргән Әлмәт, Түбән Кама, Чаллы, Казан тормышын, сәнгать яңалыкларын сорашты, «тарих музеендагы әдәбият бүлеге башка чыкмадымы?» дип белеште. Аннары сүз яңадан Алма-Атага әйләнеп кайтты.

Ришат аганың гаиләсе дә башы-аягы белән сәхнәгә бәйләнгән. Тормыш иптәше Ләмига ханым Сираҗетдинова М. Әуэзов исемендәге казакъ драма театрында уйнаган. Улы Заур быел Алма-Ата консерваториясен тәмамлый, инде атасы белән берничә тапкыр гастрольләрдә йөреп кайтырга да өлгергән. Кызлары Зөһрә дә Мәскәү консер-

ваториясенең фортепьяно классын тәмамлый. Мөслим Абдуллинның да төпчек улы музыкант икән.

«Татар — казакъ музыкаль бәйләнешләрен дәлилләп күрсәтерлек исемнәр күп алар, — диде Ришат ага саубуллашканда. — Ике халыкның уртак балалары булган җырчы, композитор Маһирә, Казагыстанның халык артисты Әнвәр Өметбаев, СССР халык артистлары Ирмәк Сиркәбаев, Бибигөл Түләгәнева, әле яңа гына Италиядә укып кайткан яшь җырчы Йолдыз Баймулдина... Ә Казагыстанның халык артисты, доцент, күренекле композитор Латыйф Хәмидине кая куясың? Муса Җәлилнең дусты булган бу хөрмәтле кеше турында да сез беренче чиратта язарга тиеш!»

Алма-Атага килгән юлчылар В. И. Ленин исемендәге культура сарае тирәсен күрми китми. Моннан Алатауның карлы түбәләренә асылмалы юл менеп китә, шәһәрнең панорамасы яхшы күренә. Абай проспекты шушыннан башлана, гранит кыяга уеп иҗат ителгән шагыйрь сыны мәйданга аерым бер тантаналы төс биреп тора. Мәйданга терәлеп торган, милли бизәкләр белән сырланып эшләнгән яңа зур кинотеатрның исеме — «Арман», ягъни «Хыял»! Бик күңелле монда.

Ә кайберәүләр шагыйрь исемен йөрткән театрга юнәлә. Биредә алар тере Абай — Ришат Абдуллин белән очраша. Талантлы артистның тылсымлы сәнгате казакъ культурасы нигезенә гранит ташлар салган кешенең уй-хыялларын, казакъ халкының якты тормышка бару юлындагы көрәшләрен күз алдына бастыра. Утызынчы сезон шушы рольдә! Чын мәгънәсендә еллар сынавын үткән иҗат бу.

**Ринат Мөхәммәдиев**

# ТЕАТРЫБЫЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ ТӘНКЫЙТЬЧЕСЕ

**1906** елның 22 декабрендә Казанда «Новый клуб» бинасында «Кызганыч бала» һәм «Гыйшык бәласе» исемле пьесалар уйнала. Бу көн мәдәниятебез тарихына татарча беренче рәсми спектакль куелу һәм татар театры туган көн буларак кереп кала. Әлеге пьесаларның беренчесе Г. Камал, икенчесе Г. Кәрам тәрҗемәләре. Г. Камал һәм Г. Кәрам... Бу ике исемнең янәшә килүе очраклы бер хәл булып тоелырга мөмкин. Чөнки Г. Камал хаклы рәвештә татар театрының остазы исемен йөртүче мәшһүр драматургыбыз, бу — һәркемгә мәгълүм. Ә Г. Кәрам кем?

Аның тулы исеме Габдрахман Хәбибулла улы Рәхмәтуллин. Габдрахман 1878 елда Казанда туып, ата-анасыннан яшьли ятим кала. Ул Мифтах Иманкулов дигән кеше тәрбиясендә үсә. Башта Казан мәдрәсәләренең берсендә, аннан соң Истамбул университетының әдәбият факультетында укый. Рус, француз һәм төрек телләрен яхшы белгән Габдрахман дөнья әдәбияты классикларының әсәрләрен өйрәнеп, үзенең әдәби һәм иҗтимагый фикерләү офыкларын киңәйтә.

1905 ел революциясен ул Казанда каршылый һәм «Казан мөхбире», «Йолдыз» газеталарының беренче саннарыннан ук без аның Г. Кәрам псевдонимы белән бастырган мәкалә, рецензияләрен очрата башлыйбыз. (Ул киләчәктә дә матбугатта шушы псевдоним белән язьиша, замандашлары да аны нигездә Г. Кәрам буларак кына беләләр.)

Габдрахман Кәрам беренче мәкаләләреннән үк үзен театр тәнкыйтьчесе буларак таныта. Аның хакында күренекле әдәбият галиме Г. Сәгъди: «1905 ел революциясеннән соң татарда үзенең күбрәк игътибарын (бәлки бөтен игътибарын) сәхнәгә, сәхнә әсәрләренә каратучы, шуларны тәнкыйтькә багышлаучы бер тәнкыйтьче дә чыкты. Г. Кәрам әнә шул тәнкыйтьче», — дип язган иде [1].

Әле беренче театр труппалары оешып кына килгән бер заманда, 1906 елның башында ук, Г. Кәрам Фатих Халидинең «Морат Сәлимов» драмасы һәм «Мәхрүсә ханым» пьесаларына рецензия язып чыга. «Йолдыз» газетасының бишенче санында басылган бу мәкаләдә үк инде авторның театр һәм драматургия өлкәсендә зур мәгълүматлы каләм иясе булуы күзгә ташлана. Менә шушы көннән башлап, татар театры тормышындагы һәр вакыйга, һәр яңалык Г. Кәрамның игътибарыннан читтә калмый. Беренче театр труппалары, аларда уйнаучы талантлы яшь артистлар, татар театрының беренче режиссерлары — алар барысы да тугры сүзле принципиаль тән-

---

[1] Г. Сәгъди. Бездә әдәби тәнкыйть. 1927 ел, 17 бит.

кыйтьченең ярдәмен тоеп яшиләр һәм иҗат итәләр. Ул яшь татар театрының һәр уңышына чын күңелдән куана, кимчелекләрен күреп исә тирән борчуга төшә.

Тәнкыйтьче матбугат битләрендә даими рәвештә еллык күзәтүләр ясый. Ул күзәтүләрендә Г. Кәрам артистлар уенын, куела торган әсәрне тикшереп һәм бәяләп кенә калмыйча, кайсы пьесаның ничә тапкыр уйналуы, театр труппаларының составы, тамашачыларның кемнәр булуы һәм аларның спектакльне ничек кабул итүе кебек күп кенә башка белешмәләр дә бирә. Аның рецензияләре гомумән киң фикерле булулары белән дә аерылып торалар. Г. Кәрам тәнкыйтенең үзенчәлеге шунда ки, ул драма әсәрләренә һәм спектакльгә анализ ясау, һәр артист уенындагы уңай һәм кимчелекле якларын күрсәтү белән генә чикләнми, ә спектакль турында, барыннан да элек, сәхнә белән зал, автор белән артист, артист белән тамашачы арасындагы бәйләнеш аларның бер-берсен аңлау яисә аңламауларыннан чыгып хөкем йөртә.

Кәрам — сәхнә әсәрләренә карата аеруча таләпчән тәнкыйтьче. Мәсәлән, татар драматургиясенең формалашып килгән бер чорында ул, тирән борчылу белән: «Бездә бу көндә мөкәмәл вә яхшы пьесалар юк дәрәҗәсендә аз. Бу пьесаларыбыз хакында фәлән уендагы фәлән тип дип әйтә алмыйбыз. Чөнки бездә типлар юк», — дип чыккан иде [1]. Ләкин шул ук вакытта тәнкыйтьче драматургиябезнең һәр уңышын чын күңелдән куанып каршы ала. Ул Г. Камалның иске тормышны фаш итүче «Бәхетсез егет», «Банкрот», «Безнең шәһәрнең серләре» кебек әсәрләренә югары бәя бирә, «Йолдыз» газетасы битләрендә һәркайсына махсус тәнкыйть мәкаләсен багышлый.

«Сәйяр» труппасы 1910—1911 ел сезонын Ф. Әмирханның «Яшьләр» драмасы белән ача. Шул уңайдан язылган мәкаләсендә Г. Кәрам әсәрнең форма ягыннан камиллеген күрсәтә һәм реакция елларында яшьләр арасында барган фикер каршылыкларының төп конфликт итеп алынуын хуплап чыга. Соңрак, 1914 елда, «Яшьләр»нең чираттагы куелышы уңае белән, әсәр турында ул: «Әллә кай җирләре, әллә кай сүзләре Горькийның «Мещаннар»ын хәтерләтәдер» [2], — дип яза. Ф. Әмирхан иҗатына тәнкыйтьче аеруча игътибарлы була, аның сәхнә өчен язылган әсәрләрен вакытлы матбугат битләрендә кат-кат күздән кичерә. Ф. Әмирхан иҗатына мөнәсәбәттә Г. Кәрамның гомумән икеләнгәне булмады, ул аның өчен заманның прогрессив идеяләре белән коралланган зур талант иде һәм шулай булып калды да. Мәсәлән, Ф. Сәйфи-Казанлы «Тигезсезләр»не «ялтыравыклы ялган» дип чыккан бер чорда ул шул ук әсәр турында: «Бу — туп-туры безнең яңа тормышыбызның матур кисәкләреннән оста каләм илә тасвир кылынган матур-матур ләүхәләредер» [3], — дип, әсәрдә реалистик башлангычлар булуын күрсәтте. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, Кәрамның мәкаләләре һәр вакыт тыйнак һәм тыныч бер тон белән язылалар. Ләкин шунысы әһәмиятле, мондый тынычлык, салкын канлылык артында яхшы зәвыклы, культуралы шәхес, принципиаль тәнкыйтьче тора. Ул сүзен үлчәп әйтә, ләкин кире алмый. Тәнкыйтьченең бу сыйфаты Ф. Әмирхан иҗатына мөнәсәбәттә аеруча ачык күренә.

Габдрахман Кәрам иҗаты белән танышканда тәнкыйтьченең фикер колачына, алдына куйган бурычларның никадәр күп төрле булуына сокланып куясың. Әле генә тәнкыйтьче сәхнә әсәрен анализлый иде, менә инде ул тамашаның үзенә күчә: артистлар үз рольләренә туры киләме, үз-үзләрен тоту, сөйләшү манералары ничек, киемнәре килешәме, грим дөрес салынганмы? — Инде тәнкыйтьчене әнә шул характердагы дистәләрчә сораулар борчый. Бер уйлаганда, болар тәнкыйть өчен кечкенә детальләр булып тоела, тәнкыйтьне, беренче чиратта, зуррак, әһәмиятлерәк мәсьәләләр кызыксындырырга тиеш кебек... Ә шулай да, театр әлеге детальләрдән тыш мөмкинмени? Димәк, театр тәнкыйтьчесе дә аларны читләтеп уза алмый. «Өченче пәрдәдә Кариев парик вә грим җәһәтеннән безгә охшамады. Уникe ел эчендә яшь бер солдатның, нинди авырлыкта булса да, ул кадәр картаю ихтималы юк. Кариев бу пәрдәдә җитмеш яшьлек бер карт кыяфәте илә карый иде» [4]. Мисал итеп шушы өзекне алуыбыз бер дә гаҗәпләндермәсен. Г. Кәрам мәшһүр артист һәм режиссер

---

[1] «Кояш», 1914 ел, 329 сан.
[2] Шунда ук, 1914 ел, 329 сан.
[3] «Аң», 1915 ел, 4 сан, 86 бит.
[4] «Кояш», 1914 ел, 358 сан.

Габдулла Кариев иҗатына зур ихтирам белән карый. Аның искиткеч зур талантына соклана, аның белән горурлана. Ләкин тәнкыйтьченең гадәте шундый, зур талантлар иҗатына ул аеруча таләпчән, аларның кечкенә генә гаепләрен дә игътибардан читтә калдыра алмый. Андыйлар турында сүз барганда ул аларны рус һәм башка тугандаш милләтләрнең атаклы сәхнә осталары белән чагыштырып карый. Мәсәлән, әзербәйҗан язучысы Нариман Наримановның «Надир шаһ» исемле тарихи фаҗигасы куелу уңае белән язылган мәкаләдә шундый юллар бар: «Ул (Г. Кариев — Р. М.) гайрәтле юлбасар Надирны да, яхшы йөрәкле шаһны да гаять дөрес вә туры итеп әҗра итә алды. Бу рольне иҗат иткән Кавказның мәшһүр артисты Араблинский да Кариевтан аз артык булыр, шөбһә юк, Кариевның амплуасы киңәя вә зурая бара»[1].

Г. Кәрам өчен театр һәм сәхнә иң беренче чиратта иҗат мәйданы. Тәнкыйтьче артистлардан барыннан да элек бер нәрсәне — сәхнәдә иҗатчы булуларын таләп итә. Ф. Әмирханның «Яшьләр» пьесасында Газиз ролен башкаручы Мортазин-Иманскийның уены Г. Кәрамда зур тәэсир калдыра, ул бары бер эпизод белән генә килешми: «Актык пәрдәдә Зәйнәпнең ишектән елап чыгып барганын күреп тә, аңар бер сүз дәшмәде, аны юатмады. Пьесада мондый кимчелекләрне артистлар үзләре тутырырга тиеш(?!)»[2] — дип саный ул. Тәнкыйтьченең бу таләбе бер карашка бәхәсле дә кебек, ләкин безнең өчен шушы конкрет очрактан бигрәк, Кәрамның иҗат эшенә мөнәсәбәтен ачыклау әһәмиятлерәк.

Театр тәнкыйтен бөтен җаваплылыгы белән үз җилкәсенә салган тәнкыйтьче мәкаләләрендә еш кына сәхнә әсәрләренең жанрлары, аларның специфик үзенчәлекләре һәм тарихы кебек мәсьәләләрне куеп, аларны заманына күрә гыйльми югарылыкта чишәргә омтыла. Мәсәлән, французчадан тәрҗемә ителгән «Хөкемдә хаталык» мелодрамасы куелу уңае белән язылган мәкаләдә Кәрам мелодраманың күп кенә үзенчәлекләренә туктала, бу жанрның үткәнен, бүгенгесен нигезле рәвештә күрсәтеп бирә[3]. Мелодраманың кайчандыр Европа сәхнәләрендә бик популяр жанр булып та, хәзер икенче планга калуын автор заман таләпләреннән чыгып аңлата: «Мелодрамада «сәнагыйлык», «театрлык» бик күренеп тора. Хәзерге нечкәргән мәдәни халыклар театрда җинаять һәм «интрига»лар белән генә канәгать итмиләр, бәлки рухларына азык булырлык вә авыр тормышыбызның серләренә җавап бирерлек яңа мәсьәләләр эзлиләр». Шул рәвешчә, Кәрам төрле жанрлардагы сәхнә әсәрләренең популярлыгын аларның тормыш куйган таләпләргә ни дәрәҗәдә җавап бирүләреннән чыгып аңлата. Тәнкыйтьче театрның ул дәвердә яшәгән халыкка «фикри вә тәрбияви тәэсире гадәттән тыш зур»[4] булуын тирәнтен аңлый һәм театр тамашачыга аның үз тормышын, үз мөхитен күрсәтергә тиеш, дип саный. Шул рәвешчә, Габдрахман Кәрам сәнгатьнең бурычларын аңлауда Н. Г. Чернышевский югарылыгына күтәрелде дип әйтүдә аз гына да арттыру булмас кебек.

Татар театры Беренче рус революциясе елларында туды һәм, авыр сынаулар үтеп, зур көрәш мәйданында чыныгып үсте. Шундый шартларда прогрессив идеяләр белән сугарылган алдынгы интеллигенция вәкилләре рус һәм Көнбатыш Европа драматургларының иҗатын өйрәнү, аларның иң яхшы әсәрләрен тәрҗемә итүнең әһәмиятен нигезләп чыктылар. Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар кебек үк, Г. Кәрам да татар укучысын, татар тамашачысын рус һәм Европа классиклары белән якыннан таныштыру өчен көчен кызганмый эшли. «Театрыбыз милли уеннар белән генә дәвам итә алмаячак. Бу мөмкин дә түгел»[5],— ди ул.

Рус һәм дөнья әдәбияты белән яхшы таныш булган Г. Кәрам беренче мәкаләләрендә үк сәхнә әсәрләрен тәрҗемә итү мәсьәләсен күтәрә. Мәкаләләрнең берсендә ул Гогольнең «Ревизор», «Борынгы алпавытлар», «Өйләнү» кебек әсәрләренең театр өчен генә түгел, гомумән, әдәбиятыбыз өчен дә зур әһәмиятен билгеләп, тәрҗемәчеләргә: «Рус мөхәррирләренең мөһим вә гүзәл әсәрләрене тәрҗемә итмәк илә әдәбиятыбызны зиннәтләндерсәләр иде»[6],— дигән теләк белдерә. Татар сәхнәсендә

---

[1] «Аң», 1916 ел, 24 сан, 390 бит.
[2] «Кояш», 1914 ел, 329 сан.
[3] «Кояш», 1914 ел, 358 сан.
[4] «Кояш», 1914 ел, 358 сан.
[5] «Кояш», 1914 ел, 358 сан.
[6] «Йолдыз», 1906 ел, 12 сан.

мәшһүр немец язучысы Шиллерның «Мәкер вә мәхәббәт» трагедиясе куелганнан соң ул: «Сәхнәбездә мондый классик әсәрләрне күрү киләчәктә милли театрыбыз өчен яхшы өметләр баглатадыр. Иншалла, моннан соң Островский, Чехов вә Андреевларны да үз сәхнәбездә күреп зиннәткә ия булырбыз»,[1] — дип яза.

Шул рәвешчә, Кәрам алдынгы татар революцион-демократик фикер ияләре белән беррәттән торып, татар театрын үстерүдә рус реалистик сәнгате тәҗрибәсен файдаланырга, репертуарга Островский, Гоголь, Горький әсәрләрен күбрәк кертергә чакыра.

Г. Кәрам үзе дә җиң сызганып шушы зур һәм җаваплы эшкә, рус һәм көнбатыш әдәбияты классиклары әсәрләрен тәрҗемә итүгә керешә. Мәсәлән, 1916 елда ук ул театрга «Мещаннар» драмасының тәрҗемәсен тәкъдим итә. Бөек Октябрь революциясен «Сәйяр» труппасы М. Горькийның Кәрам тәрҗемәсендәге шушы әсәре белән каршылый.

Г. Кәрам 1920 елда В. Шекспирның «Отелло»сын, тагын ике елдан «Король Лир»ны тәрҗемә итә. Шулай итеп, бөек инглиз драматургы әсәрләрен беренче булып татар тамашачысына тәкъдим итүче дә Г. Кәрам була. «Отелло» татар театры сәхнәсендә 1921 елда куела. Татарстан җәмәгатьчелеге бу вакыйганы культура тормышындагы зур яңалык буларак билгеләп үтә. «Татарстан хәбәрләре» (1921 ел, 85 сан) һәм рус телендә Казанда чыга торган «Известия» (1921 ел, 88 сан) газеталарында басылган мәкаләләр шул хакта сөйли.

Октябрь революциясенә кадәр үк инде Г. Кәрам Шекспир әсәрләренең татарчага тәрҗемәләре булмауны зур кимчелек санап: «Без бу бөек драматургның әсәрләрен русчадан вә төрекчәдән укып кына белә алабыз. Татарчада бу көнгә кадәр бөек даһи әсәрләренең тәрҗемәсе күренгәне юк, әмма халкыбызны ул әйбәт вә кыйммәтле әдәбият илә таныштырa башларга бик вакыт»,[2] — дип, мәсьәләне көн тәртибенә куйган иде. Тәнкыйтьчене Шекспир әсәрләренең сәнгатьчә эшләнеше, стиленең нәфислеге һәм шул ук вакытта конфликтларының гаять дәрәҗәдә тирән һәм катлаулы булуы сокландыра.

Габдрахман Кәрамның татар театрын үстерүгә керткән хезмәте зур һәм күпьяклы. 1921 елда ул рус сәнгать белгече, публицист Керженцевның «Иҗади театр» исемле хезмәтен тәрҗемә итә. Бу үзешчән театрлар өчен татар телендә чыгарылган беренче кулланма була.

Г. Кәрамның иҗат колачы театр мәсьәләләре белән генә чикләнми. Әдәбиятның башка тармаклары буенча да вакытлы матбугат битләрендә кызыклы һәм төпле мәкаләләр белән еш чыгыш ясый. Мәсәлән, аның Лермонтов һәм Тарас Шевченконың 100 еллык бәйрәмнәренә багышланып язылган һәм 1914 елда «Аң» журналында басылган мәкаләләре аеруча әһәмиятле. Кәрам бу бөек шагыйрьләрнең халыкчанлыгын, аларның талант үзенчәлекләрен күрсәтә. «Шевченко халык шагыйре иде. Аның «Кобзарь»ен белмәгән вә аны күңеленнән ятламаган бер малорусны тасвир итү мөмкин түгел, аерым бер дәрт илә тыңлый, аерым бер ләззәт белән укый аны һәрбер украинлы. Шулай булмый мөмкин дә түгел, чөнки аның шигырьләре малорус милләтенең кайгы вә шатлыкларының тәрҗеманы, яралы йөрәкләрнең мәрһәмәдер»[3]. Шул рәвешчә, Г. Ибраһимов артыннан Кәрам да бу олуг шагыйрьнең иҗатын татар укучысына җиткерүдә мөһим эш башкара.

Шевченко һәм Лермонтов юбилейлары уңае белән басылган мәкаләләр очраклы рәвештә һәм көн кадагына сугу өчен генә язылмыйлар. Алар Кәрамның яңа революцион күтәрелеш елларында инде формалашып җиткән идея-эстетик карашларының ачык чагылышы иде. Тәнкыйтьченең Тукай иҗаты турында уйланулары нәтиҗәсендә туган мәкаләләре бу фикерне тагын да бер кат дәлилли. Лермонтов һәм Шевшенко иҗатларындагы кебек үк, Тукай поэзиясенең дә зурлыгын Кәрам аның халыкчанлыгында күрде. «Ул халык эченнән чыкканга, аның рухын белә, халыкның эченнән сизеп тә, теле белән әйтә алмаган хисләрне шул ук халыкның үз теле белән матур итеп, табигый итеп әйтеп бирә ала». Менә шуңа күрә дә «Тукаев чын мәгъ-

---

[1] «Йолдыз», 1913 ел, 965 сан.
[2] «Аң» журналы, 1916 ел, 8 сан.
[3] «Аң», 1914 ел, 5 сан.

нәсе белән шагыйрь һәм дә халык шагыйре булып калачактыр»[1],— дип язды тәнкыйтьче.

Тукай иҗатына мөнәсәбәттә Кәрам Октябрь революциясенә кадәрге тәнкыйтьтә гадәткә керә башлаган карашлар белән генә дә чикләнмәде. Ул, беренчеләрдән булып, Тукай сатирасының тормыштагы ролен күрсәтеп чыгучы тәнкыйтьче була. «Нәкъ ике ел инде татар тормышының, аның матбугат һәм әдәбиятының ямьсез вә килешсез якларын матур вә шуның илә бергә үзәккә үтәрлек ачы булган үткен гыйбарәләр илә күрсәтүче юк», — дип юксынды ул Тукайны[2].

Ниһаять, Г. Кәрамның күпкырлы әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлегендә аның В. И. Ленин әсәрләрен тәрҗемә итүе мөһим урын тота. Бу гаять дәрәҗәдә җаваплы эшкә Кәрам бөтен күңелен һәм осталыгын биреп керешә. Нәтиҗәдә, аның тәрҗемәсендә В. И. Ленинның «Коммунистлар интернационалы» (1926 ел), «Нәрсә эшләргә» (1930 ел) кебек хезмәтләре беренче тапкыр татар укучысына җиткерелә.

Г. Кәрам иҗатын үзе яшәгән, үзе иҗат иткән чордан аерып карау мөмкин түгел. Ул Беренче рус революциясе елларында мәйданга чыккан, иҗтимагый һәм әдәби-эстетик фикеребез формалашуга зур өлеш керткән сәнгать эшлеклеләреннән берсе булды. Аның эшчәнлеге — әдәби тәнкыйтебез тарихында онытылмас бер сәхифә.

Биредә татар театрының беренче профессиональ тәнкыйтьчесе һәм тәҗрибәле тәрҗемәченең тормыш һәм иҗат юлыннан кайбер фрагментлар күрсәтелде. Мәкаләнең башында Г. Кәрам кем һәм бу исемнең татарча беренче рәсми спектакль афишасында Г. Камал белән янәшә килүе очраклы хәлме, түгелме? дигән сораулар куелган иде. Инде моңа өлешчә җавап бирелде кебек. Республикабыз җәмәгатьчелеге театрыбызның җитмеш еллык бәйрәмен билгеләп үткән көннәрдә Габдрахман Кәрам исеме дә Галиәсгар Камал һәм Габдулла Кариев кебек «беренчеләр» белән янәшә куелырга хаклы.

---

[1] «Аң», 1914 ел, 7 сан.
[2] «Ялт-йолт» журналы, 1915 ел, 88 сан.

**Владимир Иванов,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# ГАСЫРЛАР АША КАРАП

*Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары.*

*Г. Тукай.*

Катлаулы һәм озын тарихлы шәһри Казан электән үк атаклы әдип һәм шагыйрьләр игътибарын җәлеп иткән. Пушкин, Толстой, Герцен шәһәребез турында онытылмас юллар язып калдырганнар. Казан тарихы белән К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил горурланган. Аны А. М. Горький һәм В. В. Маяковский якын күргән.

Казан тарихына бәйле бик күп сораулар арасында иң беренчесе, әлбәттә, шәһәрнең кайчан салынганлыгы һәм күпмедән бирле яшәве мәсьәләсе. Шәһәрнең кайчаннан яши башлавы хакында, чыганакның ниндиенә таянуга карап, төрле нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Бу хәл аның тарихы белән фәнни яктан кызыксынуны арттыра.

Чыннан да, төрле тикшеренүчеләр тарафыннан күрсәтелгән даталар бер-береннән еллар белән генә түгел, ә кайчакта гасырлар белән аерыла. Берәүләр шәһәр гомеренең башын XII йөздән, икенчеләр — XIII, өченчеләр исә XIV гасырдан эзлиләр. Хәтердә ки, мондый буталчыклык безгә, булачак тарихчыларга, студентлык елларыннан ук билгеле иде. Һәм без, Казан университетының СССР тарихын өйрәнү буенча фәнни түгәрәге членнары, бу мәсьәлә белән доцент Ш. Ф. Мөхәммәдьяров җитәкчелегендә илленче елларда ук шөгыльләнә башлаган идек. Шәһәрнең феодализм чоры тарихы буенча язма чыганакларны өйрәнүгә шул чакта ук керешелгән иде. Еллар үткән саен бу проблема белән кызыксыну арта барды. Һәм соңгы вакытта, башка иптәшләр белән берлектә, мин шушы мәсьәләгә яңадан әйләнеп кайттым.

Казан тарихының башлангыч чорын фәнни тикшерү — катлаулы да һәм шактый четерекле дә мәсьәлә. Эш шунда ки, соңгы вакытларга кадәр барлык тәр чыганаклар бер-берсенә бәйләнештә өйрәнелмәгән, аларны комплексны рәвештә анализлаган хезмәтләр юк иде. Тик соңгы елларда гына Казан галимнәре шәһәр тарихына караган кызыклы тикшеренүләр үткәрә башладылар. Һәм күп кенә фәнни чыганаклардан файдалану мәсьәләсен яңача хәл итәргә, хосусан алганда, «Казан тарихы» («Казанский летописец») кебек күп планлы язма чыганакны анализлауга яңача килергә мөмкинлек туды.

Казан шәһәренә нигез салыну турында әлеге елъязмада болай диелә: «Кама елгасы буенда Брягов атлы борынгы шәһәр булган, әнә шуннан Саин атлы болгар патшасы килгән. Һәм, төбәкләр буенча йөреп, 6685 (1177 — В. И.) елда Волга буенда, рус ягының иң кырыенда, Кама елгасының бирге ягында, бер башы белән Болгар җиренә, икенче башы белән Вяткага һәм Пермьга тоташкан җирдә үзенә урын

эзләп тапкан... ... һәм Брягов урынына Казан шуннан баш шәһәр булып киткән... һәм аның патшасы Саиннан Казанның башы исәпләнә»[1].

«Казан тарихы» билгесез автор тарафыннан 1562—1564 елларда язылган. К. Маркс бу чыганакны игътибарга лаек дип санаган. Ул, чыннан да, XVI йөзнең иң киң таралган тарихи язмаларыннан берсе. Бүгенге көндә фәндә аның 250 ләп нөсхәсе билгеле. Алар Мәскәү, Ленинград, Казан китапханәләрендә һәм архивларында саклана[2].

«Казан тарихы»ның төрле нөсхәләрен өйрәнгәндә без алар арасыннан элгәререк күчерелгәннәрен аерып алу, күчермәләрдәге мәгънә үзгәрешләрен тикшерү һәм барлау максатын куйдык. Эш шунда ки, «Казан тарихы»нда, югарыда китерелгән датадан тыш, шәһәр салынуга нисбәтле башка төрле даталарга да ишарә ителә, мәсәлән, нөсхәләрнең берсендә шәһәр XIII йөздә төзелгән диелә.

Казанның кайчан барлыкка килүе мәсьәләсендә чыганаклар белән расланмый торган өченче бер версиягә — шәһәр, имеш, Хәсән-бәк тарафыннан XIV йөздә салынган дигән фикергә аерым тукталып торуның кирәге юктыр дип уйлыйм. Казан һәм Хәсән исемнәрендәге охшаш яңгырашка нигезләнгән бу фикер фәнни тәнкыйтьне күтәрми.

Казанның салыну елына карата төрле версияләрнең йөрүе күп очракта чыганакларны анализлаудагы берьяклылык белән дә аңлатыла. Тикшеренүчеләр еш кына бер төрле чыганакларның әһәмиятен күпертеп җибәрәләр, икенчеләренә исә тиешенчә игътибар бирмиләр. Бу хәл, әлбәттә, хакыйкатьне табуга ярдәм итми. Мәгълүм ки, чыганакка марксистик-ленинчыл методология нигезендә фәнни тәнкыйть күзлегеннән караунның бурычы — теге яки бу версиянең фактта тарихи яктан ни дәрәҗәдә нигезләнгән һәм дөрес булуын ачыклау дигән сүз ул. Димәк, без шәһәрнең кайчан төзелүе турында «Казан тарихы» биргән мәгълүматның башка төр чыганаклар һәм тарих фактлары белән ни дәрәҗәдә ярашуын ачыкларга тиеш булып чыгабыз. Һәм нәкъ шундый тикшеренүләр, «Казан тарихы»н башка тарихи язмалар белән янәшә куеп эзлекле өйрәнү Казан шәһәренең нигезе XII йөзнең икенче яртысында, төгәлрәк әйткәндә, 1177 елда салынган дигән фикерне раслый.

Казан исеменең XII йөз рус елъязмаларында телгә алынмавы да бу нәтиҗәне юкка чыгара алмый. Ни өчен алай? А. Н. Носонов, Д. С. Лихачев, М. Д. Приселько, Б. А. Рыбаков, А. Г. Кузьмин кебек күренекле галимнәр фикеренчә, елъязмаларда рус җирләреннән читтә барган вакыйгалар хакында мәгълүмат бирү күздә тотылмаган, елъязмачылар үз алларына андый максатны куймаганнар да. Казан исә Идел буе Болгарының бер шәһәр-кальгасе буларак барлыкка килә. Шуның өстәвенә, XIII—XIV гасырларда елъязма алып бару эшенең торгынлык чоры кичерүен дә онытмаска кирәк. Д. С. Лихачев әйтүенчә, «XIII йөзнең икенче яртысы, XIV йөзнең беренче яртысына караган елъязма төпләмәләре күпчелек өлешендә беркатлы иярү, компиляция» булудан узмыйлар[3]. XIII—XIV гасыр елъязмаларына характеристика биреп, Д. С. Лихачев болай дип яза: «Чынлап та, елъязмаларда билгеле бер өлкә чикләреннән чыгарга омтылыш сизелми диярлек, елъязма материалы әлегә гаять тә ярлы, язмаларның күләме бик кечкенә, әмма, шуңа да карамастан, бу зәгыйфь омтылышларда елъязмалар язу эшенең дәвамы булган бөек князьлек чоры елъязмасының киләчәге ята иде»[4].

Соңгырак заман чыганагы булуына да карамастан, «Казан тарихы»нда шәһәргә нигез салу вакыйгасының сурәтләнүе үзе үк инде гаять зур әһәмияткә ия. Әмма «Казан тарихы» безнең өчен тагын да элгәрерәк чорның эзләрен саклавы, бигрәк тә, шәһәрнең ничек барлыкка килүе турында болгар-татарның үзендә яшәгән концепцияне гәүдәләндерүе белән аерата кыйммәтле. Рус елъязмалары (мәсәлән, Никонов елъязмасы), татар язма истәлекләре, болгар-татар фольклоры әсәрләреннән аңлашылганча, XV—XVI йөзләр өчен бу концепция шул заман факты, мәгълүм һәм гадәти

---

[1] Рус елъязмаларының тулы басмасы. 19 том. Күп галимнәрнең фикеренчә, «Саин» — болгар патшасының үз исеме түгел, ә аңа беркетелгән дәрәҗә исеме, титулатур эпитет, ягъни кушамат. Саин — данлыклы, өстен, асыл зат дигән сүз.

[2] Безнең шәһәрдәге нөсхә Казан дәүләт университеты фәнни китапханәсенең сирәк кулъязмалар бүлегендә саклана. Саклау берәмлеге — 4521.

[3] Д. С. Лихачев. Рус елъязмалары һәм аларның культура-тарихи әһәмияте. 280 бит.

[4] Шунда ук, 288 бит.

нәрсә булган, анда шул чорның тарихи-иҗтимагый аңы чагылган. Әмма тарихи-иҗтимагый аң үзе дә катып калган нәрсә түгел. XVI йөз ахырына таба һәм XVII йөздә, политик, идеологик, социаль-экономик шартлар үзгәрә бару белән, болгар-татар традициясе дә Казан тарихын күзаллауда Алтын Урда традицияләре ягына авышу юнәлешендә билгеле бер үзгәреш кичергән. «Казан тарихы»ның соңгырак нөсхәләрендә шушы факт чагылып калуы бик аңлаешлы. Аның XVI гасыр ахыры һәм XVII гасырдагы күчермәләрендә болгар традициясе арткы планга күчә, Алтын Урда тематикасы көчәя, кайсыбер нөсхәләрдә шәһәрнең салыну датасы инде күрсәтелми башлый, Болгардагы һәм Алтын Урдадагы Саиннар бутап йөртелә[1]. Казан дәүләт университеты китапханәсендә саклана торган нөсхәдә нәкъ әнә шундый тенденция чагыла.

Ләкин, «Казан тарихы»ның соңгырак чор нөсхәләре төрле үзгәрешләр кичерүгә, күчерүчеләрнең тенденциоз булу ихтималына һ. б. сәбәпләргә дә карамастан, болгар традициясе анда бөтенләй юкка чыкмый. Язма истәлекнең кыйммәтле сыйфаты да шунда: еллар узу белән ул төрле үзгәрешләргә дучар ителсә дә, андагы фактлар эзсез югалмый. Казан шәһәренә нинди шартларда нигез салыну хакында «Казан тарихы»ның барлык нөсхәләрендә дә махсус бүлек бар һәм язылу рәвеше, стиле, фактологик материалы буенча барлык күчермәләрдә дә ул бердәй диярлек. Мәгълүм булуынча, академик М. Н. Тихомиров та болгар-татар нәселдәшлеген, бердәмлеген тикшерүдә «Казан тарихы»ның беренче өлеше (68 бүлеккә кадәр) зур әһәмияткә ия дип саный.

Бу мәсьәләдә татар легендалары һәм риваятьләренең дә мәгълүм кыйммәте бар. Мәсәлән, «Дастан Аксак-Тимер»дә, Җиһангир Болгарга басып кереп, Болгар патшасы Габдулланы үтергәч, патшаның Алим-бәк һәм Алтын-бәк исемле уллары Кама-Чулман аръягына киткәннәр, Алтын-бәк анда Казан каласын салган, диелә. Бу «Казан тарихы»нда хәбәр ителгән мәгълүматларга да беркадәр туры килә. Аннары истәлекләрдә Габдулла хан нәселенең Казанда 104 ел (Малов нөсхәсендә — 150 ел) патшалык итүе, яңа Казанга күчкәч, мөселман ханнары хакимлегенең тагын 158 ел (Иван Грозный шәһәрне алганчы) дәвам итүе хакында сөйләнә.

Бу мәгълүматлардан аңлашылганча, Казан фактта болгар-татар патша һәм ханнары династияләре тарафыннан идарә ителә торган политик үзәк буларак аерылып чыккан. Ә бу исә югарыда әйтелгән вакыйгаларга кадәр үк шәһәр инде яшәгән дигән фикергә китерә.

«Казан тарихы» Брягов дигән болгар шәһәреннән Саин патша килүен хәбәр итә. Татар язма истәлекләренең иң элгәрге нөсхәләрендә дә Казанга нигез салыну болгар патшасы (Алтын-бәк) исеменә бәйле рәвештә карала. «Казан тарихы»ндагы тагын бер-ике детальгә игътибар итик: «Кама буенда Брягов дип йөртелгән элекке шәһәр бар иде... аны башлап Владимир князе Андрей Юрьевич алган... һәм Казан Брягов урынына баш шәһәр булган. һәм тиздән яңа урда...» Елъязмада, шулай итеп, Казанның Владимир-Суздаль князе Андрей Юрьевичның Бряговны тар-мар итүеннән соң, әмма монгол яулары килгәнче салынганлыгы күрсәтелә. Бу өзек шәһәрне Алтын Урда ханнары салган дигән фикергә капма-каршы килә. «Казан тарихы»ның төп нөсхәсен тикшерүдән күренгәнчә, анда тасвирланган вакыйгалар, һичшиксез, монголларга кадәр күп элгәре булып үткән.

Тарихи чыганакларны өйрәнүгә бәйләнешле бу археографик мәсьәләләр Г. Ибраһимов исемендәге Казан тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советының киңәйтелгән утырышында җентекләп тикшерелде. Мәскәүдә СССР Фәннәр академиясе феодализм тарихы секторының академик Л. В. Черепнин җитәкчелегендә үткән утырышында да ул хакта җитди сүз барды. Докладчыларның берсе сыйфатында утырышта бу юлларның авторына да чыгыш ясарга туры килде. Докладта без мәсьәләне өйрәнү тарихына һәм «Казан тарихы» нөсхәләрен чагыштырмача анализлауга төп игътибарны юнәлдерергә тырыштык. Фикер алышуда катнашкан тарих фәннәре докторлары А. А. Зимин, С. М. Каштанов, доцентлар Ш. Ф. Мөхәммәдьяров, М. Р. Булатов 1177 ел датасы белән тулысынча килешкәнлекләрен белдерделәр.

---

[1] Идел-Болгар традициясе йогынтысында булса кирәк, «Саин» эпитеты Бату-хан һәм аның улы Сартакка да кушылып йөртелгән. (— Автор искәрмәсе.)

Шулай итеп, елъязмаларның иң элгәрге нөсхәләрендә Казан шәһәре төзелү хакында беренче тапкыр бирелгән мәгълүматка таянып һәм төрле чыганакларны комплекслы анализлау нигезендә, Казан шәһәре 1177 елда салынган дип әйтә алабыз. Мондый нәтиҗә шәһәрләрнең барлыкка килү датасын билгеләүдә совет фәнендә кабул ителгән теоретик-методологик принциплар белән тулысынча яраша. Бу дата археология казанышлары, бигрәк тә профессор А. Х. Халиков һәм аның шәкертләре алып барган тикшеренүләр белән дә раслана. Шул рәвешчә, Казан үзенең 800 еллык юбилеена килә.

**Альфред Халиков,**

тарих фәннәре докторы, профессор

## КАЗАН КАЙЧАН һӘМ КАЙДАН БАШЛАНЫП КИТКӘН

Казан шәһәренә 1177 елда нигез салынган дигән фикерне моңа кадәр дә күп тарихчылар яклап чыга. Мәсәлән, Дм. Зиновьев, А. Смирнов, А. Вечтомов, М. Пинегин, Н. Полевой һ. б. галимнәр, «Казан тарихы»на таянып, нәкъ шул датаны өстен күрәләр. Елъязманы немец теленә тәрҗемә итеп, 1969 елда Вена һәм Кельн шәһәрләрендә бастырып чыгарган тарихчы Франк Кемпфер да шундый ук фикердә тора. Әмма әлеге чыганакның фәнни кыйммәтенә шик белдереп, аны тенденциозлыкта гаепләп, 1177 ел датасын тарихи анахронизм дип санаучы тикшеренүчеләр дә юк түгел [1].

1177 ел датасының дөреслеккә туры килүен исбатлау өчен безгә төрле тарихи истәлекләр һәм елъязмалардагы мәгълүматларны чагыштырып карарга, ул ерак чорларның конкрет-тарихи шартларын тикшерергә туры киләчәк.

В. В. Иванов әйтеп киткәнчә, «Казан тарихы»нда шәһәр монгол яуларыннан күп элгәрәк салынган дип күрсәтелә. «Казан тарихы»ның беренче редакциясендә Казанның салынуы болгар патшасы Саин исеме белән бәйле рәвештә карала. Әлеге патша, диелә язма истәлектә, бу җиргә Кама буендагы Брягов (яисә Бряхимов, дөресе — Ибраһим — А. Х.) шәһәреннән килә һәм болгар җирләренең читендә, Идел буенда, яңа шәһәр салу өчен менә дигән урын эзләп таба. Шәһәргә нигез салучылар күп санлы еланнар белән сугышып, аларны куып таратып һәм үтереп бетерәләр. Шул урында үзләре төзегән шәһәргә Казан дип исем кушалар. Язмада әйтелгәнчә, рус князьләре яңа шәһәр кору эшенә комачаулый алмыйлар.

Мәгълүм булуынча, Идел буе Болгар дәүләте белән Төньяк-көнчыгыш рус князьлекләре арасындагы экономик һәм культура бәйләнешләре X—XI гасырлардан ук ныгый башлый. Әмма урта гасырлардагы феодаль дәүләтләр арасындагы мөнәсәбәтләргә хас булганча, бу бәйләнешләр еш кына хәрби бәрелешләр белән аралашып бара. Идел һәм аның эреле-ваклы кушылдыклары буенда яңа җирләр үзләштерү көчәйгән һәм чикләр бер-берсенә якыная барган саен, әлеге каршылыклар да кискенрәк төс алган. Рус елъязмалары һәм «Казан тарихы» хәбәр иткәнчә, Владимир-Суздаль җирләренең бөек князе Андрей Боголюбский 1164 елда болгарларның «данлыклы Бряхимов шәһәрен ала һәм аларның җирен тар-мар китерә». 1174 елда (башка мәгълүматлар буенча 1175 елда) Болгар иленең чикләрен киңәйтү политикасының иң

---

[1] Бу хакта кара: В. В. Иванов, И. М. Ионенко, А. Х. Халиков. Казан кайчан барлыкка килгән. «Татарстан коммунисты» журналы, 1974 ел, 10 сан; В. В. Иванов, А. Х. Халиков. Казанның кайчан барлыкка килүе турында. «История СССР» журналы, 1975 ел, 6 сан; А. Х. Халиков. Казанның кайчан һәм кайда салына башлавы, атамасы хакында. «Археология и этнография Татарии». 2 чыгарылыш, Казан, 1976 ел.

зур дошманы Андрей Боголюбский астыртын рәвештә үтерелә. Бу заговорны князьнең болгар нәселеннән булган һәм иренең болгар җирләренә яу белән баруын кичерә алмаган хатыны оештыра. Шул вакыйгадан соң ук Владимир-Суздаль князьлегендә эчке чуалышлар, ызгыш-талашлар куба. Даулашлар өч елга сузыла һәм 1177 елда аеруча көчәя: князь Всеволод Ростов шәһәрендә башланган күтәрелешне бастырып, күп кешеләрне кыра, ә Рязань князе Глеб Владимир-Суздаль җирләренә басып керә, кыпчаклар белән бергә Владимир шәһәренә кадәр килеп җитә. Шушы шартларда яшәгән рус князьләрендә болгарлар кайгысы булмый, әлбәттә. Һәм алар болгар иленең яңа хәрби кала төзүенә комачаулык итмиләр. Монда төрле чыганаклардан алынган мәгълүматларның туры килүен күрсәтеп китәргә кирәк: рус елъязмаларында әйтелгәнчә, рус җирләрендә гауга өч ел (1175—1177) дәвам итә. «Казан тарихы» да «андагы җирләрнең өч ел буе харап ителүе» турында сөйли.

Шул рәвешчә, Владимир князьлегендә фетнә кузгатуда болгар патшасының да кулы уйнаган дияргә мөмкин. Казан шәһәренең нигезе салыну белән үк патша бу яңа калага Кама аръягыннан болгар бәкләрен һәм аларның кешеләрен, чирмешләрне (мариларның борынгы бабаларын), удмуртларны һәм чукынудан баш тартып, Иделнең югары агымындагы Ростов шәһәреннән качып килгән кара халыкны күчереп утырта. Ары таба «Казан тарихы»нда Владимир князе Андрей Боголюбский тарафыннан җимерелгән Брягов шәһәре урынына Казан каласының башкала булып калуы хакында сүз бара.

Бу мәгълүматларның күбесен башка тарихи чыганаклар: төрле рус елъязмалары, болгар-татар истәлекләре, тарихи легендалары һәм риваятьләре, тел-фольклор материаллары да раслый. Аларны бер-берсе белән чагыштырып анализлау XII гасырның икенче яртысы Казанны төзү өчен иң уңайлы чор булуын күрсәтә.

Казан Идел буе Болгарының төньяк-көнбатыш чиген саклый торган крепость — кальгә итеп төзелә. Бу хәл тарихи яктан да аклана. Көнбатыш илләре белән шәрык дөньясының иң мөһим сәүдә юлларыннан берсе Иделгә хуҗа булу өчен болгар һәм борынгы рус князьләре арасында көрәш XI йөздә үк башлана. Идел һәм Ока елгаларында таланган сәүдәгәрләренең үчен алып, 1088 елда болгарлар «Муромны бастылар һәм таладылар, авылларны яндырдылар» диелә рус елъязмасында. 1107 елда болгар гаскәре Суздаль шәһәренә килеп җитә, ә 1120 елда князь Юрий Долгорукий «Болгарга килә, күп кешеләрне әсир итә һәм аларның полкын җиңә». 1152 елда болгарлар Идел буенча Ярославльгә кадәр күтәреләләр һәм шәһәрне камап торалар. Алда әйтелгәнчә, рус һәм болгар феодаллары арасында Идел өчен көрәш Владимир-Суздаль князе Андрей Боголюбский яшәгән чорда аеруча көчәя. Идел юлын үз кулына алуны ул тышкы политикасының иң төп бурычларыннан берсе итеп саный.

Болгарларның Иделдәге иң әһәмиятле терәк пунктларыннан берсе Ибраһим («Казан тарихы»нда — Бряхимов) шәһәре була. Кама тамагына урнашкан бу кала Каманы гына түгел, Иделнең түбәнге агымын да саклый һәм Болгар иленең үзәгенә юлны бикләп тора. Андрей Боголюбский яу белән килеп шәһәрне җимергәннән соң болгар патшасы алдына яңа кала салу бурычы килеп баса. Бу елларда Болгарның төньяк-көнбатыш чикләре мари урманнарына, ягъни хәзерге Казан суы бассейнына кадәр килеп җитә. Шуңа күрә илнең төньяк-көнбатыш чикләрен саклап торырга тиешле яңа кала өчен иң отышлы урын шушы елга тамагы булып чыга.

Төрле кулъязмалардан алынган һәм Казан салыну чорында булып үткән вакыйгалар хакында сөйли торган хәбәрләрнең «Казан тарихы» мәгълүматлары белән туры килүе, бу язмаларда күрсәтелгән барлык даталарның бер-берсенә бик якын торуы 1177 елны Казан шәһәренә нигез салыну датасы дип билгеләргә мөмкинлек бирә.

«Казан тарихы»ның шәһәрне төзи башлар алдыннан еланнар белән сугышу турында язган өлеше (татарларның тарихи легенда һәм риваятьләрендә дә нәкъ шул хакта сөйләнелә) Казан салынган чорны болгар-татар традициясенә китереп бәйли һәм шәһәрнең чик буе крепосте төсендә салынуына өстәмә дәлил булып тора. Монда шунысы әһәмиятле, андый легендалар монгол яуларына кадәрге Идел буе болгарының Биләр, Җүкәтау кебек иң эре шәһәрләре салыну белән бәйләнештә генә барлыкка килгәннәр. Монгол һәм Алтын Урда традицияләрендә исә елан культы юк һәм аларның шәһәр тарихларында (мәсәлән, Сарай-Бату, Сарай-Берке шәһәрләре тарихы) еланнар белән көрәш телгә алынмый. Шул ук вакытта, археологик, этнографик һәм

фольклор материаллары күрсәтүенчә, Урта Идел һәм Түбән Кама буйларында елан культы һәм еланнар белән көрәш темасы монгол яуларына кадәр күп элек яшәп килгән.

Еланнар культы, шул исәптән ике башлы, канатлы аждаһа-елан культы болгарларда һәм аларның күршеләре венгрлар һәм башкортларда мәҗүсилек чорында нык үскән булган. Ибне Фадлан, мәсәлән, башкортларның бер каверме еланнарга табына, болгарлар да аларга хөрмәт белән карыйлар дип күрсәтә. Биләр шәһәрлегендә табылган һәм канатлы дракон сурәте төшерелгән мөһерләр дә шул хакта сөйли. Ә ике башлы аждаһа-елан белән көрәшүче җайдак турындагы сюжет болгарларга иран телле халыклардан кергән булса кирәк. Батыр җайдакның ике башлы елан — Аҗи-Дахака белән көрәшүе темасы нәкъ менә иран эпосы өчен хас күренеш.

Исеме үк күрсәтеп торганча, шәһәр Казан исемле елга буена урнашкан. «Казан тарихы»нда, А. М. Курбскийның «Тарих»ында, XVI—XVII йөз рус елъязмаларында һәм башка язма документларда (мәсәлән, XVII йөз башы теркәү кәгазьләрендә) Казан елгасы, кайбер телчеләр уйлаганча, «Казанга» түгел, ә Казан яки Казан-елга дип аталган. «Казан тарихы» бу хакта «шул елга исеменнән алынып, шәһәр дә Казан дип атала» дип яза. Торак урыннары күпчелек очракларда чыннан да елга исеме белән аталып йөртеләләр. Әйтик, Мәскәү шәһәре Мәскәү елгасына, Самар шәһәре Самара суына карап аталганнар. Ә Казан атамасына килсәк, әле хәзерге вакытка кадәр аның мәгънәсе тиешенчә ачылганы юк. Берәүләр, мәгълүм легендага нигезләп, аны кухня җиһазын белдерүче казан сүзенә бәйлиләр (мәсәлән, Н. П. Рычков, В. А. Никонов, Герберштейн шулай аңлаталар). Башкалар исә (К. Фукс, П. И. Загоскин, Мункачи, Г. В. Йосыпов, В. Егоров) болгар һәм Казан җирендә һичкайчан яшәмәгән Казан яки Газан хан исеменнән чыгып аңлатмакчы булалар. Өченчеләр (мәсәлән, Г. Саттаров) бу атама болгар яки аларның ата-бабаларының «каз» дип йөртелгән ниндидер мифик кабиләсе исеменнән барлыкка килгән дип саныйлар.

«Казан» атамасының килеп чыгуы хакындагы һәртөрле фикер һәм фараз итүләрне Ш. Мәрҗани санап үтә: 1) Казан дигән елга исеменнән; 2) казанны хәтерләтүче иңкү җиргә утырган булуыннан; 3) Казан яки Газан хан исеменнән; 4) елга суына төшеп югалган казаннан.

Фин галиме Х. Паасоненны исәпләмәгәндә, соңгы вакытка кадәр «Казан» сүзен этимологик яктан тирәнтен анализлауга омтылыш күренмәде шикелле. Х. Паасоненның исә табышы шунда ки, ул, «Казан» атамасы бик борынгы заманда туган һәм кухня җиһазын белдерүче казан төшенчәсе белән аның бернинди уртаклыгы юк, дигән фикер әйтә. Мәсәлән, ди ул, күрше халыклардан чуваш теленә бу атама «хузан» рәвешендә кергән (ә гади казанны алар хуран дип йөртәләр), удмурт телендә ул «кузон» дип, тау мариларында «озан», көнчыгыш мариларда «озан суаз» дип әйтелә.

Безнең фикеребезчә, «Казан» атамасы елгага һәм калага борынгы болгарлар тарафыннан бирелгән һәм ул болгарларда чик буе төшенчәсен аңлаткан. Казан сүзе ике кисәктән — «каз» тамырыннан һәм «ан» суффиксыннан тора. Бу суффикс борынгы төрки телләрендә урын, улыс, төбәк, территория дигән мәгънәне аңлата. Якут телендә (ул иң архаик төрки телләрнең берсе) «ан» сүзе хәзергәчә сакланып калган һәм ул башлангыч, беренче, керү урыны, тишек, капка дигән мәгънәләргә туры килә. Болгар телендә дә ул, күрәсең, шундыйрак мәгънәдә кулланылгандыр һәм «Каз-ан», «Каш-ан», «Шур-ан», «Бар-ан» дигән топонимнар ясауда катнашкандыр. Һәрхәлдә, «каз-ан» сүзенең борынгы заманда «чик башы», «чик буе», «өлкә, төбәкнең бер кырые» төшенчәсендә йөргән булуына шикләнмәскә мөмкин. «Каш-ан» топонимы да шул ук мәгънәне аңлаткан. Болгар шәһәрләре Кашан-I һәм Кашан-II Кама елгасының уң як ярына урнашкан булганнар һәм X—XI йөзләрдә Болгар дәүләтенең төньяк-көнбатыш чиге булып саналганнар. Болгар җирләре XII йөздә тагын да төньяккарак сузылгач, Казан елгасы дигән атама һәм аңа бәйле топонимнар: «каз-иле», «казан», «казанбаш» һ. б. барлыкка килә («Каз-иле» дигән атама монда чик буе өлкәсен аңлата).

Казан шәһәре монгол чорына кадәр, ягъни XII гасырда гына чик буе крепосте булып хезмәт иткән, ә XIII—XV гасырларда исә ул кнэзьлек, ханлык үзәгенә әверелә, дәүләтнең эчке территориясендә кала һәм хәрби кальгә буларак әһәмиятен югалта.

Шулай итеп, «Казан тарихы» шәһәргә нигез салу чорында аның кайда урнашканлыгын, «Болгар җиренең бер кырыенда утыруын» бик төгәл билгели. Чыннан да, XII йөздә Казан суы дәүләтнең төньяк-көнбатыш чиге булып торган, ә төньяк һәм көнбатышка таба марилар һәм Идел буендагы башка халыкларның җирләре сузылган, Идел буеннан рус җиренең чикләре якынлашып килгән.

Борынгы Казан каласының кайда урнашканлыгы хакында археологлар төрлечә фикер йөрткәннәр. Н. Ф. Калинин борынгы шәһәр үзәкләре элекке монастырь урнашкан Елантауда һәм Урта Кабан күле буендагы Архиерей дачасы урынында булуы ихтимал дип саный. Әмма бу тирәләрдә алып барылган археологик казынулар XVI—XVII йөзләргә кадәрге культура катламының булмавын күрсәтте.

Ныгытылган шәһәр өчен иң уңайлы урын Казан суы белән Иделнең сул як яры арасындагы киң үзәнлек өстендә торучы хәзерге Кремль калкулыгы булган. Моннан Идел һәм Казан елгасы буйларын ерактан күзәтеп торырга мөмкин.

Шушы калкулык борынында, бигрәк тә аның төньяк-көнчыгыш өлешендә, археологлар Казанның иң борынгы эзләрен таптылар. Алар 1926—1929 һәм 1953—1954 елларда алып барылган казынулар вакытында ук ачыла башлаган иде инде. 1974—1975 елларда анык бер максат белән үткәрелгән казу эшләре барышында исә ул эзләр аеруча ачык күренде. 1974 елда Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы һәм Министрлар Советы урнашкан бина каршындагы бакчаның 158 квадрат метры, ә 1975 елда Благовещенский собор белән Мәгариф һәм Сәламәтлек саклау министрлыклары арасында 80 квадрат метр мәйдан казып өйрәнелде. Боларның икесендә дә 1552 елга кадәрге культура катламын, беренче тапкыр буларак, өч өлешкә аерып өйрәнергә мөмкин булды. Бу өч катламның һәрберсе аерым дәвергә караган булса да, алар үзара эзлекле рәвештә бәйләнгән һәм бер-берсенең дәвамы булып тора.

Югаргы катлам — иң калыны (1974 елда казылган мәйданда 30—40 сантиметр, 1975 елдагысында 150 сантиметрга кадәр) — Казанның ханлык башкаласы булган чорында, XV йөзнең икенче яртысыннан 1552 елга — Казан алынганга кадәрге чорда тупланган. Бирегә күп санлы хуҗалык җиһазлары калдыклары, чүп чокырлары, шулай ук һөнәрчеләрнең тирән базлы өй җимерекләре өйрәнелде. Элек һөнәрче мастерское булган урында күп санда бакыр, җиз, терекөмеш тамчылары, металл әйберләрнең калдыклары, сыек металлны формаларга агызу өчен кулланылган балчык кашык табылды. Монда эшләгән бакырчы, күрәсең, хан йорты заказларын үтәгән. 1975 елда казылган мәйданда тимерче йорты, алачык урынындагы зур тимер сандал, хуҗалык корылмалары калдыклары һ. б. өйрәнелде. Киң кулланышта булган кызыл балчык керамика, шомартып киң сызыклар төшергән һәм сырлап-бизәкләп яки көрән йөгертеп эшләнгән савыт-саба үрнәкләре, металл әйберләр бик характерлы. Монда шулай ук 1975 елда табылган сәүдәгәр пломбасы игътибарны җәлеп итә, ул төньяк Германиядәге шәһәрләрнең берсендә эшләнгән.

Урта катлам 1974 елгы казылмада 20—30 сантиметр, 1975 елгысында бер метр калынлыгында. Ул XIII йөз ахыры, XIV йөз һәм XV йөзнең беренче яртысына туры килә.

Бу дәверләрдә Казан Алтын Урда чоры Идел буе Болгарының феодаль княэьлек үзәкләреннән берсе була. Әлеге горизонтта табылган материаль культура калдыклары, аерым алганда, аркылы шома сызыклар төшереп ясалган кызыл балчык чүлмәккувшиннар болгар һәм казан-татар культурасының бердәмлеге, эчке үсешендәге эзлеклелек хакында сөйли.

Иң түбәндә ятучы катламның калынлыгы 8—16 сантиметрдан артмый, әмма ул Кремль калкулыгындагы шәһәрнең иң борынгы чорында барлыкка килүе белән гаять кызыклы. Анда кызыл балчык савыт-саба үрнәкләре күп түгел, тик алар монгол яуларына кадәрге чорда болгар шәһәрләрендә җитештерелгән керамика үрнәкләре белән гаять охшашлар. Кызгылт-сары, кызгылт-көрән төстәге балчыктан ясалган ул чүлмәк-савытларның тышкы ягы шулай ук еш һәм шома сызыклар белән бизәлгән. Алар барысы да XII—XIII йөзләрдә ясалган. Шушы ук горизонтта угро-фин телле җирле халыклар культурасы өчен хас ысул белән, кулдан ясалган керамика үрнәкләре дә, катламның монголларга кадәрге дәвергә каравын раслаучы башка әйберләр дә: XII йөздә эшләнгән тимер балта, иран стилендәге кандил рәвешле керамика, тимер ук очлары һ. б. очрый.

1975 елда үткәрелгән казу эшләре күрсәткәнчә, түбән горизонттагы культура катламы үзе ике өлешкә бүленә, аларның һәрберсенең өске ягында янгын эзе сакланган. Иң беренче (түбәнге) өлешнең өске ягында XII—XIII йөз ук очы, ә икенче өлешнең өстендә типик монгол угының очы табылды. Ул кечкенә катламның түбәнгесен, күрәсең, Казанның (рус елъязмасында Хомол) 1205 елда Всеволод гаскәрләре тарафыннан алынуына, ә югаргысын 1276—1278 елда Мәнгү-Тимернең Казанга ясаган һөҗүменә бәйләп карарга кирәктер.

Әлеге тикшеренүләр һәм башка тарихи-археологик мәгълүматлардан чыгып, Казанның кайсы вакытта, кайда һәм ни рәвешле салына башлавы, тарихи үсеш барышында ул үткән иң элгәрге дәверләр турында мөһим нәтиҗәләр ясарга мөмкин. Казан XII йөзнең соңгы чиреге башында, төгәлрәк әйтсәк, 1177 елда, болгарларның Иделдәге әһәмиятле терәк пункты сыйфатында, стратегик һәм географик яктан иң уңай урында, ныгытылган кальгә-шәһәр буларак төзелә.

Нигезе салынган вакыттан алып безнең көннәргә кадәр, ягъни 800 ел буена, Казанның тарихи үсеш юлы өзелмичә килә.

Борынгы Казан XII йөзнең соңгы чирегендә һәм XIII йөз башында, әйткәнебезчә, хәзерге Кремль калкулыгының төньяк-көнчыгыш өлешен биләп торган. Төньяк-көнбатыш яктан ул тирән чокыр белән аерылган, аның көньяк-көнчыгыш ягын хәзерге Сәламәтлек саклау министрлыгы бинасы тирәсеннән сузылган текә яр кисеп үткән. Кальгә якынча 45000 квадрат метр, ягъни урта кул болгар шәһәре мәйданын биләгән.

Борынгы Казан, күрәсең, политик яки һөнәрчелек үзәге түгел, ә күбрәк хәрби крепость булып хезмәт иткәндер. Шәһәрнең борынгы культура катламнары шул хакта сөйли, анда, һөнәрчелек һәм төрле керамика калдыкларыннан бигрәк, хәрби тормыш әзләре, сугыш кораллары, хайван сөякләре сакланган.

Чик буен белдерүче елга исеме белән генә аталган шәһәрнең исеме дә, ихтимал, җирле халык телендә ныклап берегеп һәм үзләшеп җитмәгән булгандыр. Бу хәл рус елъязмасында һәм башка язма чыганакларда да чагылып кала. Безнең фикеребезчә, Казан һәм казанлылар, мәсәлән, рус елъязмасында 1183 елда (икенче бер елъязмада 1184 ел) телгә алына. Ул елны рус кнэзьләре тарафыннан болгарларның башкаласы Бөек шәһәргә зур поход оештырыла. Гаскәрнең күпчелек өлеше зур көймә һәм корабларга утырып Идел буйлап төшә. Казанлылар, зур яуга каршы чыгарлык көчләре булмаганлыктан, аны түбәнгә үткәреп җибәрәләр һәм башкалага хәбәр итәләр.

Тиздән, дошман гаскәрен тоткарлау өчен, башкалага бару юлында ныгытмалар барлыкка килә. Тукчин шәһәре янында руслар, мәсәлән, ике көнгә тоткарланалар, ә Бөек шәһәр тирәсендә, урманны егып, яңа ныгытма корыла. Ул арада болгар җиренең төрле төбәкләренә чапкыннар җибәрелә, ун көн эчендә башкалага ярдәмгә биш мең кешелек ополчение килеп җитүе турында хәбәр бар. Шулар арасында чик буе шәһәре Собекульдән (кайсыбер елъязмаларда Собекудя, Сабакуль дип яки «собекуляне», «кусяне» дип язылa) килгән кешеләр дә була. Этимологик яктан тикшергәндә, бу исемнәрдә Казан күздә тотылуын чамаларга була. Чувашлар Казанны Хузан дип йөртәләр (казанлылар, димәк, русча «хузане» булып чыга. Удмурт телендә — «кузоне»). «Кусяне», «кузоне», «хузане» — әйтелеш буенча якын торган сүзләр. «Соба» яки «Саба» кисәкләре дә очраклы түгел. Борынгы төрки телдә һәм, күрәсең, болгар телендә дә «саб» (саба) тамыры «хәбәрче», «күзәтче» һәм шуңа якын мәгънәләрне белдергән. Димәк, «Сабакузя» (рус елъязмаларында тагын «Собекудя», «Кузя», «Собекуля») сүзен сакчы шәһәр, «собекудяне», «собекузяне» сүзләрен сакта торучы казанлылар дип тәрҗемә итәргә мөмкин. Шәһәрнең утырган урыны бу фикерне раслап тора.

Казан сүзен мари теленә калькалаштырсак, «Хомол» килеп чыга. Мари һәм башка угро-фин телләрендә дә «хом», «ком» — «кырый», «чит», «тыш» дигәнне, ә «ола» — шәһәрне аңлата (Йошкар-Ола — Кызыл шәһәр дигән сүз). Күрәсең, тарихи язмышларын Казан белән бәйләгән, шәһәр эчендә болгарлар белән якыннан аралашып яшәгән марилар (моны кулдан ясалган һәм шәһәрнең иң элгәрге культура катламында табылган борынгы мари савыт-сабалары да раслый) Казанны шул ук мәгънәдә үз телләрендә «Комола» яки «Хомола», ягъни чик буе шәһәре дип атаганнардыр. Мариларга якынрак яшәгән русларның шәһәр исемен аларга ияреп «Хомола» дип атаулары бик мөмкин хәл (мари телендә «к» белән «х» бер-берсен алыштыра).

Рус елъязмаларында хәбәр ителгәнчә, 1205 елда бөек князь Всеволод Юрьевич Идел буйлап болгарларга каршы гаскәр җибәрә, ул гаскәрь нәкъ менә Хомол шәһәренә кадәр килеп җитә, «күп кешеләрне әсир итә, үтерә, учаннарны күпләп җимерә, күп товар ала, шуннан соң кире борылып кайта». Күрәсең, рус гаскәре бу шәһәрне сугышып алган һәм күп эре көймәләрне (учан) юкка чыгарган, кулга күп байлык төшергән. Алда әйтелгәнчә, бу вакыйга Кремльдә үткәрелгән археологик материаллар белән дә раслана.

1205 елдагы шушы хәлләрдән соң шәһәр, чик саклаучы кала буларак, яңадан ныгытыла. Һәрхәлдә, князь Святослав 1220 елда яңа һөҗүмгә килгәч, Идел ягыннан флангны ныгыту өчен анда Ростов полкын калдырырга мәҗбүр була. Бу поход Тәтеш тирәсендәге болгар шәһәрен (рус елъязмаларында «Ошель») талау белән тәмамлана.

Казан һәм аның барлыкка килүе турындагы тарихи легендаларга һәм риваятьләргә мөрәҗәгать итик. Җирле халыклар арасыннан чуваш, мари, удмурт риваятьләрендә Казан турында ни дә булса бармы? Бар һәм алар шәһәрнең монгол явына кадәр үк булганлыгын раслыйлар. Чуваш легендаларының берсендә болай диелә: «Төрле кавем халыклар болгар кнезе кул астында күршеләр белән сәүдә итешеп, тыныч кына яшәгәннәр. Казаннан башка аларның тагын башка шәһәрләре дә булган... Көтмәгәндә көньяк-көнчыгыштан татарлар килеп, аларны тәмам бөлдерәләр, бик күп болгар кешеләренең гомере киселә, князьне куып җибәрәләр, халыкка ясак салалар».

Бу риваятьтән чыгып, әлбәттә, Казан монголлар тарафыннан 1236—1240 елларда алынган дигән нәтиҗә ясарга ярамый. Шәһәрне алар шактый соңрак, 1276—1278 елларда буйсындырганнар булырга тиеш. Рәшид-әд-Дин һәм Абел-Гази язуынча, Алтын Урда ханы Мәнгү-Тимер шул елларда «болгар патшалыгына яу белән барган, җиңү яулап, ике елдан соң үз йортына кайткан». Мәнгү-Тимернең болгарлар белән сугышуы хакында рус елъязмаларында да хәбәр ителә. Бәрелешләрдә Мәнгү-Тимер ягыннан Смоленск кнезе Федор Черемный да катнаша. «Степенная книга»да язылганча, Мәнгү-Тимер, рәхмәт йөзеннән, үз кызын аңа кияүгә бирә һәм, имеш, бик күп шәһәрләрне, шул исәптән, Чернигов, Болгар, Казанны бүләк итә. Казанның XIII йөздә монголлар тарафыннан алынуы, алда әйтеп киткәнебезчә, археологик материаллар белән дә раслана. Әмма шәһәр бу юлы да тиз арада аякка баскан һәм тагын да киңәйтелгән. XIII йөз ахырына таба ул Болгар иленең иң зур политик һәм экономик үзәкләреннән берсенә әверелә.

Шәһәр һәм аның тирә-юненә монгол баскыннарыннан качып килгән болгарлар утыралар. Археологик һәм башка тарихи мәгълүматлар, болгар-татар елъязмалары, тарихи-генеологик ядкарьләр шул хакта сөйли. Болгар патшасының уллары (Алим-бәк һәм Алтын-бәк яки Ихсан-бәк һәм Инсан-бәк) Казан елгасы буена китеп шәһәрләр салалар. (Георги кучермәсенең иң элгәргесендә патша улларының элек салынган шәһәргә күчеп килүләре турында хәбәр ителә.) Камадан төньякта, шул исәптән, Казан суы буйлап урнашкан болгар шәһәр-авылларының күбесе XIII йөзнең икенче яртысында барлыкка килгән.

Хәзерге Казан ягы, ихтимал, XIII йөзнең икенче яртысында яулап алынган, әмма тулысынча буйсындырылмаган болгар җиренең бер төбәге, үзәге булгандыр дип саналырга да хаклыдыр. Архиерей дачасы дип аталган җирдә (хәзер Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты территориясе) асыл сөяк болгарларның бу замангача сакланган кабер ташларындагы язулар да шуңа ишарәли. Н. Ф. Калинин фикеренчә, XIII йөз ахырында, XIV йөз башында ук инде биредә югары катлау болгарларның зираты булган, шул заманда ук анда әмир һәм солтан титулларын йөрткән кешеләр күмелгән.

Кремль территориясендә алып барылган казу эшләре XIII—XIV йөзләрдә кала чикләренең киңәя баруын күрсәтәләр. Ул чорның материаль культурасы калдыклары Кремльнең төньяк-көнчыгыш ягында гына түгел, көнбатыш һәм көньягында да, хәтта хәзерге Тайницкая һәм Воскресенская дип йөртелгән манаралар янында да күзәтелә. Шәһәрнең кальгәсе ул чорда хәзерге Сәламәтлек саклау министрлыгыннан көньяктарак үткән. Консисторская башня тирәсендә XIII—XIV йөзләрдә болгар каберлеге булган. Князьлек чорында Казан кальгәсенең буе 400 метр, киңлеге 250 метр чамасы булган, ягъни ул инде 100000 квадрат метр чамасы мәйдан биләгән. Кальгә янәшәсен-

дә утырган ачык бистә дә үсә килә. Элекке цирк тирәсендә табылган, шома сызыклар төшерелеп яки көрән йөгертелеп эшләнгән саргылт-кызыл тестәге болгар савыт-сабасы калдыклары да нәкъ менә XIII—XIV йөзләргә карый. Кальгәдә дә, бистәдә дә йортларны агачтан салганнар. Ләкин кальгәдә ул вакытта ук инде таш һәм кирпеч биналар да булган. Шәһәрнең князьлек чорына караган горизонтлардан чыккан кирпеч ватыклары, тезү кораллары (таш кискеч өтерге), акбур валчыклары шул фикерне раслый.

XIV гасырда Казан шәһәре белән бер үк вакытта, шул ук елга буйлап кырык чакрым чамасы өстәрәк, икенче бер кала да булган (аның калдыклары Биектау районының Камай һәм Рус Урматы авыллары арасында урнашкан).

Иделдән бер читтә, чагыштырмача тынычрак җирдә корылган бу кала да, А. П. Смирнов фикере буенча, XII йөздә, монголларга кадәрге чорда барлыкка килә. Казан суы буенда утырганга аны да Казан (Иске Казан) дип йөртәләр. XIII—XIV гасырларда ул зур экономик үзәк ролен уйнаган, мәйданы бер миллион ярым квадрат метрдан да артык булган. Күрәсең, куркыныч килгән көннәрдә халык Казан суы тамагындагы шәһәрдән шушында килеп яшеренгәндер. Вакыт-вакыт, бигрәк тә 1205 һәм 1278 еллардагы кебек каты һөҗүмнәрдән соң, төп шәһәрдә тормыш бөтенләй диярлек тукталып торган булуы да ихтимал. Аннары шәһәр халкы тагын үз йортларына кайткан, шәһәрне торгызган, тормыш иске эзенә төшеп, җәйләнып китә торган булгандыр... Археологик мәгълүматлар тарихта бер генә тапкыр кабатланмаган нәкъ шундый хәлләрне: шәһәрдәге яну-җимерелүләр, шуңа карамастан, аның яңадан аякка бастырылуы, һаман киңәюе, үсүе турында сөйли. Менә шушындый шартларда соңгырак буыннар, күрәсең, Иделдән читтә утырган шәһәрне элгәрерәк салынган, искерәк шәһәр итеп күз алдына китерә башлаганнардыр.

XIV гасыр уртасында һәм икенче яртысында Болгарның көньяк һәм үзәк өлкәләре каты һөҗүмнәргә дучар була, алардан бигрәк тә шәһри Болгар җәфа чигә. Мәсәлән, 1361, 1382, 1391 елларда биргә Алтын Урда ханнары яу белән килә, 1359, 1366, 1369, 1370, 1391 елларда Новгород ушкуйниклары һөҗүм итә. Кама аръягы җирләре тәмам бөлдерелә, акрынлап ташландык хәлгә килә. Шул шартларда Казан бөтен Болгар җиренең политик һәм экономик үзәге ролен уйный башлый. Бу чордан калган картографик, нумизматик һәм елъязма мәгълүматлар белән танышу кызыклы. Идел һәм Урал буйлары өлкәләрен иң беренче булып диярлек 1367 елда итальян монахлары Франциско һәм Доминико Пицигано картага төшергәннәр. Шул картада Иделнең сул як яры белән Кама елгасы арасында манарасына флаг эленеп куелган зур шәһәр сурәте бар.

Андый билге бары тик баш шәһәрне белдерү өчен генә кулланылган. Каманың сул як яры буенда һәм Кама тамагыннан аска урнаштырылган Жукотин (Җүкәтау), Керменчуг (Кирмәнчек), Болгар шәһәрләре флагсыз гына билгеләнгән. Баш шәһәрне аңлатучы әләм тагын бер шәһәргә генә — «һәлак булган шәһәр» дип исемләнгән һәм Идел-Камадан бер читтәрәк утырган шәһәргә генә куелган. Бусы — монгол яуларына кадәрге Болгар дәүләтенең башкаласы, XIV йөздә инде шомлы хәрабәләр хәлендә ятса да, килгән-киткән кешеләрне хәйран калдыра торган Бөек шәһәр (Булэр) билгесе.

XVI—XVII йөзгә караган иң беренче рус географик карталарында да Казанның урыны Франциско һәм Доминико Пицигано карталарындагыча күрсәтелүен искә алсак, 1367 елда ук инде аның бик мәгълүм шәһәр, илнең политик һәм экономик үзәге булганлыгын күрербез.

XIV йөз ахыры, XV йөз башында, шәһри Болгарның әһәмияте югала барган чорда, «Болгар» атамасын яңа башкалага күчерергә, Казанны «Яңа Болгар» (Болгар Әл-Җәдит) дип исемләргә омтылыш мисалы үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли.

Рус елъязмаларында һәм «Казан тарихы»нда да язылуынча, 1445 ел «шул ук көздә Олуг-Мөхәммәтнең улы Мамотяк князь Либей (Никонов елъязмасында — Азый) биләмәсе булган Казанны ала, ә үзе Казанда патша булып утыра». Шул рәвешчә, 1445 елның көзеннән Казан тарихында яңа чор — ханлык чоры башлана. Шәһәребез тарихының бу дәвере төрле чыганакларда һәм хезмәтләрдә (мәсәлән, М. Г. Худяков, Н. Ф. Калинин, Ш. Ф. Мөхәммәдъяров хезмәтләрендә) җитәрлек яктыртылганлыктан, бу язмабызны шушында тәгәлләү урынлы булыр.

**Рәфыйк Нәфиков,**
тарих фәннәре докторы, профессор

# ФАТИХ ӘМИРХАН — ПУБЛИЦИСТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

Фатих Әмирхан — өч революцияне башыннан кичергән, революция давылларында формалашкан күпкырлы язучы. Әмма әдипнең иҗади үсеш юлы тиешле дәрәҗәдә ныклап өйрәнелмәгән, аның иҗтимагый эшчәнлегенең кайбер мөһим яклары җитәрлек ачыкланмаган әле.

Ф. Әмирхан әдәбият мәйданына 1905 елгы революция тәэсирендә килә. Габитовлар һәм Әхмеровлар семьясы, Х. Ямашев, М. Вахитов, М. Дулат-Али һәм С. Гассарлар белән якыннан аралашуы аның дөньяга карашына һичшиксез көчле тәэсир ясаган булырга тиеш. Соңга таба аның дуслары арасында без Г. Кариев, С. Рахманколый, Ф. Агиев, К. Бәкер кебек язучыларны, журналистларны, артистларны күрәбез. Ул гомере буена Габдулла Тукай белән дусларча якын мөнәсәбәттә яши.

Замандашларының истәлекләренә караганда, алар Г. Тукай белән «икесе бер төслерәк» кеше булалар («Казан утлары» журналы, 1970 ел, 8 сан, 169 бит). Габдулла Тукай Казанга килгән көннән башлап, Фатих Әмирхан аңа зур ихтирам һәм җылы мөнәсәбәт саклый. Ф. Әмирханның халык шагыйре Тукайга йогынтысы ифрат зур була. Ул шагыйрьгә үз иҗатындагы аерым кимчелекләрдән арынырга, осталыгын үстерергә ярдәм итә, аны бик еш кына милләтчеләрнең һәм дин әһелләренең һөҗүменнән саклап кала. Көрәшче һәм гражданин шагыйрь буларак, үз чиратында Г. Тукай да ул чагындагы иҗтимагый фикер каршылыкларына, дини фанатизмга, реакциягә һәм милли чикләнгәнлеккә каршы килешмәүчән көрәше белән дустына уңай йогынты ясый. Кыскасы, Г. Тукай белән Ф. Әмирхан бер-берсен тулыландырып торганнар.

Фатих Әмирханның «Тукай үлем алдыннан» дигән истәлегенә күз салыйк. Никадәр якынлык һәм үз итү, күпме сагыш һәм газап хисе аңарда:

«... Ләкин 2—3 минут үткәндә инде Тукай үзе минем янымда иде. Ул йөткерә-йөткерә сүз башлады:

— Үлемнән качып синең янга кердем әле! Юк, үлемнән түгел, ялгызлыкта үлемнән качып...

Төнге лампаның зәгыйфь кенә яктысы астында «ялгызлыкта үлемнән» качып кергән Тукайның зәгыйфь торышы минем күзләремә үлемнең нәкъ үзе, шул серле үлемнең нәкъ үзе булып күренде, йөрәк сикеренде, җан куркынды, бугазга яшьләр килеп тыгылдылар.

— Мә, Тукай, ал минем таза үпкәләремнең берсен, берәр үпкә белән дә дөньяда торырбыз әле, — дип кычкырасы килгән шикелле булды.

Бу төннән соң инде Тукай «Амур»да озак тормады.

Аны больницага илттеләр.

Иртәгә иртә белән больницага илтеләчәк дигән төнне ул минем белән күрешергә кергән иде. Сабыйларчарак шат йөз белән ул: — «Мин иртәгә Клячкинга керәм, мин киткәндә, син тормаган булырсың... Моннан соң күрешмәсәк... хуш инде!» — диде. Докторлар аркылы миңа инде аның бер ай, күп булса ай ярым гомере калганлыгы мәгълүм иде. Бу «хуш»ның да ахыргы «хуш!» икәнчелеге билгеле иде. Алай да мин аңар:

— Тиз терелеп чык, тиз күрешик! — дидем.

Ул, бүлмәдән чыга башлап:

— Юк, тиз күрешмик әле, син озаграк яшә! — диде һәм чыгып китте» [1].

Алар берсе шигырь, икенчесе проза белән иҗат итүче ике шагыйрь булалар.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, Ф. Әмирхан татар большевиклары белән якыннан аралашып яши. Большевик дуслары аны мещаннарның һәм буржуазия ялчыларының һәртөрле һөҗүмнәреннән саклыйлар, аңа фәнни социализмның, Бөек Октябрь революциясенең асылын һәм әһәмиятен аңларга булышалар. Бу уңайдан аның М. Вахитов һәм М. Дулат-Али белән дуслыгы аерым игътибарга лаек.

Ф. Әмирхан Октябрьга кадәр үк зур иҗтимагый эшчәнлек алып бара. 1903 елда, дини фанатизмга, караңгылыкка һәм рухи торгынлыкка каршы көрәшчеләр сафында торып, ул театр сәнгатен булдыру өчен көрәшә, төрле милләт вәкилләрен берләштергән яшьләр түгәрәгенә йөри. Аның дуслары арасында рус, татар, чуваш, казакъ, башкорт, мари һәм башка милләтләрнең укучы яшьләре була.

1905 елгы революциянең көчле дулкыннары татар дөньясына, шул исәптән мәктәп-мәдрәсәләр эченә дә үтеп керә. Революциянең көчле авазын ишетеп, татар шәкертләре тынчу мәдрәсәләрдән киң урамнарга чыгалар. Дини фанатизмга һәм самодержавиегә каршы көрәшкә өндәгән шәкерт җырлары — садалар илнең иң ерак почмакларына барып җитә [2].

Ф. Әмирхан шәкертләр хәрәкәтенең актив җитәкчеләреннән берсе була. Ул «Ислах» комитетын җитәкли, 1905 елның көзендә яшерен рәвештә «Әлислах» исемле газета чыгаруны оештыра, татар шәкертләренең Казанда булып үткән беренче Бөтенроссия съездында катнаша.

1906 елда Фатих Әмирхан көндәлек матбугатта катнаша башлый. «Әлгасрел-җәдит» журналының шул елгы саннарында аның «Париж Коммунасы тарихы» турындагы тәрҗемәләре басыла [3]. Европа революциясе тарихындагы бик мөһим бер этапны яктырткан бу очерк массаларны социаль революциягә өнди, аларны буржуйларга каршы көрәшкә чакыра. «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән мәшһүр лозунгны татар теленә беренче тапкыр Ф. Әмирхан тәрҗемә итә.

Очеркның эчтәлеге артык катлаулы түгел. Башта француз эшчеләренең фабрикантлар, банкирлар, купецлар, дворяннар һәм биржачылар белән үзара мөнәсәбәт тарихы бирелә. Соңгыларын автор дәүләт байлыгын зарарлы эшләргә әрәм-шәрәм итүчеләр дип саный. Ә хезмәт иясе массалары, халык «ялланып эшләүчеләргә» әйләнеп беттеләр, ди. Моннан пролетариат белән байларның мәнфәгатьләре капма-каршы булуы бик ачык күренә. Алга таба ике сыйныф арасында барган көрәш тасвирлана. Оешкан булуы һәм актив төстә забастовкалар ясау нәтиҗәсендә Франция пролетариаты хезмәт хакын күтәрүгә, эш сәгатьләрен кыскартуга, алдагы көрәш өчен кирәк булган кайбер башка хокуклар яулап алуга ирешә. Шуннан соң Франция Россия белән чагыштырыла. Россиядәге сыйныфлар, аларның иҗтимагый хәле яктыртыла. Россия белән чагыштырганда, француз пролетариаты аңлырак һәм оешканрак, ул дәүләт белән җитәкчелек итүне үз кулына алырга омтыла, ди автор.

Сыйнфый көрәшнең ифрат актуаль мәсьәләләрен яктырткан шундый мәкаләне тәрҗемә итеп, Ф. Әмирхан татар халкына конституцион иллюзияләрдән арынырга ярдәм итә, яшәп килгән тәртипләрне бары тик аңлы көрәш юлы белән генә үзгәртергә мөмкин булуын күрсәтә. Либераль карашлардагы кеше (30 нчы елларда әдәбият белгече Г. Толымбайский Ф. Әмирханны шулай дип атаган) «иезуит һәм нагайка эшләпәләре» хакимлеген сурәтләгәндә, шулай ук француз халкының монархиягә

[1] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр, II том, Казан, 1958 ел, 437 бит.

[2] Ул җырлар ерактагы казакъ даласына да килеп җиткән булган, күрәсең. Безнең әниләр шәкерт садаларын яттан беләләр һәм аларны әледән-әле безгә дә җырлап күрсәтәләр иде. Автор.

[3] «Әлгасрел-җәдит» журналы, 1906 ел, 6 һәм 8 саннар. Редакциягә бәйле булмаган сәбәпләр аркасында, очерклар тулысынча басылмый.

һәм Людовик Филиппка каршы 1830 елның июлендәге көрәшен күрсәткәндә байларны «кеше талаучылар» [1] дип атый алмас иде.

Икенче очерк [2] — беренчесенең турыдан-туры дәвамы. Ф. Әмирхан тәрҗемә иткән очеркларның бусында 1848 елдан алып Париж Коммунасының беренче көннәренә кадәрге Франция тарихы турында сүз бара. Наполеон III хөкүмәте казнаны талаучы, Франциягә «савым сыерга» әйләндерергә тырышучы биржачылар, аферистлар һәм фахишәләр хөкүмәте буларак сурәтләнә. Бу хөкүмәтнең политикасы да дөрес яктыртыла. Капиталистларның товарларына базар табу өчен ул империалистик сугышлар оештыра. Шул ук вакытта алар мәсьәләнең икенче ягын да онытмыйлар: әлеге сугышларда капиталистларның «дошманнары булган эшчеләрнең каннары түгелә һәм куәтләре кими» бара [3].

Франция-Пруссия сугышы башлангач (мәкалә авторы, Наполеон III сугышны үз властен саклап калу һәм пролетариат хәрәкәтен тар-мар итү өчен башлады, ди), Интернационалның Париж бүлеге (бу термин очеркта бар) немец эшчеләренә сугышның талау сугышы булуын фаш иткән манифест белән мөрәҗәгать итә. Моңа җавап йөзеннән немец эшчеләре күп санлы митинглар, демонстрацияләр оештыралар, барлык илләрдәге эшчеләрнең мәнфәгате уртак, алар изүчеләргә каршы көрәшкә күтәрелергә тиеш, диләр.

Шунысы кызык, мәкалә авторы ул чордагы Францияне рус-япон сугышы чорындагы Россия белән чагыштыра. Ул шулай ук кибетчеләрнең һәм итчеләрнең ялган патриотизмын фаш итә. Алга таба 1870 елның 4 сентябрендә икенче империянең җимерелүенә һәм республика игълан итүгә бәйле вакыйгалар сурәтләнә.

Әмма, ди очеркист, Тьер, Фавр һәм аларның иптәшләре безнең «патриотларга» караганда көчлерәк, хәйләкәррәк булганнар, «туктаусыз революция сүзләрен атып торганнар» [4]. Ә үзләре шул ук вакытта Париж капкасы төбендә торган пруссакларга каршы түгел, ә тагын да куркынычрак дошманга — эшче гвардияләренә каршы сугышка әзерләнгәннәр. Эчке дошманны — пролетариатны һәм ярлыларны җиңү өчен, алар тышкы дошман алдында теләсә нинди ташламалар ясарга әзер торганнар. Революцион халыкка каршы көрәшү өчен монархистлар һәм либераллар бергә берләшкән. Алар халыкны котыртып бунт ясатырга, аннан соң аларга ут ачарга ниятлиләр. Италия халкының азатлык өчен көрәшүче каһарман улы Джузеппе Гарибальдига [5] каршы чыгып, 1848 елда ук үзенең асылын ачып салган Тьер канга сусаган палач итеп бирелә. Ләкин аларның әшәке ниятләре барып чыкмый, тьерчылар Версальга кача.

Очеркта Париж Коммунасына кадәрге тарих дөрес сурәтләнә, аңардан «явыз капиталистларга» каршы социаль көрәш рухы бөркелә. Әсәр баштан ахырга кадәр интернационализм рухы белән сугарылган, очеркта либерализм фаш ителә, сыйнфый көрәшкә һәм социаль революциягә дан җырлана.

Очерк Россиядә бишенче елгы революция барган көннәрдә басыла, Романовларның һәм кадетларның черек либерализмын фаш итүдә ул мөһим роль уйный. Әгәр аны гомум тарихның мәгълүм бер өлешен татар телендә фәнни нигездә аңлаткан, татарларны Франция тарихы, фәнни социализмның кайбер положениеләре белән таныштырган беренче хезмәт дисәк, бер дә ялгышмабыз кебек.

1907 елда Ф. Әмирхан «Әлислах» газетасында дума мәсьәләсенә караган берничә мәкалә бастырып чыгара. Шуларның «Думалар» [6] дип исемләнгәнендә ул, «суллар»ның позициясен билгеләп: «Суллар, фәкыйрь халыкның тормышы хакында сөйләп, моннан соң төзеләчәк яңа тәртип эшче халык вә крестьянның үз тарафыннан вә алар файдасына төзелүен» яклыйлар, ди. Автор фәкыйрьләргә дә бер кисәк бирергә, ләкин өстен сыйныфларны да какмаска кирәк, дип урта хәлле буржуазияне яклап чыккан кадетларны һәм аларга якыннарны тәнкыйть итә [7].

---

[1] «Әлгасрел-җәдит» журналы, 1906 ел, 6 сан, 338 бит.
[2] «Әлгасрел-җәдит» журналы, 1906 ел, 8 сан. Шушы ук санда Габдулла Тукай тәрҗемә иткән «Ачлык патша» исемле брошюраның дәвамы бар.
[3] Шунда ук, 422 бит.
[4] Шунда ук, 424 бит.
[5] Шунда ук, 425 бит.
[6] «Әлислах» газетасы, 1907 ел, 3 октябрь саны.
[7] Шунда ук. Ф. Әмирхан алга табарак реакцион партия булган «уңнар»ның да позициясен дөрес күрсәтә.

Ф. Әмирхан кадетларны «урталар» дип атый. Болар, ди ул, уңнар һәм суллар уртасында торалар һәм конституция положениеләре кысасыннан читкә чыкмыйлар [1]. Әлеге мәкаләләрдән күренгәнчә, язучы кадетларны эшче-крестьяннар мәнфәгатен кайгырта торган партия дип санамый. Аның мәкаләләреннән чыга торган беренче нәтиҗә шул. Икенче мөһим нәтиҗә итеп шуны әйтергә кирәк, Ф. Әмирхан яшәп килгән тәртипләрне үзгәртүне гадел һәм кирәкле эш итеп саный, ул тәртипләрне халык, хезмәт ияләре файдасына үзгәртүне яклый, башкача әйткәндә, революцион хәрәкәтләрне кире какмый.

Дөрес, мәкаләдә авторның кемнәрне «суллар» дип атавы ачылып җитми. Әмма әлеге сорауга төгәл җавапны аның башка мәкаләләреннән табарга мөмкин. «3 нче июнь кануны вә партияләр» [2] дигән мәкаләдә, әлеге контрреволюцион законның төрле сәяси партияләргә булган тәэсирен аңлатканнан һәм төрле буржуаз партияләрнең тигезләнүен билгеләгәннән соң, Ф. Әмирхан эсерларны социалистларга тиңли, алар социалистик партия дигән ялгыш караш уздыра. Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, заманында Г. Тукай һәм Г. Камал да шундыйрак позициядә торганнар. Бу хәлне аларның сәяси карашлары өлгереп җитмәгән булу белән аңлатырга мөмкин.

Ф. Әмирханның үз мәкаләләрендә «бөтен Россиягә үзен халык дошманы итеп танытырга өлгергән» кадетларны — Пуришкевичларны һәм Шульгиннарны, октябристларны һәм карагруһчыларны, «татар Пурешкевичлары»н — Сыртлановларны, Гаспринскийларны һәм Максудовларны фаш итүе бик мөһим [3]. Моның белән ул «Мөселман иттифакы» дигән контрреволюцион партиягә дә каршы чыга. Билгеле булганча, заманында Й. Акчура бөтен программалар арасыннан «мөселманнарга» аеруча «конституцион партия», ягъни кадетлар программасы файдалырак, дип чыккан иде.

Ф. Әмирханның социал-демократларга мөнәсәбәте аерым игътибарга лаек. «3 нче июнь кануны вә партияләр» исемле мәкаләсендә ул большевиклар һәм меньшевикларның тактик фикер каршылыклары турында яза һәм большевикларның думага мөнәсәбәтен шактый дөрес күрсәтә. Мәкаләдә мондый юллар бар:

«... Күптән түгел меньшевиклар рәисе Плеханов «Товарищ» газетасына язган бер мәкаләсендә большевикларның хатты хәрәкәтләрен (тактикасын — Р. Н.) ачы сурәттә тәнкыйть итте. Ләкин большевиклар андый тәнкыйтьләрдән генә бер дә тәэсирләнмичә, әүвәлгечә дума мөнбәренә халыкка сүз ишеттерер өчен булган бер җир дип карауларында дәвам итмәктәләрдер» [4].

Алга таба автор бу фикерне тагын да ачыклый төшә: «Петербургта үзләреннән вәкил сайларга җыелган эшче-большевиклар сайланачак кеше өчен, бу халыкның мөмтаз вә бик аз сыйныфыннан гына сайланып вөҗүткә килгән думага низамнар ясашырга түгел, бәлки халыкка сүз ишеттерергә бара икәнлеген белдереп торган инструкция ясап бирделәр. Әлхасыйль, большевикларның хатты хәрәкәтләре революциянең иң кызу көннәрендә ничек булса, хәзер дә җеп кадәр дә үңлашмыйча, шул көе калгандыр», ди.

Бу юллардан большевикларның 3 нче июнь кануны алдында каушап калмаулары, ахырга кадәр үз принципларын саклаулары бик ачык күренә. Шул рәвешчә, Плехановның большевикларга каршы чыгышларын фаш итеп һәм шул юл белән большевикларның думага чын мөнәсәбәтен, реакция алдында чигенеп калмауларын күрсәтеп, Ф. Әмирхан большевикларга теләктәшлек белдерә.

1907 елның беренче январеннан Мәскәүдә татар телендә «Тәрбиятел-әтфал» исемле журнал чыга башлый. Фатих Әмирхан бу журналның оештыручысы, төп авторы һәм фактик редакторы була.

Балаларга адресланган һәм аларны ватанга бирелгәнлек рухында тәрбияләүне

[1] Шунда ук, 12 ноябрь саны.
[2] Шунда ук, 10 октябрь һәм 17 октябрь саннары.
[3] Шунда ук, 25 нче октябрь («3 нче дума» исемле мәкалә) һәм 3 декабрь саннары («Дума» исемле мәкалә h. б.).
[4] Шунда ук, 17 октябрь саны.

максат иткән бу журналның эчтәлеге бик тә, бик тә гыйбрәтле. Аның беренче санынннан ук Ф. Әмирхан тәрҗемәсендә атаклы балалар язучысы Х. Андерсенның «Шөкәтсез үрдәк бәбкәсе» исемле әкияте басыла башлый. Әлеге әкияттәге үрдәк бәбкәсе кебек, журнал үзе дә гүзәл аккош булып үсәргә хыяллана. Укучыларын ул «гасырлар буе өелеп килгән наданлыктан, очы күренмәгән караңгылыктан, мәгыйшәтнең гаделсезлегенә булган ачудан һәм төрле-төрле җәфалар диңгезеннән»[1] котылу өчен көрәшергә өнди. Анда Менделеевка багышланган, химия һәм астрономиягә караган, шулай ук кеше һәм аның тән төзелеше, табигать турында язылган фәнни-популяр мәкаләләр басылып килә, журнал кеше акылы дөньяны танып-белергә сәләтле, ул фәннең теләсә кайсы өлкәсендә уңышларга ирешә ала дигән карашны үткәрә. Беренче саныннан ук анда якты киләчәккә тирән ышаныч белән сугарылган материаллар басыла. 1 февральдә чыккан өченче санда, «газета үз көчләре белән торучыларның файдасын күзәтәдер» дигән искәрмә белән, Оренбургта большевистик «Урал» газетасы чыга башлавы хәбәр ителә. 15 февральдә чыккан икенче бер санында «Идарәдән» дигән баш мәкаләдә ачыктан-ачык хөкүмәтнең халыкка дошман булуы әйтелә. Бишенче (безгә билгеле комплектта биш сан гына бар — Р. Н.) санда халыкның думага килгән социалистларны Петербургта революцион җырлар белән каршы алуы хәбәр ителә, аларга үзенең әйбәт мөгамәләсен белдерә. Журналда Н. Думави һәм бүтән шагыйрьләрнең шигырьләре басыла.

Әмма журналны һәм аның редакциясен идеаллаштыру дөрес булмас иде. Ул фәнни социализм идеяләрен якламаган кешеләрне дә социалистлар рәтенә кертә, редакция думага карата иллюзияләрдән дә азат булмый.

Бу ул чагындагы татар демократларына хас күп кенә кимчелекләре булган демократик бер орган була. Бүтән демократ язучылар кебек, Ф. Әмирхан да көрәшнең дөрес юлын эзли. Булган кимчелекләренә дә карамастан, аның иҗаты яшәп килгән режимга, исламның искергән кануннарына каршы юнәлгән була, яшьләрдә гуманистик һәм патриотик рух тәрбияли.

Ф. Әмирхан көндәлек матбугатны сыйныфлар арасында барган катлаулы көрәштә әһәмиятле һәм мөһим иҗтимагый корал дип саный. Беренче рус революциясе елларында башта яшерен төстә, ә аннан соң легаль рәвештә аның редакторлыгында «Әлислах» газетасы чыгып килә. Газета гаять кыен шартларда чыгарыла: юк кына нәрсәләргә дә бәйләнеп цензура теңкәгә тия, редакторның болай да зур булмаган килере штрафларга китеп бара, газетаны яшьләргә һәм барлык укучыларга түләүсез җибәргәнлектән, авторларга бик аз түләргә туры килә. Әмма «Әлислах» барыбер үз идеалына турылыклы булып кала. Ф. Әмирхан, Г. Тукай, С. Рахманколый, В. Бәхтияровларның демократик идеяләргә бирелгәнлеге, царизмга нәфрәте материал мәнфәгатьләрдән көчлерәк булып чыга, үзләре ачлы-туклы яшәсәләр дә, әсәрләрен «Әлислах»та бастыралар. Патша властьларының ябу белән янауларына карамастан, газета татар большевикларының мәкаләләрен бастыруны дәвам итә. «Әлислах»ның бер санында күренекле татар большевигы Х. Ямашевның якын дусты Г. Сәйфетдиновның сатлык милләтчеләрне, һәр төрле «милләт микробларын» кискен фаш иткән ачык хаты басыла. Шул ук вакытта газета редакциясе Печән базары каһарманнарына, солтан Төркиясен мактаучы буржуазия идеологларына да сизелерлек һөҗүмнәр ясарга өлгерә.

Цензура газетаның нинди линия уздыруын бик тиз күреп ала. Югары инстанцияләргә «динчеләрне, иске стройны рәхимсез төстә тәнкыйть иткәнгә күрә, газета муллалар, буржуазия вәкилләре арасыннан үзенә күп дошманнар җыйды», дигән хәбәрләр ява. Цензорларның берсе «Әлислах»ны прогрессив басмалар рәтенә кертергә кирәк» дип яза. Газета бай сыйныфлар мәнфәгатен күздә тоткан матбугат органнары белән көрәш алып барды, ди ул. Казанда чыккан башка татар газеталарыннан «Әлислах» «милли хорафатлардан азат булуы», башка халыкларга, аларның атаклы кешеләренә хөрмәт белән каравы белән аерылып тора; мәсәлән, Гоголь юбилее уңае белән ул «бөек язучы истәлегенә багышланган» бик җылы мәкалә урнаштырды, В. Радлов турында киң итеп язды, ди. 31 январь санында газета Төркиядәге дәүләт перевороты турында яза, яңа төрек дәүләте Балкан илләре белән

[1] «Тәрбиятел-этфал», 1907 ел, 3 сан.

яңа, кешелекле мөнәсәбәтләр урнаштырыр дигән өмет белдерә. Гомумән, бу газета укучыларны дөньяви белемнәр алуның зарурлыгына ышандыра, рус уку йортларын мактап язып, «татар һәм рус халыкларының якынаюына мәгълүм бер өлеш кертә» [1].

Цензура татар иҗтимагый хәрәкәтендә газетаның нинди роль уйнавын бик яхшы аңлый, шуңа күрә редакциягә дә бертуктаусыз штрафлар сала, текстларның шактый өлешен кыскартып чыгарта. Чөнки Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Камал кебек әдипләр, халыкта милли горурлык хисләре тәрбияләп, хезмәт ияләренең аңын уяталар. Патша хөкүмәте әнә шуңардан курка. Россия патшалыгы милләтчелеккә каршы көрәш битлеге астында халык мәнфәгатьләрен яклаган матбугат органнарының авызын томаларга тырыша. Тырыша торгач... «Әлислах»ны ябалар. Ләкин революцион-демократик фикер үсешен берничек тә туктата алмыйлар. Газета ябыла, әмма Г. Тукайлар, Ф. Әмирханнар иҗат итүдән туктамый.

Ф. Әмирхан тота да «Гарәфә кич төшемдә» исемле хикәясен яза. Төшендә күргәннәрен ул тиздән өнендә күрергә хыяллана. Зиннәтләп эшләнгән зур шәһәр клубына татарның бөтен дөньяга танылган врачларын, юристларын, язучыларын, артистларын, галимнәрен җыя. Автор татар мәдәниятенең югары дәрәҗәдә үсүе, төрле милләт галимнәренең бер-берсе белән аралашып, тәҗрибә уртаклашулары, бер-берсеннән өйрәнүләре турында хыяллана һәм ул көннәрнең килеренә ышана. Ул Марска очуларны алдан күрә, татар әдәбиятының дөнья аренасына чыгуы, татар художнигының Париж Фәннәр академиясенә почетлы член булып сайлануы, 12 томлык «Татар тарихы», «Инсаният өчен» исемле татар операсы һәм башка бик күп нәрсәләр турында хыяллана.

Менә хикәя герое уяна, калтырана-калтырана киенеп, мәчеткә китә. «Мәчеттә халык күп җыелган, бәгъзылары гырлап, бәгъзылары борыннарын сызгыртып вә бәгъзылары да тын гына йоклап утыралар иде... Вәгазьнең ахырына таба мәчеттә һава бер дәрәҗә бозылды ки, миләр хәлсезләнеп, йөрәкләр сикерә һәм бөтен мәчетне тоткан гатырша мае исе, яңа читекләрдән чыккан күн исенә катнашып, борынга керел, күңелләрне болгандыра иде... Намаз укылып тәмам булды... һәркем, төрмәдән җибәрелгән кебек, тиз генә чыгар өчен ишек төбенә җыелган иде» [2].

Үз чиратында, дин әһелләре дә Ф. Әмирханга салкын карый алмаганнар. Әйдәгез, без дә аз гына хыялга бирелик, дөресрәге, Ф. Әмирханның үз әсәреннән түгел, ә икенче авторның, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, берничә авторның уртак әсәреннән стилен һәм имлясын үзгәртмичә бер өзек укып карыйк:

«Против газеты «Эль-Ислах», сотрудниками каковой являются из разных наших училищ, в г. Казани, неприлежные к учению ученики, не удовлетворяющими поведениями, цель которых не есть прогрессивность, а напротив возмущающая, почти в каждой газете помещается вроде воззвание против имамов-мулл, почему прихожане, как народ простой начали смотреть на нас имамов во время исполнения нами духовных треб и обрядов, совершенно по другому взгляду, руководствуясь противоречающими заметками газеты «Эль-Ислах», почему вполне надеясь на милостивое внимание Вашего Превосходительства (үтенеч Казан губернаторы исеменә язылган — Р. Н.). Все покорнейше просим сделать надлежащее распоряжение о приостановлении дальнейшую и издачу выше означенную газету «Эль-Ислах» [3].

Үтенеч кыскалыгы, коточкыч наданлыгы, төрәләр алдында тәлинкә тотуы белән аерылып тора, ул канцелярия кәгазьләренең донослар төренә карый. Бу документны Казан шәһәре ахуны Йосыф Сәгыйтов, 9 нчы мәчетнең указлы мулласы Садыйк Иманколов, Казан шәһәренең указлы муллалары Х. Госманов, А. Госманов, И. Халитов, М. Халитов, Х. Гаффаров, Ш. Уразгильдиев, мулла Г. Сәлихов, Әҗем мәчетенең указлы мулласы Г. Габделгаффаров, М. Урманчеевлар укмаштырган. «Милләт аталары» шул рәвешле иң гади шымчыларга әйләнәләр, кяфер чиновникларның аяк астына килеп егылалар.

Ф. Әмирхан Йосыф Сәгыйтов кебек бәндәләрнең чын йөзен шул вакытта ук яхшы аңлый. Фәтхулла хәзрәт ахун Сәгыйтовның кушаматы булып китә.

---

[1] Татарстанның Үзәк дәүләт архивы (ТҮДА). 420 фонд, 150 эш, 48, 49, 50 битләр.
[2] Ф. Әмирхан. Сайланма әсәрләр. 1 том, Казан, 1957 ел, 300—301 битләр.
[3] Татарстан Үзәк дәүләт архивы. 1 фонд, 4 тасвирлама, 3732 эш, 67 бит.

Язучы кешенең акыл көченә, фәннең үлемне җиңәчәгенә ышана. 1950 елгы яңа җәмгыятьтә, Ф. Әмирхан фикеренчә, үлгәннәрне терелтә алырдай галимнәр яшәячәк. Бу фикер ничек кенә реаль булмасын (галимнәр биологик үлем белән түгел, клиник үлем белән үлгән кешеләрне терелтергә өйрәнделәр!), ул повестьта дини инануларга каршы куела, әсәр җир кешесенең белеменә, акылына мәдхия җырлый. Ф. Әмирхан, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «җир йөзендә караңгылыкны җиңгән» кешене зурлый. Бу исә — бөек максатка ирешү өчен көрәшкә өндәү булып яңгырый. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай.

Инде Казан ахунына һәм аның әшнәләренә килгәндә, алар белән исәп-хисапны язучы үзе өзә: тормышчан детальләр, уңышлы образлар ярдәмендә дин башлыкларының көлке дәгъваларын һәм яшәү рәвешләренең түбәнлеген күрсәтә. Ул кешеләрне денлеләргә һәм денсезләргә бүләргә яратучы милләтчеләргә һөҗүм ясый. Фәтхулла хәзрәт һәм аның кебекләрнең чын йөзен күрсәтеп биргәч, халыкның дин әһелләренә ышанычы кими. Повестьның бөтен пафосы һәм көче әнә шунда.

Фатих Әмирхан күп төрле псевдонимнар куллана. Шулардан «Ташмөхәммәт» дигәне аеруча еш очрый. «Фәтхулла хәзрәт» повесте да матбугатта «Ташмөхәммәт» имзасы белән басыла. Ислам дине әһелләре һәм буржуазия ялчылары аның бу әсәрен дә игътибарсыз калдырмыйлар, көчләреннән килгән кадәр аңа кара ягарга тырышалар. Ләкин демократ язучының ышандыру куәте шул кадәр көчле һәм кискен була ки, тәнкыйтьчеләр әсәрне тулаем кире кагарга җөрьәт итмиләр, ә аның кайбер урыннарына тукталу белән генә чикләнергә мәҗбүр булалар.

Тимербай дигән бер кеше «Фәтхулла хәзрәт» повесте турындагы мәкаләсендә («Йолдыз» газетасы, 1910 ел, 516 нчы сан) мулланы терелткәннән соң артык күп ашатканы өчен авторны гаепли.

«Вакыт» газетасында билгесез рецензент «Төшмөхәммәт»не татар тормышын артык фәкыйрь итеп сурәтләгән өчен шелтәли, аерым алганда, повестьтагы кызлар һәм егетләр биюдән башканы белмиләр, бу гына аз, хәзерге яшьләрнең дөньяга карашлары артык тар, дип чыга.

«Идарәгә мәктүбе»ндә, («Йолдыз», 1910 ел, 23 март саны) әлеге тәнкыйтьчеләргә мөрәҗәгать итеп, Ф. Әмирхан болай яза: «Тимербай әфәнде «Фәтхулла хәзрәт»нең иң әһәмиятсез җирләрен алып, шуларын тәнкыйть итә. Асыл максудны аңламаска салыша». Повестьта, ди язучы, «миңа матлуп булган нәрсә фәкать мөбарәк хәзрәтебезнең хәзинәи фикрия вә рухиясе(дер). Калганнары фәкать канва эшләүче татар кызына марляның әһәмияте кадәр генә әһәмиятледер». Фикерен тагын да ачыклый төшеп, ул болай дип өсти: «Әгәр мин «Фәтхулла хәзрәт»тә физиологический яхут тыйбби тәхлилат бирүне максуд итеп тоткан булсам иде, Тимербай әфәндене алдан ышандырып куям, хәзрәтем терелгәч тә ул кадәр иштиһа белән ашамаган булыр иде... Хәзрәтемнең рухани тормышына мин үземнән бернәрсә арттырганым юк — алар һәммәсе сыйрыф тормыштан истигарә ителгәннәр».

Ф. Әмирхан үзенең псевдонимын ачкан һәм өй адресын күрсәткән өчен Тимербайга җитди кисәтү ясый, бу әдәп кысаларына сыймый торган эш, ди.

«Ташмөхәммәт» икенче тәнкыйтьчене дә кыктән җиргә төшерә. «Татарның хәзерге язучылары, — ди ул, — каһарманнарына римский праводан лекция укытсалар, чахотка бациллалары турысында диссертация яклатсалар, Галлей койрыгындагы атмосфераның фәнни тәшрихенә даир реферат ясатсалар... менә дигән эш булыр иде; Европаны узып киткәнлегебезгә, фән мәсьәләләрендә хикәяләр белән генә хәл итәр дәрәҗәгә җиткәнлегебезгә үзебез дә хәйран калып торыр идек... Хәер, бу вакытка да ерак калмады инде».

Ничек кенә гаҗәп тоелмасын, Ф. Әмирхан адресына шундый ук гаепләрне һәм шелтәләрне патша цензорлары да ташлый. Әсәрдә рус кешеләре бөтенләй юк диләр[1], шул ук вакытта «Ташмөхәммәтнең «Фәтхулла хәзрәт»е кадимчеләргә ачы сатира»[2] булуын аңлыйлар. Ф. Әмирханның татар тәнкыйтьчеләренә җавабы аларга да кагыла. Ул киләчәкнең үзе турында түгел, ә аның аерым элементлары турында гына яза. Язучы замандашларына мөрәҗәгать итә һәм шул чагындагы чынбарлык, татар тормышы нинди материал бирсә, шулардан файдаланган. Россиянең бүтән

[1] ТҮДА. 420 фонд. 150 эш, 6—7 битләр.
[2] Шунда ук. 224 эш, 106—107 һәм 116 битләр.

халыкларында хәзрәткә ошаган бәндәләр очраса да, русларда инде андый ук Фәтхулла хәзрәт була алмаган.

Шул кадәресен дә әйтергә кирәк, 1935 елда[1] Г. Толымбайский Ф. Әмирханны, аның «Фәтхулла хәзрәт»ен нигездә шундый ук позицияләрдән чыгып тәнкыйтьли, бернинди дәлилсез аңа әллә нинди ярлыклар тага. Хәзер кемнең хаклы икәнлеген тәртеп күрсәтүнең кирәге юк, әлбәттә. «Фәтхулла хәзрәт» әсәрендә авторның фантазиясе конституцион монархиядән ары китми дигән фикерне раслар өчен, Г. Толымбайский аның икенче бер әсәренә — «Гарәфә кич төшемдә» хикәясенә мөрәҗәгать итә. Ләкин анда да тәнкыйтьченең хөкемен раслардай фактлар табып булмый.

Гомеренең соңгы елларында, авыруы нык көчәйгән көннәрдә дә, Ф. Әмирханга шактый күңелсезлекләр кичерергә туры килә. Элекке эсерлар, вульгар социологлар да аны юлаучылар сафына кертергә тырышалар, әдип турында төрле уйдырмалар тараталар. Әмма Ф. Әмирхан бервакытта да алар белән бәхәскә кермәгән. Дусларына, әгәр терелсә, «гайбәтчеләргә сөйләргә азык булмасын өчен», иң элек үзенең биографиясен язарга вәгъдә иткән[2].

Үз вакытында Ф. Әмирхан белән бергә яшәгән алдынгы карашлы кешеләр аның культура тарихындагы урынын дөрес аңлаганнар һәм иҗатына дөрес бәя биргәннәр. 1912 елда «Ялт-йолт» журналы символик матбугат күргәзмәсе оештыра. Ф. Әмирхан әлеге күргәзмәнең көмеш медаленә лаек була. Журнал редакциясе аны «хыялга бай, сүзгә оста» әдип дип бәяли[3].

Кара реакция елларында революцион-демократ Ф. Әмирхан үз юлыннан тайпылмый, абсолютизмга каршы көрәшүен дәвам итә. Ул тәрҗемәчеләр группасы оештыра. Оригиналь пьесалар авторы И. Богданов, С. Рахманколый һәм башкалар белән бергә, татар укучысына Көнбатыш Европа һәм рус классикларын — Х. Андерсен, В. Шекспир, Л. Толстой, А. Пушкин, М. Лермонтов, Н. Гоголь, И. Тургенев әсәрләрен җиткерә, Г. Тукай, С. Рәмиев, Г. Камал, Г. Коләхметовлар белән бергә русча-татарча әдәби-музыкаль кичәләрдә катнаша. Ул кичәләрдә Казан большевиклары В. Александров, В. Тихомирнов, М. Жаковларның катнашуы мәгълүм. Кыскасы, каты авыру булуына да карамастан, Ф. Әмирханның социаль һәм иҗади активлыгы һәр вакытта да ташып тора.

«Өченче көнне Каюм Коләхметовны кулга алдылар, тиз арада Себергә җибәрәләр, булдыра алсаң, акча җыеп җибәр (редакция адресына да ярый)», — дип яза ул бер дустына. Аны Уралда чыга торган «Яңа тормыш» газетасының ябылуы борчый, ул татар театрын яклау өчен көрәшә. Әдәби кичәләрдә Г. Тукайның халык алдына чыгып «Кисекбаш» поэмасын укыганлыгын шатланып хәбәр итә[4].

Г. Тукай, Г. Камал һәм башка әдипләрнең иҗаты турында менә дигән мәкаләрецензияләр язуын дәвам итә, ул «Яшен», «Ялт-йолт» журналларының сотруднигы. Ф. Әмирхан — кызыклы пьесалар һәм романнар авторы.

Ул Хөсәен Ямашев җитәкчелек иткән түгәрәккә керә. Аның белән бергә, Г. Тукай, Ф. Агиев, Габдулла һәм Бари Хәсәниләр, Г. Коләхметов һәм башкалар була. Жандармерия аларны яшерен күзәтә[5].

Жандармерия документларында ул татар яшьләренең революцион хәрәкәтен оештыручы[6] буларак теркәлә алына. Аларның яшерен җыелышларында Г. Сәйфетдиновның да катнашуы билгеле.

Патша сакчылары, Г. Коләхметов, Ф. Мөхәммәдъяров, Н. Кулиев, Ф. Агиев, Ш. Әхмеров кебек әһелләр белән бергә, Ф. Әмирханны да дәүләт өчен «куркынычлы» кешеләр исемлегенә кертәләр[7]. Ф. Әмирханның һәм Г. Тукайның дусты Вафа Бәхтияров та 1909 елның ноябреннан ук инде яшертен күзәтү астында була[8].

Үз өсләреннән күзәтеп торганнарын белеп яшәү аларга җиңел булмагандыр. Бу аларның нервларын какшаткан, авыруларын көчәйткән, гомерләрен кыскарткан...

Игътибар иткәнегез бармы икән, Ф. Әмирханның «Шәрык йоклый» дигән мәка-

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 1935 ел. 2, 3, 4, 5 саннар.
[2] «Казан утлары» журналы, 1970 ел, 8 сан, 169 бит.
[3] «Ялт-йолт» журналы, 1912 ел, 34 сан, 3—6 битләр.
[4] «Казан утлары» журналы, 1966 ел, 1 сан, 108, 110, 112 битләр.
[5] Бу турыда «Казан утлары» журналының 1966 елгы 8 санында без тапкан документаль материаллар басылган иде.
[6] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, 2848 эш, 32, 34 битләр; 3610 эш, 57 бит.
[7] Шунда ук, 3482 һәм 3484 эшләр, 199—200 битләр; 3612 эш, 32, 36, 38 h. 6. битләр.
[8] Шунда ук, 3484 эш, 199—200 битләр.

ләсе нихәтле әрнү һәм ачыну белән язылган. «Шәрык йоклый... Аның кайчандыр Ибне Синалар, Фарабилар, Ибне Рөшедләрне тудырган гакылы вә гыйльми көче йоклый...» Шул ук чагында башка халыклар, ди ул, «белмәгәннәрен өйрәнәләр, белгәннәрен гамәлгә куялар». Мәкалә йоклаган халыкларның кайчан да булса уяначакларына тирән ышаныч белән сугарылган. Иң мөһиме шунда, әдип барлык милләтләрне дә алга киткән итеп, тигез итеп күрергә тели, аларны уянырга, эшкә тотынырга өнди.

Аның «Балаларга бәйрәм» дигән мәкаләсе дә шундый ук рухта язылган. «Без бүтәннәр кебек яши, бүтәннәр кебек бәйрәм итә белмибез. Үз милләтегезне сакларга телисезме?..»

Ф. Әмирхан тәнкыйть утын панисламистларга һәм пантюркистларга каршы, калын кесәле байларга каршы юнәлдерә. Халык тормышын кызыклырак итәргә чакырулар юлы белән генә милләтчеләрнең намусын уяту, алардан кискен борылыш көтү беркатлылык булыр иде [1]. Россия буржуазиясе моны эшли алмый, бу хакта иллюзияләр кору файдасыз. Ф. Әмирхан алпавытлардан да, фабрикантлардан да һәм сәүдәгәрләрдән дә яхшылык көтмәгән, бу мәсьәләдә ул башкарак даирә кешеләренә мөрәҗәгать иткән.

1914 елның 1 январенда басылган «1913 нче елда милли эшләр» [2] дигән мәкаләсендә ул бер ел эчендә башкарылган эшләргә йомгак ясый. «Бу ел эчендә без, — ди ул, — әллә никадәр матур сүзләр сөйләдек, әллә никадәр аллы-гөлле хыял кордык, ләкин шул сөйләнгән вә хыял ителгән нәрсәләрнең уннан берсен дә эшкә чыгара алмадык, сүзләр сүз көе, хыяллар хыял көе калдылар...» Кемне гаепли ул, кемнән канәгать түгел? Болай да бик ачык — буш вәгъдәләр белән «халык күзен буяучы» татар буржуазиясен, дәүләт думасында «пыскылдап-пыскылдап... сүнгән» мөселман фракциясен гаепли. «Бу елны әдәбиятыбыз өчен ачлык елы дияргә мөмкиндер... Тукаебыз үлеп китте, Г. Камал ел буе авырып уздырды, С. Рәмиевнең бер шигырен булса да күрә алмадык. Шуңа күрә «бу бәрәкәтсез елны без бер дә кызганмыйча вә бер дә сагынмаска булып озатып калабыз», ди әдип.

Бу юлларны уку гына җитми, аның әйткәннәре турында уйланырга да кирәк. Уйлап карагыз: иҗат кешесе тулы бер ел гомерен кызганмыйча озата. Борынгы римлеләр бушка узган бер көн өчен кайгырып елаганнар.

Язучыны тулы бер ел белән шулай саубуллашырга нәрсә мәҗбүр иткән соң? Әрнүен киләчәк буыннарга да ишеттерерлек итеп, ничек ул шулай яза алган? 1913 елда гаять тантаналы шартларда Романовлар династиясенең 300 еллыгы билгеләп узылуын истән чыгармыйк.

Халык мәнфәгатьләреннән ерак торган рәсми тантанага үзеңнең кискен нәфрәтеңне әйтә белергә кирәк, моның өчен революцион батырлык кирәк (ә бит кайберәүләр Ф. Әмирханны либерал дип атарга тырышканнар иде...)

Нинди генә авыр елларда да Ф. Әмирхан киләчәккә ышанычын югалтмый. Дөрес, ул күп кенә проблемаларны ахырынача аңлап та җиткерми, кайчакта дөрес үк булмаган фикерләр дә әйтә — ул заманда һәммәсен дә тиз генә аңлап бетерү җиңел булмагандыр, күрәсең.

Әмма ул революциягә кадәрге татар әдәбиятында 1905 елгы революциянең иң яхшы традицияләрен саклый, Г. Тукай, Х. Ямашевларның истәлегенә турылыклы кала, дуслары Г. Камалга, М. Вахитовка ярдәм итә, язучылардан һәм журналистлардан яшь алмаш тәрбияли. Бу хәтта аның либерал «Кояш» газетасында басылган мәкаләләрендә дә ачык сизелә. Әлбәттә, редакциягә аның исеменә Тукай стипендиясенә дигән акчалар килә тора: Семипалатинскидан — 30 сум, Амур өлкәсеннән — 7 сум 75 тиен, Бохарадан — 88 сум 85 тиен, Астраханьнан — 8 сум һ. б. [3].

Патша династиясенең 300 еллыгын санга сукмаган әдип Т. Шевченко юбилеен котлап каршы ала һәм Киев шәһәрендә бөек язучы хөрмәтенә митинглар оештырган студентларның кулга алынуы турында хәбәр итә [4].

Ул эшли торган «Кояш» газетасы империалистик сугышка каршы чыга [5].

---

[1] «Аң» журналы, 1913 ел, 4 сан, 66 бит.
[2] «Кояш» газетасы, 1914 ел, 302 сан.
[3] «Кояш», 1914 ел, 2 апрель саны.
[4] «Кояш», 1914 елның 12 март саны.
[5] ЦГИАЛ, 821 фонд, 133 тасвирлама, 603 эш, 120 бит.

1915 елның 23 январенда Казан вице-губернаторы югары инстанцияләргә болай дип хәбәр итә: «Революция булган очракта мөселманнар нинди позициядә торырга тиешлек турында татар яшьләре арасында туктаусыз сүз бара. Социал-демократик тенденцияләр көчәя» [1].

Монда матбугатның роле шактый ачык күренә. 1916 елда Казан губерна жандармериясе идарәсе Полиция департаментына болай дип хәбәр итә: «Кояш» барлык халыкларның тигез хокуклылыгын яклаган таләпләр белән татар пролетариатына һәм интеллигенциягә мөрәҗәгать итә... Татарлар тыл эшләренә җибәрелгән өчен бунт күтәргән кыргызларның мәнфәгатьләрен дә йөрәкләренә якын кабул итәләр, кыргызларга чын күңелдән теләктәшлек белдереп, тулысынча алар ягында торалар. Күп кенә газеталарда бу вакыйга уңае белән чыккан мәкаләләр шул хакта сөйли» [2].

Хезмәт ияләре 1917 елда патша монархиясен бәреп төшерәләр. Большевиклар партиясе капиталистик стройны җимерү эшенә халык массаларын туплый, үз сафларына элек артта калган һәм изелгән милләт вәкилләрен тарта.

Революцион демократия социализмга таба беренче адымнар гына ясаган бер чорда Мулланур Вахитов революцион демократиянең эшчәнлеген тагын да югарырак баскычына күтәрә: Казанда мөселман социалистлар комитетын оештыра. Иң әйбәт язучылар, артистлар, укытучылар һәм врачлар комитетның уңай йогынтысын тоялар, милләтчеләрнең саргылт-яшел флагы астында түгел, ә пролетариатның кызыл флагы тирәсенә тупланалар. Ф. Әмирхан, Г. Камал, Г. Ибраһимов, Г. Кариев, Ш. Әхмәдиев, К. Тинчурин, Ф. Мөхәммәдъяров һәм башка бик күп талант ияләре большевикларга иярә — газета чыгаралар, митингларда һәм җыелышларда чыгышлар ясыйлар, көн темасына караган скетчларын һәм пьесаларын куялар, эшче халык театрлары һәм фронт театр труппалары оештыралар (гражданнар сугышы елларында үзләре беренче булып Кызыл Армия отрядларына язылалар). Ф. Әмирхан фамилиясен дә Казан губерна комитетына сайланган алты кандидат арасында соңыннан республиканың атказанган врачы булып киткән Әбүбәкер Терегулов [3] белән бергә күрәбез.

Чистай өязендә яшәгән айларында ул хезмәт ияләрен Совет властен якларга чакырып авылларга чыга. Җирле партия органнары аңа халык белән аралашырга мөмкинлек тудыралар, аның бик яхшы оратор булуыннан нык файдаланалар. Ул үзе дә бу кайгыртучанлыкны һәм ышанычны аңлый. М. Дулат-Алидан марксистик әдәбият, В. И. Ленинның «Пролетар революция һәм ренегат Каутский», «Совет властеның чираттагы бурычлары» һ. б. хезмәтләрен ала [4].

Ф. Әмирхан 1918 ел ахырында һәм 1919 ел башында пропаганда эшендә актив катнаша. Бөек Октябрь социалистик революциясенең бер еллыгына ул «Бүген без нәрсә бәйрәм итәбез» һәм «Яшәсен Кызыл Армия!» [5] дигән хезмәтләрне татарчага тәрҗемә итә. Яшьләрне бөтен көченә киләчәк өчен хезмәт итәргә, Совет властен ныгытырга чакыра [6]. Өлкән язучы Афзал Шамов аның белән ничек очрашуынифрат оста тасвирлый. Ул үзе һәм замандашлары Ш. Усманов, Г. Кутуй, һ. Такташ, Ф. Әмирханның татар әдәбияты тарихын бозучыларга һәм фальцификацияләүчеләргә каршы, халык шагыйре Тукайның намуслы исеме өчен көрәшен бөтен гомерләре буена истә калдыралар [7]. Андый истәлекләр бүген дә яшьләргә өйрәтә, хак эш өчен көрәшә белергә чакыра.

Ф. Әмирхан каты авырый, ләкин тормыш белән бәйләнешен беркайчан да өзми, үзенең «Хәят» әсәрен язып бетерү, актив журналистлык эшчәнлеге алып бару хыялы белән яна. Чын көрәшче буларак, ул яшьләргә Ватан өчен хезмәт итәргә, совет властен ныгытырга, «халык белән бергә барырга» васыять итә [8].

---

[1] Татарстанның Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, 3105 эш, 15 бит.
[2] Татарстанның Үзәк дәүләт архивы, 199 фонд, 3141 эш, 18—19 битләр; 3121 эш, 96 бит.
[3] «Корылтай», 1917 ел, 18 август саны.
[4] КПССның Татарстан өлкә комитеты архивы, 868 фонд, 113 эш, 66 бит.
[5] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 98 фонд, 1 тасвирлама, 62 эш.
[6] «Совет әдәбияты» журналы, 1961 ел, 1 сан, 104 бит.
[7] «Казан утлары» журналы, 1966 ел, 1 сан.
[8] «Казан утлары» журналы, 1970 ел, 8 сан, 169 бит.

Фәрит Хатипов

# ЭШЧЕ РУХЫ

КПСС ның XXV съездында Л. И. Брежнев социалистик реализм әдәбиятының производство темасын яктыртудагы зур уңышларын билгеләп узды. «Бу тема хәзер чын сәнгатьчә форма алды» [1],— диде ул. Бүгенге эшче характерын, аның рухи йөзен сәнгатьчә чагылдыру өлкәсендә татар совет әдәбиятының да мөһим өлеше бар.

Татар әдәбиятында эшче темасына караган әсәрләрнең үзләрен хәзер берничә төркемгә бүләргә мөмкин. Безнең нефтьчеләргә, төзүчеләргә, завод-фабрика эшчеләре һәм механизаторларга, шулай ук промышленностьның күп кенә бүтән тармакларында эшләүчеләргә багышланган әдәби әсәрләребез бар. Производство темасының әле бер вакытта да шундый киң фронт белән яктыртылганы юк иде. Роман, повестьларыбызның күбесе совет эшчеләренең бүгенге рухи дөньясын сурәтли, арада беренче бишьеллыклар чорында совет эшчесе формалашу процессына багышланганнары да очрый. Бүгенге язучыларыбыз совет эшчесенең күңел байлыгына тирәнрәк үтеп керергә омтылалар. Бу яктан караганда, хәзерге әсәрләр 20—30 нчы еллардагы кайбер «производство романнары»ннан шактый аерылып тора.

## I

«Акчарлаклар», «Шагыйрьнең алтын приискасында» кебек әсәрләрен язганчы, Ш. Камал белән М. Гафурига хәтсез вакытлар сезонлы эшче булып йөрергә, балыкчылар, шахтерлар арасында эшләргә туры килә. Инде соңрак чорга килсәк, И. Гази, Ә. Еники, Ш. Маннур, Г. Әпсәләмов, А. Расихлар да башта промышленностьның төрле тармакларында гади эшче булып эшлиләр, күңелләренә эшчеләр коллективы рухын сеңдерәләр. Шул тәҗрибә, яңа чор кешесенең психологиясе белән якынлык аларга «Бригадир кыз» һәм «Канатланыр чак», «Вөҗдан», «Сүнмәс утлар», «Дустым Мансур», «Агымсуларга карап» кебек тормышчан әсәрләр иҗат итәргә булыша.

Безнең байтак әсәрләрдә беренче бишьеллыклар дәверендәге хезмәт героикасы, татар эшчеләр сыйныфында, аларның психологиясендә социалистик аңлылык кебек яңа сыйфатлар бөреләнүе тасвирлана.

Ә. Еникинең «Вөҗдан» повестенда затлы мехлар эшкәртүче, каракүл бөдрәләрен «укый белүче» һәм шушы кыйммәтле мехны экспортка озатучы мишәр агайлар белән танышабыз. Автор аларны эшлекле, тыйнак һәм сабыр холыклы кешеләр итеп тасвирлый.

«Вөҗдан» — мул кичерешле, драматик киеренкелек белән сугарылган әсәр. Ул үтә тыгыз һәм җыйнак язылган булуы белән аерылып тора. Әсәрнең үзәгенә бер-

[1] «Известия» газетасы, 1976 ел, 25 февраль.

бирсен өзелеп яратучы егет белән кызның гыйшкы куелган, бу мәхәббәтнең сөенеч белән башланып, үкенеч белән тәгәлләнүе сурәтләнә. Интим мөнәсәбәтләр әхлак, производство, иҗтимагый-политик мәсьәләләр белән тыгыз бәйләнештә күрсәтелгән. Боларның һәркайсы укучы күңелендә тирән кичерешләр, катлаулы хисләр уята. Әлеге уй-хисләр, бәя-мөнәсәбәтләр агымы әсәр сюжетына драматик төс бирә.

Завод эшчеләре тормышы Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», Э. Касыймовның «Томан аша» һәм «Һаваларда тургай» романнарында яктыртылды. Әпсәләмов совет эшчесенең күңел байлыгын, рухи матурлыгын зур осталык белән ача. Геройларның үз эшләрен йөрәк җылысы салып, яратып, рухи ләззәт тоеп башкарулары, профессиональ горурлыклары гаять калку итеп сурәтләнә. Хезмәт темасы тышкы хәрәкәтләр аша гына түгел, ә бәлки эчке яктан, персонажның күңеле позициясеннән торып яктыртыла, завод тормышындагы мөһим проблемалар кешенең рухи дөньясы аркылы сурәтләнә.

Кызганычка каршы, Касыймов дилогиясе хакында алай әйтеп булмый.

Сүз дә юк, танылган бу прозаик химиклар тормышының барлык якларын да бердәй тулылык белән күрсәтергә омтыла, роман жанры, бигрәк тә дилогия формасы, моның өчен чикләнмәгән мөмкинлек бирә, дип уйлый. Бүгенге завод тормышына, эшчеләр коллективына нәрсәләр хас булса, теге яки бу күләмдә әсәрдә без шуларның һәммәсен дә очратабыз. Ләкин биредә автор иңләп булмастайны иңләргә омтыла. Нәтиҗәдә әсәрнең үзәген югалта, дилбегәне кулдан ычкындырып җибәрә. Дөрес, «Томан аша» китабының ахырына таба заводның үзәк лаборатория җитәкчесе Госман әсәрдәге барлык вакыйгаларны бер ноктага җыйнарлык проблеманы элэктереп ала кебек. Сүз җир астындагы тозлы сулардан үтә файдалы һәм арзанлы эремәләр аерып алу турында бара. «Җегәр һәм көчне, акыл һәм сәләтне һич кызганмыйча багышларга кирәк», — ди Госман. Завод җитәкчеләре, зур галимнәр дә шуны үк куәтлиләр. Икенче китапта автор тулысы белән шул мавыктыргыч көрәшне сурәтләр дип өмет итәсең. Әмма өмет акланмый. Инде икенче китап та бетеп килә, ә Госман әле һаман да көрәшнең иң җитдиен киләчәккә калдыра бара. «Аның иң зурысы, иң авыры алда бит әле...» — ди. Миңа калса, көрәшнең «иң зурысын, иң авырын», бер фокуска туплап, менә шушы утыз табаклы дилогиядә күрсәтергә кирәк иде.

Әгәр дә язучы үзенең романын, әйтик, Д. Гранинның «Искатели», «Иду на грозу» әсәрләре кебек, аерым бер проблема тирәсенә генә корса, ул җыйнаклана төшәр, әмма шуның белән бергә, романлык хасиятен югалтып, гади повестька әйләнеп калыр иде, дип әйтүләрнең дә булуы мөмкин. Әйе, андый «куркыныч» бар. Ләкин тыгыз эчтәлекле, төзек сюжетлы, киеренке повесть таркау һәм сүлпән романга караганда күп тапкыр әйбәтрәк бит. Бу очракта мәҗбүри рәвештә роман формасына иярү, аны ничек тә күп планлы, киң тармаклы итәргә тырышу һич тә жанр файдасына хезмәт итмәгән. Мөһим мәсьәләләр күтәрү, җитди фикерләр әйтү, әһәмиятле вакыйгаларны, масштаблы характерларны яктырту — һәр жанр алдына куела торган бурыч. Роман алдына исә бу бурыч тагын да ныграк зурайтылган күләмдә килеп баса. Роман жанрына хас булган эпик киңлек идея-проблематиканың зурлыгы белән кушылганда гына чын сәнгать әсәре туа.

Романның күләменә пропорциональ рәвештә аның мавыктыру-әйдәү көче дә арта барса гына, әсәр уңыш казанырга мөмкин. Э. Касыймовның бу дилогиясен укып чыгу өчен исә бик зур түземлек һәм күп вакыт кирәк. Әсәрнең үзәк бер сюжеты табылмаганга, ул бердәм ситуация белән элмәкләп алынмаганга күрә, дилогия завод тормышы хроникасы төсен алган. Эпизодларны теләгән кадәр дәвам иттерергә дә, урта бер җирдә өзеп калдырырга да була. Характерлы деталь: беренче китап буенча завод тормышының төрле яклары белән башлыча төрле экскурсоводлар гына таныштырып йөри. Хроника, иллюстрация алымы, сюжетның таркаулыгы, сүлпәнлеге геройларның күңел дөньясына үтеп керүгә дә комачаулаган. Әсәрдә сурәтләнгән хәлвакыйгалар киеренке рухи хәрәкәтне, катлаулы психологик процессны бирә алмый — димәк, әсәргә психологик сүлпәнлек хас. Дилогиянең иң зур кимчелеге — аның композицион таркаулыгында, күренеш-вакыйгаларның, картиналарның үзәккә берекмәгәнлегендә. Соңгы вакытта бу җитешсезлек безнең прозаны басып бара шикелле. Байтак роман, повестьлар сәнгать әсәре булып өешмәгән хәлдә дөньяга чыга. Шуңа күрә бу урында роман композициясенә җентеклерәк тукталырга булдык.

Роман формасы башка бер генә төрдә һәм жанрда да булмаган үзенчәлек белән — сюжет тармакларының киңлеге белән аерылып тора. Аның бу сыйфатын панорама, диорама картиналарындагы киң планлылык белән чагыштырырга мөмкин. Ләкин алардан үзгә буларак, роман масштаблылыгы дәвамлы хәрәкәт белән кушыла. Соңгы вакытта бу хасият зур масштаблы сугыш күренешләрен сурәтләгән фильмнарга күчте. Кино сәнгате сәхнә законнары белән чикләнмәгән. Менә шушы хәл фильмга хәрәкәтне иңгә һәм буйга теләгәнчә үстерү мөмкинлеген бирә.

Әмма киң тармаклылык үзмаксат түгел. Сюжетның һәрбер сызыгы чынбарлыктагы бәйләнешне чагылдыра, әсәр композициясенә шул элемтәне гәүдәләндерү чарасы буларак килеп керә.

Ләкин хәрәкәт киңлеге җәһәтеннән барлык романнар да бердәй дип әйтеп булмый. Сюжет характеры ягыннан аларны ким дигәндә ике төргә бүлеп карарга кирәк: чагыштырмача таррак сюжетлы романнар һәм киң планлы, күп тармаклы романнар. Чагыштырмача таррак сюжетлы романнарга мисал итеп, З. Бигиевның «Меңнәр яки гүзәл кыз Хәдичә», Гетеның «Яшь Вертернең газап чигүләре», Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр», Э. Касыймовның «Гомер ике килми», Г. Әпсәләмовның «Газинур», Д. Лондонның «Белый Клык» һәм «Мартин Иден» романнарын китерергә мөмкин. Киң планлы әсәрләргә Г. Ибраһимовның «Безнең көннәр», Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», Л. Толстойның «Сугыш һәм тынычлык», М. Шолоховның «Тын Дон» романнары мисал була ала. Бу ике төркем арасында тегесенә дә, монысына да якын торган романнар да була.

Роман жанрында беренче заттан сөйләү сирәк очрый. Инде шулай да вакыйгалар персонаж исеменнән хикәя ителә икән, андый роман чагыштырмача таррак сюжетлы була. Әсәрнең кысалары нигездә хикәяләүче геройның күргәннәре белән чикләнә. Моңа тагын күренешләрне аерым бер герой позициясеннән торып, аның карашы аша сурәтләү формасы якын тора. Бу ике алым җыйнаграк сюжетлар өчен кулай күренә, ә киң планлы эпопеяларда аларны эзлекле куллану мөмкин түгел, алар язучының кулын бәйли. Дөрес, персонаж позициясеннән торып тасвирлау киң планлы романнарда да очрый. Ләкин монда, сюжетның яңа тармагына күчкән саен, герой позициясе дә алмашына бара, автор сюжет тармагын үзе белән ияртеп алып киткән каһарман карашына күчә, ул күргәнчә тасвирлый башлый. «Ут һәм Су» романында Ә. Баянов байтак вакытлар буена хикәяләүне баш герой Фәез Насыйбуллин карашына кора. Әмма ул катнашмаган күренешләр турында сөйләргә кирәк булгач, вакыйганы башка геройлар карашы аркылы үткәреп тасвирлый башлый.

Проза әсәрләрендәге иң универсаль форма — автор исеменнән хикәяләү. Ул чагыштырмача таррак сюжетлы романнарда да, бик киң планлы әсәрләрдә дә бердәй уңыш белән кулланыла. Мондый формада әдип үзен аеруча иркен хис итә, автор хыялы нинди дә булса чикләүләрне белми.

Ләкин, шуның белән бергә, роман материалының бер төрле дә чиге юк дип уйлау шулай ук чынбарлыкка туры килми. Роман сурәтләгән объект никадәр генә киң, күпкырлы булмасын, ул барыбер тема белән, үзәк ситуация белән уратып, элмәкләп алынган була. Язучылар чиксез чынбарлык агымыннан аның билгеле бер этапларын, ситуацияләрен алып сурәтлиләр һәм ситуациянең чагыштырмача тәгәлләнгәнен күрсәтәләр. Әгәр дә романда сурәтләү материалының чикләре ачык тәсмерләнмәсә, ул бер үзәк ситуация белән иңләп алынмаса, мондый әсәр укучыларда канәгатьсезлек хисе уята.

Бер генә сызыклы әсәр авторы алдында ул сюжетны үзәккә җыю бурычы тормый, бер сызык үзе шул үзәкне тәшкил итә. Романда исә иңгә җәелү тенденциясе һәр вакытта да үзәккә тартылу тенденциясе белән кушыла. Һәрбер тармаклану үзәкне ныгытуга хезмәт итә. Һәрбер композицион төзек романның үзәге, умыртка баганасы, Ф. Хөсни әйтмешли, фарватеры була. Киң планлылыкка омтылыш арткан саен, шуңа пропорциональ рәвештә, үзәккә җыю көче дә арта бара. Эпик масштаблылык чынбарлыкны киңрәк иңләү, тормыштагы катлаулы бәйләнешләрне чагылдырырга омтылу җирлегендә туган. Моның киресе буларак, үзәккә тартылу әлеге киң планлылыкка бердәмлек, бөтенлек бирү, үзәккә беркетү ниятеннән чыгып барлыкка килгән.

Шунысын да истән чыгармаска кирәк, киңлеккә җәелү һәм үзәккә берегү тенденцияләренең берләшүен без әдәбиятның бары тик роман жанрында гына очратабыз.

II

Әгәр психологизм турында сүз йөртәбез икән, бу очракта без сюжетның, вакыйга белән генә чикләнмичә, күңел хәрәкәте белән үрелүен, ягъни әдәбият үсешенең шактый югары этабын, рухи тормышны эстетик үзләштергән дәверен күздә тотабыз. Хәзер психологик яктан киеренке сюжетлы әсәрләр табигый күренеш, норма дип кабул ителә. Мондый әсәрләрдә конфликтларның көчләре психологик өлкәдә туа.

Соңгы елларда илебездә һәм шул исәптән Татарстан җирендә зур төзелешләр күбәйде. Шуларга бәйле рәвештә төзүчеләр хакында язылган роман, повестьлар саны да артты.

Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романындагы төп каршылыклар тормышны, хезмәтне төрлечә аңлаудан килеп чыга. КамГЭС баш идарәсе управляющие Анатолий Самойлович Лазарев, төзү-монтаж идарәсе управляющие Фәез Насыйбуллиннар төзү эшләрен оештыруда традицион энтузиазмга, романтикага, героикага нык таяналар, производствода өзеклек килеп чыкмасын өчен актив оештыру чаралары күрәләр. Автор аларның холык-фигыльләрендәге уртак якларга басым ясый. Әсәрдә бигрәк тә Фәез Насыйбуллин образы җентекле эшләнгән. Күренеш-вакыйгалар, кешеләр нигездә аның карашы аркылы бәяләнә. Әсәрне үзәккә берләштерүдә моның нинди роль уйнавын алдарак күреп үткән идек инде. Язучы кайсы герой карашына нигезләнеп хикәяләсә, шул геройның рухи тормышы да тирәннән һәм җентекле яктыртыла, аның уй-хисләре үзенең табигый агышында бирелә. Чөнки герой үзенең күңел тибрәнешен ничек тоя, шулай сөйли.

«Ут һәм Су» романында Фәез Насыйбуллин рухи яктан шактый бай, төпле фикер йөртүче кеше итеп бирелә. Бу ягы белән Ә. Баянов герое без күрергә күнеккән образлардан нык аерылып тора. Ш. Бикчуринның «Каты токым» романындагы нефтьчеләр кебек, Фәез дә үз эшенең зур нәтиҗәләрен күз алдына китерә. Төзүче кеше турыдан-туры табигать белән мөнәсәбәткә керә, табигатькә җитди үзгәрешләр кертә. Фәезне төзеләсе шәһәрләрнең матурлыгы, уңайлыгы турындагы мәсьәлә борчый. Кешенең табигатькә йогынтысы уйсыз-исәпсез, берьяклы гына булмасын, башта күз күреп җиткермәгән нәрсәләр өчен соңыннан үкенерлек булмасын ди. Ул җәмгыятьнең зур байлыгы, яшәү чыганагы булган табигатькә үтә сак мөнәсәбәт кирәклеген искәртә. Фәез галәм, тормыш, тирә-юнь, аңа йогынты ясау турында уйлана. «Булдыксыз промышленниклар дистәләрчә мең кеше психологиясенә яман тәэсир ясыйлар, елгаларны, күлләрне генә түгел, күңелләрне-җаннарны пычраталар»,— дип пошына. Автор Фәезне киң карашлы, кыю, туры сүзле, саф күңелле заман герое итеп сурәтли.

Хикәя итү башлыча Фәез карашына нигезләнеп алып барылганлыктан, башка геройларның характеры, рухи дөньясы аңа күренгән дәрәҗәдә генә яктыртыла, ягъни автор аларның күңел түрләренә, эчке дөньяларына үтеп керми, тышкы психологик чагылыш белән чикләнә. Аның герое Фәез башка кешеләр халәте турында тик фараз гына итә. Ул фараз дөрес булырга, якынча гына туры килергә яки дөреслеккә бөтенләй туры килмәскә мөмкин. Шуңа күрә хикәяләүнең мондый төрендә: «Башкалар ни уйлыйдыр, әйтү кыен» рәвешендәге җөмләләр еш очрый.

Романда Фәездән кала тагын баш идарә инженеры Казимир Романович Лебедев һәм участок начальнигы Борис Филиновларның рухи дөньясы шактый тирән ачыла. Алар — бер типтагы инженерлар, иҗади фикер йөртүче, төзү эшләрен фәнни, ритмик нигезгә корырга омтылучы җитәкчеләр, рационализаторлар. Бу образлар аркылы җитәкче характеры, аның рухи байлыгы, күңел киңлеге, җитәкчелеккә фән-техника прогрессының йогынтысы, кеше һәм төзелеш арасындагы мөнәсәбәт мәсьәләләре күтәрелә. Әсәрнең башында һәм бигрәк тә ахырына таба язучы әлеге талантлы белгечләргә карата укучыда симпатия уятырга тели. Ләкин алар шактый катлаулы һәм каршылыклы образлар. Борис Филиновны алып карыйк. Бер яктан, ул зур төзелешләрдә катнашкан гаять тәҗрибәле һәм талантлы инженер. Икенче яктан, аның характерында без совет кешеләренә хас булмаган күп кенә начар сыйфатлар очратабыз. Һәр рационализаторлык тәкъдиме өчен бик күп акча даулый. Борис сәгате

тулу белән эшеннән китеп бара, шуның аркасында бик җитди брак ясауга юл куя. Ахырдан Лебедев белән аны казна хисабына төзәтәләр. Борис Филинов дусты Фәез Насыйбуллин өстенә нахакка бик зур гаеп ташлый, Пичугинның үлүен куанып көтә һ. б.

Тагын баш идарә управляющие Анатолий Самойлович Лазарев белән баш инженер Казимир Романович Лебедев арасындагы конфликт игътибарны үзенә тарта. Каршылык квартиралар төзүгә төрлечә караш җирлегендә туа. Управляющий Лазарев бер салганда гомергә торырлык таш йортлар кору ягында, ә инженер Лебедев, төзелешкә килгән һәр семьяны квартира белән тәэмин итү өчен, вакытлыча бараклар, бер катлы агач йортлар җиткерү яклы. Автор баштарак Лебедев ягын куәтли. Ләкин моңа укучыны ышандырып җиткерә алмый. Беренчедән, Лебедев тәкъдиме экономик нигезле түгел, икенчедән, вакытлы бараклар салу зур йортлар төзүдән тизрәк түгел бит. Ахырдан Лазарев тәкъдиме җиңеп чыга: йортлар төзү комбинаты оештырыла, ул иң төп индустриаль үзәккә әйләнә, төзелешнең колачы бик нык киңәя. Әмма роман ахырында автор Лазаревны укучыларга иң яман кеше итеп күрсәтергә тырыша. Тик бу омтылыш шулай ук психологик һәм художество ягыннан нигезләнмәгән килеш кала.

Кыскасы, Ә. Баянов образлар сызганда ак һәм кара төсләр белән генә эш итми. Ул еш кына интеллектуаль сыйфатларга игътибар юнәлтә. Характер үсешенә кителмәгән борылышлар кертеп җибәрә. Әмма бу борылышлар кайчак логик яктан дәлилләнмәгән килеш кала. Кайбер кызыклы фикерләр вакыйгаларның үзләреннән килеп чыкмый.

Безнең бүгенге прозада, аерым алганда, Ә. Еники, Г. Әпсәләмов, Ә. Баянов әсәрләрендә сүзсез бәхәсләргә, караш, күңел дуэленә иркен урын бирелә. «Ут һәм Су»-да полемика кеше белән бүре арасында бара. Бәхәс табигатьтәге гармония, кайбер очракларда табигать гармониясенең кеше тарафыннан бозылуы кебек бик җитди мәсьәләләр хакында бара. Табигать, җәнлекләр исеменнән сөйләүче бүре зирәк акыл иясе итеп бирелә. Ә кеше, үз куәте, зиһене белән масаеп китеп, үтә примитив фикерләр әйтеп ташлый: «Иртәгә миңа табигать бирә торган мех, ефәкне, җитен һәм киндерне, каучук һәм мамыкны, агачны һәм металлны, табигый буяуларны химия дигән тылсымлы көч бирәчәк. Хайванның тиресен тунау кирәк булмаган кебек, иртәгә миңа аның тәнен кимерүнең дә кирәге булмаячак. Минем табынымда үз кулым белән ясаган аксым, үз кулым белән ясаган май, үз кулым белән ясаган шикәр һәм башка әйберләр булачак».

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, Ә. Баянов хикәяләүне баш герой Фәез Насыйбуллин исеменнән алып бара. Шуңа күрә әсәрдәге калган геройлар арасындагы психологик көрәшне «күзәтү эше» дә аңа тапшырылган. «Шулай озак кына утыргач, Фәез Коля белән Борисның сүзсез дуэлен сизә башлады. Коля тегеңә әллә нинди кызганыч бер ачу белән — үзенең тора алмавын, көчсезлеген тоюдандыр бәлки — әледәнәле усал караш ташлый. Бориска уңайсыз, ул башын аска ия, читкә борыла яки аратирә Коляның үтергеч карашын күреп, аңа көйрәп торган күзләре белән текәлә... Фәез белә: бу — рәхимсез дуэль, карашлар, күзләр сугышы. Кылычлар чыңлаган тавышлар ишетелгәндәй тоела... Әйтерсең Борис чигенә һәм, кысрыклана башлагач, тагын алга ыргыла».

Алдагы мисалда күңел көрәше бөтен конкретлыгы белән эчке яктан күрсәтелә, процессның үзе яктыртыла иде, соңгысында күзәтүче Фәез үзенең күз карашына эләккән тышкы психологик чагылыш детальләрен генә хәбәр итә. Рухи процессны эчке яктан күрсәтү белән аның тышкы чагылышын бирү арасындагы аерма әнә шуннан гыйбарәт. Ләкин, инде әйткәнчә, күзәтүче герой позициясеннән торып тасвирлау принцибы «Ут һәм Су» романында ахыргача эзлекле сакланмаган. Фәез катнашмаган вакыйгаларны сөйләргә кирәк булганда автор дилбегәне үз кулына ала.

### III

Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү, зур тизлекләр өчен көрәш производство темасына караган барлык роман-повестьларда диярлек үзәк проблема буларак яктыртыла. Эшчеләр, инженер-техник хезмәткәрләр моңа вакытның кадерен белү, иҗа-

ди эзләнү, яңа технологик алымнар куллану, эшне тәгәл һәм пөхтә оештыру ярдәмендә ирешәләр. Бүгенге эшчеләрнең рухи дөньясын характерлауда иҗади моментка зур гына урын бирелә һәм монда җәмгыятьнең тирән мәгънәле җитди социаль казанышы чагыла. Г. Ахунов, Ә. Баянов һәм башка язучылар тотрыклы ритм, ныклы график белән эшләүне яклап чыгалар һәм зарарлы кабалануга, производствоны һәм кеше җанын даими киеренке хәлдә тотуга каршы төшәләр.

Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да» повесте КамАЗ тезүчеләре, шоферлар образын сурәтләүгә багышланган. Тема җитди, яңа, шул ук вакытта автор өчен таныш һәм якын.

Чөнки М. Хәбибуллин үзе байтак еллар шофер булып эшләгән кеше. Повестьта без шушы авыр һәм катлаулы профессия кешеләренең тормышын, осталыгын кыен юлларда, критик моментларда үзара ярдәмләшүен күрсәткән байтак уңышлы сәхифәләрне очратабыз. Аның геройлары юлны, машинаны һәм шулай ук тизлекне күңелләре белән тоялар. Тизлеккә омтылыш — шофер рухының аерылмас бер сыйфаты. КамАЗ комплексының масштабы белән генә түгел, төзелү темпы белән дә тиңсез булуын искә алсак, кешеләрнең дәртле омтылышын сурәтләү бик табигый иканлеге күренер.

Әмма хезмәт җитештерүчәнлеген аңлау һәм аңлату мәсьәләсендә М. Хәбибуллин повесте Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Ә. Баянов язганнардан шактый нык аерыла. Бу мәсьәләдә ул моңарчы язылган әсәрләр белән полемикага керә кебек. Язучы ударник шоферлар хезмәтен айлар, еллар буена дәвам итә торган көндәлек сабыр-тыныч эш итеп түгел, вакытның кадерен белү, машинаны даими карап йөрү нәтиҗәсе итеп түгел, кыска вакытлы узышу, балкып алу рәвешендә күз алдына китерә. Әсәрнең төп уңай герое Зөлфәт алга чыгу, ике план бирү өчен, машинасының да тизлеген ике тапкырга диярлек арттыра, карлы юлдагы машинаны йөкле МАЗ белән 110 чакрым тизлектә узып китә, борылмада 60 километр бирә. Авыр балласт төягән МАЗның мондый тизлек бирә алу-алмавына кагылып тормастан, бу фактны берничә аспектта карарга мөмкин. МАЗ — тиз йөрешле җиңел машина түгел, аның дизель моторы да, башка частьлары да зур тизлек режимына көйләнмәгән. Әгәр аңа көчләп яңа режим бирәсең икән, машина бик тиз туза, сафтан чыга. Биредә әле безне, моннан да бигрәк, шоферның психологик халәте кызыксындыра. Мондый гадәттән тыш зур тизлектә реакция җитезлеген саклау өчен, шофер үзен үтә киеренке хәлдә тотарга тиеш була һәм нәтиҗәдә аның нервылары бик тиз арып кала, сизгерлеге, эшләү сәләте кими.

Дөрес, автомобиль — тиз йөрешле, аеруча киң таралган һәм әле һаман да ишәя-арта бара торган универсаль транспорт төре. Шул ук вакытта, сер түгел, тиешле тәртип-саклык җитмәгәндә, ул — җитди генә хәвеф чыганагы да. Бу ягы белән ул җәмгыять алдына бик үткен проблема китереп куя. Аның тискәре нәтиҗәсен киметү өчен көрәш дәүләт күләмендәге мөһим бурычлардан санала.

М. Хәбибуллин исә бу мәсьәләгә берьяклырак карый. Аның уңай геройлары юл йөрү кагыйдәләре белән артык исәпләшеп тормыйлар, хәтәр ситуацияләр тудыралар, авария чигендә йөриләр. һәм моның өчен автохуҗалык җитәкчелегеннән шелтә алмыйлар гына түгел, киресенчә, эштә югарырак күтәреләләр. Ә тәнкыйть чыбыгы тәртип бозмаган, ләкин акрын-иплебрәк йөргән шоферга эләгә. Кыскасы, әгәр дә реаль тормыштагы шофер әсәрнең уңай геройлары үрнәгендә эшли башласа, я шул ук көнне ГАИга эләгә яки авариягә юлыга. Еш кына безнең язучылар ГАИ хезмәткәрләренең күпьеллык сабыр, тырыш хезмәт нәтиҗәләрен бер селтәнүдә юкка чыгарып ташлыйлар. Машинада шоферларның әчеп йөрүләрен, авария ситуацияләре тудыруларын гадәти күренеш итеп сурәтлиләр. Кайбер авторлар хәтта хәлләрне гадиләштерүгә кадәр барып җитәләр. Аларның геройлары больницага, яңа гына бала тапкан анага күчтәнәч итеп, кызыл аракы, коньяк алып киләләр, шәфкать туташлары, врачлар шул аракыны үз куллары белән авыру анага илтеп тапшыралар.

Проза әсәрләрен тикшерүгә багышланган бер докладында Р. Төхфәтуллин: «Былтыргы проза әсәрләрендә сюжет вакыйга киеренкелегенә корылган»[1],— диган иде. Аның бу фикерен тагын да конкретлаштыра төшеп, болай дип өстәргә мөмкин: тор-

[1] «Казан утлары» журналы, 1969 ел, 6 сан, 141 бит.

мышны өстән-өстән яктырткан роман-повестьларда эчке драматизмны хәвефле хәлләр тезмәсе алыштыра бара. Авторлар сюжет киеренкелеген хәвефле хәлләр эченнән эзлиләр.

Әйткәнемчә, М. Хәбибуллин повесте — ил игътибарына лаеклы төзелеш турында. Шундый зур төзелештә киеренке вакыйгалар тезмәсе китереп чыгарыр өчен, автор иң әүвәл производство ритмын җимереп ташлый. Зур өмә оештырырга ике көн калган, шунда тимер балкаларның юклыгы, аларның Казанда булуы исләренә төшә. Эшне тиешенчә план нигезендә оештырмаганда, бары тик нервылар киеренкелегенә, штурмга корганда, беркадәр алгарак карап, перспективаны күздә тотып җитәкчелек итмәгәндә, әйтелгән кимчелекләрнең бөтенесе дә булырга мөмкин. Ләкин ул чагында аларны табигый хәл итеп түгел, кимчелек итеп сурәтләргә, җитешсезлекне китереп чыгарган сәбәпләрне ачып салырга кирәк иде.

Автор физика, механика законнары белән дә шактый иркен эш итә. Тау менгәндә көч килгәч, Зөлфәт машинасының көйсез моторы сүнеп калмый, нишләптер муфта янып чыга. Югыйсә, аңа кадәр муфта турында, аның тузган булуы турында сүз дә чыкканы юк иде.

«Айлар буе төкерек җиргә төшмәстәй салкыннар торды», дип раслый әсәрнең герое Ислам. Димәк, калын боз катарлык суык та, вакыт та җитәрлек булган. Һәм, чыннан да, Казаннан балкалар алып кайтучы утыз КрАЗның егерме тугызы шул боз аркылы хәвеф-хәтәрсез, исән-имин чыгып китәләр. Тик берәве генә боз астына китә. Әмма менә шушы берсе баткач, калган егерме тугызының батмавы яки егерме тугыз батмагач, берсенең убылуы аңлашылып җитми.

Машина бату күренеше А. Чаковскийның «Блокада» романында да тасвирлана. Анда, машина суга күмелгәнче, кузовындагы капчыкларын бушатып бетерә язалар. Машина акрын гына бата. Ә «Тау белән тау очрашмаса да...» повестенда боз ярылу белән «машина упкынга, су төбенә оча». «Кабина түбәсенә бәрелү»дән Исламның башы ярыла, ул аңын югалта. Әмма ни өчен бәрелә — бу сорау җавапсыз кала. Ике әсәрдәге хәлләрнең кайсына ышанырга да белмисең...

Инде килеп тагын бер әсәргә — Мәхмүт Хәсәновның «Кама автомобиль заводын төзүчеләр тормышын» сурәтләргә вәгъдә иткән «Кама таңнары» романына тукталып узыйк. Мәгълүм булганча, бу роман, «Казан утлары» журналында басылганнан соң, нәшриятта аерым китап булып чыкты. Журнал вариантында семья мөнәсәбәтләре генә алынган, китапка исә беркадәр производство мәсьәләләре дә китереп кушылган. Ләкин асылда без китап вариантында да КамАЗ төзелешен һәм аның төзүчеләрен күрмибез. Әсәрнең баш герое Имам Хисамович Котдусов бөтен роман буена командировкада йөри, берсеннән кайта, икенчесенә китә. Командировкадан бушаган арада елга буйларында, болыннарда, авыл басуларында йөреп күңел ача. Укучыга аның нәрсә өчен хезмәт хакы алганлыгы да аңлашылып җитми. Конкрет эшне сурәтлисе урында автор гомуми сүзләр белән чикләнә: «ул яңалык», «ул ысул», «ул мәсьәлә»; «Эшне тулы мәгънәсе белән җайга салдык»; «Дөнья чаклы эш. Өйгә дә чертежлар, схемалар ияреп кайта»; «Бер яңалыкны производствога кертеп, бөтен союзга яңгырадык»; «Моңарчы илебездә күрелмәгән, гомумән зур төзелешләр практикасында булмаган бер яңа ысул кулланылды»; «Ул тәкъдим телгә кергәнгә дә бик аз вакыт үтте бит әле»; «Төзелештә сәгатьлек график керту өчен оптималь вариант хәзерләп бирдек» һ. б. Бу гомум сүзләрнең берсенең дә конкрет эчтәлеге ачылмаган, җанлы картиналарга күчерелмәгән. Автор биредә кемне сурәтләгәнен дә ачыкламаган — төзүчеме ул, әллә конструктормы? Әсәрнең уңай дип тәкъдим ителгән геройлары төзелеш мәйданына якын килү белән адашып калалар. Котдусовның яраткан яшь коллегасы Соснов җаваплы киңәшмәдә болай дип сөйли: промбазада «кранчы завод өчен кирәк панельне яки блокны түгел, шунда ачыклыкта, якын-тирәдә яткан берәр тимер-бетон конструкциясен машинага сала да җибәрә». Җитәкчеләр бу хәбәрне шактый тыныч кабул итәләр. Генеральный директор «Без аларны, әлбәттә, исәпкә алырбыз»,— дию белән бетерә. Хәлбуки, тормышта мондый хәлнең булуына ышану бик кыен. Бу рәвешле гомумән нәрсә дә булса төзү мөмкин түгел.

Күңел дөньясын сурәтләү мәсьәләсенә бездә төрле тәнкыйтьче төрлечә карый. Кайберләребез аны кеше психологиясендә казыну дип атый, икенчеләребез рухи хәяткә тирәнрәк үтеп керә алмаган өчен борчыла. Ләкин нинди генә позиция билә-

мә, бер хакыйкать ачык: тышкы вакыйгаларны гына чагылдыру — ул герой тормышының ярты ягы белән генә чикләнү дигән сүз. Әгәр дә Соснов сөйләгән хәлләр кайда да булса урын алган икән, автор мондый шәригатькә хилаф күренешнең эчке пружинасын, механизмын ачып күрсәтергә, аны психологик нигезләргә тиеш иде. Чыннан да, кирәкле детальләрне тәямичә, кирәксезен салып җибәрү кранчыга нинди файда бирә, мондый психология нинди җирлектә туган? Тәзүчеләр ничек моның белән килешеп яшиләр?..

«Тау белән тау очрашмаса да...» повестенда Зөлфәт үз машинасының моторы тартмаганын да, шул мотор белән тауга менәсе барын да яхшы белә, шулай булса да балластны нормадан уздырып салдыра. Бу очракта безгә автор нияте генә аңлашыла: аңа тау менгәндә киеренке ситуация тудырырга кирәк. Ә менә нәрсә уйлый аның герое? Күңеленнән нинди хисләр, кичерешләр үтеп китә? Шуларга психологик нигезле, дәлилле җаваплар тапканда гына без геройларның сәер эш-хәрәкәтләрен кабул итә алабыз.

«Кама таңнары»ның икенче бер герое «электрон-хисаплау үзәге тарафыннан тәкъдим ителгән» алымны, «төзелешне фәнни рельсларга» күчерүне түбәндәгечә «күзаллый»: «Төзелеш мәйданына китерелгән блоклар, панельләр, тимер-бетон конструкцияләр машиналардан җиргә бушатылып тормый, кран ярдәмендә турыдантуры өскә, тиешле урынга бирелә». Шулай итеп, машиналар блокларны урнаштырганны, монтажлаганны көтеп торалар. Кран саклап бик күп вакыт бушка узганлыктан, әлек бер шофер китереп өлгерткән материалны хәзер берничә машина ташырга мәҗбүр була, йөк ташу эшләренең үзкыйммәте шактый арта, шоферның хезмәт хакы кими. Әсәрдә бу тәкъдим бертөрле каршылыкка да очрамый, экономик һәм психологик нигезләнми дә. Шушы «яңалыкны» тәкъдим иткән кеше безнең күз алдына рухи ярлы, примитив фикерле, производствоны белмәүче дилетант кыяфәтендә килеп баса. Хәлбуки, автор аны уңай герой дип тәкъдим итә. Каян килә бу каршылык? Минемчә, авторның үзе тасвирлый торган өлкәне җитәрлек дәрәҗәдә үзләштермәгәнлегеннән, аның рухына, асылына, спецификасына үтеп кермәгәнлегеннән, чынбарлык күренеше язучының үз стихиясенә әверелмәгәнлектән килә. Шуңа күрә дә автор персонажларын, ул-бу булмагае дип, төзелештән мөмкин кадәр читтәрәк тотарга тырыша. Чөнки фән һәм техника революциясе производство операцияләренең шактый катлаулануына китерә, бүгенге эшчедән тирән интеллектуаль әзерлек сорый. Эшнең үзенчәлеген җитәрлек белмәгән очракта язучыларыбыз өстән-өстәнрәк йөзүне хәерлерәк күрәләр, аның үзәгенә, асылына барып җитәргә тырышмыйлар. Тәнкыйтьтә еш кына язучы производствоны белергә һәм аны әсәрләрендә күрсәтергә тиешме, дигән сорау куела. Һәм гадәттә художник өчен производстводан да бигрәк кеше рухын сурәтләү мөһим дигән җавап алына. Иң әүвәл мондый сорау үзе сәеррәк, тормышны белергә кирәкме, белмәсәң дә ярыймы дигән кебегрәк яңгырый. Кузгаткан темаңны профессиональ югарылыкта, шул профиль кешесе дәрәҗәсендә белү — язучының бурычы һәм элементар шарты бит ул. Икенчедән, производство белән кеше рухы бер-берсенә бәйле күренешләр, производство нечкәлекләрен, серләрен яхшылап төшенми торып, профессиональ психологияне тәгәл күз алдына китерү мөмкин түгел. Әгәр дә художник промышленность, төзелешнең билгеле бер тармагын, хезмәт процессын бөтен нечкәлекләренә кадәр өйрәнсә, аның күз алдында кеше күңеленең дә гаҗәп үзенчәлекле яклары ачылып китәчәк. Андый танышлык, компонентлык юк икән, фактлар распаганча, рухи дөнья да бикле хәлдә калачак.

Бездә еш кына шулай килеп чыга, әсәрнең герое зәмһәрир салкыннарында машинасын ачык һавада калдырып китә, суын агызу турында уйламый да, килүенә блок та, радиатор да исән, шофер утыра да китә. Икенчеләрендә исә, киресенчә, җәйге чиләдә дә шоферыбыз машинасына су салып кузгала. Язучы моның сәбәбен, психологик ягын ачып тормый. Кыскасы, яхшы әсәр тудыру өчен язучының үзе сурәтли торган тормыш өлкәсен тирән белүе мәҗбүри икән.

Шуның белән бергә, без сәнгать дәреслегенә, төгәллеккә ирешүдә технологик грамоталылыкның үзенең генә ролен абсолютлаштырырга да теләмибез. Күреп киттек, кайбер язучыларны производство процессын белмәүдә һич тә гаепләп булмый. Әмма әсәрләре сәнгать югарылыгына күтәрелеп җитмәгән. Профессиональ

компонентлык — ул чынбарлык турындагы белемнең бер дәрәҗәсе, бер тигезлеге. Моннан тыш әле язучы булган кешедән тормыш, җәмгыять, аның закончалыклары, кешенең характеры, рухи дөньясы турында тирән фәлсәфи белем, киң караш таләп ителә, күренешнең асылына үтеп керү һәм шуларны сәнгатьчә гәүдәләндерү осталыгы сорала. Сурәтләнгән хәл-вакыйгаларның, тойгы-кичерешләрнең очы-очка ялганмавы, берсен икенчесе юкка чыгаруы, әлбәттә, әнә шундый киң карашның җитмәвеннән килеп чыга.

Совет әдәбияты өчен социаль бәрелешләрнең героикасын һәм драматизмын реаль тасвирлау хас. Безнең әсәрләрдә революцион көрәшләрнең күп корбаннар тартып алуы, гүзәл гомерләрне кисеп калдыруы тормыштагыча күрсәтелә. Трагик финал укучы хисенә тирән йогынты ясый. Башлыча әнә шул психологик тәэсирне күздә тотып булса кирәк, фаҗигале-героик хәлләрне сурәтләү традициясе һич тә кӧтелмәгәндә тыныч төзелеш турындагы әсәрләргә күчерелә. Язучылар гүяки хезмәт шартларында геройның характерын, рухи матурлыгын ачу мөмкинлегенә ышанмыйчарак карыйлар, шуңа күрә үтә киеренке ясалма хәлләр китереп чыгаралар. Хәтта бер ел эчендә «басылган өч әсәрдә, сюжет үстерү алымы буларак, авария кулланыла», дип билгеләп үтә Р. Мостафин. Эшчеләр тематикасына язылган роман-повестьларда авария нәтиҗәсендә үлү күренешләре байтак очрый. Кызганычка каршы, производство технологиясенең бозылуы, планлаштыру, тәэмин итүдәге кимчелекләр, ватылу-җимерелү фактлары әле тормышта булып тора. Ләкин, минем аңлавымча, язучының бурычы фактны теркәп, укучының күз яшен сыгып чыгару белән генә тәгәлләнми. Авария — социалистик җәмгыять өчен норма түгел, бәлки нормадан тайпылыш нәтиҗәсе. Әгәр дә һәлакәткә китергән аварияне сурәтләргә керешкәнсең икән, синең әсәрең иң әүвәл ватылу-җимерелүне тудырган сәбәпләрне җентекләп тикшерүгә һәм алга таба аларны булдырмау юлларын ачыклауга юнәлтелергә тиеш. Кыскасы, язучы авария темасын бары тик аварияга каршы көрәшүче буларак күтәрә. Кызганычка каршы, безнең роман, повестьларда мәсьәләнең нәкъ менә шушы иҗтимагый мөһим ягы искә алынмый. Ачы үкенечле вакыйгалар ничектер табигыйгадәти күренеш буларак бирелә, конкрет сәбәп бик өстә ятканлыгы күренеп торган хәлдә дә, кем гаебе белән эшләнгәнлеге ачылмый кала. Ә бит сәнгатьнең гомумиләштерү сыйфаты бар. Безнең әсәрләр буенча фикер йөртеп, кайбер укучыларда ялгыш караш калырга мөмкин.

Соңгы вакытта безнең әсәрләр, оператив рәвештә русчага тәрҗемә ителеп, Мәскәү нәшриятлары аркылы тагын да киңрәк аудиториягә тәкъдим ителә башлады. Алар арасында чын мәгънәсендә горурлык тойгысы уята торганнары да бар. Шуның белән бергә, кайберләре өчен уңайсызлык хисе кичерәсең. Чөнки алар әдәбиятыбызның йөзен берьяклырак чагылдыралар. Безгә бу хакта да ныклап уйланырга кирәк.

# ТИРӘННӘН АЛЫП...

Күренекле әдәбият галиме Гали Халитның узган ел чыккан «Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән»[1] дигән китабында Г. Тукай, Г. Камал, Ш. Камал, М. Фәйзи, Ф. Бурнаш, Г. Ибраһимов, Һ. Такташ, Ф. Кәрим, М. Җәлил, Ә. Еники, Ф. Хөсни кебек танылган шагыйрь, прозаик һәм драматургларның исемнәре бергә килеп очраша, татар әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе традиция һәм новаторлык мәсьәләләре тирәсендә бер җепкә тезелә. Кем турында гына язмасын, нинди генә проблеманы тикшермәсен — аларның барысында да галимнең киң эрудициясе, совет әдәбият белеме казанышлары югарылыгында торып фикер йөртүе чагылып бара. Ул әдәбият фәне өлкәсендә яшәп килгән кайбер иске карашларны тәнкыйть күзлегеннән үткәрә, фәнни анализның перспектив яңа ысулларын тәкъдим итә.

Китап Г. Тукай иҗатына багышланган тирән эчтәлекле мәкалә белән ачыла. Бу аңлашыла да. Чөнки XX гасыр татар әдәбиятын бер генә мизгелгә дә Г. Тукайның бөек мирасыннан аерып карау мөмкин түгел. Без бүген дә үзебезнең һәр әдәби адымыбызны Тукай белән үлчәргә, аның бөтен дөнья әдәбияты югарылыгында яңгыраган шигъри тавышына колак салырга тиешбез. Гали Халит — халык шагыйре иҗатын өйрәнүгә күп көч куйган абруйлы галимнәребезнең берсе. Аның «Шагыйрь тавышы» исемле мәкаләсе — Г. Тукай турындагы күп еллык эзләнүләренең нәтиҗәсе ул. Тукай иҗатының социологик асылына, сәнгатьчә фикерләү үзенчәлегенә галим тагын да тирәнрәк үтеп кергән, моңарчы күләгәдәрәк калган яисә бөтенләй игътибар ителмәгән мәсьәләләргә тукталган. Гали Халит аның революцион үзгәрешләр чорында туган гражданин, көрәшче шагыйрь икәнен раслый, Тукай поэзиясендәге тарихи оптимизм, гуманизм, халыкчанлык һәм реализмның чыганакларын барлый, үз халкының иҗтимагый аңын тәрбияләүдә шагыйрь мирасының әһәмиятен ача.

Революциягә кадәрге татар тормышы үзенең бөтен катлаулылыгы белән Тукай әсәрләрендә чагылыш тапты. Аның шигъри адымына тиңдәшсез новаторлык, заман белән бергә атлау, Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәбиятлары традицияләренә иҗади якын килү хас. Чыннан да, Гали Халит әйткәнчә, «төрки поэзия тарихында беренче мәртәбә дияргә мөмкин, аның иҗатында Көнчыгыш һәм Көнбатыш шигъри традицияләре берберсе белән очрашып, тыгыз мөнәсәбәткә, бәйләнешкә керделәр, бер-берсеннән аерылмаслык эретмә, синтез хасил иттеләр» (11 бит).

Мәкаләдә Көнбатыш һәм Көнчыгыш әдәбиятлары синтезы мәсьәләсе иҗат методлары, әдәби жанрлар, шигырь төзелешенең төрле аспектлары җирлегендә тикшерелә. Моңарчы халык шагыйре турындагы хезмәтләрдә аның реалистлыгына игътибар ителде, ә романтизмы читтәрәк кала килде. Гали Халит шагыйрь иҗатында романтик башлангычның да зур урын алып торуын һәм аның киләчәктә тагы да тирәнрәк өйрәнелергә тиешлеген әйтә. Әле унынчы елларда ук күренекле төрек әдәбиятчысы Фуат Көпрүлүзадә Тукайның кыска гына иҗат чорында немец романтиклары дәрәҗәсенә күтәрелүе турында язган иде («Төрек йорты», 1914 ел, 4 кисәк, 6 сан, 514 бит). Гали Халит фикеренең әһәмияте шунда, ул реалист Тукайны романтик Тукайдан аерып карарга ярамый, ди. «Шунысы... бәхәссез, дип яза ул, — бу ике иҗат методы татар шагыйре мирасында беренче мәртәбә тыгыз мөнәсәбәткә кереп, бер-берсеннән аерылмас башлангыч тәшкил иттеләр һәм милли поэзиянең үсешендә яңа дәвер ачтылар» (13 бит).

[1] Г. Халит. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. Тәнкыйть мәкаләләре. Казан, 1975 ел.

Галиәсгар Камал һәм Шәриф Камал турындагы мәкаләләр 1939 елда ук язылган булган. Аннан соң шактый вакыт үтсә дә, аларны һич тә искергән, актуальлеген югалткан дип әйтеп булмый. Киресенчә, бу мәкаләләр безне бүген дә уйландыралар, яңа тикшеренүләргә этәрәләр. Ә утызынчы еллар әдәбият белеме өчен аларның әһәмияте аеруча зур була. Ул елларда шактый нык тамыр җәйгән вульгар социологизмнан аермалы буларак, Гали Халит объектив тормыш чынбарлыгының язучы тарафыннан куркыпрлы эстетик мөнәсәбәтләрдә гәүдәләнә алу мөмкинлеген нигезләп күрсәтә. Бу җәһәттән Шәриф Камал турындагы мәкалә бигрәк тә игътибарга лаек. Галим биредә беренче булып Шәриф Камал реализмының импрессионистик тенденцияләр белән бәйләнешенә игътибар иткән.

Мәгълүм булганча, импрессионизм (французча «тәэсир» дигән мәгънәдә) XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында реалистик сәнгатьнең бер тармагы буларак дөньяга килә. Буржуаз җәмгыятьнең гаять зур каршылыклар кичергән чорында туып, тиздән ул үзе ике канатка аерылып китә. Модернизм һәм декадентлык әдәбияты импрессионизмны объектив тормыш белән мөнәсәбәтен өзгән, социаль моментларны сурәтләүдән баш тарткан һәм субъективлыкка корылган «аң агымы» әдәбиятына калдырырга омтыла (М. Пруст, О. Уайльд, К. Бальмонт, И. Анненский һ. б.). Реалист язучылар иҗатын исә, импрессионизм яңа алымнар, язу техникасы белән баета (Л. Толстой, А. Чехов, И. Бунин һ. б.). Әмма бездә шактый вакытлар, бигрәк тә әдәбият белеме вульгар социологизм тәэсирен кичергән чорда, импрессионизм тулаем диярлек тискәре күренеш итеп санала, аның әдәбиятка алып килгән уңай яклары искә алынмый. Соңгы елларда Б. Сучков, В. Днепров кебек күренекле совет галимнәре мондый карашларның берьяклы булуы турында язып чыктылар, импрессионистик стильнең аерым алымнарын социалистик реализм вәкилләре дә файдаланута игътибар иттеләр.

Шәриф Камал иҗатындагы импрессионистик тенденцияләргә Гали Халит нигездә уңай бәя бирә һәм аларның язучы әсәрләрендә үзенчәлекле эволюция кичерүен дә билгеләп үтә. 1909—1913 елларда язылган новеллалар өчен хас булган импрессионистик алымнар һәм мотивлар турында ул болай ди: «Геройның исемен әйтми генә, билгесез рәвештә башлап китү, ситуация һәм конфликтларның кайвакыт бик очраклы хәлләрдән килеп чыгуы, кеше газаплы тойгыларының чыганагы, сәбәбе кайдадыр яшеренеп тору, тормыш күренешләрен, хәлләрне билгеле бер субъектив ягынраак өзеп алу; табигать күренешләрен дә, кешеләр портретын да вакыйгаларга, кешеләр психологиясенә берьяклы, ягъни авыр, газаплы, күңелсез итеп янәшә куярга тырышу — менә болар Ш. Камал хикәяләрендә импрессионистик тенденцияләрнең билгеле бер чагылышы булды диярга мөмкин» (68 бит).

Сүз дә юк, бу өзектә Шәриф Камалның башлангыч чор иҗатындагы импрессионистик тенденцияләр төгәл һәм оста тотып алынган. Чыннан да, язучының беренче новеллаларында сезонлы эшчеләрнең фаҗигале тормышларын, газаплы кичерешләрен гәүдәләндерү беренче урында тора.

Әмма Шәриф Камал реализмындагы импрессионистик тенденцияләргә Россия җирлегендә җанланып киткән революцион хәрәкәт яңа бер төсмер бирә, аны субъективлык басымыннан азмы-күпме арындырып, тормышның үзенә якынайта. Новеллаларда сизелер-сизелмәс кенә бирелгән, астарак яшеренеп яткан социаль момент «Акчарлаклар» повестенда инде өскәрәк калкып чыга, кешеләр арасындагы мөнәсәбәт матурлык концепциясе таләпләреннән чыгып үлчәнә башлый. Импрессионистик мотивларның яктырак буяулар белән баюы, хисләрнең җылынуы табигать күренешләрен сурәтләгәндә күзгә аеруча ачык ташлана. Әйтергә кирәк, башка реалист язучылардан (мәсәлән, Ф. Әмирханнан) аермалы буларак, Шәриф Камалдагы пейзаж бик тә кыска һәм җыйнак. Еш кына ул рәссам тарафыннан иҗат ителгән картина-миниатюраны хәтерләтә һәм һәр вакыт диярлек кеше психологиясе белән тыгыз үрелеп бирелә. Новеллаларда бу пейзаж драматизм, трагизм белән сугарыла (нәкъ менә шушы ягы белән ул өлешчә генә булса да экспрессионистик алымнарны хәтерләтә), ә «Акчарлаклар»да исә ул геройларның бәхет турындагы хыялларына, мәхәббәт турындагы хисләренә бәйле рәвештә социаль эчтәлек ала, романтик пафос белән сугарылган лиризм буларак үсеп китә.

«Тормышчан батырлык һәм сәнгатьчә матурлык» (1963) исемле мәкаләдә автор Галимҗан Ибраһимовның катлаулы иҗади эзләнүләр аша социалистик идеалга, социалистик реализмга килүе турында яза. Әдип әсәрләрендәге психологизмның, контраст-

лар поэтикасының, пейзаж символикасының, сюжет һәм эпик сурәтләү алымнарының бер чордан икенче чорга нинди үзгәреш, үсеш кичерүен күзәтә.

Психологик прозаның күренекле вәкиле Әмирхан Еники турындагы мәкалә — әдәби иҗатка объектив һәм принципиаль бәя бирүнең матур бер үрнәге. Гали Халит, язучының кырыс реализмын тарихи-иҗтимагый принциптан чыгып өйрәнү белән бергә, аны романтик тенденцияләр, эмоциональ-психологик башлангыч белән тыгыз мөнәсәбәттә тикшерүнең дә мөһимлеген исбатлый. Әмирхан Еники реализмының икенче бер әзлекле тенденциясе итеп, ул «явызлыкка һөҗүм, аны фаш итү пафосын» исәпли. «Саз чәчәге», «Рәшә» повестьларында сатира, ирония, юморның зур урын алып торуына һәм аларның бик тә үзенчәлекле рәвештә «драматик һәм психологик контрастлар тирәнлегендә ятканлыгына» игътибар итә.

Әмирхан Еники — психологик сатира остасы. Аның иҗатында көлке объектлары классик сатирадагы кебек гипербола, гротеск, карикатурага хас арттырып, күпертеп, шәрәләндереп сурәтләүләрдән азат. Шул сәбәпле, аның тискәре геройлары капма-каршылыклар көрәшен гәүдәләндергән җанлы кешеләр булып күз алдына килеп басалар. Кызганычка каршы, бездә психологик сатира үзенчәлекләре бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән.

Китапның икенче бүлеге әдәби тәнкыйть һәм эстетик фикер мәсьәләләренә багышланган. Татар әдәби хәрәкәтенең барлык чорларын иңләгән, теоретик гомумиләштерүләргә бай мәкаләләрне укыгач, авторның киң диапазонлы галим икәнлегенә тагын бер кат инанасың. Биредә галим урта гасыр татар әдәбияты турында да, XIX гасыр мәгърифәтчелек реализмы турында да кызыклы фикерләр әйтә. Ул шулай ук XX йөз башы һәм егерменче еллар әдәби хәрәкәтен, эстетик фикерен тәфсилләп тикшерә, бүгенге әдәби процессның, әдәби тәнкыйть һәм әдәбият белеменең актуаль мәсьәләләрен дә читтә калдырмый.

Әдәбиятыбызның кайсы гына чорына мөрәҗәгать итмәсен, Гали Халитның игътибар үзәгендә иҗат методы мәсьәләсе тора. Бүгенге совет әдәбият белеме өчен гаять актуаль булган бу проблеманы ул төрле аспектларда карый (иҗат методларының тарихы, идеологик һәм эстетик асылы, үзара мөнәсәбәте, аларның заман, әдәби стильләр, эстетик категорияләр, жанрлар, традиция һәм новаторлык күренешләре белән бәйләнешы һ. б). Гали Халит иҗат методын һәр вакытта да хәрәкәттәге, үзгәрештәге күренеш итеп саный, аның эчтәлеген әдәби, эстетик һәм фәлсәфи яссылыкларда ачарга омтыла.

Гали Халит мәкаләләренең икенче бер көчле ягы — иҗат методларын тизләтелгән әдәби үсеш фонында карау, аның катлаулы диалектикасын ачыкларга тырышу. Октябрьгача һәм совет чорында күп кенә милли әдәбиятлар тизләтелгән үсеш процессы кичерделәр. Иҗтимагый-тарихи һәм әдәби шартларга бәйле рәвештә, Гали Халит тизләтелгән үсешнең өч төрле формасын тәкъдим итә: иҗат методларының һәм әдәби агымнарның классик эзлеклелек белән берберсен тиз алмаштырып килүе; әдәби чылбырдагы буыннарның кайсы да булса төшеп калуы; төрле иҗат методлары, әдәби агымнарның бергә очрашуы, аралашып яки янәшә яшәве.

Автор, татар әдәбиятын тизләтелгән үсешнең соңгы төренә кертеп, аның төрле чорларын анализлый. Аның фикеренчә, әдәбиятыбызның тизләтелгән үсеше өчен зарури булган алшартлар түбәндәгеләр: татарларның азатлык хәрәкәтендә актив катнашуы, күп гасырлык язма әдәби традицияләр булу, рус һәм Европа әдәбиятлары тәҗрибәсен үзләштерү. Тизләтелгән үсешнең хәзерлек чоры итеп Гали Халит XIX йөзнең соңгы чирегенә белән 1905—1907 еллгы революция аралыгындагы мәгърифәтчелек реализмын исәпли. Дөрестән дә, мәгърифәтчелек әдәбиятының үзендә үк дифференциацияләнмәгән хәлдә башка иҗат методлары өчен хас булган тенденцияләр — сентиментализм, натурализм, классицизм яралгылары — очрый. Шунлыктан, безнеңчә, мәгърифәтчелек реализмының бу чорын тизләтелгән үсешнең беренче этабы дип билгеләү зур хата булмаса кирәк.

Мәгърифәтчелек реализмы мәсьәләләре башлыча «Тизләтелгән әдәби үсеш һәм иҗат методлары», «Әдәбиятның төп үзәнен һәм үзенчәлеген күреп» исемле мәкаләләрдә кузгатыла. XIX йөз мәгърифәтчелек әдәбияты турында бездә шактый язылды. Башка авторлардан аермалы буларак, Гали Халит мәгърифәтчелек реализмының икенче этабына, моңарчы күләгәдәрәк калган үзенчәлекләренә игътибар итә. «Европа һәм рус мәгърифәтчелек әдәбиятлары белән чагыштырганда,— ди ул,— татар мәгърифәтчелек әдәбиятында, беренче нәүбәттә, милли уяныш, милли азатлык идеяләренең өстенлек

итүе күзгә ташлана» (236 бит). Безнеңчә, бу — бик тә әһәмиятле фикер.

XX йөз башы татар әдәбияты гаять катлаулы һәм каршылыклы үсеш юлы уза. Бу чорда критик реализм әдәбияты формалаша, аның белән янәшәдә үк «Европа тибындагы» романтизм үсеп чыга. Ләкин шул ук вакытта мәгърифәтчелек реализмы да әдәби процесстан төшеп калмый, ә яңа төсмерләр белән баеган хәлдә яшәвен дәвам иттерә. Иҗат методларының бер үк вакытта, бер үк ноктага җыелып мәйданга чыгулары Гали Халит тизләтелгән үсеш нәтиҗәсе итеп аңлата. Аның XX йөз башында мәгърифәтчелек реализмы яңа дәвер кичерде дигән фикерен дә хупламый мөмкин түгел. Чынлап да, бу чорда мәгърифәтчелек реализмы мөстәкыйль иҗат методы буларак та, критик реалистлар һәм романтиклар иҗатында аерым тенденцияләр рәвешендә дә очрый. Бу хәл аңлашыла да. XX гасыр башында татарлар арасында буржуаз мөнәсәбәтләр үсү дәвам итсә дә, иҗтимагый тормышта феодализм калдыкларының басымы әле шактый сизелерлек иде. Нәкъ менә шушы хәл әдәби процесста, башка иҗат методлары белән бергә, феодаль торгынлыкка каршы юнәлдерелгән мәгърифәтчелек реализмының дә яшәве өчен җирлек калдыра. Шунныктан ул тизләтелгән үсешнең икенче этабында да уңай һәм зарури күренеш була.

Безнеңчә дә мәгърифәтчелек реализмын ике этапка — XIX һәм XX йөзләргә бүлеп өйрәнү нәтиҗәле булачак. Ләкин мәгърифәтчелек реализмының (шул исәптән мәгърифәтчелек романтизмының да) икенче этабы аз өйрәнелгән. Хәзергә әле бу турыда аерым күзәтүләр генә бар. Мәсьәләнең тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәвенә мәгърифәтчелек реализмы әсәрләрен критик реализм эстетикасы таләпләреннән чыгып анализлау да комачаулый булса кирәк. Мәсәлән, барлык фәнни хезмәтләрдә диярлек Фатих Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повесте критик реализмның классик үрнәге итеп карала. Ә чынбарлыкта исә ул мәгърифәтчелек реализмы әсәре, мәгърифәтчелек реализмы сатирасы. Гали Халит та башка иҗат методы нигезендә язылган әсәрләрне мәҗбүри рәвештә критик реализм кысаларына кертеп утырту белән килешми. Тагын шуны да әйтеп китәсе килә, XX йөз башындагы мәгърифәтчелек әдәбиятында (һәм реализмда, һәм романтизмда) сатира зур урын алып тора. Бу мәсьәлә Г. Халитның да игътибарын җәлеп иткән. Ибраһим Нуруллин белән бәхәскә кереп, ул сатираның критик реализмга гына хас булмыйча, мәгърифәтчелек әдәбияты өчен аеруча характерлы булуын һәм моның бөтендөнья әдәбияты тәҗрибәсе белән раслануын күрсәтә. Чынннан да, бу шулай. Сатираның иң әйбәт үрнәкләре бездә мәгърифәтчелек әдәбияты белән мөнәсәбәттә туа. Моңа мисал итеп Ш. Мөхәммәдевнең «Япон сугышы яки Батыргали агай», З. Һадиның «Җиһанша хәзрәт», Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт», С. Рәмиевнең «Низамлы мәдрәсә» кебек әсәрләрен телгә алу да җитә.

Татар мәгърифәтчелек әдәбиятының идеологик асылы, эстетик табигате, аның башка иҗат методлары белән бәйләнешләре хакында әйтелгән фикерләр дә кызыклы. Шуларның берсе — татар әдәбиятында мәгърифәтчелек идеалларының ике иҗат методына — мәгърифәтчелек реализмына һәм мәгърифәтчелек романтизмына нигез булуы. Аның бу фикерен бер татар әдәбияты мисалы белән генә түгел, ә Совет Көнчыгышындагы шактый күп әдәбиятларның үсеш тарихы белән дә раслап булыр иде.

Реализм һәм романтизм мәсьәләләрен яктыртуга Гали Халит китабында иң күп урын бирелгән. Октябрьга кадәрге әдәбиятны тикшерәме, совет чорына кайтып, 20 елларга, Бөек Ватан сугышы елларына, Әмирхан Еники иҗатына, эстетик фикер тарихына мөрәҗәгать итәме — һәр очракта да галим бу мәсьәләгә кагылмыйча үтми. Реализм белән романтизмның үзара керешүе мәсьәләсе — Гали Халит эзләнүләренең иң отышлы ягы. Соңгы вакытта әдәбият теоретиклары һәр язучының иҗаты үзенең эчтәлеге белән бер-берсеннән аерылгысыз күренешләрне — реализмны да, романтизмны да берләштерә, тик берәүләрдә реализм, ә икенче берәүләрдә романтизм өстенлек ала, дигән фикерне куәтлиләр. Бу хәл эстетик идеалның үзенчәлеге, аның структурасында нинди башлангыч хакимлек итүе белән аңлатыла. Гали Халитның да реализм һәм романтизм турындагы фикерләре шул юнәлештә бара. Реализм һәм романтизм синтезының нәтиҗәсе итеп ул татар әдәбиятында «романтик реализм» агымы туа, яңа революцион күтәрелеш елларында Г. Тукай, М. Гафури, Г. Ибраһимовлар иҗатында аның көчле яралгылары күренә дип күрсәтә. Бу термин ни дәрәҗәдә уңышлыдыр, реализм һәм романтизм синтезы өченче бер иҗат тибын тудырамы, юкмы — бу турыда киләчәктә ныклап уйланырга кирәк, билгеле. Әмма шунысы бәхәссез, XX йөз башы һәм

егерменче еллар татар совет әдәбиятында реалистик һәм романтик алымнар белән язылган әсәрләр гаять зур урын алып тора.

Гали Халит XX йөз башы татар әдәбиятыннан «саф» иҗат методларын эзләүне урынсыз дип исәпли. Аныңча, саф критик реализм, саф романтизм булмау татар әдәбияты җирлегендә катлаулы һәм каршылыклы идеологик һәм эстетик күренешләрнең бергә очрашу, тизләтелгән әдәби үсеш процессы нәтиҗәсе. Бу уңай белән ул реализм һәм романтизмның импрессионизм, символизм, акмеизм кебек модернистик, декадентлык тенденцияләре белән үзара бәйләнешен тикшерә, аларның әдәби процесска уңай һәм тискәре йогынтысын күрсәтә.

Хәзер күпчелек хезмәтләрдә реализмның асыл сыйфаты итеп социаль детерминизмны күрсәтү гадәткә керде. Шул ук вакытта кайбер әдәбиятчылар социаль принципның реализмда гына түгел, ә романтизмда да булуына игътибар итә башладылар. Әлеге мәсьәләгә Гали Халит та туктала. «Чыннан да,— дип билгеләп үтә ул,— әгәр романтизм татар әдәбиятында реализмның психологик һәм лирик тонусын күтәрүгә, геройның гомумиләштерелгән, ягъни калкурак итеп сурәтләнгән типик образын тудыруга ярдәм иткән булса, реализм исә романтизмдагы иҗтимагый принципның, социаль детерминизмның үсүенә булышты» (252 бит).

Бу — бик тә урынлы һәм вакытлы әйтелгән фикер. Фәнни-теоретик мәсьәләләрне дөрес хәл итүдә аның практик әһәмияте бик зур. Романтизмдагы социаль детерминизмны танымау, аны бары тик реализм өчен генә хас дип исәпләү әлеге иҗат методларын бер-берсенә каршы куюга этәрде, романтизм сәнгатьчә фикерләүнең түбәнрәк баскычы итеп кузалланды. Шул сәбәпле, аерым әсәрләрнең иҗат методларын билгеләүдә төрле төгәлсезлекләргә, тартып-сузуларга юл куелды. Кирәгеннән артык социологизмга бирелеп, М. Фәйзинең «Галиябану» драмасын критик реализм тантанасының чагылышы итеп бәяләдек, ә Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында реализм белән романтизмның янәшә яшәвен яки бәрелешүен күрдек. Романтизмның да социаль детерминизм белән сугарыла алу мөмкинлеген искә алып, Гали Халит мондый карашлар белән килешми, хисләр көрәшен гәүдәләндергән һәр ике әсәрнең дә романтизм казанышы булуы турында әйтә. Ләкин XX йөз башы романтизмындагы социаль детерминизмны бары тик реализм тәэсирендә генә туган әдәби-эстетик күренеш итеп карау белән килешеп бетәсе килми. Безнеңчә, ул романтизмның борынгырак чорларына да характерлы. Әзербәйҗан, үзбәк әдәбиятларының атаклы классиклары Хакани, Низами, Физули кебек шагыйрьләргә мөрәҗәгать итсәк, алар романтизмында рухи принциптан чыгып бәяләнгән һәм тискәре образлар белән тыгыз мөнәсәбәттә бирелгән социаль детерминизмны очратырбыз. Әмма әдәбиятчылар әле бу моментка аз игътибар итәләр. Шул сәбәпле романтик тәнкыйть һәм сатирадагы социаль момент романтизм өчен хас реалистик тенденция итеп өйрәнелә.

Китапта 20 нче елларның бай һәм катлаулы әдәби процессын өйрәнүгә багышланган мәкаләләр дә урын алган. 20 еллар әдәбиятын тикшергәндә автор XX йөз башы татар демократик әдәбият мисалында күтәрелгән проблемаларга кабат туктала, сәнгатьчә фикерләүнең тагын да тирәнрәк катламнарына үтеп керә. Шундый үзәк проблемалардан берсе — социалистик революциядән соң да тизләтелгән үсеш процессының тукталмавы, ә, киресенчә, яңа иҗтимагый-тарихи шартларда һәм эстетик җирлектә моңарчы күрелмәгән куәт белән үсеп китүе, яңа чор кичерүе. Тизләтелгән үсешнең бу өченче этабына карата галим ясаган әһәмиятле нәтиҗәләрнең икенчесе — «романтик реализм»ның, бу чор татар әдәбиятында кабатланмас сыйфат үзгәрешләре кичереп, социалистик реализм әдәбияты формалашуы өчен ныклы нигез салуы. Прогрессив романтизм белән критик реализм казанышларын бер ноктага җыйган, синтезлаган «романтик реализм» галим тарафыннан 20 нче елларда иң алдынгы әдәби агым итеп тәкъдим ителә. Галимнең гыйсъянчылык романтизмына биргән бәясе дә шул хакта сөйли. Моңарчы гыйсъянчылык романтизмының уңай якларын күрсәтүдән бигрәк, аның тискәре якларына, чикләнгәнлеге турында сүз йөртелде. Гали Халит гыйсъянчылыкны бары тик буржуаз анархизм, бунтарьлык күренеше итеп карауга каршы чыга, киресенчә, ул аның революцион романтизм белән тыгыз мөнәсәбәттә булуына басым ясый. Гомумән, Г. Халит китабында романтизмны җитлекмәгән әдәбият итеп карарга теләүнең эзе дә юк. Ул аны зур идея-эстетик тәэсир итү көченә ия булган һәм киләчәккә юнәлдерелгән әдәби күренеш итеп аңлата.

Галим Һади Такташ әсәрләренең иҗат методы турында да уйлана. Мәсәлән, ул атак-

лы «Гасырлар һәм минутлар» поэмасын революцион романтизмның әйбәт үрнәге дип саный. Мәсьәләгә болай якын килү Такташ иҗаты турындагы искергән карашлардан, схематик фикерләрдән арыну мөмкинлеген тудыра, аны өйрәнүнең яңа перспективаларын билгели. Кыскасы, Гали Халит тәкъдим иткән концепция 20 нче еллардагы иҗат методлары эволюциясен «романтизмнан — социалистик реализмга», «критик реализмнан — социалистик реализмга» формулалары рәвешендә турысызыклы аңлауга юл куймый. Автор социалистик реализм теориясен догматикларча аңлатуга каршы. Ул аны диалектик каршылыклар бердәмлегендә һәм үсешендә формалашкан эстетик категория итеп карый. Социалистик реализмга төрле язучылар төрлечә: берәүләр аңа традицион романтизм, икенчеләр гыйсъянчылык романтизмы, өченчеләр критик реализм аша катлаулы юл үтеп киләләр. Автор расларганча, егерменче еллар әдәбиятында бу реалистик һәм романтик башлангычларны бергә җыя торган көч бар иде: «ул — тарихи-иҗтимагый шартларның һәм сыйнфый-идеологик факторларның бердәмлеге» (230 бит). Шул ук вакытта социалистик реализм романтизм белән реализмның гади кушылмасы да түгел. Социалистик реализм моңарчы татар әдәбиятында булып үткән әдәби методлар — традицион романтизм, мәгърифәтчелек реализмы, критик реализм, яңа романтизмнарның уңай традицияләрен һәм бөтендөнья әдәбиятының прогрессив казанышларын иҗади үзләштерә, заман белән бергә атлап, үзенең потенциаль мөмкинлекләрен киңрәк һәм тирәнрәк ача торган хәрәкәттәге эстетикага әверелә. Шул рәвешчә, 20 нче еллар татар әдәбиятында «яңаны көчлерәк итеп раслаган һәм явызлыкка рәхимсез хөкем чыгарган», чын тормыш диалектикасын гәүдәләндергән яңа иҗат методы — социалистик реализмның нигез ташлары салына.

Бер төркем мәкаләләр әдәби-эстетик фикернең аерым этапларын, әдәби тәнкыйть мәсьәләләрен яктыртуга багышланган. Аларда XX йөз башы татар демократик әдәбиятындагы реалистик һәм романтик эстетиканың ничек формалашуы, үзенчәлекләре турында тәфсилле фикер йөртелә, егерменче еллардагы әдәбият белеменең күп төрле актуаль проблемалары — методологик асылы, социологик нигезе, метод һәм агымнар, әдәби традиция һәм новаторлык мәсьәләләре, аерым язучыларга әдәби тәнкыйтьнең мөнәсәбәте ачыклана.

Кыскасы, теоретик фикернең тирәнлеге, полемик үткенлек, проблемаларның концептуаль характерда булуы, татар әдәбиятының үсеш закончалыкларын рус һәм Европа әдәбиятлары белән уңышлы чагыштырып бирү — Гали Халит китабының асылын билгели торган төп сыйфатлар. Көн тәртибенә куйган проблема һәм методологик принципларның әһәмияте бер татар әдәбияты белән генә чикләнми. Гомумән, совет Көнчыгышындагы башка төрки әдәбиятларның художестволы фикерләү үзенчәлекләрен өйрәнүдә дә аларның практик әһәмияте бар. «Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән» дигән яңа китабы белән Гали Халит үзенең бөтен дә татар әдәбият фәненең әйдәп баручысы икәнлеген раслый. Бик күп актуаль мәсьәләләрне күтәргән бу китап — әдәбият белемебезнең үсеш күрсәткече һәм казанышы.

**РЕЗЕДА ГАНИЕВА,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# ФАТИХ ӘМИРХАН ПРОЗАСЫ РУС ТЕЛЕНДӘ

Татар әдәбиятында үзенең иҗтимагый-психологик повестьлары, лирик хикәяләре, ялкынлы публицистикасы һәм сатирик әсәрләре белән танылган Ф. Әмирхан рус укучысына, 30 нчы еллардан бирле таныш. Милли әдәбиятлар альманахы сериясеннән чыккан «Сборник татарской литературы»[1] дигән җыентыкта, Г. Тукай, С. Рәмиев, Дәрдмәнд, М. Гафури, Ш. Бабич, Г. Ибраһимов, Ш. Камал әсәрләре белән беррәттән, Ф. Әмирханның «Татар кызы» һәм «Сәмигулла абзый» исемле әсәрләренең дә тәрҗемәләре урнаштырыла.

Моннан тыш, төрле елларда Ф. Әмирханның сайланма әсәрләреннән торган берничә җыентык чыга[2]. 1957 елда, татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уңае белән, «Огонек» журналының 21 санында «Татар кызы» урнаштырыла (тәрҗемәче Галия Хантемирова). Шул ук елда Татарстан китап нәшриятының балалар әдәбияты редакциясе әдипнең «Нәҗип» исемле хикәясен «Первый цветок» дигән исем белән аерым китап итеп чыгара (тәрҗемәче Ю. Карев). 1975 елгы җыентыкта да ике яңа тәрҗемә — Ф. Әмирханга гына хас нәфислек, нечкә лиризм белән сугарылган «Беренче ашкыну» һәм «Милләтне тәрәккый итү» кебек үтергеч сатира рухында язылган хикәяләр өстәлгән.

1931 елгы тәрҗемәләр «авторизованный» дип бирелгәннәр. Аннан соңгы елларда әдипнең күпчелек әсәрләрен Г. Хантемирова, драма әсәрләрен З. Халитова, Ю. Светланов тәрҗемә иткән. Бары тик 1959 елгы җыентыктагы «Танымаганлыктан таныштык» хикәясе А. Ибраһимов тәрҗемәсендә бирелгән.

Билгеле, Ф. Әмирханны тәрҗемә итү, башка тел стихиясендә аңа хас интонацияне, яңгырашны табу бик тә авыр эш. Шушы зур, җаваплы, мактаулы эшне инде менә егерме ел буе Г. Хантемирова башкарып килә. Тәрҗемәче оригиналның телен яхшы белә, һәр сүзнең күп санлы мәгънәләрен тоеп, сизеп, урынлы куллана ала. Ул татар теленә генә хас булган мәгънә төсмерләрен һәм төшенчәләрне русча бирү мөмкинлекләрен табу өстендә күп уйланган. Чөнки ул бу өлкәдә зур белгеч, тәрҗемәдә милли үзенчәлекләрне саклау турында кандидатлык диссертациясе яклаган кеше. 1974 елда аның китабы да чыкты[3].

Ф. Әмирханның күп кенә әсәрләре берничә тапкыр тәрҗемә ителгән. Мәсәлән, «Татар кызы», «Сәмигулла абзый», «Фәтхулла хәзрәт», «Хәят» кебек әсәрләре кат-кат басылганнар һәм аларга тәрҗемәдән-тәрҗемәгә үзгәрешләр кертә барган.

Сүзне бит тәрҗемә вариантлары булган «Татар кызы»ннан башлыйк. Татар хатын-кызларының аяныч язмышын үз күзләре белән күреп, шуңа тирән борчылып язылган һәм дөнья әдәбиятының шедеврлары рәтеннән куелырлык бу әсәрдә һәр сүз, уеп куелгандай, тыгыз урнашкан, һәрбер сүзнең эчке мәгънәсе зур, тирән. Әсәрдәге кызның исеме дә юк, ул — шул чордагы меңнәрчә хатын-кызларның уртак язмышын гәүдәләндерә, моны беренче юлдан ук сизеп була: «Туды. Туганда ул кеше иде...» 1931 елда, бу тәгъбирнең сүзгә-сүз «родилась» дип тәрҗемә ителүе дә сәер түгел. Ләкин рус телендәге родилась сүзе һәр өч затны да белдерә ала, шуңа күрә Г. Хантемирова аны өченче затка күчереп: «Родилась девочка» дип алган.

---

[1] П. Радимов редакциясендә. М.— Л., ГИХЛ, 1931 ел.

[2] Ф. Амирхан. Татарка. Избранные произведения. Гослитиздат, 1959; Ф. Амирхан. Хаят. Повести и рассказы. Татарстан нәшрияты, Казан, 1968 ел; Ф. Амирхан. Избранные. Рассказы и повести. «Художественная литература» нәшрияты, 1975 ел.

[3] Г. Хантемирова. Национальное своеобразие оригинала и проблемы перевода. Рус телендә, Казан, 1974 ел.

1931 елгы альманахта бу әсәрнең исеме, тәрҗемә ителмичә, «Татар-кызы» дип куелган. Җәяләр эчендә «Дочь татарина» дигән аңлатма исем бар. 1957 елдан бирле ул «Татарка» дип тәрҗемә ителеп килә. Матбугатта «Татарская девушка»[1] дигән варианты да очрый.

Ф. Әмирхан үзе «Татар кызы»ның багышламасын беренче заттан яза: «Терелә́й күмелергә теләмәгән мөселман шәрык кызларына багышлыйм». 1931 һәм 1957 елгы тәрҗемәләрдә беренче зат формасы сакланса да, соңгыларында, пассив формага күчеп, «посвящается» формасы белән бара. Һичшиксез, авторның үз сүзе булгач, беренче затны саклау кирәк иде.

Әсәрнең төрле тәрҗемәләрен чагыштырып карасаң, аның һаман төгәлрәк була баруын күрәсең. Һәрбер яңа чыкканында тәрҗемәнең сыйфаты яхшыра, оригиналга стилистик һәм мәгънәви яктан якынлык арта. Мисал өчен бер җөмлә алыйк: «Кайвакытларда кулларын, аякларын биләүгә чорнап, аны хәрәкәтләнмәскә мәҗбүр иттеләр... Ләкин ул моңар протест итәргә, риза түгеллеген белгертергә кодрәтле, елый, кычкыра ала, үз хөрриятен берәүдән дә җуялттырырга риза түгеллеген ирексезләүчеләрнең күзләренә туп-туры карап белдерә ала иде». 1931 елгы тәрҗемәдә ул болай бирелгән: «Иногда, обмотав пеленками, не давали ей возможности двигать руками и ногами... Но она имела возможность кричать, плакать и острым взглядом выражать негодование против насильников, покушающихся на ее свободу». 1957 елгы тәрҗемәдә лаконизм өстенлек алган: «Правда, ее пеленали и принуждали не двигаться. Но она могла сопротивляться: плакать, кричать и открыто смотреть в глаза своим притеснителям» («Огонек» журналы, 15 бит). 1975 елгы тәрҗемә, безнеңчә, Ф. Әмирхан әйтергә теләгән мәгънәне аеруча тулы чагылдыра кебек: «Правда, иногда ее пеленали и принуждали не двигаться. Но она могла протестовать: плакать, кричать, и свою решимость никому не позволять отнимать у нее свободу она могла выразить тем, что прямо смотрела в глаза своим притеснителям».

Тагын бер мисал китерик: татар кызын дүрт диварга япъыргач, кара көч болай ди: «Алты өлгеле тәрәзә сиңа кояш булыр; өйнең биш бүлмәсе — Европа, Азия, Африка, Америка һәм Австралия булырлар; тәрәзә алдындагы зәгыйфь гөл кисәкләре урманнар, кырлар, бакчалар урынына хезмәт итәрләр; комган вә ләгәндәге тынчыган сулар сиңа елгалар, күлләр, диңгезләр урынына ярарлар; күмер, куй мае, гатырша мае исләреннән җыелган сулышлар белән агуланган һава сиңа бөтен җир йөзендәге һава урынына булыр; өеңдәге һәр көнне ишетә торганың кычкырыш, тиргәш, елашлар сиңа музыка урынына булырлар, миллиард ярым санлы адәм балалары урынына җиде-сигез җанлы курчак һәм атаң булырлар; адәм балаларының меңнәрчә еллык тырышлыгы белән барлыкка килгән фәннәр һәм фәлсәфә урынына «изгелекле» наданлыгың булыр!»

1931 һәм 1975 елгы тәрҗемәләрне чагыштырып карыйк:

— Шестистекольное окно своей комнаты — солнце для тебя. Пять комнат квартиры — для тебя страны света. Цветы на подоконниках — для тебя сады, поля и леса. Вода в умывальнике и ведрах для тебя заменят реки, озера и моря. Сплетни, дрязги, плач на дому — для тебя музыка, а святое твое невежество для тебя наука, созданная веками.

Окно в шесть переплетов — твое солнце, пять комнат дома — заменят тебе пять частей света: Европу, Азию, Африку, Америку и Австралию; хилые цветы на подоконниках — для тебя сады, поля и леса; затхлая вода в кумгане и в тазу сойдет за реки, озера и моря; спертый воздух, отравленный запахами угля, бараньего сала и благовонного масла, заменит тебе вольный воздух всей земли; крики, плач и перебранка, которые ты будешь ежедневно слушать дома, заменят тебе музыку; семь или восемь живых кукол и отец заменят тебе полуторамиллиардное население земного шара; науку и философию — плод тысячелетних усилий человечества — заменит тебе «священное» твое невежество.

[1] Ф. Әмирхан. Первый цветок. Казан, 1957 ел. Сүз башын кара.

Иң соңгы, ягъни 1975 елгы, тәрҗемәдә оригиналдагы кара көч әйткән коточкыч кансыз, рәхимсез сүзләр, анда сурәтләнгән караңгылык, ирексезлек, коллык картинасы ярыйсы ук тулы чагыла.

Тәрҗемәдәге үзгәрешләрнең шактый күпчелеге лексик һәм синтаксик синонимнар ярдәмендә мәгънәләрне төгәлләүгә кайтып кала. Мәсәлән, **бишекка салдылар, аның өчен җавап бирде, татар кызының ышанмавы какшый башлады** һ. б. гыйбарәләр 1931 елда, **«уложили в колыбель», «за нее ответила», «девочка начала колебаться»** формасында бирелгән булсалар, 1975 елгысында **«положили в колыбель», «вместо нее ответила», «недоверие татарки было поколеблено»** дип тәрҗемә ителгән.

Ф. Әмирхан татар кызын изеп торган «шәфкатьсез кысу машинасы» турында сөйли. Татар әдәбияты өчен бу—яңа образ, яңа символика. 1931 елгы тәрҗемәдә ул, иҗтимагый момент искә алынып, «безжалостный пресс» дип бирелә. 1975 елгы тәрҗемәдә бу мәгънә бөтенләй юкка чыгып, «безжалостные тиски» формасында әйтелә. Аннан соңгы тәрҗемәләрдә «безжалостная машина» тезмәләре кулланылып, бу сүз зур иҗтимагый яңгыраш алган.

Ислам дөньясында гына әйтелә торган гыйбарәләрнең тәрҗемәләре шактый төрле. Мәсәлән, «Кыз балага ир малайлар белән уйнап йөрү оят!» җөмләсе болай бирелә: «Девочкам стыдно играть вместе с мальчишками» (1931); «Девочкам драться с мальчишками неприлично» (1957); «Девочке играть с мальчиками неприлично» (1975). «Неприлично» дип бирү уңышлырак, чөнки татар дөньясы ислам «приличие»ләрен саклап яшәгән бит! «Бөтен хатын-кыз таифәсе гаурәт» дигән җөмлә дә төрлечә бирелгән: «Весь женский пол аурат» (1931); «Весь род женский есть соблазн» (1957); «Вся женская половина рода человеческого есть соблазн» (1975).

Мисаллардан күренгәнчә, «Татар кызы» әсәрен тәрҗемә итү елдан-ел яхшыра, камилләшә барган. Шуның белән бергә, соңгы елларда кертелгән кайбер үзгәрешләрне һич тә хуплап һәм мактап булмый. Мәсәлән, «Туганда ул кеше иде» җөмләсе 1931 елда «Тогда она была человеком» дип бирелгән, 1975 елда, «Когда она родилась, она была человеческим существом» дип тәрҗемәләнеп, билгеле бер күләмдә татарчалык килеп чыккан. Янсә «Кара көч үзенең бу җиңүен бик тантаналы бәйрәм итте» җөмләсен алыйк. «Темная сила торжественно отпраздновала эту победу» (1931); «Темная сила торжествовала словно в праздник, она победила» (1975).

Оригиналда: «Инде җанлы курчак булып җиттең!» дип, кара көч авызыннан әйтелгән сүзләр 1931 елгы тәрҗемәдә нәкъ шулай аңлашыла да: «Вот теперь-то ты настоящая живая кукла». 1957 елда да дөрес: «Теперь ты стала настоящей куклой!» 1968 һәм 1975 елгы тәрҗемәләрдә, ни өчендер, ул үзгәртелеп: «Теперь ты станешь настоящей куклой!» дип бирелгән. Татар кызы җанлы курчак булып җиткән бит инде, авызыннан сүз дә чыгармый. Нигә шулай үзгәртергә кирәк булды икән?!.

Кайбер сүзләрнең тәрҗемәләре бәхәс уята. «Гәүдәң—гаурәт» дигәндәге **гәүдә** сүзе **фигура** дип түгел, **тело** дип тәрҗемә ителсә, дөресрәк булыр иде. «Кара көч карар бирде» дигән җөмлә «темная сила приказала» дип бирелгән. «Бикчәмер ризасы — тәңре ризасы» дигән җөмләне дә **«божья воля»** дип тәрҗемә итүгә караганда, **«воля аллаха»** дип әйтү урынлырак булмас идеме икән?

Яңа тәрҗемәдә дә әле төгәл дип әйтеп булмый торган сүзләр һәм җөмләләр очраштыра. Кечкенә генә бир мисал. **«Алты өлгеле тәрәзә»** тезмәсе ничек кенә әйтелми: шестистекольное окно (1931); окно в шесть оконниц (1957); окно в шесть переплетов (1968 һәм 1975). Кайсысы дөрес икәнен әйтү дә кыен, һәрберсе дә оригиналдагы мәгънәне авыррак бирә кебек.

Янсә менә бер өзек: «Җансыз курчакларны кунакларга йөртеп, туйлар ясатып, кияүләр кертеп, киленнәр төшереп... уйнарга кирәк иде». Татар халкының әйләнешү гореф-гадәтләренә караган никадәр мәгълүмат бар монда! Тәрҗемәләргә килик: «мертвые куклы должны быть друг к другу ходить в гости, устраивать свадьбы, жениться, выходить замуж, быть кумой и кумушкой...» (1931); «...водить их в гости, выдавать невест замуж, играть свадьбы, делать подарки сватам...» (1957); «ходить в гости, играть свадьбы, выдавать невест замуж, принимать молодицу, делать подарки сва-

там» (1968); «ходить в гости, выдавать невест замуж, принимать молодицу, делать подарки сватам» (1975). Боларда этнографик момент ачылып бетми кебек.

Әсәрдәге соңгы җөмлә гаҗәп зур мәгънәви йөк күтәреп тора. Ләкин тәрҗемәчеләр аны аңлап җиткермәгән, ахрысы. Ф. Әмирхан мөселман дөньясының Коръәннән бер аять тәкърарлауларын яза. «Терелəй күмелгән кыз баладан ни гонаһы өчен үтерелгәнлеген сорау көне — кыямәт көнедер, — диләр иде». 1931 елгы тәрҗемә менә болай: «В день страшного суда спросят заживо погребенную, за какую вину подвергли тебя подобной смерти?» 1957 елгысында: «... Стих о дне страшного суда, на котором девушку спросят, за совершение какого греха она умерщвлена». 1959 елгы тәрҗемәдә: «...повторяли стих из корана: День страшного суда — это день, когда заживо погребенную девушку спросят, за совершение какого греха она умерщвлена...» 1968 һәм 1975 елгы тәрҗемәләрдән исә бөтенләй башка мәгънә аңлашыла: «День, когда заживо погребенную девушку спросят, за совершение какого греха она умерщвлена, — есть день страшного суда...».

Тәрҗемәләрдән күренгәнчә, төрле мәгънәләрнең барлыкка килүе сүз тәртибенең үзгәрешенә, актуаль кисәкләргә бүленеш компонентлары — сөйләм предметы һәм сөйләм яңалыгының урыннары алмашуга бәйле. 1959 елгы тәрҗемә Ф. Әмирхан әйтергә теләгән фикерне төгәлрәк бирә кебек.

Аерым төгәлсезлекләр очрауга карамастан, Ф. Әмирханның «Татар кызы» рус укучысына да оригиналдагыча тәэсир итә алырдай, форма һәм эчтәлек ягыннан бер бөтен итеп кабул ителердәй әсәр булып яңгырый.

1931 елгы альманахта бирелгән хикәяләрдән икенчесе «Сәмигулла абзый»ның тәрҗемәсе дә шактый төгәл эшләнгән. Сәмигулла абзыйның каршылыклы сөйләме, аның тынгысыз мескенлеге, шул чор татар дөньясының тарлыгы һәм чикләнгәнлеге тәрҗемәдә шактый чагылыш тапкан. Сәмигулла абзыйның сөйләменә хас тәгъбир дә табылган. Һәр репликаны диярлек ул **«это ты не так»** дип башлый. Татар телендәге «алай түгел» тәгъбиренә шактый төгәл мәгънәви эквивалент табылган. Ләкин соңга таба Сәмигулла абзыйның Мәкәрҗәдән бүләккә чәй-шикәр алып кайту турындагы планнары, һаман чәй турындагы сүзләре тәрҗемә ителмичә калган, Сәмигулла абзыйның төшендә дә үзгәрешләр бар.

Соңгы тәрҗемәләрдә оригиналга якынаю ачык сизелә. Кайбер төгәлсезлекләр юкка чыккан. Мәсәлән, Сәмигулла абзыйның кызын «килен-кызны» **невестка** дип бирү урынына **молодица** диелгән. Рус телендә генә кулланыла торган тәгъбирләрдән **«матушка»** урынына, **мать** сүзе кулланыла. Татар телендә **анасы** эндәшенә тәңгәллек ягыннан соңгысы, һичшиксез, отышлырак. «Һәм рәхәт, һәм ләззәтле иде бу төш!» дигән соңгы җөмлә «Какой это был приятный сон!» урынына, мәгънәви һәм лексик яктан төгәлрәк итеп, «Отраден и сладок был этот сон!» дип тәрҗемә ителгән. «Пилүни шикәр ләззәтсез була» җөмләсендәге ләззәтсез сүзе элек «не вкусен» дип тәрҗемә ителгән булса, Г. Хантемирова бик урынлы рәвештә «В пиленом сахаре сладости мало» дигән вариантны сайлаган. Чыннан да, шикәр тәмсез булмый бит инде.

Ф. Әмирхан кеше күңеленең иң тирән почмакларына да үтеп керә алырлык йомшак лиризм белән сугарылган «Хәят», «Кадерле минутлар», «Рәхәт көн», «Беренче ашкыну» әсәрләрендә мәхәббәткә дан җырлый, аның кешене бәхетле итә алуына ышана. Тема үзе үк Ф. Әмирханның сүз-стиль чараларын сайлаудагы үзенчәлеген тудырган. Бу әсәрләргә шигъри лексика, эмоциональ кабатлаулар, җөмләнең эмоциональ төзелеше һәм шуларның барысыннан бергә туа торган интонация хас.

Сүз сайлаудагы бу осталык, стиль нәфислеге һәм нәзакәтлелеге «Кадерле минутлар» хикәясендә аеруча калку чагыла. Г. Хантемирова да шул стильне тәрҗемәдә саклый алган. «Легкий встречный ветерок играл ее локонами, выбившимися из-под белоснежного шарфика. Вот они, совсем освободившись от шарфика, рассыпались по розовым щекам и, словно черные шелковые нити, шаловливо поблескивали в задумчивых бледных лучах заходящего солнца».

Бу хикәядә мәхәббәт шатлыгын, аның газабын, ялкынын, бәхетен сурәтләү И. С. Тургенев интонациясен һәм стилен хәтерләтә[1]. Шундый ук нәфислек, гүзәллек,

[1] Ф. Әмирханга И. С. Тургенев иҗатының тәэсире турында кара: Ю. Г. Нигматуллина. И. С. Тургенев и татарская литература начала XX века. Казан, КДУ нәшрияты, 1961 ел.

сафлык! Ирексездән И. С. Тургеневның «Ася», «Вешние воды», «Первая любовь» повестьлары хәтергә төшә.

Ф. Әмирханның «Хәят»ны аеруча яратып язуы күренеп тора. Тәрҗемәче өчен дә бу шулай булса кирәк. Рус укучысы да фәрештә кебек Хәятның эчке һәм тышкы матурлыгына, сафлыгына, киң күңеллелегенә, садәлегенә, табигыйлегенә гашыйк булыр дип уйлыйбыз. Тәрҗемәче бу сыйфатларны тулы күрсәтердәй чаралар табуга ирешкән.

«Хәят», «Фәтхулла хәзрәт», «Габделбасыйр гыйшкы» повестьларының тәрҗемәләрен карап чыгу тәрҗемәченең туктаусыз эзләнүен күрсәтә. Тәрҗемәнең сыйфатын яхшыртуга Г. Хантемирова кайчак җөмләдәге сүз тәртибен үзгәртү аша да ирешә. «Беззвучно зашептал ошеломленный Габделбасыйр» (1968)—«Ошеломленный Габделбасыйр беззвучно зашептал» (1975) һ. б. Күп кенә башка очракларда тәрҗемәче сүзләрнең уңышлырак синонимнарын табуга ирешә, фразаларны җыйнакландыра: «проникали в здание» (1968); «входили в здание» (1975); «люди зашумели» (1968); «люди зароптали» (1975); «девическая пора» (1968); «девичья пора» (1975)... «Ул нинди башбаштаклык тагын? Ул нинди марҗалык ул?» «Своевольничать? Это что за манеры, присущие русским женщинам?..» (1968, «Преосвященный Фатхулла»), «Это что за манеры? Научились у русских женщин?..» (1975).

Ф. Әмирхан, үз чорының әдибе буларак, шул чордагы әдәби тел нормаларын билгеле бер дәрәҗәдә саклап иҗат итәргә тиеш булган. Шуңа күрә аның әсәрләрендә дә гарәп-фарсы алынмалары шактый күп кулланыла. Тәрҗемәче күпчелек очракта аларның мәгънәсен төгәл бирә алган, бу катлаулы, җаваплы эшне башкарып чыгуда аңа зур көч куярга туры килгәнлеге күренеп тора.

Татар тормышына гына бәйләнешле булган күренешләрнең тәрҗемәнең төгәллеге өчен әһәмияте зур. Мәсәлән, «Фәтхулла хәзрәт»тә «Мәкәрҗә өстендә» генә бакчага чыгучы абыстайлар турында сөйләгән урын бар. 1968 елгы тәрҗемәдә болай диелә: «Во время ярмарки в Ташьяке в сад приходили погулять абыстаи в зеленых чапанах». Төгәлсезлек шунда: Ташаяк ярминкәсе Казанның үзендә була, ә «Мәкәрҗә өстендә» дигән гыйбарә татар байлары Мәкәрҗәгә киткәч, аларның хатыннары бераз иркенлек алып, бакчага чыгуларына ишарә итә. Тәрҗемәче Г. Хантемирова аны уңышлы рәвештә төзәткән дә: «Во время макарьевской ярмарки...»

Тәрҗемәләр белән танышып чыккач, кайбер сүзләрнең тагын да төгәлрәк булуын күрәсе килү теләге туды. Мәсәлән, «Танымаганлыктан таныштык» хикәясендә «нурлы күзле» — «блестящие глаза» дип бирелгән — «лучистые глаза» урынлырак булыр иде бит. «Фәтхулла хәзрәт»тә «әхлакый тәрәккый заманыдагы тормышыбыз»— «наша чистая жизнь» дип тәрҗемә ителгән. Сукыр Каюм «Кривой Каюм»га әйләнгән. «Кадерле минутлар»да Аляның нәзек, каргылт-кызыл иреннәре, «пухлые, алые губы» итеп күрсәтелә. Фәтхулла хәзрәт тарафыннан җырланган «Җаным, җаным, җанашым, авыртмыйммы җан башың?» җырында да баш авырту турында сүз бармый бит! «Тәрҗемәи хәлем»дә Ф. Әмирхан «Әтәчетдин» казыйдан гыйлем алуы турында сөйли. Исеме казыйның эшләгән эшләренә туры китереп сайланган: ул шәкертләрне кыйнарга оста икән. Тәрҗемәдә ул «Петушитдин» дип бирелгән. Ничектер, «жултый-жултый, жуп-жултый, жултый чәчәк саплары» кебегрәк килеп чыкмыймы соң?..

Авторның вакыйгага, персонажга мөнәсәбәте ул кулланган бәяләү сүзләре аша ачыклана. Мәсәлән, «Бәйрәмнәр»дән мисал: **ашыга-ашыга** мәчеткә юнәлде; Вәли абзый **лыш-лыш** елады; халыкның бер кыйсеме дә **мыш-мыш** йокладылар; **үкереп** елыйсын китерә иде һ. б. Шулардагы **ашыга-ашыга, лыш-лыш, мыш-мыш, үкереп** дигән сүзләрнең тәрҗемәдә мәгънәви эквивалентлары юк, тәрҗемә теориясендәгечә әйтсәк, алар компенсацияләнмәгәннәр. «Тәрҗемәи хәлем»дә автор **«чикылдаган** фәлсәфи мәкаләләр» язуы турында әйтә. «Сугубо философские статьи» дип әйтү генә Ф. Әмирханның ирониясен бирәп бетерә алмый.

Тәрҗемәдә кайбер сүзләрнең мәгънәсен гомумән аңлап бетермәү аларны төшереп калдыруга китергән. Мәсәлән, «Кадерле минутлар» хикәясендә берничә тапкыр **адарынып** дигән сүз кулланылган: **«адарынып,** куркынып, сынымны турайттым» (402 б.); «үткен генә **адарынып** үбеп алды» (398 б.) Матур әдәбиятта һәм җанлы сөйләмдә бу сүз хәзер дә кулланыла бит.

Синтаксик омономия булу тәрҗемәчене авыр хәлгә куйган. «Бәйрәмнәр» хикәясендәге Вәли абзый «...ишек алдына чыккач, очраган бер хәерчегә кесәсеннән ике тиен көмеш бирә». Монда оригиналда өтер кую мәгънәне үзгәрткән. Әллә ничә хәерче килмәгән аның янына, бераүсенә генә бирә Вәли бай хәерне. Тәрҗемәдә исә болай: «Каждому нищему, который протягивал к нему руку..., доставал из кармана двухкопеечную монету...»

Татар исемнәрен һәм титулатура, туганлык атамаларын бирү мәсьәләсе дә тәрҗемәдә зур җаваплылык таләп итә. Мәсәлән, Маһитап абыстай 1931 елгы тәрҗемәдә **Магтаб** абстай, 1968 һәм 1975 елгыларында Мэгитэп абыстай дип бирелгән. Һәр икесен дә уңышлы дип әйтеп булмый. Фарсы теленнән кергән бу исемнең татарча яңгырашын төгәл һәм гади итеп **Магитап** яисә **Махитап** дигәндә уңышлырак булыр иде.

«Әхмәт әфәнде» кебек сүз тезмәләр «Эфенди Ахмет» дип тәрҗемә ителгән. Әгәр «Сәмигулла абзый», «Миңсылу кодача», «Маһитап абыстай» кебек сүз тезмәләр шул хәлендә тәрҗемә ителмичә бирелгән икән, бу очракта «Эфенди Ахмет» дип әйтү ни дәрәҗәдә урынлы икән? Шуңа ук бәйләнешле тагын бер нәрсә. «Абзый» сүзе беренче тәрҗемәләрдә «Самигулла абзы» булып тәрҗемә ителсә, аннан «Самигулла абзый»га әйләнеп, соңгы тәрҗемәләрдә «Почтенный Самигулла» булып киткән. «Благочинный Самигулла» дигән исем дә очрый. Безнең карашыбызча, «Самигулла абзый» тезмәсен русчада шул рәвешле бирү, әлбәттә, отышлырак булыр иде. «Фәтхулла хәзрәт»тә «Преосвященный Фатхулла»га әйләнгән. Әлбәттә, әдәби әсәрнең эчтәлеген рус укучысына аңа якын төшенчәләр белән бирү әйбәт эш. Ләкин «Ваше преосвященство» дигән сан ислам дөньясында булган нәрсә түгел, шуңа да «Фатхулла-хазрет» дип бирү уңышлырак.

Алда әйткәнебезчә, Ф. Әмирханның ике хикәясе А. Ибраһимов һәм Ю. Карев тарафыннан тәрҗемә ителә. А. Ибраһимов оригиналдагы төгәллеккә мәгънәви компенсация җирлегендә ирешүне максат итеп куйган. Ул рус телендә үзен иркен сизә, кайчак сүзләрне җиңел генә төшереп тә калдыра. Тәрҗемә авторларының сүз сайлаудагы үзенчәлекләрен түбәндәге мисаллар күрсәтә ала: «бай малае», «илле тиен көмеш», «илүмә киләләр», «немецнең дә исен җибәрү», «арык ат» дигән гыйбарәләрне Г. Хантемирова «байский сынок», «пятьдесят копеек серебром», «путаются», «поразил», «тощая лошаденка» дип биргән булса, А. Ибраһимов менә мондый сүзләр сайлаган: «барчук», «полтина серебром», «увиваются», «ошарашил», «тощая кляча». Әмма А. Ибраһимов еш кына үзеннән сүз өсти һәм нәтиҗәдә төгәлсезлекләр җибәргәли.

Ф. Әмирхан кебек тел остасы, нечкә стилист, зур әдипне тәрҗемә итүдә югарыда күрсәтелгән аерым кыенлыклар булу табигыйдыр да. Гомумән алганда, Г. Хантемирова тәрҗемәләре Ф. Әмирханның язу манерасын, әсәрләренең идея-художество үзенчәлекләрен күз алдына китереп бастыра ала дип ышанып әйтә алабыз.

Ф. Әмирханның искиткеч тирән мәгънәле, татар халкының киләчәк тормышына зур ышаныч белән язган «Гарәфә кич төшемдә» дигән хикәясе бар. Ни өчендер, ул тәрҗемәчеләр игътибарыннан читтә калган. Бу хикәядә шул чор өчен төш кенә булган яңа татар интеллигенциясенең тууы сурәтләнә: «Зиннәтле татар клубы. Җыелган кешеләр арасында татар гимназияләренең талиб вә талибаты, татарлар тарафыннан ачылган һөнәр мәктәпләренең шәкертләре, төрле дәрелфөнүннәрнең студент вә студенткалары... милли театрларыбызның артист вә артисткалары... татар адвокатлары, табиплар..., мөгаллимнәр, юристкалар, мөгаллимәләр... әсәрләре Европа һәм Азиянең төрле телләренә тәрҗемә ителгән татар мөхәррир вә мөхәррирәләре бу җәмгыятьтә бар иде».

Ф. Әмирханның тууына 90 ел тулу көнендә оештырылган кичәдә Казандагы Актерлар йортының зур залы аның иҗаты алдында хөрмәт, соклану белән тагын бер кат баш иергә килгән һәм әдибебез хыялланган татар совет интеллигенциясе белән шыгрым тулы иде.

**ФЛЕРА САФИУЛЛИНА,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# КАРИЛЕ НУГАЙЛАРЫНЫҢ ФОЛЬКЛОР ҮРНӘКЛӘРЕ

Халык телендә һәм фәнни әдәбиятта «Әстерхан татарлары» дигән атама киң таралган. Ләкин бу шактый киң төшенчә конкретлаштыруны таләп итә. Әстерхан татарлары термины берничә этник группаны үз эченә ала: кариле нугайлары (русча «юртовские татары» дип йөртәләр), ягъни Әстерханның төп халкы, аборигеннары; карагашлар (1740 елдан бирле даими рәвештә Кызыл Яр, өлешчә Харабалы районнарында яшәүче нугай халкының үзенчәлекле этник төркеме); Әстерхан шәһәрендә һәм өлкәнең авылларында яшәүче Идел буе татарлары. Идел буе татарлары дигәндә, элекке Сембер, Казан, Саратов, Пенза һ. б. губерналардан күчеп утырган татарлар күзалдында тотыла. Аларның күпчелеген көнбатыш диалекты вәкилләре — мишәрләр тәшкил итә. Идел буе татарларын кариле нугайлары һәм карагашлар «үрьягы татарлары» яки «казанлылар» дип тә атыйлар.

«Кариле» сүзе, җирле халык аңлатуынча, «кара өйле» сүзеннән килеп чыккан, ягъни алар күчмә тормыш алып барганда кара киездән ясалган чатыр, тирмәләрдә көн иткәннәр.

Кариле нугайлары Әстерхан шәһәре тирәсендәге авылларда яшиләр. 1850 елда кариле нугайларының саны 9 меңнән артмаган. Нариман район Советы башкарма комитеты мәгълүматларына караганда, бу төбәктә кариле нугайларының саны, Идел буе татарларын да кертеп, унсигез мең тирәсенә җитә.

Кариле нугайлары тарихи-этнографик яктан шактый нык өйрәнелгән. Мәсәлән, И. Г. Георги, П. Небольсин, А. Далингер кебек галимнәрнең күп кенә хезмәтләре аларга багышланган.

Кариле нугайлары үзләрен Әстерхан өлкәсендә яшәүче башка этник төркемнәрдән аерып йөртәләр һәм элекке заманнардан ук Әстерхан тирәсендә яшәп килгән җирле халык — нугайлар дип саныйлар. Әстерхан ханлыгы Рус дәүләтенә кушылгач, кариле нугайлары дәүләт крестьяннары разрядына кертелгәннәр һәм мал асрау, балык тоту белән шөгыльләнгәннәр. Аларга шәһәрдә яшәү тыелган, шуңа күрә Әстерхан шәһәре тирәсенә авыл-авыл булып урнашканнар. Һәр авылның «табунная голова»сы (халык телендә «күлебе») булган. Петр I заманыннан башлап кариле нугайлары сугарулы игенчелеккә, яшелчәчелеккә күчәләр: кавын, карбыз, помидор, кыяр үстереп, Әстерхан шәһәрен һ. б. өлкәләрне тәэмин итеп торалар.

XVIII гасырның икенче яртысыннан кариле нугайлары Идел буе татарлары белән экономик мөнәсәбәтләргә керә башлыйлар, тора-бара алар арасында этник мөнәсәбәтләр дә урнаша. Бу процесс Октябрь революциясеннән соң көчәя: кариле нугай авылларына шактый күп санда Идел буе татарлары күчеп утыра. Берничә гасыр дәвамында Идел буе татарлары белән аралашып яшәү кариле нугайларының материаль һәм рухи культураларына, телләренә сизелерлек йогынты ясаган. Мәсәлән, кариле нугайларында татар көйләре шактый киң таралган. Популяр көйләрдән «Баламишкин», «Шахта», «Сарман», «Галиябану» һ. б. көйләрне санарга мөмкин. Шул ук вакытта кариле нугайлары үзләренә генә хас кайбер этнографик үзенчәлекләрне дә саклап калганнар. Соңгыларына туй йолаларын, хуҗалык алып бару ысулын һ. б. кертергә

мөмкин. Түбәндә без 1972 елда кариле нугайларына оештырылган диалектологик экспедиция вакытында язып алынган кайбер фольклор үрнәкләре белән таныштырып китмәкче булабыз.

Кариле нугайларына, казан татарларындагы кебек үк, хат язуда (бигрәк тә солдат хатларында) традицион башлам куллану хас булган. Менә шуның бер үрнәге:

**Әй, минем язган хатым, Әстерханга карай төш.**
**Ичбер җиргә туктама, мисле бер канатлы кош.**
**Ах, минем үзем булып, Кызанга [1] барып күреп.**
**Атам-анам сау микән, янә дә тәтәм [2] тыныч.**
**Сәламемне айтпага бу синең изге бурыч.**

Кариле нугайларының һәрбер авылында традицион шигырь яшәп килә. Шунысы игътибарга лаек, ул шигырьләрдә элек кариле нугайлары арасында атаклы булган җырчылар, хушаваз осталары, импровизаторлар телгә алына.

Кариле нугайларында шулай ук элек-электән туйларга, зур мәҗлесләргә җырчылар, музыкантлар чакыру гадәте булган, бу традиция хәзерге көндә дә саклана.

**Л. АРСЛАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

## Туй башлыгы, хуҗаларны мактау

Әссәләмәгаләйкем! Аманмысыз, муллатай!
Эндәвеч чакырып туй итепсез, атыраптан [3] калдырмай.
Айлак [4] күп калк килепте ау, атыраптан берәү калмай,
Җигеп килгән арбасын әүләгә [5] сыйдыралмай.
Уртага шатыр корып, утырганнар җайма-җай.
Мин дә барып карадым, астан кырын чыгалай.
Уртада бер зат торы, елтыраган алтындай.
Карасам быжаклый [6] икән, унын санын айталмай.
Яулак, йөзек уннан күп, унын санын шыгалмай.
Капкадан шыгып китте, тратайка тырылдай,
Артыннан тимер күчәр тас түбәдәй саңгырдай.
Угай [7] шәшкән акшаныз каты яуган яңгырдай.
Айлак хөрмәт иттенез, рәхмәт яусын, муллатай.
Индеген өлкүн туена шакыртарсыз калдырмай [8].

## Авыл җырлары

Җырла диеп, җуралар [9], кыстайсыз мине куймай,
Мин тегелмен Фәхретдин, я дә Шәйдә Ибрай.
Әммә дуслар хакы өчен һиммәтен җиргә куймай
Бер-ике аваз айтаем, чү калып утыр тыннай.
Ярлы Түбә, Җәмәле җайлы икән кыдырмага [10],
Сәмик авыл, Колакау мисле утырган батага [11].

---

[1] Кызан — Тат. Башмаковка авылы.
[2] Тәтәм — апам.
[3] Атыраптан — тирә-яктан.
[4] Айлак — бик.
[5] Әүләгә — ишегалдына.
[6] Быжаклый — балкый, ялтырый.
[7] Угай — ана.
[8] Нариман районы, Кызан авылында Калмөхәмәт Әхмәт улы Исаевтан 1972 елның маенда язып алынды. 1905 елда туган.— Авт.
[9] Җуралар — дуслар.
[10] Кыдырмага — ял итәргә, күңел ачарга.
[11] Батага — ватага.

Кызан, Каргалык, Майлыгүл җыелып килер калага,
Киләчеләр кире калк керешмәсен арага.
Каңга дигән каңгыс калк кангырып китсен далага,
Барын айтып килгәндә: ачпалы күпер, агым су,
Җан Тияктән садага [4].

## Көлке такмак

Бер ишке [5] бар иде ау,
Мен булсын дип идем ау.
Кара түбә бавырында [6]
Ут утлап иде ау.
Кара түбә бавырында
Суеп ятыр ишкемде.
Төбе тишек казанда
Пешереп ятыр ишкемде.
Катык-кытык табакка
Төшереп ятыр ишкемде.
Багаларына [7] мактай,
Кызларына сулактай,
Мин карепкә [8] тырнактай,
Күзем яше борчактай.
Баласына ат менгезде,
Киләнсен дә йөрсен дип,
Мин карепкә тай менгезде,
Дуласын да ексын дип.

## Чит авылдан өйләнгән егет сүзләре

Казыкладым казык бау,
Ат атландым черкес тау.
Черкес таудан бер кыз алдым,
Унын да аты Җәмилә ау.
Җәмилә биргән биш тия [9],
Бишәве дә яшь тия,
Аягыннан ут чыга
Кинәттән тисә ташка.
Ябынганым, ястанганым
Төлке тунның якасы,
Ашаганым-эчкәнем
Каз-ирәктен [10] баласы.
Сөйгәнем дә бер кызның солтаны [11].

---

[4] Нариман районы, Җәмәле сигезьеллык мәктәбе укытучысы Басыйр Дәүләтгәрәй улы Ишбердиевтән язып алынды.

[5] Ишке — кәҗә.

[6] Бавырында — буенда, итәгендә.

[7] Багаларына — балаларына.

[8] Карепкә — мескенгә.

[9] Тия — дөя.

[10] Ирәктен — үрдәкнең.

[11] Нариман районы, Курченко авылында пенсионер Исмәгыйль абый Хәйруллинның җыр дәфтәреннән күчереп алынды.— Авт.

## Гәрәй Рәхим

# ТЕЛӘКНАМӘЛӘР

Халык арасында теләкнамә әйтү гадәте яши. Теләкнамә әйтүнең билгеле бер ныклы калыбы бар, аның югары патетик дәрәҗәдәге ритмы, стиле, экспрессивлыгы бу жанрны форма ягыннан бик тотрыклы итә. Ләкин теләкнамәләр эчтәлек ягыннан тотрыклы һәм массовый түгел. Теләкнамә әйтүче һәр кеше, бу жанрның формасын саклаган хәлдә, аңа үз фикерен, үз эчтәлеген, үз образын сала. Чөнки теләкнамәләр күбесенчә гадәти булмаган конкрет хәлләр, язмышлар, күренешләргә багышлана. Шул ук вакытта теләкнамәләр шушы тирәлеккә киң билгеле булган кешеләргә, илгә киң билгеле булган күренешләргә, тормыш-көнкүрешкә тирән эз салып киткән вакыйгаларга төбәп әйтелә.

Теләкнамәләр бик борынгыдан, мәҗүсилек чорыннан ук калган жанр булырга тиеш. Чөнки, беренчедән, алар арасында гадәти булмаган күренешләрнең табигатькә бәйләнешлелары күп очрый (Ай, Кояш тотылу, койрыклы йолдызларның Җиргә якын килүе, бу төбәкләргә хас булмаган гаять корылык, су басу, давыл, янгын, гомуми үлем-җитем); икенчедән, теләкнамәләрдә гарәп-фарсы сүзләре юк диярлек. Ә бу күренеш аның татар халкына ислам дине кергәнче үк яшәгәнен күрсәтә. Соңгырак чорларда теләкнамәләрнең ил язмышы, иҗтимагый вакыйгалар белән дә бәйләп әйтелә башлавы, аның мәҗүсилек эчтәлегеннән иҗтимагый-дөньяви эчтәлеккә табан үсешен күрсәтә булса кирәк.

Теләкнамәдә, кагыйдә буларак, трагизм өстенлек итә, дидем. Шуңа күрә булса кирәк, Бөек Ватан сугышы елларында безнең авылда (Лениногорск районы, Аланлык авылы) теләкнамәләр шактый активлашып китте.

Түбәндә тәкъдим ителә торган әсәрләрдә теләкнамә жанрының даими калыпларыннан читкә киткәләүләр бар. Чөнки мин монда халыкта яши торган төп-төгәл теләкнамә формасын күрсәтүне төп максат итеп куймадым, ә шул жанр нигезендә яңа әдәби әсәрләр тудыруны күздә тоттым.

**АВТОР**

### СУГЫШ КЫРЫНДА ЯТЫП КАЛГАН ӘТИЛӘР ТЕЛӘГЕ

И углым!

Илләр күреп кайт, җирләр күреп кайт, ирләр күреп кайт, дөньяда ни булса, барын да күреп кайт — ләкин мин күргәннәрне күрмә!

Баллар таты, ширбәтләр таты, майлар таты, җимешләр таты, иреннәр таты, дөньяда ни тәм бар, барын да таты — ләкин мин татыганнарны татыма!

Сандугачлар сайравын ишет, үзәк өзгеч симфонияләр ишет, гомердә ишетмәгән халык җырларын ишет, дөньяда ни моң бар, барын да ишет — ләкин мин ишеткәннәрне ишетмә!

Мин күргәннәр, мин татыганнар, мин ишеткәннәр барысы да кешелек өчен мыскыл, түбәнлек, адәм хуры. Мин күргәннәрне, мин татыганнарны, мин ишеткәннәрне сөйләсәң сүз җитмәс, язсаң кәгазь җитмәс, еласаң күз яше җитмәс.

И улым!

Тау-ташларны актарып алтыннар эзлә, нефть эзлә, металлар эзлә, күмер эзлә; тирән су төпләренә төшеп мәрҗәннәр эзлә, алтын балыклар эзлә, файдалы үсемнәр эзлә; иксез-чиксез галәмнәргә менеп, яңа дөньялар эзлә, яңа планеталар эзлә, яңа айлар эзлә, яңа кояшлар эзлә — дөньяда ни кызык бар, ни сер бар, барын да эзлә, ләкин, беренче чиратта, безнең каберләрне эзлә!

## ТОРМЫШКА ЯЛВАРУ

Тормыш — яшәеш!

Җирсезләргә җир бир, илсезләргә ил бир, дансызларга дан бир, шансызларга шан бир, сансызларга сан бир!

Телсезләргә тел бир, котсызларга кот бир, башсызларга баш бир, мәнсезләргә мән бир!

Мәзәксезләргә мәзәк бир, фатирсызларга фатир бир, имансызларга иман бир, холыксызларга холык бир!

Тормыш — яшәеш!

Адәм баласына изгелек теләүчеләргә алар теләгәннең барысын да бир! Ләкин мылтыклыларга дары бирмә, әләкчеләргә тел бирмә, сатлыкларга ил бирмә!

## ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

Хәерле көн, күтәрелеп килүче кояш!

Син шундый яшь, әйтерсең әле генә коендырып биләүгә төрелгән сабый; син шундый матур, әйтерсең балигъ булып килүче егет!

Сиңа әле бик озак, төш җиткәнчегә кадәр күтәреләсе дә күтәреләсе!

Син әле җирдәге бөтен нәрсәләргә — чәчәкләргә, бөҗәкләргә, өйләргә, кешеләргә дөньяга көнне тудырган иртәнге караш белән карыйсың. Көнбагыш чәчәкләре, сокланудан башларын борып, сиңа ияреп баралар.

Төш уртасы җиткән мәлдә син үзеңне күк йөзенең иң биек тәхетендә итеп сизәрсең һәм җирдәге бөтен нәрсәләрнең күзләренә туры карарсың. Бу ноктада син шул кадәр куәтле булырсың ки, җирдәге күләгәләр синнән куркудан соң чиккәчә кысылып-кыскарып калыр!

Ләкин нәкъ менә шул мизгелдә инде син үзеңдә моннан да биеккәрәк, моннан да югарырак менәргә көч юк икәнен тоярсың һәм кинәт сүлпәнләнеп китәрсең; ул гына да түгел, син инде бу тәхеттә утыра алмас дәрәҗәдә көчсезләнеп, акрын гына түбән таба шуыша башларсың. Әле кайсы якка диген — җир өстеннән якты көнне алып китүче көнбагыш ягына...

Менә шунда инде син җирдәге бөтен нәрсәләргә: чәчәкләргә, бөҗәкләргә, өйләргә, кешеләргә бөтенләй икенче төрле, үлеп баручы кичке караш белән; бөтенләй икенче, кап-кара төн туачак яктан карарсың. Дөрес, көнбагыш чәчәкләре әле син күк йөзеннән бөтенләй тәгәрәп төшкәнгә кадәр, башларын борып, синең арттан ияреп барырлар, ләкин ин-

де алар син офыкка кереп югалуга, кинәт сиңа сыртларын биреп, яңа таң туачак көнчыгыш якка борылырлар.
Ләкин әле моңа кадәр бик ерак, әлегә син — күтәрелеп килүче кояш! Сиңа әле бик озак, төш җиткәнчегә кадәр күтәреләсе дә күтәреләсе!
Хәерле юл, күтәрелеп килүче кояш!

## БЕР СҮЗ

Дусларыннан, үз-үзеннән тәмам туеп, дөнья белән бәхилләшеп йөргән бер мизгелдә кешене коткару өчен бер сүз җитә... Карарын тормышка ашыру өчен дә...
Озакка сузылган кайгылардан пыскып сүнә башлаган йөрәккә шатлык учаклары кабызып җибәрү өчен бер сүз җитә... Аны тәмам сүндерү өчен дә...
Зарыктырып килгән шатлыктан юмартланып дөньяга гел елмаю гына өләшеп йөргән кешегә үч пычагы тоттыру өчен дә бер сүз җитә... Елмаюларын мең кат арттыру өчен дә...
Ярый әле, тарих хезмәт шатлыкларыбызны кичергәндә безне эгоист ясый торган бер сүз дә тудырмаган.

## АЛДАУНЫ ЯКЛАУ

Әгәр тормыш кешеләрне алдарга өйрәтмәгән булса, кешеләр бер-берсен бу кадәр ярата алырлар иде микән?!
Якын дустын тиздән яман чир алып китәчәген белсә дә: «Терелерсең», — дип алдый белгән кешеләрне ничек ачуланасың?!
Үзен генә ярата белгән ата аркасында мәңгегә ятим калган сабыйны: «Тиздән әтиең кайтыр», — дип ышандыручыларга ничек үпкәлисең?!
Кипкән куллары белән бер-берсенең җилкәләренә суга-суга: «Син һаман картаймагансың әле», — дип сөйләнә белүче чал сакаллы бабайлардан ничек көләсең?!
Җирдә шул кадәр дөреслек эзләп тә, бер-берегезгә җылы сүз кирәк булганда шул дөреслекне дә корбан итә белүегез өчен яратам сезне, кешеләр!

**Шәүкәт Галиев**

# ХӘЛИМ, СӘЛИМ, МӘСӘЛИМ

## Өйрәнеп тә җиттеләр...

Велосипед өр-яңа,
Велосипед чем-кара,
Шуңа шатланып бара,
Өчәү атланып бара:
Рулен тоткан Хәлиме,
Әйләндерә Сәлиме.
Ә нишли Мәсәлиме?
Күзләрен елтырата,
Кыңгырау шылтырата!
Өчесе дә елмая,
Ай-һай, йөриләр чая!
Болар бер дә әйләнә,
Унберне дә әйләнә,
Уңыштан баш әйләнә:
— Руль тотмыйбыз, карагыз!
— Барабызмы, барабыз!
— Ха-ха-ха!
Өйрәнеп тә җиттеләр,
Әйләнеп тә төштеләр...
— Ах... ах... ах...
Өчәве өч тарафта
Тузанда аунап ята:
Күзен тоткан Хәлиме,
Тезен ерткан Сәлиме.
Ә нишли Мәсәлиме?
Тора да өйгә таба
Аксаклап җәяү чаба...

## Бар да тигез икәннәр

Ай-һай, кояш пешерә,
Суга куып төшерә!
Өч туган да йөгергән.
Елгага чабып кергән.
Өчәү рәттән тезелгән:
Хәлимнең су — тезеннән,
Сәлимнең су — биленнән,
Мәсәлимнең — муеннан...

Менә йөзеп киткәннәр,
Бар да тигез икәннәр —
Колакка — колак бара,
Колачлап кына бара!

Килеп кара син әле,
Белеп кара син әле.
Кайсы — Хәлим, кайсы — Сәлим,
Кайсы Мәсәлим әле?

## Һәркем әйтә дөресен

Таң белән уяндылар,
Кармакларын алдылар,
Балыкка кузгалдылар.
— Кояш чыкты! — ди Хәлим.
— Чыгып килә! — ди Сәлим.
— Күренми... — ди Мәсәлим.
Һәркем әйтә дөресен,
Күрәлгән кадәресен.

Тиздән берни күрмиләр,
Калкавычны күзлиләр.
Бата-калка калкавыч,
Калкавыч ул алдавыч,
Ашауны оныттырды,
Вакытны оныттырды.
Һаман балык тоттырды...

Мәсәлим бер караса —
Кояш баеган ласа!
— Баеп бара, — ди Сәлим.
— Баемаган, — ди Хәлим.
Һәркем әйтә дөресен,
Күренгән кадәресен.

Ардылар да талдылар,
Кайттылар да аудылар.
«Берүземә, ди мәче,
Бар балыкны салдылар!»
Һәркем әйтә дөресен,
Чын булган кадәресен!..

## «Ул безнең гадәт түгел!»

Өйдә иде Сәлиме,
Үксеп керде Хәлиме.
— Абый, сиңа кем тиде? —
Ишетте дә: «Эх!» — диде.
Гарьлегеннән сызланып,
Йөгерде җиң сызганып.

Күп тә вакыт үтмәде,
Тимгәләнеп битләре,
Колаклары кызарып,
Кайтты Сәлим тырналып:

— Ул бүтән тимәс, — диде, —
Якын да килмәс, — диде.

Хәлим шыңшып бетергән.
Ник әйткәнгә үкенгән.
Сәлимгә акыл биргән:
— Кыйнашу әйбәт түгел,
Ул безнең гадәт түгел...

Ә Сәлим болай дигән:
— Кыйнату әйбәт түгел,
Ул безнең гадәт түгел!

## Оят качкан...

Тәмле ис бөркелеп тора,
Авыз суы килеп тора —
Өстәлнең тап уртасында
Майлы бәлеш көлеп тора.

Майлы бәлеш көлеп тора:
Хәлим, Сәлим, Мәсәлимне
Сыныйм, дигән кебек тора...

Утырдылар ашык-пошык,
Уйнап тора өч зур кашык,
Чәйнәлгәнме, чәйнәлмәгән —
Ул чаклысы шәйләнмәгән...
Менә сүзгә килешәләр,
Өчәү бәлеш бүлешәләр:

— Бусы миңа! — ди Мәсәлим.
— Миңа! Миңа! — дия Сәлим.
— Юк, юк, миңа! — дия Хәлим.

Кыланулар хәттин ашкан,
Моны күреп Оят качкан...
Инде туйгач тамаклары,
Бушап калгач табаклары,
Әкренләп дуслашалар,
Берсен-берсе кысташалар:

— Синеке бу! — дия Хәлим.
— Сиңа! Сиңа! — дия Сәлим.
— Юк, юк, сиңа! — ди Мәсәлим.

Өчесе дә бик кызара,
Бик уңайсыз бит үзара:
«Бәлешне дә ямьсезләдек,
Үзебез дә тәмсезләндек...»

Үкенешеп болар яткан.
Шунда гына Оят кайткан.

## Җәүдәт Дәрзаманов

### Тылсымлы чүкеч

Үстең инде улым, дип,
Эш өйрәнсен кулың, дип,
Әти чүкеч тоттырды,
Бер кадакка суктырды.

Суктым ике, суктым өч,
Дүртенчегә бетте көч.
Көч беткәнен сизептер,
Бармакка төште чүкеч.

Әти сукса, нык суга,
Кадактан да ут чыга.
Каян килә мондый көч,
Тылсымлы мәллә чүкеч?

### Алмаз

Бер итеге уңга карый,
Берсе карый сул якка.
Уңын сулга бутап кигәч,
Кыендыр ул аякка.

Бияләй — ишле-сыңарлы,
Бүрек каплаган күзен.
Әллә малай, әллә кыз ул,
Танып та булмый үзен.

Танымаса танымаслар,
Алмаз сөенә генә:
Инде бүген икенче көн
Үзе киенә менә.

------------

# МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

Мәсәл — әдәбиятта лирик-эпик жанр яки дидактик поэзия жанры әсәрләренең бер төре. Аңарда аполог (үгет-нәсихәтле кыска хикәя) һәм кайчакта төгәл сюжеты булмаган кинаяле хикәятнең (притча) сыйфатлары берләшә. Ул нинди дә булса бер затны яки вакыйганы рәхимсез көлеп фаш итү максаты белән языла. Бу исә күпләрнең эчен пошырган, күпләрнең теңкәсенә тигән яманлыклардан арыну өчен, гаделсезлекләрне хурлык тамгасы белән тамгалау өчен кирәк. Шуңа күрә дә мәсәл моннан меңләп еллар элек үк инде сәнгатьтә дәһшәтле һәм рәхимсез көрәш коралы итеп кулланыла. Мәсәлнең биографиясе бөтен дөньяга билгеле Эзоп иҗаты белән генә дә башланмый — борынгы грек илендә мәсәлләрне Эзопка чаклы, мәсәлән, Гезиод, Архилох һәм Симонид язган. Ә алар бит безнең замангача эраның беренче гасырларында яшәгәннәр... Шул ук елларда иҗат иткән Рим мәсәлчесе Федр исемен һәм һиндлыларның «Панчатантра» исемле атаклы китабын да искә алырга кирәк! Аннары Европада Лафонтен, Лессинг, Россиядә Кантемир, Ломоносов, Тредиаковский, Хемницер, Фонвизин, Сумароков, Крыловлар мәйданга килә. Татар әдәбиятында исә мәсәл жанрын Габдулла Тукай һәм Мәҗит Гафури кебек осталар үстерә.

Мәсәлне, гәрчә аның иң борынгылары безнең бүгенге көннәргә (Эзоп, «Панчатантра» һ. б.) күпләр хәтерендә сакланган вариантларның прозаик язмасы төсендә җиткерелгән булса да, барыннан да элек, шигырь белән язылган кыска хикәя дип санарга кирәк. Аның персонажлары итеп гадәттә җанварлар яки бөҗәкләр, үләннәр, хәтта теләсә нинди җансыз әйберләр дә алына. Шулар катнашкан вакыйганы автор үзе хикәяли, я аның турында персонажлардан читләтеп сөйләтә. Факт, сюжет, аллегория — мәсәлне бары тик шулар мәсәл итә. Әмма аның тагын бер нәрсәсе — мәсәлне я башлап китә, я азакка нокта куя торган йомгак сүзе булырга тиеш. Читләтеп сөйләнелгәнне гомумиләштерә торган нәтиҗә ясау, кинаянең мәгънәсен ачып бирү, укучыга «таныш» булып каласы образның чын йөзен күрсәтү бары тик шуның белән эшләнә.

Дөрес, соңгы вакытларда төрле әдәбиятларда фельетонга тартым итебрәк, кайчакта исә тасвиры бик кыска әйтелгән һәм «нәтиҗәсе» дә берничә авыз сүздән генә торган мәсәлләр дә языла башлады (сигез, дүрт, хәтта ике юлы парчалар). Ә Демьян Бедный, Владимир Маяковский, Сергей Михалков кебек шагыйрьләрнең кайбер мәсәлләрендә «мораль» дигән төшенчә дә («сабак» яки «артсабак» сүзе!) лозунг характерындагы агитацион өндәү төсендә бернинди читләтүсез, турыдан-туры әйтелә. Бу, әлбәттә, жанрның заманча үзгәрешенә кайтып кала.

Мәсәлнең образлы стиле белән җанлы сөйләм булып яңгырарга тиешле теле исә һәр чакта да гади булган. Авторлар аны үз монологлары һәм персонажлар диалоглары ярдәмендә тормышчан һәм халыкчан итәләр, шигырь юллары үлчәмен вакыйгага бәйле рәвештә үзгәртә белеп баеталар.

Журналның сатира һәм юмор почмагында әледән-әле мәсәлчеләр мәҗлесе үткәреп, без укучыларны дөнья әдәбияты һәм илебез халыклары әдәбиятларының төрле елларда иҗат ителгән иң яхшы мәсәлләре белән таныштырырга уйлыйбыз. Мәсәлләр безне бүтәннәрнең аларда фаш ителгән кимчелекләреннән генә көлдермәс, ә

үзебез турында да уйланырга, үз сыйфатларыбызны да читтән карап бәяләргә өйрәтер. Елмая һәм көлә белү, тормыш чүп-чарларын шаян ут чаткылары белән көйдерү — һәркемгә хас булырга тиешле тәрбия чарасы бит ул.

ЗӘКИ НУРИ.

# Эзоп

Борынгы грек мәсәлчесе. Безнең эрагача алтынчы гасырларда яшәгән. Мәсәл жанрын «уйлап табучы» һәм аны канунлаштыручы дип санала. Шунлыктан 4—3 гасыр (антик чор һәм византия чоры) мәсәлләренең (алар биш йөзләп чамасы) дә Эзопныкы дип бастырылганы билгеле. Күпчелек әсәрләренең сюжеты кемдер теге яки бу яман хәлне үзгәртергә тели, ләкин шуны булдыра алмый дигән эчтәлеккә корылган була. Бөтенесе диярлек җәнлекләр яки җанварлар булган персонажларын шартлы итеп күрсәтә. Вакыйгаларны халык сөйләменә бик якын булган тел белән гади итеп һәм читләтү алымы белән сурәтли. Шуңа күрә хәзер дә күчерелмә мәгънәле шундый сөйләмне әдәбиятта «Эзоп теле» дип атыйлар. Цензура басымы көчле булган заманда бик күп әдипләр, «алдау чарасы» буларак, нәкъ шул яшерен язу алымы белән (чәнечкеле ирония сүзләрен мактау яки олылау формасында әйтү, перифразлар, псевдонимнар, ачыктан-ачык аллюзияләр, метафоралар, эвмеизмнар, «эчке ягын тышка әйләндереп» язылган сүзләр куллану һ. б.) эш итәләр. Рус шагыйре П. А. Вяземский моны «әсәр эчтәлегенә акыл цензура күзенә күренмичә үтеп керә ала» — дигән төшенчә буларак аңлата.

## Койрыксыз төлке

Капкынга эләгеп койрыксыз калган бер төлке уйлый-уйлый да «бу оят белән ничек яшәмәк кирәк» дигән фикергә килә. Аннары, үзенең шәхси гариплеген бүтәннәр бәхетсезлеге белән бутап яшерер өчен, төлкеләрнең барчасы да аңа охшаш булырга тиешлеген кайгыртырга керешә. Менә җыя ул барча төлкеләрне һәм аларны «сез бөтенегез койрыкларыгызны кистерергә тиешсез!» дигән фикергә күндерә башлый: имештер, аныңча, бердән, койрыкның бернинди матурлыгы юк, икенчедән, өстерәп йөрер өчен ул артык йөк кенә. Әмма шунда төлкеләрнең берсе аңа үзенең өзеп әйтелгән җавабын бирә: «Эх, син! Әгәр дә ки үз файдаңа булмаса, син безгә һичкайчан да мондый киңәш бирмәс идең!..»

Бу мәсәл бары тик үзе турында гына уйлап, үз якыннарына тегенди яки мондый ялган киңәш биргән затларга кагыла.

## Әтәч һәм урман тавыгы

Берәүнең берничә әтәче була. Көннәрнең берендә базарга баргач, ул кулга иялләштерелгән урман тавыгы күрә дә, үз әтәчләре белән бергә яшәтер өчен, шуны сатып ала. Ә әтәчләр аны типкәли, йолыккалый һәм үз ояларыннан куа башлыйлар. Урман тавыгы исә: «Үз нәселләреннән булмаган өчен мине шулай сөйкемсез күрәләр» дип ачынып уйлый. Әмма, бераз вакыт үткәч, күрә: әтәчләр берсен-берсе канга батырышып талашалар икән. Урман тавыгы әйтә шунда: «Юк,

әтәчләрнең мине рәнҗетүеннән һичкайчан да һәм һич тә зарланмам мин, чөнки аларның үз-үзләрен дә кызганмавын күрәм».

Мәсәл менә нәрсә турында сөйли: үзләренә иң якын кешеләрне дә кызгана белмәгәннәрнең ачулы кыланышын кичерү акыллы кешеләр өчен күп тапкыр җиңелрәк.

## Күзсез кеше

Бер сукыр, кулына нинди кош яки җәнлек тоттырсалар да, шуны бары тик капшап, кулындагы җан иясенең нәрсә икәнен төп-төгәл әйтеп бирә белгән икән. Бер вакыт моның алдына бүре баласы китереп куялар. Ул шуны, гадәтенчә, капшап карый да үзалдына уйланып әйтә: «Белмим, бүре баласымы бу, төлкенекеме, әллә шуларга охшаш бүтән берәр җәнлекнекемедер,— ди.— Әмма миңа бик билгеле бер нәрсә бар: моны сарык көтүенә якын да җибәрә күрмәгез».

Явыз яки әшәке кешеләрнең сыйфаты нинди икәнен, нәкъ менә шуныңча, кыяфәтен күрүгә үк яки хәтта аны капшап карап та белеп була.

## Сабанчы һәм бүре

Сабанчы инде эшләп арыган үгезләрен туара да су эчертергә алып китә. Үзенә ризык эзләп аптыраган бер ач бүре исә шул чакны аның буразнада калдырылган сабаны янына килеп чыга да үгезләренең камытларын ялый башлый. Алай гына да түгел, үзе дә шуны сизмәстән, бер камытка хәтта башын ук тыга, ләкин, башын шуннан һич чыгара алмыйча, сабанны кыр буйлап өстерәп китә. Үгезләрен эчерткән һәм ашаткан сабанчы басуга әйләнеп кайтуга шуны күреп ала да бүрегә каты тавыш белән үз күңелендәгене белдерә: «Явызның да явызы булган җан иясе бит син! Кешеләр эшләп тапканны талап, мал ботарлап йөрүләреңне ташлап, син дә менә шулай чын-чынлап сабанчылык эшенә керешсәң икән!»

Әйе шул, явыз затларның холкына, хәтта алар яхшы булып күренергә тырышсалар да, һичбер кайчан да ышанырга ярамый.

**Азат Вергазов**

# СИН ДӘ РӘИС, МИН ДӘ РӘИС...



Пенсиягә чыгуга Мотыйг абзыйны урам комитеты рәисе итеп сайлап куйдылар. Әй, тырышты Мотыйг абзый, әй, тырышты... Ул көн дә чисталык хакында әңгәмә үткәрү дисеңме, ул диспутлар оештыру дисеңме... Ул гына да түгел, Мотыйг абзый әллә кайдан лупа (зурайтып күрсәтә торган пыяла) эзләп тапты. Кичләрен урам халкын үз өенә җыя да, гади күзгә бөтенләй диярлек күренми торган вак кына җан ияләрен баш чаклы итеп күрсәтә. Котың чыгар менә. Җитмәсә, Мотыйг абзый үтә җитди итеп өстәп куя:

— Менә, җәмәгать, урамдагы чүп-чарда үрчи бу пуразитлар. Шуңа күрә дә...

Һәм ул, эштән арып кайткан кешеләр утыргычларында йоклап китеп бөрәм-бөрәм идәнгә егылып төшә башлаганчы, шул «пуразитлар»ның зарары турында сөйли. Тик, ни сәбәптәндер, урамда чүп-чар кимеми генә түгел, киресенчә, көннән-көн арта бара.

Аптырагач, Мотыйг абзый киңәшкә дип инде дистә еллар күрше урамда комитет рәисе булып торучы Хикмәтулла карт янына китте.

— Хикмәтулла абзый, дип әйтимме, син миннән алты-җиде яшькә олырак бугай... Менә әйт әле, Хикмәтулла абзый, билгеле булганча, син дә рәис, мин дә рәис, ничек сезнең урам чиста да, безнеке чиста түгел? Нинди чара күрәсез дип соравым.

Хикмәтулла абзый көрәктәй учы белән кыш бабайныкы төсле сакалын төзәткәләп алды да сабыр гына:

— Без... шул инде... себерәбез, — дип куйды.

# ӘЙБӘТ БУЛА

Бер җыелышта механик Габделхәй үрә басты да гайрәт орды:

— Җәмәгать, карап-карап йөрим дә, тагы бер карап куям. Безнең персидательне әйтәм, җитди генә кеше үзе, ә яка артына җибәрә бит, малай. Нишләтеп карасы, ә?

Председатель абзый җыелыштан соң Габделхәйнең кулын кысты:

— Рәхмәт, кем, Габделхәй, артта-чатта пыштырдап йөрмисең, күзгә терәп әйттең. Ә туры әйтү әйбәт ул.

...Ел ахыры җитте. Колхоз председателе идарә членнарын җыеп, бүләкләнергә тиеш кешеләрне билгеләргә керешге. Председатель колхозчыларның исемлеген укып, бүләкләнергә тиеш дип санаганнарын әйтеп бара, идарә членнары аны хуплап тора.

Габделхәйне дә читләтеп үтмәде председатель.

— Искиткеч шәп кеше ул безнең Габделхәй,— диде.— Үзе тагы туры сүзле. Аңа күптән коммунизмда яшәргә иде инде. Җыен юкбар материаль кызыксындырулардан әллә ничаклы өстен тора ул. Бүләк бирсәк, кимсетербез генә без аны.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## РЕСПУБЛИКАБЫЗДА ҺӘМ ИЛЕБЕЗДӘ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ КӨННӘРЕ

### ТАНТАНАЛЫ КИЧӘ

20 майда республикабыз башкаласы Казанда халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайның 90 еллыгына багышланган тантаналы кичә булып үтте. Ул көнне Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының тамаша залы шәһәр хезмәт ияләре вәкилләре, әдәбият һәм сәнгать, культура һәм фән эшлеклеләре, партия һәм җәмәгать оешмалары работниклары, укучы яшьләр белән тулды. Президиумга илебезнең башкаласы Мәскәүдән, Ленинград шәһәреннән, Белоруссия, Казагыстан, Үзбәкстан союздаш республикаларыннан, Башкортстан, Дагстан, Каракалпак, Мари, Мордва, Чуваш автономияле республикаларыннан Г. Тукай юбилеена килгән әдипләр, бүгенге татар әдәбиятының аксакаллары, шулай ук КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. А. Табеев, ТАССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов, КПСС өлкә комитетының икенче секретаре Ф. И. Панин, КПСС өлкә комитеты секретарьлары М. Т. Троицкий һәм М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов һ. б. лар күтәрелә.

Тантаналы җыелышны кереш сүз белән КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев ачты. ТАССР Министрлар Советы



**М. Луконин трибунада.**

Председателе урынбасары, Г. Тукай юбилеен үткәрү буенча республика комиссиясе председателе М. Х. Хәсәнов шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында доклад сөйләде. Аннары илебезнең төрле почмакларыннан Тукай тантанасына килгән кунаклар сүз алдылар. СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Г. Тукайның 90 еллыгын үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе, күренекле әдип Михаил Луконин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, башкорт халык шагыйре Мостай Кәрим, казакъ язучысы Амантай Сатаев, Үзбәкстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Нормурат Нарзуллаев, Мари АССР Язучылар союзы идарәсе председателе Василий Столяров, Каракалпак АССР Язучылар союзы идарәсе председателе, каракалпак халык язучысы Ибраһим Юсупов, чуваш язучысы Анатри Давыдов, күренекле тәрҗемәче Семен Липкин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе члены Михаил Годенко бөек татар шагыйре Габдулла Тукай мирасының интернациональ әһәмияте, үзләренең туган җирләрендә Тукайга булган ихтирам һәм мәхәббәт, шагыйрь иҗатының төрле халыклар өчен уртак хәзинә булып әверелүе хакында сөйләделәр. Утырыштан соң Татарстан сәнгать осталары зур концерт бирде.

### ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

18 май көнне СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы конференц-залына илнең төрле шәһәрләреннән килгән әдип һәм фән эшлеклеләре, Казан галимнәре җыелды. Монда татар халык шагыйре Габдулла Тукайның 90 еллыгы уңае белән аның тормышын һәм иҗат мирасын өйрәнүгә багышланган фәнни конференция эшли башлады. Конференцияне кереш сүз белән ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары, филология фәннәре докторы, профессор М. Х. Хәсәнов ачты. Беренче утырышта татар совет поэзиясендә Г. Тукай традицияләре дигән темага шагыйрь Сибгат Хәким, Г. Тукай иҗатын өйрәнүнең хәзерге торышы һәм бурычлары турында филология фәннәре докторы Гали Халит, шагыйребезнең халыклар дуслыгы өчен көрәше хакында тарих фәннәре докторы, профессор М. К. Мөхәррәмов, Тукайның сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге темасына филология фәннәре докторы, профессор Н. Г. Нигъмәтуллина, Тукай һәм татар милли әдәби теле дигән темага филология фәннәре докторы, профессор М. З. Зәкиев докладлар белән чыктылар. Урта Азия халыкларының прогрессив әдәбиятларын үстерүдә Г. Тукайның роле турында Таҗикстан ССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты профессор И. С. Брагинский (Мәскәү) әзерләгән доклад тыңланды.

Көннең икенче яртысында Г. Тукай иҗатында рус һәм Көнбатыш Европа әдәбият-

лары традицияләре, Г. Тукай һәм үзбәк әдәбияты, башкорт поэзиясендә Тукай традицияләре, Г. Тукай һәм кумык әдәбияты, Тукай һәм каракалпак совет поэзиясе, Г. Тукай мари телендә дигән темаларга филология фәннәре кандидатлары Э. Г. Нигъмәтуллин, Ш. Турдыев (Ташкент), С. Г. Сафуанов (Уфа), С. Х. Акбиев (Дагстан), К. Ходайбергенов (Нукус), К. К. Васин (Йошкар-Ола) иптәшләр үз докладларын сөйләделәр.

19 майда фәнни конференция үз эшен дәвам иттерде. Тукай һәм татар совет музыкасы, Г. Тукай Уральскида, шагыйрьнең әдәби-эстетик карашлары формалашуы, 1905—1907 ел революциясеннән соң Г. Тукайның иҗтимагый-политик карашларының үсеше, Г. Тукай һәм татар телендә сатирик журналлар, Тукайның тел концепциясе мәсьәләләре буенча сәнгать фәннәре кандидаты М. Н. Нигъмәтҗанов, тарих фәннәре докторы, профессор Р. И. Нәфиков, филология фәннәре докторы, профессор И. З. Нуруллин, философия фәннәре кандидаты Я. А. Абдуллин һәм фәнни хезмәткәр Р. М. Әмирханов, филология фәннәре кандидаты У. И. Гыймадиев (Уфа), филология фәннәре докторы, профессор В. Х. Хаков докладлары тыңланды. Филология фәннәре кандидаты А. Алексеев (Чабаксар) Тукай һәм чуваш әдәбияты темасына белдерү ясады.

Конференциядә катнашучылар Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Ленинградта яшәүче рәссам Фәйзерахман Әминовның «Минем иҗатымда — Тукай» дигән темага чыгышын тыңладылар.

Фәнни конференция эшендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев катнашты.

## «ТУКАЙГА ЯДКАРЬ»

Татарстан Дәүләт музее һәм СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институты музей бинасында «Тукайга ядкарь» дип исемләнгән фәнни утырыш үткәрделәр. Тыңлаучыларга филология фәннәре кандидатлары М. Сәгыйтов, Ш. Садретдинов, тарих фәннәре кандидаты Р. Фәхретдинов, педагогия фәннәре кандидатлары Г. Әдһәмова, Г. Әминов, С. Исмәгыйлова, фәнни хезмәткәрләр Н. Хисамов, Л. Җамалетдинов, Р. Гайнанов, яшь художник Э. Зарипов, музейның әдәби бүлеге мөдире Д. Баһаутдинова, аспирантлар Г. Гыйбадуллин, Р. Әхмәтовның Тукай телендә сурәтләү чаралары, Тукай һәм Сәгыйть Рәмиев, Тукайның тарихи карашлары, Тукай — мәктәптә, шагыйрьнең иҗатында борынгы татар әдәбияты традицияләре Тукай һәм татар халык әкиятләре, Тукай псевдонимнары, Тукай — иллюстрацияләрдә, кульязма «Әлгасрел-җәдит» журналы турында, Тукай һәм Хәмзә, Тукай һәм Акмулла дигән темаларга чыгыш һәм белдерүләре тәкъдим ителде.

Соңра Г. Тукай премиясе лауреаты, күренекле әдип һәм галим Нәкый Исәнбәт һәм филология фәннәре кандидаты пенсионерка Маһинур Фәйзуллина чыгышларга карата үз фикерләре белән уртаклаштылар. Утырыштагылар шулай ук шагыйрьнең «Ысулы кадимче» поэмасын мәшһүр актер, «Сәйяр» труппасының җитәкчесе Габдулла Кариев башкаруында тыңладылар. Г. Кариев тавышы язылган бу пластинка хәзер музейда саклана.

Утырышны филология фәннәре докторы Гали Халит алып барды.

## ЛАУРЕАТЛАРГА БҮЛӘК ТАПШЫРУ

18 майда ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары, Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре комитеты председателе М. Х. Хәсәнов драматург Д. Н. Вәлиев, шагыйрь М. С. Шабаев, Республика күчмә театрының баш режиссеры Р. Р. Тумашевка татар халык шагыйре Г. Тукай исемендәге 1976 ел премиясе лауреатларының Почет дипломнарын һәм значокларын тапшырды. КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы исеменнән М. Х. Хәсәнов бүләкләнүчеләрне кайнар котлады.

## КЫРЛАЙДАГЫ ТАНТАНА

Шагыйрьнең 90 еллык юбилее көннәре Тукай-Кырлай авылында аеруча зур тантана төсен алды. Монда Г. Тукайга багышланган өр-яңа мемориаль комплекс: шагыйрьгә яңа һәйкәл, ике катлы музей бинасы, китапханә һәм кунак өе, «Шүрәле» дип аталган истәлек паркы салынган. Зур



**Кырлай кызлары кунаклар каршылый.**

культура йорты, урта мәктәп өлгертеп җиткерелгән. Яшеллек арасыннан шагыйрь иҗат иткән геройларның республикабыз художниклары тарафыннан эшләнгән сыннары карап тора. Янда кырлайлылар кулы белән тудырылган ясалма күл ялтырап ята. Төрле шәһәр һәм төбәкләрдән, Казаннан һәм Арча районы колхоз-совхозларыннан 21 май көнне Тукай бәйрәменә килгән кунакларны, йөзләрчә хезмәт ияләрен Кырлай үзенең шундый яңа күренешләре, төс-бизәкләре белән каршы алды. КПСС-ның Арча райкомы беренче секретаре

Х. З. Зәйнуллин, район советы башкарма комитеты председателе Т. Б. Борһанов, «Тукай-Кырлай» колхозы председателе Л. Г. Вәлиуллин, авыл советы председателе М. А. Абдуллин кунакларны Тукай мемориалы белән таныштырдылар. Г. Тукай юбилеен үткәрү буенча Бөтенсоюз комиссиясе председателе шагыйрь Михаил Луконин, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, башкорт халык шагыйре Мостай Кәрим, М. Горький һәм Г. Тукай исемендәге премияләр лауреаты шагыйрь Сибгат Хәким, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, Г. Тукай премиясе лауреаты Гариф Ахунов, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов музей янындагы яңа ачылган шагыйрь һәйкәле алдына чәчәкләр куялар. Ул һәйкәлне рәссам Бакый Урманче проекты нигезендә КамАЗ төзүчеләре Альфред Парсин, Валентин Васильев, Владимир Кузьмин, Алексей Свереденков, Алексей Утробин иптәшләр эшләгән. Кунаклар яңа бинага урнашкан музей белән дә җентекләп таныштылар. Музейда Фәйзерахман Әминов, Харис Якупов, К. Е. Максимов, Н. В. Кузнецов, С. О. Лывин, Лотфулла Фәттахов һ. б. күренекле художникларның Тукайга багышланган әсәрләреннән картина галереясы оештырылган. Ф. Әминов «Кырлай» дигән әсәрен музейга бүләк итте. Аның «Тукай әкиятләре», «Су буе» кебек әсәрләре дә шагыйребезнең туган якларын җанлы итеп күз алдына бастырулары белән күпләрнең игътибарына лаек. Быел музей Г. Тукай истәлегенә бәйләнешле башка экспонатлар белән дә баетылган.

Шул ук көнне Кырлайда «Дуслык меридианнары» дигән исем белән тантаналы шигъри митинг булды. Аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов ачты. Митингта шагыйрьләр Сибгат Хәким, Михаил Луконин, белорус язучысы Артур Вольский, Уральскидан әдип Николай Корсунов, башкорт шагыйре Рафаэль Сафин, удмурт әдибе Василий Романов, Үзбәкстаннан Нормурат Нарзуллаев, казакъ язучысы Амантай Сатаев, Г. Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Шәүкәт Галиев чыгыш ясадылар.

Аннары митингка җыелган халык Тукай-Кырлай мәктәбе пионер дружинасының чыгышын карап алкышлады, республика сәнгать осталары концерт бирде. Кырлайдагы Тукай бәйрәме яз һәм хезмәт, әдәбиятлар һәм халыклар дуслыгы тантанасы буларак күп елларга истә калыр.

## «ТУКАЙ» ТЕПЛОХОДЫНДА

Бер төркем татар язучылары Казан елга портында тукталган «Тукай» теплоходы командасы белән очраштылар. Шагыйрьнең 90 еллыгына багышлап үткәрелгән митинг булды, андагы Г. Тукай бүлмәсенә яңа китаплар, әдипнең яңа рәсеме бүләк ителде. Соңыннан елгачылар алдында Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артистлары концерт бирде.

*
* *

В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсендә Г. Тукай иҗатына багышланган китап күргәзмәсе оештырылды. Анда әдипнең революциягә кадәр һәм совет чорында чыккан җыентыклары, Тукай иҗаты турындагы хезмәтләр, истәлекләр, библиографик материаллар тупланган иде. Китапханәнең өлкән библиографы Н. Нуруллина «Г. Тукай исемендәге республика премиясе лауреатлары» белән библиографик белешмә төзегән.

*
* *

Казанның язу җайланмалары заводы җәмәгатьчелеге, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры белән берлектә, Г. Тукай юбилеена багышлап кичә уздырды. Кичәгә «Тукай-Кырлай» колхозыннан кунаклар чакырылган иде. Кичәне Кырлайда Тукай мемориалын төзүгә зур өлеш керткән, әдәбиятыбызның иң якын һәм эшлекле дусларыннан берсе — завод директоры Нәҗип Якупов ачты. Г. Тукай иҗаты турында әдәбият галиме Г. Халит сөйләде. Соңыннан Татар дәүләт академия театры артистлары чыгышы булды.

## БАШКОРТСТАНДА Г. ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Башкортстан АССР Культура министрлыгы һәм республика Язучылар союзы идарәсе М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театрында Г. Тукай юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә үткәрделәр. Кичәнең «Шагыйрь турында шагыйрьләр» дип аталган беренче өлешендә Наҗар Нәҗми Тукайның тормышы һәм иҗаты хакында шигъри сүз әйтте. Башкортстанның халык шагыйрьләре Сәйфи Кудаш һәм Мостай Кәрим чыгыш ясап, Тукайга багышланган шигырьләрен укыдылар. Кичәдә Татарстан Язучылар союзы исеменнән Сибгат Хәким һәм союз идарәсе җаваплы секретаре Равил Фәйзуллин катнашты. Г. Тукай премиясе лауреаты С. Хәкимнең чыгышын уфалылар зур кызыксыну белән тыңладылар. Равил Фәйзуллин Башкортстан язучылар союзына Тукай портретын бүләк итте. Кичәдә шулай ук башкорт әдипләре Зәйнәп Биишева, Муса Гали, Рафаэль Сафин, Равил Бикбаев, Әнгам Атнабаев чыгыш ясады. Кичәнең әдәби өлешен Башкортстан язучылар союзы идарәсе председателе Әсгать Мирзаһитов алып барды.

Аннары республиканың күренекле сәнгать осталары М. Хисмәтуллин, М. Идрисов, Р. Туйсина, Ә. Ишбирдин, Х. Яруллин, И. Смаков һ. б. катнашында зур концерт булды.

Шагыйрьләребездән Сибгат Хәким һәм Равил Фәйзуллин 13 май көнне Уфаның

педагогия институтында уткэн Г. Тукай кичэсендэ дэ катнаштылар һэм чыгыш ясадылар.

*

* *

Уфаның Н. К. Крупская исемендэге Республика китапханэсендэ зур китап кургэзмэсе оештырылды. Анда бөек шагыйрьнең татар, башкорт, рус теллэрендэ чыккан китаплары җыелган. Республиканың башка китапханэлэрендэ дэ, культура сарайларында һэм клубларда лекциялэр һэм әңгәмәлэр уткэрелде.

## УРАЛЬСКИДА Г. ТУКАЙ КҮРГӘЗМӘСЕ

Шэһэрнең тарих һэм крайны өйрэнү буенча өлкэ музеенда Г. Тукайга багышланган кургэзмэ эшли башлады. Бу кургэзмэ даими булачак. Стендларга Габдулла Тукаевның Җаекта уткэргэн унике ел гомере хакында сөйли торган фоторэсемнэр, төрле документлар эленгэн. Яшь Тукайның 1905—1906 елларда революцион көрэштэ катнашуын курсэткэн экспонатлар: социалдемократлар оешмасы бастырып чыгарган листовкалар, прокламациялэр, революцион җыр текстлары игътибарны җэлеп итэ. Аларны эшчелэр арасында таратуда Габдулла да катнашкан. Монда шулай ук Тукайның беренче шигырьлэре басылган газета кучермэлэрен дэ курергэ мөмкин. Г. Тукай кургэзмэсе «Эдэби Уральск» дип исемлэнгэн туристик маршрут исемлегенэ кертелгэн.

## ТАТАРСТАН РӘССАМНАРЫ — ТУКАЙГА

Г. Тукай юбилее уңае белэн Татарстан сынлы сэнгать музеенда кургэзмэ ачылды. Анда Г. Арсланов, Б. Урманче, Л. Фэттахов, Б. Элменов, Ф. Эминов, В. Кудель-



Г. Тукайның Кырлайдагы һэйкэле.

кин, М. Мавровская, Е. Симбирин, В. Карамышев, Н. Кузнецов, С. Лывин, Г. Мусин, Х. Казаков, Р. Төхфэтуллин, Т. Хаҗиэхмэтов, Р. Госманов, И. Эхмэдиев һ. б. куп рэссамнарның даһи шагыйребез образын гэудэлэндергэн портрет жанрындагы эсэрлэре, акварельлэр, китапларга иллюстрациялэр — барлыгы ике йөзлэп эсэр куелган.

## «ТУКАЙГА ЧӘЧӘКЛӘР»

Татарстан китап нэшрияты шул исемдэ шагыйрьгэ багышланган җыентык чыгарды. Китапта чит ил һэм төрле миллэт совет язучыларының Тукай һэм аның иҗаты хакында фикерлэре, шигырьлэре, кайбер татар совет шагыйрьлэренең дэ Тукайга багышланган эсэрлэре тупланган.



**И. Юзеев, Н. Арсланов, М. Кэрим, Д. Вэлиев, Э. Еники Кырлай урманында.**

## РЕСПУБЛИКАНЫҢ НЕФТЬ РАЙОННАРЫНДА

Татарстанның нефть районнарында, шэһэр һэм поселокларда Г. Тукайның тууына 90 ел тулуга багышланган эдэби-музыкаль кичэлэр узды. Элмэт шэһэренең техника йортында уткэрелгэн тантаналы кичэне шэһэр советы председателе урынбасары А. И. Страхов ачты. Эдэбиятта бөек Тукай традициялэре турында Татарстан Язучылар союзының Элмэт булеге җитэкчесе Эдип Маликов доклад ясады. Шагыйрьлэрдэн Г. Афзал, С. Сөлэйманова, К. Булатова узлэренең яңа шигырьлэрен укыдылар. Элмэт татар дэулэт драма театры артистлары зур концерт бирде. Э. Фэйзинең «Тукай» пьесасыннан өзек курсэтелде.

*

* *

Элмэт бораулау эшлэре идарэсе коллективы Тукай кичэсенэ шагыйрэ С. Сөлэймановны чакырды. Ул бөек шагыйрьнең иҗат юлы турында сөйлэде, тыңлаучыларның куплэгэн сорауларына җавап бирде.

Тукай кичэлэрендэ Элмэттэге мэктэп-интернатта Э. Маликов, Г. Кашапов, Яңа Кэшер һэм Бикасаз мэктэплэрендэ К. Булатова чыгыш ясады.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!

1977 ел өчен газета-журналларга язылу вакыты җитте. Сез алдагы елда да «Казан утлары» журналын алдырырга телисездер һәм аның киләсе ел планнары белән кызыксынасыздыр. Халкыбызның фидакарь хезмәте, илебездә булып торган политик һәм иҗтимагый вакыйгалар язучыларыбызны яңа әсәрләр язарга рухландырып тора. Аларның күбесе редакциягә повесть һәм романнар, шигырь һәм поэмаларын китереп тә өлгерде инде. Аяз Гыйлаҗевның «Мең чакрым юл», Барлас Камаловның «Канатлы кырмыска», Рафаил Төхфәтуллинның «Китә казлар», Эдуард Касыймовның «Өй артында шомыртым», Хәсән Сарьянның «Бер ананың биш улы», Миргазыян Юнысның «Көтеп алынган давыл», Әхәт Гафаровның «Кашан каласы», Мәхмүт Хәсәновның «Инженерлар» дигән повестьлары, яшь прозаиклардан Тәүфикъ Әйдинең «Божра» һәм Әхмәт Сәйфетдиновның «Җырла, иркәм» әсәрләре редакция хезмәткәрләре тарафыннан өйрәнелә дә башлады инде.

Гариф Ахуновның «Идел кызы» романы татар интеллигенциясенең Октябрь революциясенә килүе һәм яшь совет дәүләтен саклап калудагы көрәшен сурәтли. «Казан утлары» журналының алдагы елдагы беренче санын без әнә шушы зур күләмле әсәр белән башлап җибәрәчәкбез.

Мирсәй Әмир, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники, Фатих Хөсни, Шәйхи Маннур, Әхсән Баян, Туфан Миңнуллин һ. б. повесть һәм хикәяләр китерергә вәгъдә итүен дә исәпкә алсак, киләсе елның проза бүлеге шактый бай һәм кызыклы булуы көтелә.

1977 елда поэзия сөючеләр дә журналыбыздан канәгать булырлар дип уйлыйбыз. Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Саҗидә Сөләйманова, Марс Шабаев, Роберт Әхмәтҗанов, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Мингалимов, Рәшит Гәрәй, Гәрәй Рәхим, Фәнис Яруллин, Зөлфәтләрнең туган ил иминлеге, халыклар дуслыгы, республикабыз тормышы турындагы лирик уйланулары, Салих Баттал, Әхмәт Исхак, Зәки Нури, Идрис Туктарларның юмористик әсәрләре, Шәүкәт Галиев, Хәкимҗан Халиков, Галимҗан Латыйп, Зәкия Туфайлова, Зәһирә Гомәроваларның балалар өчен язган шигырьләре һ. б. язучыларның шигъри әсәрләре журналыбызның поэзия бүлегендә урын алачак.

1977 ел да юбилейларга, әдәби бәйрәмнәргә бай ел. Бу елда илебез халкы Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгын, республикабыз хезмәт ияләре Казанның 800 еллыгын, Галимҗан Ибраһимовның тууына 90 ел тулган көнне һ. б. билгеләп үтәчәк. Шул уңай белән журналда фәнни-публицистик мәкаләләр, очерклар, архив материаллары, фоторәсемнәр биреп барылачак. Очерклар бүлеге унынчы бишьеллык батырларының әдәби портретлары, аерым проблемаларга кагылышлы хезмәтләр белән баетылачак.

Тәнкыйть бүлеге алдагы ел саннарында «Бүгенге поэзия турында сөйләшү» алып барачак. Бүгенге әдәбиятның актуаль мәсьәләләренә багышланган чыгышлар, тугандаш халыклар әдәбиятларының татар әдәбияты белән бәйләнешлары турында мәкаләләр, яңа китапларга күзәтүләр һ. б. әдәбият фәне белән кызыксынучыларга күп ярдәм итәчәк.

Хөрмәтле укучыбыз!

«Казан утлары» журналына илебезнең барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин. Элемтә бүлеге хезмәткәрләренә 73210 номерлы индексны әйтсәгез, бу язылуны тизләтер генә.

Журналга язылу бәясе бер елга 6 сум.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ